ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

5. 1992



# «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕНӘ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләрен, аның күп меңнәрчә укучыларын һәм алар йөзендә барлык әдәбият сөючеләрне журналның чыга башлавына 70 ел тулу уңаеннан кайнар котлый!

Әдәбиятыбызның якты көзгесенә әверелгән бу басманың беренче саны «Безнең юл» исеме белән гражданнар сугышы тәмамланып килгәндә, ил хуҗалыгы хәрабә хәлендә булганда, Идел буенда, Татарстанда коточкыч ачлык хөкем сөргәндә басылып чыкты.

Бөек язучы, галим һәм мәгърифәтче Галимҗан Ибраһимов фатыйхасы белән туган журнал күпне кичергән халкыбызның җан азыгы, тугры юлдашы һәм киңәшчесе булып әверелде һәм менә җитмеш ел инде татар әдәби хәрәкәтен җитәкләп-әйдәп бара.

Бердәнбер әдәби журнал буларак, «Казан утлары» халкыбызның театр, музыка, рәсем сәнгатьләрен дә колачлап, алар тирәсендә эшлекле һәм файдалы эзләнүләргә юл ачты, аларның да уңышлы үсүенә зур этәргеч булды. Татар халкының иҗтимагый-сәяси фикерен формалаштыру, фән-мәдәният тарихыбызны барлап, теркәп баруны да журнал зур фидакарьлек һәм рухи юмартлык белән үз өстенә алды һәм бу изге бурычын да уңышлы гына башкарып килә.

Билгеле булганча, Ватан сугышы вакытында күп кенә әдәби журналлар ябылды. Ә «Казан утлары», чыгуын дәвам итеп, үзенең авторлары белән бергәләп җиңү яулашты. Халкыбызның рухи ныклыгын, тугрылыгын, батырлыгын сурәтләде. Халык язмышын уртаклашып яшәгән журнал чын-чынлап күпләрнең өстәл китабына әверелде.

Шулай итеп, «Казан утлары» үзенең күп кырлы эшчәнлеге белән әдәбиятның, сәнгатьнең яшәешебездәге бәя биреп бетергесез зур ролен раслады һәм раслап килә. Үзгәртеп кору чорында, халык тормышыннан, аның рухи дөньясыннан аерылмыйча яшәп, әле эшлисе эшләрнең иге-чиге юклыгын онытмау зарур. Озак еллар буе имгәтелеп, бөтен дөньяга чәчелеп-сибелеп килгән әдәби һәм рухи мирасыбызны бергә җыю, аларны бөртекләп барлау — журналыбызның бурычыдыр. Матурдан матур яңа әдәби әсәрләрнең тууына булышлык итү, мәгърифәтебезне өр-яңадан үзгәртеп кору, яңа талантларны тәрбияләп үстерү кебек мөһим эшләр дә онытылмас, дип ышанабыз. Милләт язмышы хәл ителәчәк алдагы еллар 70 ел буена халыкның юлдашы булган «Казан утлары» журналына әнә шундый изге бурычлар йөкли.

Журналны олы бәйрәме белән котлаганда, аның хезмәткәрләренә, укучыларына зур иҗат уңышлары теләгәндә, нәкъ шул эшләнәсе эшләрне искә төшерү — заманага яңача карашыбызны билгеләр.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

5 (835)

1992

КАЗАН

## Бу санда

«КАЗАН УТЛАРЫ»НА — 70 ЕЛ

Р. ФӘЙЗУЛЛИН. «Казан утлары» — безнең юл . . . 3
Г. БӘШИРОВ. Кыйбла билгеләгәндә... . . . . 8
Ә. ЕНИКИ. Чорлар аша . . . . . . . . 17
Н. НӘҖМИ. Әдәбият илчесе . . . . . . . 20
Г. АХУНОВ. Әдәби мәккәбез яшәсен! . . . . 22
М. ХӘБИБУЛЛИН. Без тарихта эзлебез . . . . 24
Л. ИХСАНОВА. Артта калган көннәр истәлеге . . 26
Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Милли академиябез . . . 28
Безне котлыйлар . . . . . 7, 16, 21, 23, 25, 27, 28
Журналыбызны кемнәр җитәкләгән? . . . . . 122

ОЛУГ ЮБИЛЕЙГА — ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗ

Н. НӘҖМИ. Шагыйрь итмәскә. *Шигырь* . . . . 29
Г. АФЗАЛ. Алтын Урда. *Шигырь* . . . . . . 30
И. ЮЗЕЕВ. Китәрмендер, ахры, бер көнне мин. *Шигырь* . . . . . . . . . . . . . 31
М. ШАБАЕВ. И татар гынам... *Шигырь* . . . . 31
Ф. ЯРУЛЛИН. Әйтегез, әгәр белсәгез. *Шигырь* . 32
М. ӘГЪЛӘМОВ. Ижат. *Шигырь* . . . . . . 32
ЗӨЛФӘТ. Ялгыз сандугач. *Шигырь* . . . . . 34
Н. ИЗМАЙЛОВА. «Хор» дигән сүз бездә юк бугай. *Шигырь* . . . . . . . . . . . . 35
Р. НИЗАМИЕВ. Бүген! *Шигырь* . . . . . . 35
Г. МОРАТ. Җан сурәте. *Шигырь* . . . . . . 36
Л. ЗӨЛКАРНӘЙ. Бичура. *Шигырь* . . . . . 37
Р. СУЛТИ. Егерме ике. *Шигырь* . . . . . . 38

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Сират күпере. *Роман* . . . 39
Л. ЛЕРОН. Багышлаулар бәйләме . . . . . . 124

ӘДӘБИ МИРАС

Гасыр башы шигъриятеннән . . . . . . . . 127

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Я. АБДУЛЛИН. Тәнзыймат һәм Идел-Урал татарлары арасында мәгърифәтчелек хәрәкәте . . 133
С. АПАКАЙ. Сан-Францискода татар җәмгыяте . 140
А. МӘМӘТ. Кырым татарлары . . . . . . . 146
Ф. ВӘЛИЕВ. Себердә ислам . . . . . . . . 153
В. КУЛИЕВ. Мирза Кәзимбәк һәм татар мәгърифәтчеләре . . . . . . . . . . . . . 177

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
***(баш мөхәррир урынбасары)***
**Индус Таһиров**
**Марс Шабаев**
***(җаваплы сәркатип)***
**Тәүфикъ Әйди**
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

СӘНГАТЬ

Х. ГОБӘЙДУЛЛИН. «Нур»да балкыган гомер . 158
Ф. ГАЛИУЛЛИН. Татар дикторы . . . . . . . 161

КАЙТКАН ИСЕМНӘР

Р. ГЫЙЛӘҖИЕВА. Ялкынлы моң . . . . . . . 167

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

С. ХӘЙРЕТДИНОВ. Ерактагы якын матбугат . . 172

ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

М. ӘХМӘТҖАНОВ. Татар-башкорт дуслыгы . . 183

УКУЧЫ СҮЗЕ

Ә. НИЗАМЕТДИНОВ. Гел булдың исләремдә . . 186

Котлыйбыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . . 189

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

К 70-летию журнала: статьи Р. ФАЙЗУЛЛИНА, Г. БАШИРОВА, А. ЕНИКИ, Н. НАДЖМИ, Г. АХУНОВА, М. ХАБИБУЛЛИНА, Л. ИХСАНОВОЙ, Р. МУХАМАДИЕВА; поздравления, библиографическая информация «Кто возглавлял журнал?».
«Поэты к юбилею»: стихи Н. НАДЖМИ, Г. АФЗАЛ, И. ЮЗЕЕВА, М. ШАБАЕВА, Ф. ЯРУЛЛИНА, М. АГЛЯМОВА, ЗУЛЬФАТА, Р. НИЗАМИЕВА, Н. ИЗМАЙЛОВОЙ, Г. МУРАТА, Л. ЗУЛЬКАРНАЯ, Р. СУЛЬТИ.
«Проза и поэзия»: продолжение романа Р. МУХАМАДИЕВА «Мост над адом». Эпиграммы Л. ЛЕРОНА.
«Литературное наследие»: стихи татарских поэтов начала XX века.
«К истории культуры»: статьи Я. АБДУЛЛИНА «Просветительское движение среди Волжско-Уральских татар», С. АПАКАЯ «Татарское общество в Сан-Франциско», А. МАМАТА «Крымские татары», Ф. ВАЛИЕВА «Ислам в Сибири», В. КУЛИЕВА «Мирза Казимбек и татарские просветители».
«Искусство»: статья Х. ГУБАЙДУЛЛИНА посвящена творчеству С. Гизатуллиной-Волжской и статья Ф. ГАЛИУЛЛИНА о дикторе татарского радио К. Саттаровой.
«Возвращенные имена»: статья Р. ГИЛЯЗИЕВОЙ о поэте В. Заяд.
«Литературная критика»: статья С. ХАЙРУТДИНОВА «Далекая близкая пресса».
«Острый ракурс»: статья М. АХМЕТЗЯНОВА «Татаро-башкирская дружба».
На наших обложках: государственный герб Республики Татарстан; коллектив редакции журнала.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Кояш Тимбикова, Тәүфикъ Әйди, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.

Производствога бирелде 07.04.92 ел. Басарга кул куелды 07.05.92 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 40518. Заказ В-150. Бәясе 1 сум 80 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1992 ел.

70

# «КАЗАН УТЛАРЫ» — БЕЗНЕҢ ЮЛ

«Казан утлары»на 70 ел.

Үз вакытында аның 50 еллык юбилее уздырылды, 60 еллыгы... Менә хәзер — 70 еллыгы... Журналыбызның чишмә башы булып 1922 елда чыга башлаган «Безнең юл» санала. Соңгы елларга кадәр татар телендәге бердәнбер калын әдәби журнал булып килгән басмабыз тарихын, шулай итеп, гражданнар сугышы басылып, совет хакимияте ныклабрак урнашкан, әмма чын милли матбага сүлпәнәярәк төшкән бер дәвердән башлыйлар. Ә бит ныклабрак уйлап карасаң, татар халкының әдәби-сәяси журналлар чыгару тарихы еракка рак — гасыр башына — «Әлгасрел-җәдид», «Шура», «Аң» кебек басмаларга барып тоташа. «Казан утлары» журналын аларның варисы, дәвамчысы итеп санасак, бәлки, 70 еллык урынына 90 еллык юбилеен үткәрү дөресрәк булыр иде. Ә инде милли журналлар яралгысы рәвешендә үткән гасырның икенче яртысында ук чыга башлаган татар календарьларын да игътибарга алсак, әлеге санны 100 дән дә өскәрәк үстереп булыр иде. Хәер, юбилей санын түгәрәгрәк, саллырак күрү теләге үзмаксат түгел. Журналыбызның 70 еллык гомере дә халыкның иҗтимагый-эстетик фикер үсеше, әдәбият һәм мәдәниятыбызның үткән юлы турында анализ ясап җитди уйланырлык һәм, ниһаять, бәйрәми хис белән юбилей итеп үткәрерлек олы вакыйга.

Җитмеш ел үзе тарих өчен бер мизгел генә булса да, адәм балалары хәятендә өч буын алышынырлык озын гомер бит ул! Бер кояш астында янәшә-күрше яшәүче халыклар белән уртак язмыш үтеп, безнең татар халкы да ниләр генә кичермәде дә, нинди генә сынаулар үтмәде бу гомер эчендә! Инкыйлаб-революция зилзиләләре дә; аклар-кызылларга аерылып пычакка пычак килүләр дә; ачлыктан яки үләт чирләрендә нәсел-ыру белән кырылулар да; яңаны төзим дип, булганны юк итүләр дә; сыйныф-классларга бүленә-бүленә, диннәр белән көрәшә-көрәшә, алфавит-имляларны кат-кат алыштыра-алыштыра кыйбласыз, имансыз калулар да; сәяси авантюристлардан культ ясап, үзләре «шөреп-винт» хәленә калып, миллионнарның яуларда, лагерьларда һәлак булулары да; табигать кануннары һәм халык мәнфәгате белән исәпләшмичә, җир-суны мәсхәрә итеп «бөек-бөек» төзелешләр, хәрби-промышленность комплекслары корулар да; утопик хыял — коммунизмга фанатикларча ихлас ышанып, хакыйкатькә хилафлык кыла-кыла, физик көч һәм акыл сәләтен кирәкмәгәнгә исраф итүләр дә... һәммәсе, һәммәсе булган бу дәвердә!

Әлбәттә, гел фаҗига-хаталардан гына тормаган дөнья. Тормышның нигез максаты барыбер — тәрәккыят. Хыял-өмет, сөю-сәгадәт, идеал яшәткән кешене. Гомер маягы булган әнә шул идеалын, мирас һәм васыять итеп, баласы күңеленә салырга тырышкан. Якты киләчәккә, ирекке омтылыш, буыннардан буыннарга күчеп, һаман үскән, яңарган, көчәйгән генә. Тарих — канлымы ул, шанлымы — барыбер халык хәтеренә чигелә барган. Телефон-радио яңа керә башлаган, телевидение дигәннәренең әле эзе дә булмаган ул ерак елларда әлеге тарих кайда чигелеп, чор-дәвер кардиограммасы кайда сурәтләнеп калган соң? Әлбәттә, беренче нәүбәттә, басма сүздә. Китапларда, гәҗит-журналларда. Һәр басманың, һәр журналның — үз биографиясе, үз язмышы. Мәгълүм нәрсә: гасыр башында — халык рухының көчле бер уяну чорында татарча байтак журналлар чыгып алган. Өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә, хатын-кыз өчен дә... Диниләре дә, һәҗүле-көлкеләләре дә... 20 еллардан соң да, бик нык идеологияләштерелгән булса да, милли матбугатыбыз тарихында янә бер күтәрелеш булып алган. Әмма бу хәл озакка бармаган шул. Репрессия еллары башланган, сугышлар кабынып киткән. Кайбер журналлар туктап кала, кайберләрен ябалар... «Казан утлары»ның бәхете шунда: язмыш тарафыннан нәселне саклап калырга тиешле таза күзәнәкле зат

кебек, ул, сәяси катаклизмнарга бирешмичә, күпмедер компромиссларга барып, исемнәрен алыштыра-алыштыра булса да, җисемен-рухын саклады, халык тарихы елъязмасы рәвешендә өзелмичә яшәвен дәвам итә алды.

Архив исе сеңгән журнал тупләмәләрен карап утырам. «Казан утлары» — 1922 елдан алып 1930 елга кадәр гарәп шрифтында «Безнең юл» исеме белән чыккан. Утызынчы елдан икегә бүленеп, «Яналиф» (Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Совет язучылар оешмасы органы) һәм «Атака» (Татарстан пролетариат язучылары ассоциациясе органы) исемнәре белән басылган. Ә 1933 елдан 1965 елга кадәр — «Совет әдәбияты», ә соңгы дистә елларда хәзерге «Казан утлары» атамасы белән дөньяга чыгып килә. Заман сәясәте һәм аның шаукымнарына бәйле рәвештә журналның оештыручылары да (Татар социаль Шуралар җөмһүриятенең Мәркәз Башкарма комитеты һәм халык комиссарлары Советы; Татарстан халык мәгарифе комиссариаты, РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты, Совет язучылары оешмасы; ТАПП һәм Кызыл Армия-флот язучыларының Татарстан оешмасы; Татарстан язучылар берлеге, Татарстан Министрлар Кабинеты, редакциянең хезмәт коллективы...), титул билгеләмәләре дә (гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый журнал; сәясәт, сәнгать, экономика һәм тәнкыйть журналы; әдәби-гыйльми, иҗтимагый басма; әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы; әдәби һәм иҗтимагый-политик журнал; әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал), структурасы да һәм редакциянең эш урыннары да үзгәреп, алышынып торды. Билгеләмә-атамалар төрле чорда төрле сүз тезмәләрендә бирелсәләр дә, аларда төп ике төшенчә һәрчак сакланып киленде — «әдәби» һәм «иҗтимагый». Ягъни иҗтимагый әһәмияткә ия булган иң яхшы нәфис әсәрләрне бастыручы әдәби журнал ул — «Казан утлары». Әдәбиятыбызның, гомумән, мәдәниятебезнең елъязмасы, тарихи көзгесе. Алай гына түгел, журналыбыз язмышы — халык язмышы белән тәңгәл булды диясе килә. Юкса, ачлы-туклы елларда да, илне «боз суккан» чорларда да халык аны саклап калыр идеме соң? Сугыш кырларында иң кадерле хатлар белән бергә поход сумкаларында йөртерләр идеме аны? Котып тарафларында яки чүлле Кара-ком якларында, шахта баракларында яки тайга киңлекләрендә меңләгән укучылар, туган як сәламе һәм ана телебез аһәңе итеп, зарыгып көтеп алырлар идеме? Ә инде балачактан ук үзен әдәбиятка багышларга, гәҗиттә йә журналда беренче нәни мәкаләсен яки шигырен бастырырга хыялланган яшь җаннар өчен «Казан утлары»ның бәһасен әйтеп тә торасы юктыр...

Сүз — изгелек кылыр өчен яратылган, диләр. Бәхәсле булса да, бу гыйбарәгә ышанасы килә. Кешелекнең бөек ядкәрләре — Коръәнме ул, Библия яки Инҗилме — «дөньяда яманлык кылма, изгелек кыл» дигән рух белән сугарылмаганнармыни? Әгәр Сүз, чыннан да, изге икән,— төп коралы Сүз булган язучы кеше дә изге максатка — Хакыйкатькә, Әхлакка, Матурлыкка хезмәт итәргә тиештер бит. Язган һәр әсәр дә, һәр китап та, күмәк әдипләр чыгарган әдәби басма да... Бүген без юбиляр журналыбызның абруен никадәр генә күтәрергә тырышсак та, нихәл итмәк кирәк, адәм хатадан хали булмаган кебек, аның да ялгышлары, хаклык юлыннан тайпылулары да булгалаган. Гуманизм критерийларына, эстетик идеалларга хыянәт иткән сәхифәләр дә очраштыргалый журнал битләрендә. Олы талант ияләрен буржуа ялчылары дип бәяләүләр дә, чын милләт хадимнәрен «халык дошманнары» итеп фаш итүләр дә, «оборона әдәбиятының магнитостройлары өчен көрәш»ләр дә, коммунизмга алып баручы «юлбашчы»ларга мәдхия укулар да, АЭСларга дан җырлаулар да... Әмма 70 ел эчендә шактый калын (үзенчә җыелма бер томлык китап!) басма булып дөнья күргән 835 санның (барлык тиражын җыйсаң, үзе бер зур тау булыр иде!) дәрәҗәсен һәм кыйммәтен әле әйтеп узган саташулар билгелиме соң? Һич юк, әлбәттә. Соңгы 60—70 ел эчендә бар булган иң күренекле әсәрләребез нәкъ менә шушы журналда дөнья күрде, укучыларга, халыкка барып иреште. Сугыштан соңгы әдәби хәзинәбезгә карата бу фикер бигрәк тә рас килә. Йә, шушы журналга мөнәсәбәте булмаган яки әсәрен анда бастыруны дәрәҗә санамаган берәр татар әдибен табып була микән? Яки «Казан утлары» дигән Әдәбият Капкасын үтмичә иҗат мәйданында танылу алган берәр яшь язучы булдымы икән? Бу урында, бәлки, журнал тарихын бизәп калдырган әсәрләрне санап, авторларның исемнәрен тезеп үтү дә урынлы булыр иде. Дөресен әйтим, очына чыга алмам дип куркам. (Шунысы да бар: моннан 20—30 яки 10—15 ел элек классик саналган кайбер әсәрләр тоныкланып йә бөтенләй онытылып калды бу демократия чорында; яки киресенчә, тоталитар режим вакытында тыелган йә күләгәдә калганнары яңа янгыраш, танылу алды. Һәрхәлдә, әсәр исемнәре санау шактый четерекле шөгыль). Төрле жанрлардан, кечерәк күләмлеләрен дә кертеп исәпләсәң, меңнәрләгән бит алар!

Язышкан авторлар, табигый, тагын да күбрәк чыгачак. Шикләнмичә әйтә алам: и укучым, татар әдәбиятының нинди әсәре күңелегезгә яктылык һәм изгелек иңдереп калган булса, ул иң әүвәл безнең журналда басылган булыр.

Журнал — рухыбызның тарихи елъязмасы дидек. Әйе, бу чынлап та шулай. 70 ел буена тоташ, сугыш елларында да өзелмичә чыгып килгән бердәнбер журнал дидек. Әйе, бусы да шулай. Әмма бөтен бер халыкның гомуми мәдәнияте өчен бер генә басмасы булуы сөенеч түгел шул. Шуңа күрә дә журналга төрле тармакларга «таралып җигелергә» туры килә. Нәфис әдәбияттан тыш, мисалга фән дөньясын гына алыйк: гуманитар өлкәдә, бигрәк тә әдәбият, тарих, тел белеме фәннәрендә берничә академигыбыз, йөзләгән фән кандидатлары һәм докторларыбыз бар икән, аларның күбесе шушы журналда язышып, хезмәтләрен бастырып гыйлем үрләрен яуладылар. Аяныч, әле моңарчы театр, музыка, рәсем сәнгате, гомумән, мәдәният тарихы буенча махсус басмаларыбыз булмады диярлек. Шуңа күрә рәссамнар, композиторлар, артистлар иҗаты турында да журналда шактый мул урын биреп килende. Безнең республика шартларында бу вазифаны үтәүне журнал үзенең бурычы дип санады һәм хәзер дә шул фикердә тора.

Табигый ки, бер генә халык та фәкать үз кабыгында, үз биләмәсендә генә яшәп тәрәккыяткә ирешә алмый. Шуны истә тотып, журнал чит ил һәм күршетирә кардәш халыклар әдәбиятының гомумкешелеккә, гуманизмга хезмәт итә торган иң яхшы үрнәкләрен дә даими яктыртып килә.

Илнең тарихи үзгәрешләр кичерүе, ачыктан-ачык сөйләшү заманы килүе — күпгасырлык рухи мирасыбыз, аны тудырган мәшһүр талантлар турында курыкмыйча дөресен язарга мөмкинлек бирде. Татар тарихы бик бай, дөньялыкта тирән эз калдырган шәхесләр күп — әллә ничә басмаларга җитәрлек. Халык иҗаты үрнәкләреннән күпмедер дәвер онытылып торган җыр-бәетләр, поэма-дастаннар дисеңме; үз вакытында чит илләрдә басылып та, бездә дөнья күрмәгән гыйльми-тарихи хезмәтләр дисеңме; яшерен фондларда сакланган, әмма безгә әлегә мәгълүм булмаган архив документлары дисеңме... Боларны халыкка ирештерү — журналның киләчәктә башкарырга тиешле мөһим эшләренең берсе.

Даими укучыларыбыз белә булыр — моңарчы килгән күркәм традицияләрне дәвам итү белән бергә, яңа рубрикалар ачылды: «Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы», «Мәдәниятебез тарихыннан», «Әдәби мирас», «Остаханә» «Тарихи шәхесләр», «Мәгърифәт төбәкләрендә» һ. б. Милләтебезнең бүгенге көне һәм киләчәге, гореф-гадәтләребез, туган телебез язмышы һәрвакыт игътибар үзәгендә. Журналда Коръәннән сүрәләр, гарәп һәм латин әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре, яшьләр иҗатыннан үрнәкләр, драма әсәрләре, сәнгать сәхифәләренә дә киң урын бирелә.

Журналның 1922 елда чыккан башлангыч саннарның берсендә редакциянең әдипләргә, шагыйрьләргә, гыйлем-әдәбият мөхибләренә юллаган мөрәҗәгатендә мондый юллар бар: «Безнең юл»ның чыгуы татар җөмһүриятенең мәркәзендә — Казанда булса да, бу мәҗмуга Русиянең төрле якларында яшәгән һәммә татар-башкорт халыкларына хезмәт итүне үзенә максат итеп ала. Менә шул авыр, зур бурычны үтәүдә без эчке Идел-Урал, Сибириянең төрле почмакларында эшләүче әдипләр, шагыйрьләр, барлык гыйлем-әдәбият мөхибләренең ярдәменә ышанып, эшкә керештек. Үтенәбез: бер яктан, бу журналның таралуына, икенче яктан, гыйльми-сәяси, әдәби материаллар, мәкаләләр җибәрү белән, бу журналга булышсыннар иде... Эшче-крестьян гаммәсенең азатлыгы юлында эшләүче иптәшләр бу журналны үзләренең уртак хезмәтләре итеп карасыннар иде».

Моннан 70 ел элек чыккан мөрәҗәгать, күрәсездер, бүген дә актуаль яңгырый. Шуны истән чыгармыйк: «Казан утлары» — бүгенге Татарстан җирлегендә яшәүче милләттәшләребезнең журналы гына түгел, ә бөтентатар халкы журналы. Тиражыбызның яртылабы Татарстаннан тыш төбәкләрдә һәм чит илләрдә таралуы шуны раслый. Соңгы елларда без кичерә торган сәяси һәм икътисади үзгәрешләр, дистә еллар буе үзенчә хәрәкәттә булган дәүләт структураларының тотрыксызлыгы яки җимерелүе — журналыбыз язмышында, бигрәк тә аның таралуы (яздырып алдыру) процессында чагылыш тапмый калмый. Республикалар тулы мөстәкыйльлек алып, аерымланган заманда, бәһа һәм акчалар төрлелеге чорында, шактый очсыз бәягә, элеккеге СССР территориясендәге теләсә нинди почта бүлегендә журналга җиңел генә язылып булмастыр хәзер. Шулай да оптимист булыйк, «тырышкан табар, ташка кадак кагар», дигәндәй, эштә тырыш, уйда зирәк, коммерциягә маһир халкыбыз бу авыр ситуациядән чыгу җаен тапмый калмас. Куйган ачык максат, журналга нык ышаныч булса — югалмабыз. Татарстаннан читтә ана телебездә милли басмаларыбызны укучы һәр кеше кадерле безгә. Әлбәттә, редакция үзе дә үз укучыларына тагын да якынаю

юлларын эзләячәк, төрле регионнарда журнал тарату постларын булдырачак, рекламалауның нәтиҗәле чараларын күрәчәк.

Журналның үткәне турында зур сүзләр сөйләү, киләчәккә олы максатлар кую, алда торган проблемаларны хәл итү юлларын билгеләү һәм башка оештыру эшләре белән мавыгып, безгә кадәр журналны чыгарган фидакарь кешеләрне онытсак, алда әйтелгән 835 санны әзерләүдә катнашкан меңләгән хезмәттәшләребезне искә алмасак, без ихтирамга лаек булмабыз. Кем булып эшләсә дә — типографиядә хәреф җыючымы, әллә баш мөхәррирме, бүлек мөдире яки корректормы, машинисткамы, җаваплы сәркатипме, редколлегия әгъзасы йә хисапчымы, бүгенге яшь хезмәттәшебезме яки ветеранмы, исәнме, әллә гүр иясеме — барыбер — барчагызга-барчагызга олуг рәхмәт! Сезсез журнал тарихы булмас иде. Сезсез бүгенгебез булмас иде.

Журнал юбилее уңае белән үз-үзебезгә, ягъни әдипләребез колагына да берничә сүз әйтми калып булмый. Яшермик, күбебез бүгенге көнгә кадәр иске рух һәм күнегелгән алым белән, инерция белән язып ята. «Җанының ваклыгын заманга сылтап», денем өчен түгел, көнем өчен, дип язганнар белән халык тарихын язып булмый. Конъюнктур максат куеп, тема актуальлеге белән генә киң аренага чыгу көннәре үтте. Шикаятьләр яки «югарыдан» шылтыраттырып йогынты ясау заманнары бетте. Әгәр әсәрең талантсыз икән, «мин фәлән елдан язучылар таныклыгы йөртәм», «фәлән елдан бирле басылганым юк» кебек наив аргументлар көчсез хәзер. Моны һәммәбез ачык аңлыйк. Заман куйган таләп зур, югары. Гомумкешелек ирешкән фәлсәфи-эстетик югарылыкны яулап кына, үз халкыңа игелекле хезмәт итеп, милләтеңнең рухын, зурлыгын дөньяга күрсәтә алырбыз. Онытмыйк: без, бүгенге көн һәм XXI гасыр кешеләре өчен иҗат итәбез.

Соңгы елларда без шактый ишәйсәк тә, сан сыйфатка күчте, дип кистереп әйтә алмыйбыз. Әгәр авыз тутырып, «Казан» утлары» — бөтентатарның төп калын журналы, дип әйтәбез икән, исеме җисеменә туры килергә дә тиеш. Ягъни бөтен дөньяга таралган татар халкы тормышын күбрәк чагылдырырга, милләттәшләрне үзара якынайтырга, берләштерергә, цивилизация дөньясында татарның үзенә лаек урынын алуда булышырга тиеш булабыз. Дөресен әйтергә кирәк, без әле күбрәк үзебез яши торган Идел буе төбәге турында гына язабыз. Соңгы елларда даими чыгып килә торган «Татар халкы: төрле төбәкләрдә, төрле илләрдә» дигән рубрика әле әйтелгән берьяклылыкны бетереп, талантлы яңа әсәрләр хисабына тагын да үсәр, шәбәер дигән өметебез бар.

Татарстанның дәүләт бәйсезлеген яклау, ныгыту һәм аны тормышка ашыруга өлеш кертүне журнал иң җаваплы бурычларының берсе дип саный. «Казан утлары»ның 70 еллыгы — Татарстанның мөстәкыйльлеге — республикадагы халыкларның күмәк тавыш бирү, ягъни референдум белән ныгытылган, расланган елына туры килде. Якын көннәрдә Бөтендөнья татарлары конгрессы ачылачак. Референдум юлы белән бәйсезлек яулап алу, бөтендөнья татарлары җыены үткәрү — болар халкыбыз тарихында моңарчы булмаган тарихи вакыйгалар. Киләчәккә өметебез һәм ышанычыбыз зур. «Казан утлары» — зур тәҗрибәгә һәм якты сәхифәләргә ия булган мөхтәрәм басма — иншалла, халкыбызның XXI гасырдагы яшәешенең дә гадел елъязмачысы, килер буыннарның рухи юлдашы булыр.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
«Казан утлары» журналының баш мөхәррире,
Татарстан халык депутаты.

# МЕҢ ЯШӘ, СӨЕКЛЕ «КАЗАН УТЛАРЫ»!

Татар дөньясының бердәнбер саллы журналын, милләтебез рухының кабатланмас елъязмасын, халыкның әдәбе сагында торучы каләм әһелләренең төп иҗади мәйданы булган басманы һәм аның тырыш хезмәткәрләрен олуг бәйрәмнәре белән ихлас күңелдән тәбрик итәбез!

«Казан утлары» татарны инде җитмеш ел буена җылытты, җиде дистәлек гомеренең күпчелеге диктатлык шартларында үтсә дә, мәдәният тормышын хәл кадәри дөрес яктыртырга омтылды, ил башында торган хаким идеология әдипләрне «соцреализм» кысаларына көчләп кертмәкчә чакта да, әдәбиятны яшәтүче табигый сәнгатьчәлекне исән калдырырга тырышты. Барысы өчен дә рәхмәт аңа! Туган халкының хадименә әверелгән олпат журналның 835 томлык җыйналмасы үзе генә дә тирән тамырлы тарихыбызны күпкырлы рәвештә күз алдына китерә ала. Журнал безнең киләчәк буыннарга менә нинди хәзинә калдыра!

Гасыр башында чыккан байтак журналларның рухи варисы булган «Казан утлары», әйе, зирәклек яшен күрсәтүче бүгенге гүзәл бәйрәменә авыр дәверләр аша килде. Һәм җитмеш еллык юбилеен да ул катлаулы заманда билгеләп үтә. Милли дәүләтчелеген торгызуда беренче уңышларга ирешкән халкыбызны алдагы көрәштә тагын да авыррак сынаулар көтә. Язучыларның иҗат ирек кайбер киртәләрдән азат ителсә дә, ташка басылган сүз «дәүләткә зыян китерүче товар»га әйләнде. Үзенең яшәвенә куркыныч янаган шушы җаһил чорда, иншалла, олы тормыш тәҗрибәсе туплаган журналыбыз һәрвакыттагыча сынатмас: тылсымлы учак буларак, халыкны киләчәктә дә үз тирәсендә тотар. Иле барның теле бар, димәк, әдипләре барның журналы бар. А м и н! Изге теләкләребезне кабул итеп, мең яшә, сөекле журналыбыз «К а з а н  у т л а р ы»! Бәйрәмең мөбарәк булсын!

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ**

* * *

«Казан утлары» редакциясе коллективын, Татарстан Республикасының барлык язучыларын олы юбилей — татар телендә калын әдәби журналның беренче саны чыгуга 70 ел тулу белән кайнар котлыйбыз. Сезнең журналыгыз чыга башлавыннан ук киң танылды, үзенең җаваплы миссиясен намуслы үтәде һәм үти. Татар әдәбиятының иң яхшы көчләре нәкъ менә шушы басма тирәсендә тупланды. Журнал әдәби иҗатның барлык жанрларын, шул исәптән чагыштырмача яшь жанрлар — профессиональ тәнкыйтьне, эстетиканы, публицистиканы уңышлы үстерүгә булышты, татар музыка һәм рәсем сәнгатьләренең күтәрелешенә ярдәм итте.

«Казан утлары» журналы Бөек Ватан сугышы елларында да чыгудан туктамады, фронтовик язучылар белән ныклы элемтә тотты, аларның әсәрләрен бастыра килде. Хәзер, татар әдәбияты һәм мәдәнияте яңа күтәрелеш кичергәндә, «Казан утлары» — БДБнең суверен дәүләтләре журналлары арасында иң абруйлы басмаларның берсе.

Сезгә, кадерле дуслар, изге һәм игелекле хезмәтегездә яңа уңышлар телибез.

**РОССИЯ ЯЗУЧЫЛАРЫ**

Гомәр Бәширов

# КЫЙБЛА БИЛГЕЛӘГӘНДӘ...



Бу мәкаләне язарга дип кулыма каләм алгач, озак кына икеләнеп утырдым. Туксаннан артып киткән озын-озак гомерем юлында ничәмә-ничә революцияне, һәлакәтле сугышларны, ачлыкларны, репрессияләрне, тагын әллә никадәр хәвеф-хәтәрләрне башымнан кичерсәм дә, мондый ук буталчык хәлгә тарыганым булмады шикелле. Йөрәкне иң авырттырганы матди кыенлыклар гына түгел, иң үзәккә үткәне — үзеңнең алдангaн буын вәкиле булуыңны хис итеп, гомереңбуена чын күңелдән инанып килгән хыялларыңның кинәт берьюлы җимерелеп төшүе. Безне оятсыз рәвештә алдадылар. Безнең буын кешеләре халыкның милли азатлыгы, хезмәт ияләренең якты киләчәге өчен көрәште. Шул идеяләрне гамәлгә ашыру өчен партиягә керде, сугышларда җәфа чикте, ачлыктан тилмерде, төрмәләрдә, лагерьларда һәлак булды. Ә нәтиҗәсе нинди?

Фаҗига бит бу! Буш хыялга алданып имансыз, телсез, милләтсез кала яздык. Бик аздан гына халык буларак таркалып бетми калдык. «Хөррият! Хөррият!» — дип, рухланып якты кояшка таба кузгалып киткән кәрванибыз ерып чыга алмастай сазлыкка барып керде. Җитмеш елдан артыкка сузылган бу канлы, фаҗигале экспериментның нәтиҗәсе хәзер күз алдында. Бөтен кешелек җәмгыятенә куркыныч тудыручы фашизмны җир йөзеннән себереп түгүче данлы, куәтле ил бүгенге көндә билен бөгеп капкорсак капиталга яңадан баш ияргә мәҗбүр булды.

Рухи халәтең шундыйрак булганда нәрсә язып булсын икән?

Шулай да, тешне кысып булса да, язарга кирәк! Бердән, без җәфа чиккән бу җирдә дистә ел бөтенләй үк мәгънәсез узмагандыр лабаса, аннан нәрсә дә булса мирас булып калгандыр бит? Халыкның азатлыкка омтылу дәртеннән туган ялкынлы хисләре әдәбиятта, сәнгатьтә нииндидер эз калдыргандыр бит?

Моны күрмәгәнгә, белмәгәнгә салыну азатлык өчен көрәшләрдә һәлак булган каһарманнарыбызга хыянәт итү булыр иде. Бүгенгенең иртәне бар, үткәннәрдән гыйбрәт ал, дигән халык.

Икенчедән, империяне зир-зәбәр китереп җимереп ташлаган бу зилзилә көтмәгәндә безгә азатлык капкасын ачты, татар халкында мөстәкыйльлеккә өмет уятты. Февральнең марты бар, җаны барның өмете бар. «Ал җәсарәт, алга омтыл, һич ялыкмый алга бар», — дигән Тукай. Бу гыйбрәтле еллар сабагы көрәшкә күтәрелгән яңа буынга, бәлки, ярап куяр.

Журналыбызның җитмеш яше тулу хакында сүз кузгалганда күңелдә төрле фикерләр уяна. Тәгаен җитмеш белән генә чикләнеп кую урынлы булыр микән? Бәлки, бу датаны шартлы дип исәпләргә кирәктер? Чөнки татар әдәбиятында — «Безнең юл»га кадәр дә мәшһүр журналлар: «Шура», «Аң», «Карчыга», «Ялт-Йолт» һ. б. журналлар чыгып килгән иде бит әле.

Хәер, әдәбият тарихы бу хакта үз сүзен әйтер.

Бу мәсьәләнең икенче ягы да бар. Революциядән соң бездә әдәбиятның «чишмә башын» совет чорыннан гына алып китү гадәткә керде. Алай гына да түгел, матбугатта классик әдәбиятның үрнәкләре торган саен сирәгрәк телгә алына башлады. Элекке язуыбызны «комган әлифбасы» дип кимсетүчеләр дә булмады түгел. Бу хәл элек мәдрәсәләрдә укыган, матур әдәбиятны үзенә тормыш юлдашы итеп алган укымышлы кешеләрдә, гомумән, әдәбият сөючеләрдә, тирән юксыну хисе тудырды. Ул вакытта әле яңа гына борынлап чыккан совет әдәбияты исә җәмгыять тормышында шәп-шәрә далага корылган ялгыз чатыр сыман гына иде. Ул елларда совет чоры тудырган әдәбиятның борынгыдан килгән әдәбият дәвамы түгел, бәлки революция тудырган яңа эчтәлекле өр-яңа

әдәбият булуын бик тырышып белдерергә ашыктылар. Шул сәбәпле хәтта журналның исеменә дә «совет» сүзе өстәлде. Монда яналыкка омтылудан бигрәк, халыкның үзәгенә үткән иске тормыштан ваз кичү, аңа тискәре карашның көчле булуы да сизелә иде.

Гаҗәп бу тормыш дигәнең. Әгәр дә шул елларда кем дә булса «совет» сүзенең журнал тышыннан гына түгел, хәтта конституциябездән дә төшеп калу ихтималы турында сүз кузгатса, аны «контр» дип, «тиешле урын»га озатырлар иде. Ә язмыш исә безнең белән менә ниләр кыланды!

Сугыштан соң батырлар күбәя, диләр. Хәзер социализм идеясен тәмам чишендереп, шәп-шәрә калдырганнан соң, кайберәүләр бик батыраеп китеп, Октябрь революциясенең зарурлыгын инкарь итә башлыйлар. Янәсе, әгәр революция булмаса, бу бәлаләрнең берсен дә кичерергә туры килмәгән булыр иде. Дөресен генә әйткәндә, бу темага сүз кузгату, әрмән халкына җир тетрәү кирәк идеме, әллә кирәк түгел идеме, дигән кебегрәк мәгънәсезлек, буш сафсата гына. Октябрь революциясенең, табигатьтәге зилзилә кебек үк, котылгысыз бер катаклизм икәнлеген генә аңлап буладыр бит! Моны патша Россиясенең халыклар төрмәсе булуын үз күзе белән күрмәгән, патша палачлары камчысын үз җилкәсендә татымаган кеше генә әйтә ала.

Шунысын онытмыйк: Октябрь революциясе бөтен дөнья хезмәт ияләре аңында азатлык, хөррият чаңы булып яңгырады. Аларда патшасыз да, алтын капчык хакимиятеннән башка да яшәп була икән, дигән якты өмет уятты!

Инде татар милләте күзлегеннән караганда, революция безгә самодержавие чылбырыннан ычкынып, бераз гына булса да иркен сулыш алырга, 365 елга сузылган коллыктан соң туган җиребезне үз исеме белән «Татарстан» дип атарга мөмкинлек тудырды. Татар зыялыларының революцияне нинди күтәренке рух белән, нинди ялкынлы дәрт, фидакарьлек белән каршы алуын белсәгез иде сез! Безнең көннәрдә кабынып киткән мөстәкыйльлек өчен көрәш шәрә җирдә тумады. Татар халкының азатлыгы өчен көрәшүче бүгенге каһарманнарыбыз революция елларында Мирсәет Солтангалиев, Мулланур Вахитов, Якуб Чанышевлар кулындагы хөррият байрагын тагын да югарырак күтәрделәр.

Шулай итеп, советлар власте күз алдында юкка чыкты. Берничә көн эчендә төрле кисәкләргә таркалды. Без моңарчы күз күрмәгән, хәтта теоретик яктан нигезе дә салынмаган ниндидер яңа җәмгыятькә аяк басу алдында торабыз. Нинди булачак ул җәмгыять? Анысын хәзергә беркем дә әйтә алмый. Без хәзер «социализм» дип авыз да ача алмыйбыз. Чөнки без югары мәдәниятке ия булуны, аңлы булуны таләп итүче нинди дә булса алдынгы җәмгыять оештырырга сәләтсез булып чыктык. Капитализм дөньясы исә бездән көлә генә. Әлхасил, нәкъ Рәсәйдәгечә: эт баш, сыер аяк...

Шунысы бик ачык, ул инде совет җәмгыяте булмаячак. Димәк, әдәбиятыбызның да «совет дәвере» дигән чоры шунда тәмамланды. Әдәбиятыбыз үзенең асылына кайтып, моннан соң үзенең төп исеме белән т а т а р  ә д ә б и я т ы дип кенә аталырга тиеш була торгандыр.

Совет дәвере әдәбиятына йомгак ясала икән, ул дәвердә хакимлек иткән коммунистик идеологиягә язучыларның нинди мөнәсәбәттә булуы мәсьәләсе дә читтә кала алмый торгандыр. Бигрәк тә бүгенге көннәрдә. Чөнки хәзерге яшь буынның Сталин чорындагы әдәбиятка һәм аны иҗат итүчеләргә карашы һич тә объектив түгел. Әлек безгә ят булган плюрализмга без һаман да күнегә алмыйбыз. Бездә җәмәгатьчелек фикере һаман да гадел булып житә алмый. Әле бер якка, әле икенче якка авышып китәбез. Тегеелларда газета-журналлар «бөек атабыз даһи Сталинны» тәкерекләрен чәчеп, һушларыннан язардай булып мактасалар, хәзер коммунистларны да шундый ук ярсу нәфрәт белән сүгәләр. Әйтерсең, коммунистларның, гомумән, Сталин вакытында яшәүчеләрнең һичбер юньле гамәлләре булмаган, алар һәммәсе дә гомерләре буена «ура» кычкырып, кул чабып кына утырганнар. Хакыйкать алай бик ансат һәм беркатлы түгел иде бит. Озак еллар редакцияләрдә, нәшриятта һәм язучылар берлегендә эшләгәндә бу катлаулы процессларның күбесе минем күз алдымнан үтте. Язучылар коллективы иҗат хөрлеген, әдәбиятыбызны, туган телебезне көче житкән кадәр сакларга, диктаторлыкка каршы көрәшергә тырышты.

Моңа Татарстан язучылары тормышыннан бик күп дәлилләр китерергә булыр иде. Мәсәлән, 1989 елда басыла башлаган «Идел» журналы кебек яшьләр басмасы чыгару кирәклеген язучылар коллективы моннан утыз ел элек үк кузгаткан иде инде. Шул фикерне раслый торган хәтсез материал туплап, мин, коллективның ул вакыттагы рәисе буларак, КПСС өлкә комитетының беренче сәр-

катибы З. И. Моратовка кердем. Мин аңа журналның Татарстанга гына түгел, бәлки җөмһүриятебездән читтә яшәүче яшьләребезгә бигрәк тә кирәкле булуына аеруча басым ясарга тырыштым. Соңыннан аңлавымча, сәркатибнең нәкъ әнә шуннан коты чыкты да инде!

— Юк, юк! Бу сүзеңнән татар шовинистлыгы исе килә! Бу синең сүзең түгел, сине монда котыртып кертканнәр. Ул өлкәләрнең үз властьлары бар, үзләре кайгыртсыннар! — диде.

Өлкә комитетының беренче сәркатибы итеп татар кешесен китереп утыртуның да иң төп сәбәбе әнә шул — алар милләтчелектә гаепләнүдән, шайтаннан өреккәндәй, куркып яшәделәр. Мөмкин булган барлык ысуллар белән әдәбиятта-сәнгатьтә булсын, башка өлкәләрдә булсын — милли горурлыкны, гомумән, милли хисне бик тырышып бастыра килделәр. Безнең әдәби тормышта моңа мисалларны бик күп китерергә мөмкин. Мәсәлән, минем «Яхшы түгел» дигән хикәямне бастырып чыгарган өчен бер елны «Азат хатын» журналы хезмәткәрләрен премиядән мәхрүм иттеләр. Журналны сәяси сукырлыкта гаепләп чыктылар. Нинди куркыныч крамола тапкан соң ул хикәядән өлкә комитетының пропаганда сәркатибы? Татар егете марҗа кызына урамда үбешеп тору бездә әдәпсезлек саналуын аңлатып бирә... Фәкать шул гына!

Пропаганда сәркатибы миңа матбугатта хикәямне һәм «Азат хатын» журналын яклап чыгарга рөхсәт итмәде. Сәбәбен белергә теләгәч:

— Ата казны котыртасы юк әле! — диде.

Менә шулай! Ничек әле син татар башың белән үз халкыңның гадәтен башкалардан өстен итеп күрсәтергә маташасың! Тавышың чыкмасын!

Язучылар союзы бу җәһәттән һәрвакыт игътибар үзәгендә булды. Бездә «ата казның» кәефен бозарлык берәр мәсьәлә кузгала башладымы, шунда ук аны бүтән юнәлешкә борып җибәрү чарасы күрелә иде. Мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты укытуның елдан-ел начарлана баруы язучыларны күптән үк борчый иде инде. Идарә шуңа багышлап махсус җыелыш уздырырга булды. Моны ишеткәч «өстә» хафага төштеләр. Пропаганда сәркатибы: «Истә-оста югында каян килеп чыкты әле ул татар теле?» — диде. Чарасын тиз үк күрделәр. Безгә «ярдәмгә» тел профессорын җибәрергә булдылар. Ул мәсьәләне бөтенләй башка якка борып җибәрмәкче булды. Әдәби телдәге гарәп-фарсы сүзләре урынына рус сүзләре кулланырга кирәген расларга тотынды. Язучылар аның бу «теориясен» пыр туздырып сүтеп ташладылар, ахырда профессорны трибунада берүзен генә калдырып, җыелышны ташлап чыктылар. Менә шулай бара иде эшләр.

Иҗат хөрлеге өчен тартыш теге яисә бу юнәлештә өзлексез дәвам итте.

Күпләрнең хәтерендәдер, язучыларның һәр җыелышына өлкә комитетыннан кем дә булса килмичә калмый торган иде. Килә, тыңлап утыра да ләм-мим бер сүз әйтмичә китеп тә бара. Бу бигрәк тә партия әгъзаларын җәберли иде. Коммунист була торып сиңа һичбер ышаныч булмау, һәрвакыт диктат астында мескен хәлендә яшәвебез тәмам җанга тия, күңелләрдә канәгатьсезлек тудыра иде. Бу хиснең тышка бәреп чыкканы да булгалады. Бер җыелышта Ибраһим Гази, түземсезлеген җуеп, хәтта протест белдерергә мәҗбүр булды.

— Бу нинди ышанычсыз бәндәләр булдык инде без! Нигә безгә җыелыш саен шпионнар җибәрәләр! — диде.

Кемнәрдер уңайсызланды, кемнәрдер көлеп кенә уздырды, әмма теге җибәрелгән кеше, кызарынса да, тыңлап утыруын дәвам итте. Әлеге гадәт аңа карап барыбер үзгәрмәде.

Әдәбият һәм сәнгатькә партия җитәкчелегенең ни рәвешле «гамәлгә» ашырылуын Ф. Табиев 1971 елны май аенда уздырган бер киңәшмә мисалында да күрергә мөмкин. Бу киңәшмәгә әдәбият-сәнгать әһелләренең 350ләп иң алдынгы вәкилләре чакырылган иде. Ф. Табиев бик озаклап тышкы һәм эчке эшләр, республика алдында торган төрле бурычлар хакында сөйләде. Сүз дә юк, оста сөйләде. Шуннан соң нәрсә? Без бит инде киңәшмәгә дәшкәннәр икән, табигый, сәркатипның әдәбият-сәнгать турында да сүз кузгатуын, безнең гамәлебезгә карата нинидер җитди, рухландыргыч сүз әйтүен көтә башладык. Ләкин бик нык ялгышканбыз булып чыкты. Кая ул! Сәркатип нинди дә булса акыллы киңәш, юньле сүз әйтәсе урында диктатор тоны белән кычкырынып, тавышланып, ачулы сүзләр белән безгә нотация укыды. Хәзер, имеш, бөтен эшне нинидер бүтәннәр түгел, продукт эшләп чыгаручылар, эшчеләр, колхозчылар һәм аларны оештыручылар, партия органнары хәл итә! Партия сезнең теләсә нинди дәгъваларыгызга чартлатып җавап бирә ала! Менә шулай!..

Табиев сөйләп бетергәннән соң, пропаганда сәркатибының кат-кат үтенүенә карамастан, залдан авыз ачып бер генә сүз әйтүче дә, бер генә сорау бирүче дә булмады. Кинәшмәдән без башларыбызны иеп, җәберләнеп чыктык. Әдәбият-сәнгатькә житәкчелек итә белмәүнен ин тупас күренеше иде бу.

Мондыйрак сүз кузгалгач, укучыда шик туарга мөмкин бит әле. Ничек аңларга? Алтмыш елдан артык партия әгъзасы булып яшәгән кеше ничек хәзер генә коммунистлар житәкчелеген тәнкыйтьли башлады әле? Әйе, шулай диюләре ихтимал. Бик урынлы сорау. Ул хәзер дә күңелләрдә канәгатьсезлек тудыра торган мәсьәлә. Әмма эш шунда ки, без яшь чакта ышанып кергән элекке чын партия соңгы елларда бик үзгәрде. Мин яшь вакыттагы коммунистлар дошман өстенә беренче булып кылычын айкап ташланучы ил каһарманнары иде! Соңгы еллардагы житәкчеләр исә партиянең миллионнарча әгъзаларыннан, аның төп массасыннан тәмам ераклаштылар. Соңгы вакытта ишетүебезгә караганда, партия әгъзаларыннан тиенләп җыйган миллионнарны өстә утыручылар, халыктан яшереп, чит ил банкларына озатуга кадәр барып житкәннәр! Таркалыр алдыннан коммунистлар партиясенең халык алдында дәрәҗәсе бик түбәнәйгән, аның әгъзасы булып эшләү элекке кебек күңелдә якты өметләр тудырмый башлаган иде инде.

Шулай итеп, Октябрьдән башланып киткән бу «совет дәвере» дигәнебез хәзер йомгаклауга мохтаҗ булып кала. Үзеннән үзе шундый сорау килеп туа. Йә хуш, эшем кырган кешеләрдәй, бик яман җилкендек, «кызарындык», унга-сулга селтәнеп, бик хәтәр тузынып алдык, «иске тузаннарны кактык», «яңа үрләр яуладык» дип бөтен дөньяга сөрән салдык. Чыннан да шулай микән бу, дөресме? Житмеш елдан артык яшәгән татар совет әдәбияты борынгы заманнарда ук башланып киткән меңъяшәр әдәбиятыбызны элек булмаган нинди кыйммәтле сыйфатлар, эстетик ачышлар белән баетты? Кәрванybыз киләчәккә таба юнәлгәндә әдәбиятыбыз йөгенә совет чорыннан нинди затлы әсәрләр өсти алабыз, әдәбият-сәнгать йолдызлыгында нинди яңа йолдызлар кабынды? Шуларга җавап бирер вакыт, тарих алдында имтихан тотар вакыт житте.

Кайберәүләрнең бу фикергә каршы чыгулары, совет дәвере әдәбиятына «Татар әдәбияты тарихы» китапларында тиешле бәһа бирелүен искә төшерүе мөмкин. Әйе, андый тарих бар. Ләкин ул «тарих»ның тоталитар дәүләт идеологиясе тәэсирендә язылуын онытырга ярамый. Ул китапларда теркәлгән тарихи фактлар нигездә дөрес күрсәтелсәләр дә, «тарихның» бишенче китабында Сталин культының фаш ителүе телгә алынса да, тарих гомумән алганда коммунистик идеологиягә, аның житәкчеләренә мәдхия укудан арына алмаган. Димәк, әгәр дә без киләчәктә чын мәгънәсендәге иҗат хөрлегенә омтылабыз икән, моны истә тотарга кирәктер.

Әдәбиятыбызның шушы узган чоры хакында төрле фикерләр әйтелә. «Совет дәвере»нең әдәби процесска ничек тәэсир итүе хакында, мәсәлән, талантлы язучы Радик Фәизов фикере игътибарга лаек («Соц. Татарстан», 1991 ел, 17 май). «Кая авышабыз» дигән бу мәкалә әдәбиятыбызның хәзерге торышына чын күңелдән ачынып, көчле тел белән язылган. Анда бик дөрес фикерләр дә бар. Әмма якташымның «...әдәбият мәйданына илленче елларда килеп кергән бер буын язучыларны югалган язучылар дип саныйм...» диюе белән һич тә килешәсем килми. Радик Фәизов — ифрат та тыйнак холыклы, гадел кеше. Бу фикерне әйтүгә ихтимал аның үз иҗатына зур таләпләр куюы да тәэсир иткәндер. Шулай да мин андый катгый фикерне хаклы дип санамас идем. Чөнки шул ук Радикның үз иҗаты да заманына яхшы хезмәт итте бит. Аның телгә алынган әлеге мәкаләсен уку да шундый тәэсир калдыра. «Ул фахишәләр! Алар бер дә галәмәт! Хикәяләрне, бөтен повестьларны басып алдылар. Тәмәке тарталар, голт-голт аракы эчәләр, ирләрдән болай сүгенәләр. Ул имансызлар... бөтен дөньясына акыралар, бакыралар. Аларда намус та, вөждан да юк. Кешене үтереп ташлауны чүпкә дә санамыйлар... Ярый, алар тормышта булсын да ди. Ә менә әдәби әсәр битләрендә аларга ни калган? Житмәсә өерләре белән!..» Юк, «югалган буын» вәкиле болай ялкынлы итеп әйтә алмас иде. Бу батыр йөрәкле чын көрәшче сүзе! Димәк, «югалмаган» әле язучы, һаман да сафта! Әдәбиятка куркыныч тудыручы бу юнәлешкә нәфрәт белдерү бик урынлы. Язучы бик вакытлы искәртә.

Әдәбиятыбызның 75 еллык бу дәверенең чын әдәби кыйммәтен билгеләгәндә бәхәсләр күп булыр әле. Әмма хәзергә ул чор әдәбиятын бөтенләй диярлек инкарь итеп, ул вакытта кылынган барлык «гөнаһлар»ны шул заманда актив иҗат эше белән шөгыльләнүчеләр өстенә аудару модага кереп бара. Янәсе, ул дәвердә игътибарга лаеклы фәкать берничә әсәр генә бар. Башкалары исә «өстән

кушу» буенча язылганнар, шул сәбәпле андыйлар әдәбиятка нинди дә булса файдалы өлеш кертә алмыйлар булып чыга. Кызганычка каршы, хөрмәтле әдибебез Ә. Еники дә бер мәкаләсендә нәкъ шул фикерне кабатлады. Шушы «өстән кушып яздыру» дигән шаблонга ачыклык кертәсем килә. Минем фикеремчә, ачыктан-ачык өстән кушып язылган әсәрләрне аерып алып карарга кирәк. Нинди әсәрләр алар? Мәсәлән, шәхес культы чиренең иң күперенгән бер чорында, Бөек Ватан сугышы алдыннан, татар шагыйрьләреннән иң талантлы алты-җиде иптәшкә партиянең өлкә комитетыннан Сталинга Татарстан исеменнән шигырь белән хат язарга кушылды. Менә бу, чыннан да, «өстән кушу» иде. Зур революцион вакыйгалар уңае белән дә язучыларга мәкалә яисә очерк язарга тәкъдим итәлә иде. Шул чорларда шагыйрьләрнең бер-берсе белән ярыша-ярыша Сталинга шигырь белән мәдхия укулары да бәлки өстән бирелгән әмер буенча башланган-дыр. Әмма, минемчә, бу «өстән кушып язу» дигәнне бөтен совет әдәбиятына һәм иҗат осталарына карата куллану һич тә дөрес түгел. Ул совет әдәбиятының «Казакъ кызы», «Кызыл чәчәкләр», «Тирән тамырлар», «Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр», «Тапшырылмаган хатлар», «Йөзек кашы» кебек һ. б. мәшһүр әсәрләренең авторларын үз мәсләге, үз карашы булмаган марионеткаларга тиңләү, аларны кимсетү булып чыга. Минем фикеремчә, иң әүвәл шуны истә тотарга кирәк: җитди әдәби әсәр бервакытта да кемнеңдер әмере яки киңәше белән генә туа алмый. Әдәби әсәр барлыкка килү өчен язучыны ниндидер зур идеяләр, җитди вакыйгалар, аерым шәхесләр тормышы дулкынландырып, аның күңелен кузгатырга, алар хакында язмыйча кала алмау хәленә китерергә, ягъни язарга көчле илһам бирергә тиеш. Әдәби иҗат ул авторның нәкъ үзенә генә хас рухи тормышы, ул аның фәлсәфи карашы, белеменең микъдары, фикерләү ысулы. Әсәрнең беренче сүзләреннән соңгы ноктасына кадәр ул аның эчке иҗат җимеше. Әгәр автор читтән әйтелгән идеяне үзенең рухи хәзинәсе итеп күңеленә сеңдерми икән, димәк, ул хакта яза да алмый.

Бу бер. Икенчедән, язучыларны өстән кушканны гына теркәп утыручылар итеп тамгаласак, бу аларны курчак дәрәҗәсенә төшереп, «өстә утыручыларны» исә, аларның «идеологларын» итеп күтәрү, ягъни партия аппараты житәкчеләренең интеллект җәһәтеннән иҗат кешеләреннән бик нык өстен торуын раслау булыр иде. Шунысын да уйларга кирәк, күп кабатлый торгач, моңа укучылар да ышанырга мөмкин бит. Хәлбуки, 60 еллык иҗат гомеремдә мин Никита Хрущевтан, Сусловтан башлап, өлкә комитеты секретарьларына кадәр байтак житәкчеләр белән очрашсам да, алар арасында үзенең белеме, интеллектының куәте һәм әдәбият-сәнгатьнең нечкәлекләрен тирән аңлавы белән аерылып торган кешеләрне очратмадым диярлек. Тагын шунысы да бар, әгәр дә ул житәкчеләр әдәбиятның, сәнгатьнең тормышта тоткан урынын, аның фәлсәфи тирәнлеген, эстетик куәтен тирәннән аңласалар, әдәбият-сәнгать өлкәсендә безнең күз алдыбызда булып узган тупаслыкларны җибәрмәсләр иде.

Тормышта ничек булды? Дөрес, партия аппараты әдәбият-сәнгатьнең филармония, театр, нәшрият, көндәлек матбугат кебек тармакларында үз рөхсәтеннән башка чебен дә очырмады дип әйтергә мөмкин. Әмма күренекле язучыларга, композиторларга ул кадәр үк тәэсир итә алмыйлар иде. Аларга уңай герой мисалында тәрбияләү, социалистик реализм методын куллану кирәклеге кебек киңәшләр бирүдән әллә ни эчкә үтмәделәр.

Озын сүзнең кыскасы шул: әдәби әсәрне, бигрәк тә өстә санап кителгән замана көзгесе булган әлеге мәшһүр китапларны «өстән кушып язылган» дип атау буш сүз ул. Сүз өстән кушу-кушмауда түгел, бу бик примитив аңлату. Эш теге яисә бу авторның совет чоры идеологиясен үзенеке итеп кабул итү-итмәвендә. Тагын да ачыклабрак әйткәндә, иҗат кешесе «денем өчен түгел, көнем өчен» дип яраклашып кына язарга мәҗбүр булганмы, әллә ихлас күңелдән иҗат иткәнме? Бу төп мәсьәлә. Бу хакта төрле фикерләр күренгәли. Күптән түгел университет галимнәреннән А. Яхин телевидениедән ясаган чыгышында моңа Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» әсәрен мисал итеп китерде. Аның раславынча, автор бу әсәрендә үзе әгъза булып торган коммунистлар партиясенең идеяләренә чын күңелдән инанмаган, ул аны әлеге әсәрендә дә тәнкыйтьләгән. Әмма үзенең чын фикерен, мәсьәләгә үз карашын болай укыганда гына сизелмәслек итеп, аерым детальләрдә генә сиздереп алгалаган. Мәсәлән, ул партия конференциясенең элекке дворян-бюрократлар сараенда уздырылуы белән коммунистлар партиясенең дә асылда бюрократлар оешмасы булуына киная ясаган. Авторның төп үз карашын әнә шуннан эзләргә кирәк, имеш. Мондый фикер, ягъни язучылар социализм идеясенә чын күңелдән ышанмаганнар, шулай да яраклашып совет чорын мактап язарга мәҗбүр булганнар дигән сыманрак раслаулар башка яз-

маларда да күренгәли. Болай дип раслау исә, язучылар совет дәвере идеясенә ышанмаганнар, әсәрләрендә язганнарына үзләре чын күңелдән ышанып түгел, бәлки власть башында утыручыларга яраклашып кына язганнар, ягъни икейөзле булганнар, дигән нәтиҗәгә китереп чыгара.

Бу хакта уйлаганда, дәртле хисләре белән күңелләрне кузгатып, К. Тинчурин жыры искә килеп төшә:

Без кабызган утлар сүнмәс алар,
Сүнмәс алар хәтәр җилләрендә.
Без кабызган утлар якты янар,
Якты янар хезмәт илләрендә.

Уйлап кына карагыз әле, әгәр дә үз күңеле түрендә кайнап, дулкынланып килеп тумаган булса, Кәрим абзый бу җырны шундый ялкынлы итеп яза алган булыр идеме?

Тагын бер мисал. Г. Ибраһимов 1920 елдан 1926 елга кадәр, ягъни нибары биш-алты ел эчендә никадәр популяр әсәрләр язып калдырган! «Алмачуар», «Кызыл чәчәкләр», «Яңа кешеләр», «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар» һ. б. Шундый сөаль туа: әгәр дә ул революция идеяләре белән чын күңелдән рухланмаган булса, кыска гына вакыт эчендә, бигрәк тә «өстән кушу» буенча шундый сокландыргыч әсәрләр яза алыр идеме? Юк, билгеле. Аны башка китерү дә мөмкин түгел.

Бу урында патша режимының рәхимсез золымын үзе татып карамаган, элекке заманның нинди(?)леген китапларда язылган буенча гына, ишетеп кенә белүчеләр өчен тагын бер нәрсәне аңлатып узасым килә. Октябрь революциясенең, совет властеның абруе беренче ун ел эчендә ифрат та югары иде. Бу елларда гади хезмәт халкының күпчелеге патша золымыннан, урәтникләр, стражниклар җәбереннән, байлар изүеннән коткарган өчен совет властена рәхмәт хисе белән яшәде, советларны хезмәт иясе властe итеп таныды. Дөрес, татар халкын алдадылар, халыкның күп өлешен республикадан аерып, башка өлкәләрдә калдырдылар. Ләкин патша режимындагы хокуксызлык, караңгы язмыш белән чагыштырганда шул өтек автономия дә, бераз гына булса да, иркенрәк сулыш алырга мөмкинлек бирде. Элек-электән белемгә омтылган яшь буын патша заманында керергә хакы булмаган югары уку йортларына йөзәрләп, меңәрләп ябырылды. Озакламыйча татар хезмәт ияләренең үз эченнән инженерлар, врачлар, архитекторлар, агрономнар һ. б. югары белемле белгечләр калкып чыкты. Октябрьгә кадәрге чорның мәшһүр язучыларына, артистларына халык арасыннан яшь көчләр килеп кушылды. Нәтиҗәдә әдәбият-сәнгать тагын да югарырак баскычка күтәрелде. Дөрес, совет чорында язылган әсәрләрнең һәммәсен дә озын гомерле булдылар дип әйтмәс идем. Арада «уңай герой»ларны мөмкин кадәр күпертеп, тормышны бизәп, матурлап күрсәтергә омтылучы әсәрләр дә аз булмады.

Минемчә, әдәбият галимнәренә һәм язучыларга хәзер «өстән кушып яздыру» кебек гомуми фразаларга вакыт әрәм итмичә әдәби иҗатның эченәрәк керә башларга, аның эчке серләрен ачып күрсәтергә бик вакыт. Бу дәвердә иҗат ителгән фәлән әсәрендә язучы яки шагыйрь ни дәрәҗәдә идеология мәҗбүриятенә бирелгән, ни дәрәҗәдә халык мәнфәгатен кайгыртa алган? Үзе булып кала алганмы? Кайсы очракларда ул талантының потенциаль мөмкинлекләрен тулысынча ача алмыйча «тотлыгып» калган? Бу — әдәби әсәргә жентекле эстетик һәм идеологик анализ таләп итә торган җитди хезмәт куюны сорый. Әдәбиятыбызда мондый анализга җитди дәлилләр бирерлек әсәрләрне байтак табарга мөмкин булыр иде. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романының 1914 елда басылган варианты белән совет дәверендә язылганын шул күзлектән чыгып чагыштырганда, аның бик кызык нәтиҗә бирүе мөмкин. Бу хакта Г. Нигъмәти һәм М. Хәсәнов хезмәтләрендә юл уңаеннан гына телгә алына.

Шул ук авторның революциягә кадәр үк, ягъни беренче партия идеологиясенә дә табынмыйча, үзен һәр яктан хөр санаган яшьрәк елларында язган мәшһүр «Казакъ кызы» бар бит әле. Татар әдәбиятының йөзек кашы саналырга тиешле сокландыргыч әсәр! Автор аны 1911 елда ук тәмамласа да, фәкать 1924 елда гына бастырып чыгарган. Менә әдипнең иҗат дөньясын күзгә(?) кебек ачык итеп күрсәтердәй әсәр! Революция авторның иҗат кыйбласын үзгәрткәнме, әллә юкмы? Аның талантын чикләгәнме, иҗат сулышын кысканмы, әллә киресенчә, киңәйтеп җибәргәнме? Әсәрнең ике редакциясен чагыштырып карау бу сорауларга тәфсилле җавапны шактый тулы бирер иде. Ләкин мондый чагыштырып караудан без мәхрүм калганбыз. Башка илдә булса, бу автор кулыннан чыккан

һәр кәгазь кисәге кадерләп сакланыр иде. Ләкин татар халкының нәсел-нәсәбен генә түгел, бәлки бөтен мәдәниятен юкка чыгаруны максат итеп куючы карагруһлар аның архивын юк иткәннәр. Г. Ибраһимовның вафатыннан соң ул архив дәүләт музее ишегалдында яндырылды дигән хәбәр таралды.

Әдәби эшчәнлекләре революциягә кадәр үк башланып киткән шагыйрь һәм әдипләр М. Гафури, Ш. Камал, М. Укмасый, С. Рәмиев кебек күренекле затларыбызның иҗатын шул күзлектән чыгып тагын бер күздән кичерү дә бик мәгъкуль эш булыр иде. Партия диктатының, аның пропагандасының гомумән бөтен әдәбиятка, аерым язучы иҗатына, хәтта аның шәхси язмышына ничек тәэсир итүен һәрберебез мисалында ачык күрергә мөмкин булыр иде. Бу очракта мин үзем хөрмәт иткән күренекле әдип Ибраһим Газины мисал итеп алырга булдым.

1966 елда басылып чыккан «Сайланма әсәрләр»енең беренче китабындагы сүз башында И. Гази үзе хакында мондый юллар язган: «...Мин кечкенәдән үк ятим калып, балалар йортында үстем. Әтидән мирас булып миңа бер әйләнчек кәҗә калды. Ул кәҗә дә озакламый үлде. Әти бирә алмаганны миңа совет власте бирде. Коммунистлар партиясе бирде».

Бу сүзләрнең чын күңелдән язылуы, әдипнең шул ышанычына тугрылыклы булып калуы, шәят, беркемдә дә шик тудырмый торгандыр. Мин бу мисалны алдарак искә алынган А. Яхин фикерен инкарь итү өчен китерәм. Ягъни совет язучылары эчтән бер төрле фикердә булып та, әсәрләрендә икенче төрле фикерне куәтләмәгәннәр (икейөзле булмаганнар). Совет дәвере язучыларының социализм идеясенә чын күңелдән инанып яшәүләрен шик астына кую үзе үк мәгънәсезлек. Бөтен дөнья хезмәт ияләренең симпатиясен казанган, фашизм кебек дәһшәтле дәүләтне җиңәргә куәте житкән совет властеның яшәргә хаклы булуына ни сәбәпле язучылар гына ышанмаска тиеш булды икән?

Минем уемча, язучыларның кайберләрен искә алмаганда, күпчелек социализм идеясенә ышанып иҗат иткән. Әмма бу идея ата-анага, якыннарыңа, туган илеңә яки сөйгәнеңә булган мәхәббәт кебек үк, бөтен кешелек дөньясына хас мәңгелек мәхәббәт кебек күңел түренә, иң тирәнгә кереп житә алганмы, әллә бата-калка өстәрәк кенә айкалганмы? Ахыргы чиктә әдип һәр әсәрендә үзе булып кала алганмы? Халык мәнфәгатен онытмаганмы? Әллә кайчакларда аның каләме белән үзенең ихлас күңеле түгел, бәлки мәҗбүрият идарә иткәнме? Мәсәлән, «Катя Сорокина» татар әдәбиятына кирәк идеме? Яисә «Онытылмас еллар» романында яшь малай Хәлимнең хәер сорап йөргәндәге авыр кичерешләре белән формаль җыелышларга багышланган өлешен чагыштырып карарга мөмкин. Күренә ки, үзенә ни кадәр таләпчән булса да, әдип әсәрен партия тарихына иллюстрация рәвешендә язудан арына алмаган. Ләкин, шулай булуга карамастан, бу да бит безнең халык үткән юл! Аларны әдәбият тарихыннан төшереп калдыру дөрес булмас иде.

Хәер, укучы халык бар бит әле, замана бар. Алар ни әйтер?

Минемчә, әгәр дә И. Гази гомеренең соңгы елларында каты куллы хакимнәр ихтыярына буйсынып, житәкчелек эшенә күчәргә мәҗбүр булмаса, «Тургай картаямы икән?» кебек талантлы әсәрләрне күбрәк язарга өлгергән булыр иде.

Кызганыч, бу чорның уңышларына бөтенләй күз йомып, аңа гел тискәре караштa булучылар да юк түгел. Кайберәүләр бу чорның үзен каһәрләп, ул заманда иҗат иткән мәшһүр иҗат кешеләрен кара исемлеккә теркәү юлына бастылар. Болар арасыннан Муса Җәлил белән Хәсән Туфан өстенә ташланган мәкерле сүзләр аеруча рәнжетә. Күпме михнәт чикмәде, күпме коточкыч нужалар кичермәде халкыбызның бу батыр һәм талантлы уллары! Кайсы ил шагыйренең палач балтасы астында таш йөрәкләрне эретердәй шундый ялкынлы шигырьләр язганы бар?! Шул үзе генә дә Мусаны хөрмәтле биеклеккә күтәрмимени? Кайсы әдәбиятта бар тагын Муса Җәлилнеке кебек мондый каһарманлык үрнәге, халык мәнфәгате өчен җанын фида кылу мисалы! Алар безнең горурлыгыбыз. Болар татар халкының үзе белән киләчәккә алып бара торган иң затлы мөхтәрәм исемнәре түгелмени? Ниләр генә язмыйлар! Имештер, «Туфанның... иҗат үрнәкләре бер чакта да халкыбызның авыр язмышын ачуга хезмәт итмәделәр»,— дип раслый А. Гыйләҗев.— ...Ул күпчелек очракларда шагыйрьләр шагыйре булып кына кала килде». («Имән чикләвеге», «Шәһри Казан», 1990 ел, 15 сан) Гаҗәеп хәл! Авторның авызы ни әйткәнне колагы ишетәме икән? Тагын ни кирәк? Шагыйрьләр шагыйре булу дәрәҗәсенә күтәрелү үзе үк халыкның милли горурлыгы түгелмени?! Нигә шуны гына аңламаска, яисә аңламаганга сабышырга? «Кайсыгызның кулы җылы, бәйлисе бар йөрәкне» дигән шигырь халыкның ачы

язмышы булып аңлашылмыймыни? Яки «Киек казлар» җырын, «Агыла да болыт агыла»ны тыңлаганда ихтыярсыз тәгәрәгән кайнар күз яшьләре халкыбызның тирән фаҗигасен ачып, җаннарны тетрәтмимени? Менә шул үзе әдәбият-сәнгатьнең халык язмышын кайгырту мисалы түгелмени? Хәер, кайберәүләргә мондый нечкәлекләр аңлашылмаса да гаҗәп түгел...

Хәсән Туфанның А. Гыйләҗев каршында тагын бер «гөнаһсы» булган икән әле. Ул теге яки бу мәсьәләгә А. Гыйләҗев карашында тормыйча, бәлки үзенчә, нәкъ Туфанча фикер йөртергә батырчылык иткән икән ләбаса! Мәсәлән, А. Солженицынны А. Гыйләҗев «Чорыбызның бөек пәйгамбәре» дип, аның каршында түбәнчелек белән башын игәндә, Х. Туфан нишләгән? Ул шушы «пәйгамбәргә» кизәнергә җөрьәт иткән. Әйе, дөрес, Хәсән Туфан А. Солженицынның беренче әсәрләреннән үк аның карагруһлар сафындагы кеше икәнлеген сизеп алды. Чөнки казакъ һәм башка кайбер халыкларның гасырлар буенча яшәгән туган якларын урыс җирләре дип атаган оятсыз бәндәне башкача тагын кем дип атыйсың? Х. Туфанның бу фикерен башка милләт язучылары да раслады. Бу «пәйгамбәрнең» асылда урысны гына халыкка санаучы, милләтләр мәсьәләсендә монархистлар карашын уздыручы бәндә булуын украин, белорус, казакъ язучылары да раслап чыктылар.

Бу авторның раславынча, Һади Такташ «үзенә-үзе кул салган», «Г. Камал ачтан үлгән». Дөрес түгел! Һади Такташ тиф хастасы алып китүен бөтен Казан белән. Галиәсгар абзый персональ пенсия ала иде. Ул картаеп, үз үлеме белән вафат булды һәм хөрмәт белән күмелдә.

Мәдәни халыклар мәшһүр кешеләренең абруен күз карасыдай саклыйлар, алар белән горурланалар, алар гамәле белән үзләренең тарихларын баеталар. Бездә исә нәкъ моның киресе эшләнә. Тырнак астыннан кер эзләп, халыкның хөрмәтле улларына өстенә пычрак ыргыталар.

Минемчә, мондый урынсыз кизәнү беркемне дә бизәми. Халкыбызның тарихи шәхесләре, бернигә дә карамастан, моннан соң да үзләре яулап алган хөрмәтле дәрәҗәләрендә калырлар.

Озын сүзне кыскартып, һәммәсен бергә җыеп әйтсәк, бу чор әдәбиятына бәһа биргәндә гадел булырга, тарихилыкка хас булганча, киңрәк фикер йөртергә кирәктер. Бу эштә ашык-пошык нәтиҗә чыгару зур хаталар тудырырга мөмкин. Чөнки нинди генә булмасын, нинди генә мирас калдырмасын, яхшымы, түгелме, ул — халкыбыз үткән юл, ул — безнең тарихыбыз.

Минемчә, бу хакта профессор И. Нуруллин дөрес фикер йөртә. Әдәби әсәрләргә ничек бәя бирергә? «Әсәрнең сәнгать дәрәҗәсен, авторның талант дәрәҗәсен төп үлчәү итеп алып. ...Ничек булганынча. Арттырмыйча һәм киметмичә. Каралтмыйча һәм кызартмыйча».

Күрәсең, тормышыбыздагы мәгълүм бер чорның чиге була торгандыр инде бу. Моңарчы иҗат хөрлеген буып торган төрле киртәләр, ниһаять, җимерелде. Һәрбер каләм иясе намусы белән ялгыз гына калды. Безне нинди киләчәк көтә? Һәркайсыбызның күз алдында, ул шәрә урында оештырылмас. Башыбыздан узганнардан сабак алып, акылга утырырга бик вакыттыр инде. Шәт иншалла, төрле ягы искә алыныр дип уйлыйк. Бигрәк тә бүгенге көннәр. Тарихыбызның иң кискен, иң җаваплы чорына аяк басуыбызны аеруча басым ясап әйтәсем килә. Һәркайсыбызга билгеле, халкыбыз мең елларга сузылган тарихында ифрат та авыр вакыйгалар кичергән. Әмма шулар арасында мөстәкыйльлек өчен кузгалган бүгенге көрәш иң әһәмиятлесе, иң җитдие, халыкның киләчәген хәл итә торганы. Дәүләтчелеккә хакыбыз барын раслый алабызмы? Милләт буларак үзебезне саклап калабызмы? Әллә безне моңарчы гасырлар буенча кимсетеп, изеп килгән коллык хурлыгы сагалап торамы?

Халкыбызның үз дәүләтчелеген яңадан аякка бастырып, үз байлыгына үзе хуҗа булып яши башларга мең мәртәбә хакы бар!

Яңа чорның хөр әдәбияты изге максат өчен башланган шушы көрәшләрнең алгы сафында булсын, халыкның байрак йөртүчесе булсын иде.

*1992 ел*

## Уртак байлыгыбыз

— Шәһре Казан утларын без ерактан гына, ә хәзер инде, язмыш уены аркасында, бөтенләй чит мәмләкәттән торып кына күрсәк тә, алар һаман элеккедәй күзләребездә чагылып, күңелләребезне җылыта. Дөнья ничәгә бүленсә дә, замана җилләре белән төрле илләргә таралган татар балаларының рухы шушы изге утларга карап талпына. Без шул утларның еракларга барып җиткән бер генә нуры була алсак икән, дигән өмет белән яшибез. Безнең рухиятебез шул утларда берләшеп, зур көчкә әйләнә кебек. Бу утлар безнең кабынган күңелләребез түгел микән?

Мин, «Казан утлары» безнең өчен журнал гына түгел, дигән фикерне аңлатмакчы булам. Татар халкының фаҗигале тарихын, таланган матди һәм рухи байлыкларын даулап, яктыртып, калган кадәресен бу авыр көннәрдән киләчәккә илтүче, аның чиксез тирән милли рухын терелтеп, уятып, лаеклы дәрәҗәдә олылаучы энергияне шул утлардан да көтәбез. Безнең заман югалтулардан гына тормый, милли дәртне дә, кешелек горурлыгыбызны да уятты ул. Моңа хисап бирмәсәк, үзебез гаепле булырбыз, газиз милләттәшләр.

Татарның рухи байлыгы — аның үз байлыгы гына түгел. Аның киләчәктәге бәйсезлеге дә үз байлыгы гына булмас. Чөнки, нәкъ утлар кебек, бу байлыклар өчен дә чикләр юк, без Шәрекътә моны бик яхшы беләбез. Әдәби-мәдәни бәйләнышларыбызны дәүләт чикләре өзә алмас.

Шул уңайдан, «Казан утлары»ның хәерле күп эшләрен хуплаган хәлдә, бер теләгемне дә әйтим әле. Теле, дине бер булган төрки халыкларны бер-берсеннән аерган чик тә бар. Хәзерге язуыбыз ул. Бу язу безне сукырайтты. Аны бердәй рәвешкә китермәсәк, без бер-беребезне таба алмабыз. Бу мәсьәлә хәзер җир белән күк арасында асылынып тора. «Казан утлары» шуны истә тотып, үз сәхифәләрендә барлык төрки җөмһүриятләрнең телче галимнәре, әдәбиятчылары көче белән бер бәхәс ачса, файдалы күп фикер җыелыр һәм дә, бәлки, журнал йогынтысыннан файдаланып, бу мөшкеллекне чишә алырбыз.

Шиксез ки, әлифбаларыбызны бер рәвешкә китерү, унификацияләү төрки җөмһүриятләрдә матбугатыбызның мөштәриләре, укучылары күбәйсен өчен генә түгел, рухи берлегебезне киңәйтер өчен дә бик кирәк. Бу бәйсезлекне ныгыту юлында да бер адым булыр иде. Төрки журналларның күбесендә бу мәсьәлә чагылгалый. Әмма бу хакта махсус фикер үткәрелсә, әдәби басмаларның иҗади элемтәләре дә ныгыр иде.

Тагын да яктырак янсын утлар — «Казан утлары»!

**Әсгать МОХТАР,**
Үзбәкстанның халык язучысы,
Хәмзә исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

* * *

«Казан утлары» — замананың иң авыр, иң катлаулы чорларында да кулыбызга килеп җитә алган бердәнбер милли басма иде. Милли әдәбиятыбызның, мәдәниятебезнең хәлен, милли рухыбызның халәтен без шушы журнал аша белеп яшәдек. Инде хөр мәмләкәт, азат Татарстан шартларында тавышыгыз тагын да көчәер, тарихның халыктан яшереп сакланган караңгы сәхифәләрен дә гаделл һәм дөрес күрсәтә белерсез дип өмет итәбез. Олуг бәйрәм белән котлыйбыз!

Изге эшегездә уңышлар һәм бәхет теләп — **Фәридә ХӘМИТ, Фәрит ИДЕЛЛЕ, Хәйретдин САДЫЙК, Ирек КАЗАНЛЫ, Нури БУЛАТ, Галия ШӘРӘФИ, ИЛЧӘН, Тәклимә БАРИ.**

Алмания.

# Әмирхан Еники

# ЧОРЛАР АША



Минем «Озын көй тыңлаганда» дигән кечкенә бер әдәби парчам «Безнең юл» журналының 1926 елгы 3 нче санында басылып чыккан иде. Моннан 66 ел элек. Димәк, быел 70 еллыгын бәйрәм итүче «Казан утлары» белән — ә ул «Безнең юл»ның дәвамы — минем бәйләнеш әнә шул заманнардан бирле килә икән... Тик дөресен әйтергә кирәк, «Безнең юл»да мин бик аз басылып калдым. Нәрсә турында, ничек итеп язу мәсьәләсен мин әле үзем өчен ачыклый алмыйча, эзләнеп азапланган чагым иде. Әдәбият дөньясында коммунистларның идеология басымы шактый нык сизелә башлаган иде инде. Шулай да егерменче елларның башларындарак Фатих Әмирхан, Садри Җәләл, Гали Рәхим, Җамал Вәлиди кебек искедән килгән язучыларга да (аларны «попутчиклар» дип йөртәләр иде), революция дулкыннары белән калкып чыккан, төрле «изм»нарга иярүче яшь каләм ияләренә дә мәйдан ачык иде. Әмма бу хөрлек озакка бармады, тиз бетерелде. «Попутчиклар»ның күбесен әдәбияттан гына түгел, тормыштан да сөрделәр.

Егерменче елларның ахырында инде «социализм өчен бөек көрәш чоры» башланды. Журналның исеме дә «Безнең юл»дан «Атака»га әйләнде. Ләкин мин бу вакытны «бөек кыйнау» чоры дип атар идем. Махсус һәм чамасыз көчәйтелгән «көрәш» Сталин тарафыннан халыкларны алдап һәм көчләп буйсындыру өчен чыгарылган бер сылтау гына иде.

Бу кыйнау яки кыйналудан берәү дә читтә калмады. Газета-журналларда бик әшәкә яла ягулар, гаеп тагулар, фаш итүләр башланды. Әле кайчан гына бергә аралашып йөргән язучылар да теге яки бу каләмдәшен милләтчелектә, оппортунизмда, сыйнфый уяулыгын югалтуда гаепләп зур-зур мәкаләләр белән чыктылар. Һәркем шик астында, күзәтү астында. Дошми калу үзе дә куркыныч була башлаган иде.

Менә мин дә, үсмер чагымнан ук «Ленин бабай юлына» чын ихластан ышанырга тырышкан, мөгәр чыгышым белән «чит элемент»тан саналган яшь кенә бер «каләм тибрәтүче» идем. Чит булуның җәфасын миңа инде татырга да туры килгән иде (укуны ташларга мәҗбүр иттеләр). Ихтимал, шуңа күрәдер, ә дөресрәге, хәзер купкан «бөек көрәшнең» хаклыгына ышанмаудан, минем күмәкләшеп кыйнау кампаниясенә һич тә катнашасым килмәде. Киресенчә, бөтен күңелем белән мин кыйналучылар ягында идем. Адәм балаларына нинди зур фаҗига килгәнен күрмәмешкә салыну мөмкин түгел иде. Әмма ничек тә итеп бу фаҗигадан сакланып калырга? Хәзерге шартларда моның өчен бер генә юл — әдәбияттан китеп тору кирәк иде. Мин әле әдәбиятка сыңар аягым белән генә басарга өлгергән идем. Чын язучы булып танылганым да юк әле, шуңа күрә читенү минем өчен бер дә читен булмады. Вакытлычамы әллә бөтенләйгәме мин язучы булудан туктадым.

Әдәбияттан китеп торуым кимендә бер ун елга сузылгандыр. Бу утыз белән кырыгынчы еллар арасы, һәм бу еллар арасында кешеләрнең нинди коточкыч югалтуларга, рухи имгәнүләргә дучар ителгәнен сөйләп торасы да юк. Бары җиһан сугышы башланып, фронтка эләккәч кенә мин яңадан кулыма каләм алдым. Фронттан җибәргәләгән хикәяләрем «Совет әдәбияты»нда (журналның «Атака»дан соңгы исеме) ничектер ансат кына басылып та чыкты. Авыр сугыш әдәбиятка карата идеология тезгенен бераз бушатырга мәҗбүр иткән булса кирәк, шуңа күрәдер инде һәр язучының, элек кем булуына карамастан, патриотик рухтагы әйберләренә урынны кызганмыйча бирәләр иде. Моның бик ачык мисалы — мәрхүм Фатих Кәрим иҗаты. Төрмәдән фронтка озатылган шагыйрьнең һәр язганы матбугатта чыга торды.

Дәрья кан, дәрья күз яше агызган сугыш бетте. Фашизм җиңелде. Бичара халыкның шатлыгы чиксез иде. Аяк-кулсызлар һәм исән калганнар өйләренә кайта башладылар. Шул исәптән — без язучылар да. Күпме өмет, күпме хыял иде бездә...

Дөрес, тормыш әле бик авыр иде. Авыл халкы ачтан интегә, шәһәр халкы карточкага тигән белән генә туена, өс-баш та өзгәләнеп беткән. Әмма шатлык зур, шул яшәтә, шул түзәргә ярдәм итә. Мондый шартларда партиянең бөтен кайгысы халык тормышын җиңеләйтү, халыкка күпмедер ирек бирү булырга тиеш иде. Асылда бит большевизмны фашизмнан шушы чыдам, күндәм халык коткарып калды. Партия үзен бит «ум, честь, совесть народа» дип лаф орырга ярата. Битсезлек бу... Партия җитәкчелегендә бервакытта да оят, намус дигән нәрсә булмады — бөтен эше һәртөрле ирекне буудан, кысу-тыюдан, куркыту-янаудан гыйбарәт булды.

Сугыш бетүгә бер-ике ел да үтмәгәндер, Сталинның күптән көйләнгән, тик сугыш вакытында гына бераз тынып торган репрессия тегермәне яңадан ходка җибәрелде. Репрессияләрнең нәрсә икәнен яхшы беләбез, онытасыбыз юк, шомлы дәһшәте хәзер дә әле йөрәкләрдә саклана. Әмма минем бу очракта репрессияләр алдыннан ниләр булганын искә төшерәсем килә. Бусы — бөтен җәмгыятькә, бигрәк тә аның иҗади көчләренә күбрәк кагыла. Моңарчы да зур репрессияләр башланыр алдыннан гадәттә берәр төрле идеология шаукымы куптарып, башта халыкның аңын томалыйлар, котын ала торганнар иде. Бу очракта да партия җитәкчелеге үзенең «чистарту эшен» нәкъ шуңардан башлады. Әдәбият мәсьәләләре турында Ждановның гел янаудан торган докладлы, Анна Ахматова, Зощенколарны бөтен ил алдында каһәрләү, «Звезда» һәм «Ленинград» журналларын хөкем итеп чыгарылган карарлар — башланачак репрессияләргә идеологик нигез әнә шулай салынган иде. Моннан соң кемне ни өчен утырту — бусы инде органнар эше. Әйткәнемчә, көчле идеология басымы ул барлык халыкларга да кагыла, ә сәнгать, әдәбият әһелләренә иң беренче нәүбәттә. Сугыш вакытында әзрәк бушый төшкән тезгеннең яңадан каты тартылганын без — язучылар бик тиз сиздек. Гәзитә-журнал һәм нәшрият редакторларына идея-политик таләпләр бик нык артты, электән үк «уяулык» күрсәтергә ратучы Главлитның әдәби әсәрләргә бәйләнүе аеруча көчәйде. Бигрәк тә аерым язучыларга карата саклык күрсәтүне ачык сизәргә мөмкин иде. Мин моны үз җилкәмдә дә бик тиз татыдым. Кырык алтынчы елда чыгып яткан кечкенә китабымнан «Ялгыз каз» хикәясен үземә әйтмичә генә алып ташладылар. Әле кайчан гына журналда берсүзсез басылган хикәядән нинди куркыныч гаеп тапканнардыр — миңа аңлатып та тормадылар. Ярамый, вәссәлам!

Һәм иң гаҗәбе, сугыш вакытында язганнарымны җиңел генә чыгарып барган «Совет әдәбияты»на үземчә шактый көчле язылган «Тауларга карап» хикәясен үткәрә алмадым. Бу хикәядән микроскоп аша карап та идеология таләбенә сыймаслык гаеп табу мөмкин түгел иде. Димәк, әсәрдән бигрәк, минем үземне үткәрергә теләмиләр — башкача ничек аңларга?!

Главлитның идеология сагында торучы нинди усал вахтер икәнлеген күптән белә идек. Әле «Безнең юл» заманында ук аның турында анекдотка охшашлы бер вакыйганы көлеп сөйлиләр иде. Ул елларда Главлит башында Хөсни Кәрим дигән бер мөхтәрәм абзый утыра иде. Ул үзе дә язгалый торган кеше иде. Менә бер хикәясен ул журналга биргән булган. Әлбәттә, бернинди шик-шөбһәсез үткәргәннәр: басылып чыгар алдыннан журналны Хөсни абзыйның өстәленә илтеп салганнар. Журналның эчтәлеге белән танышып чыккач, Хөсни абзый редакторга менә бу хикәяне алып ташлагыз дигән. Редактор — ул чакта Гомәр Гали — бик аптырап: «Хөсни абзый, ул бит сезнең үз хикәягез!» — дип әйткән инде. «Булса соң! — дигән Хөсни абзый, бер дә исе китмичә генә. — Ә Главлит буларак, мин аны үткәрә алмыйм. Төшерегез!»

Мәгәр Главлит эшендә моның ише көлкесеннән бигрәк, язучыны гаҗиз иткән аянычлысы ешрак була торган иде. Хәер, минем үземә Главлит белән якыннан эш итәргә аз туры килде. Аның белән әсәрне басып чыгаручылар күбрәк җәфаланалар иде. Журнал редакциясендә утыручы егетләр әсәрне басарга әзерләгәндә еш кына «Әмирхан абый, менә бу җирен сызарга кирәк, Главлит барыбер үткәрмәячәк» дип әйтә торганнар иде. Киреләнеп, сыкранып булса да, мин алар таләбенә буйсынып, барыбер йә сызарга, йә үзгәртебрәк язарга мәҗбүр була торган идем.

Шулай да бер тапкыр минем үземә дә Главлит белән эш итәргә туры килде. Редакция яратып кабул иткән «Җиз кыңгырау» хикәясен Главлит җитәкчесе Д. Шакирҗанова чыгарырга рөхсәт итмичә тоткарлап маташа икән. Тоткарлауның сәбәбе җитди булса кирәк, егетләр минем үземә аның белән кереп сөйләшергә куштылар. Мөхтәрәмә ханым янына рөхсәт сорап кердем, кара-

каршы утырып, бик әдәпле генә сөйләштек. Хикәяне тоткарлауның сәбәбен ханым миңа болай аңлатты: — Сезнең хикәядәге иске авыл колхоз авылына караганда матуррак та, туграк та булып чыккан. Бу җитди политик кимчелек түгелмени, Әмирхан иптәш? Сез шундый итеп язгансыз, укучы да ирексездән иске авылны сагына башлаячак.

Йә, моңа каршы нәрсә дип әйтергә?.. Минем өчен укучының «сагына башлавы» бик әйбәт инде ул. Моның өчен бәлки рәхмәт тә әйтергә ярый торгандыр, ләкин бу очракта мин кем алдында утыруымны онытмаска тиеш идем. Ә ханымны, баксаң, хикәянең нәкъ менә укучыга тәэсире борчый икән. Димәк, аны шушы җәһәттән ничектер тынычландырырга кирәк. Һәм мин аңа әйбәтләп кенә болай дидем: — Үзегез күргәнчә, хикәядә үсмер малайның кичерешләре аша авыл туе тасвир ителә, моның политик зарары булмаска тиештер, шәт! Инде «иске» авыл белән «яңа» авылга килгәндә, ул елларда колхозлар юк иде әле, шуңа күрә укучы башына аларны чагыштырып карау килмәс дип ышанам. Авылларыбыз һаман да шул ук авыллар ич!

Главлитның позициясе башта ук йомшак иде, югарыдан шелтә булмагае дип кенә карышкандыр, ахрысы, һәрхәлдә шушы сөйләшүдән соң, Шакирҗанова хикәяне чыгарырга үзенең «фатихасын» бирде.

Дөресен генә әйткәндә, минем бер әсәрем дә җиңел һәм шома гына үтеп китә алмый иде. Хрущев заманында җылы җилләр исә башласа да, озакка бармады, яңадан салкыннар кире әйләнеп кайтты. Мәсәлән, шул елларда миңа «Рәшә»не чыгара алмыйча бик җәфаланырга туры килде. Мәскәүдә башланган «салкыннар» безгә икеләтә катырак булып кайта иде.

Әмма, нилләр генә кичерергә туры килмәсен, минем «Казан утлары»на хөрмәтем һәм рәхмәтем бик зур. Барлык повестьларым, хикәяләремнең бик күбесе аның битләрендә басылып чыкты. Иҗат гомеремне мин аңардан аерым карый алмыйм, сөенечләрем дә, көенечләрем дә күбрәк аның белән бәйләнгән... Хәер, шушы ук сүзләрне безнең һәрбер әдип һәм шагыйребез әйтә алыр иде. Һәркайсыбыз аның аша әдәбиятка кердек, үстек, танылдык. Шуңа күрә дә ул әдәбиятыбызның зур бер ачык көзгесе булып танылды: барысы да — көчлесе дә, зәгыйфе дә — аңарда үзенең чагылышын күрде.

Без инде журналыбызның нинди идеология басымы астында эшләп килүен әйткән идек. Ләкин, шуңа да карамастан, монда тагын бер кызыклы фактны күзәтергә була: һәрбер чын язучы, әгәр ул тумыштан ук конъюнктурщик булмаса, һәрвакытта дөреслеккә омтыла, чөнки аның чын тормышны үзе күргәнчә чагылдырасы килә. Ә тормыш дигәнең гаять киң колачлы, бик катлаулы күренеш, аны һич кенә дә бер идеология кысаларына сыйдырып бетерү мөмкин түгел... һәм безнең журнал битләрендә идеология таләпләренә көчләп тә сыйдырып булмый торган кыю әсәрләр дә ара-тирә чыккалый иде. Мисал өчен Әхсән Баянның «Яшьлегемне эзлим», Нурихан Фәттахның «Артта калган юллар» һәм Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»ен искә төшерү дә җитсә кирәк.

Билгеле инде, бу — журналны доньяга чыгаручыларның да зур тәвәккәллеге иде. Аларның күбесе үзләре дә турыдан-туры әдәбият белән шөгыльләнүчеләр буларак, әдәби иҗатның нәрсә икәнен яхшы аңлаганнар. Мин моны сугыштан соңгы елларда редакторлык вазифаларын үтәгән Гази Кашшаф, Газиз Мөхәммәтшин, Рафаэль Мостафин, шулай ук күп әсәрләрне кулларыннан үткәргән Фәрваз Миңнуллин, Яхъя Халитлар турында әйтә алам. Менә шулар, югарыдан каты шелтә алачакларын белеп торсалар да,безнең «гөнаһлы» әсәрләребезгә алдан шауламыйча гына мәйдан бирделәр. Ни өчен? Тыеп торучы түрәләр киләләр дә китәләр, ә матур әдәбият кала, ул бездән соң да яшәргә тиеш!

Соңгы елларда журналга Ренат Харис, Равил Фәйзуллин кебек яшь, энергияле шәхесләрнең мөхәррирлек итүе, редакция составында озак еллардан бирле Рәшит Әхмәтҗанов, Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Тәүфикъ Әйди, Кояш Тимбикова, Рашат Низамиев кебек гомерләрен әдәбиятка багышлаган кешеләрнең бирелеп эшләүләре нәтиҗәсендә «Казан утлары»ның дәрәҗәсе һәм абруе тагы да үсә төште.

Билгеле, хәзерге гаять тирән үзгәрешләр чорында журналның эшләү шартлары да бик нык үзгәрде. Күк капусы ачылгандай, аңа котелмәгән хөрлек һәм иркенлек килде. Әмма моңа карап журналыбызның халык һәм заман алдында җаваплылыгы, миңа калса, һич тә кимемәде. Киресенчә үсте генә... Хәзер инде ул милләтебезнең, милли мәдәниятебезнең һәм әдәбиятыбызның киләчәк язмышы өчен бары үзе генә җаваплы. Әмма бу үтә катлаулы заманыбызда да «Казан утлары» кыйбласын дөрес сайлар, юлын туры билгеләр дип ихлас күңелдән ышанасым килә.

Нажар Нәҗми

# ӘДӘБИЯТ ИЛЧЕСЕ



«Казан утлары» журналы «Идел» чыкканга кадәр татарча язылган матур әдәбиятны чагылдырган, аның яңалыкларын күрсәткән, бик тапталган сүз белән әйткәндә, аның бердәнбер көзгесе иде. Бездән, Башкорстаннан торып караганда аны татар әдәбиятының илчесе, дип тә атарга мөмкин. «Казан утлары»н Башкортстанда укучылар саны (заманында рәсми тыюлар аркасында журналны алдыручылар саны бик нык кимегән булса да) хәзер ел саен арта бара. Бу очракта саннарга мөрәҗәгать итми мөмкин түгелдер. Мәсәлән, журнал бездә, Башкортстанда, 1991 елда 7884 данә таралган булса (бу мәгълүмат журналда чыккан иде инде), 1992 елда аның саны 8901 гә житте, ә киләсе елларда аның арта барачагы көн кебек ачык. Ни өчен шулай? Нинди сәбәп? Беренчедән, әлбәттә, журналда басылган әсәрләрнең сыйфаты сәбәпле булса, икенче сәбәп — халык күнеленең, милли тойгының нык уяна башлануы, милли зәвыкның үсә баруы. Бу үсештә турыдан-туры журналга кагылмаса да, Башкортстандагы Татар иҗтимагый үзәгенең һәм «Кызыл таң» газетасының эшчәнлекләре эзсез түгел, дип әйтер идем.

Шушы уңай белән, кызык өчен генә булса да, татар әдәбиятына байтак язучылар биргән районнарыбызда журналның ничек таралуын әйтеп китмәкчемен. Мәсәлән, Дүртөйле районында 1992 елда 440 данә (1991 елда 385), Илеш районында 500 данә (1991 елда 458), Кушнаренко районында 263 данә (1991 елда 232), Яңавыл районында 188 данә (1991 елда 239). Яңавыл татар әдәбиятына Нил һәм Илдар Юзеевларны биргән район, әмма быел аларның якташлары «саранланганнар» шикелле. Ә менә Бүздәк районы барсыннан да уздырып җибәргән — анда журнал 529 данә таралган. Шунысы кызык, узган елда бер данә дә алдырмаган Архангель районы быел килеп ун данә журнал алдыра.

Миңа килгәндә, «Казан утлары» журналын, «Агыйдел» журналы шикелле үк, туган журналым итеп тоям. «Казан утлары»нда кайчан басыла башлаганымны хәтерләмим, әмма мәрхүм, зур шагыйрь Нури Арсланның (ул вакытта журналның шигърият бүлеген алып бара иде) «Татар теле» шигырен соратып алганлыгы истән чыкмый. Уфага телефон аша шалтыратып минем Мәскәү янындагы иҗат йортында икәнлегемне белеп, шунда язуы онытырлык түгел. Шуннан соң ул вакыты-вакыты белән шигырьләр җибәрүне сорап, хатлар язды. Мондый сыйфат һәр кешедә дә булмый һәм мондый мөнәсәбәт һәрбер авторга тәтеми.

Нури Арслан журналдан киткәч, шигырьләр җибәрүне сорап хат язучылар булмаса да (бәлки соңыннан үз авторлары итеп тә исәпләгәннәрдер), шигырьләремне журналга тәкъдим итә бардым, шуларның берсе дә кире кагылмады.

Гомеремдә «Казан утлары» белән иҗади бәйләнешемнең иң зур вакыйгасы итеп, журналда «Иблис» поэмасының чыгуын санар идем.

Тыйнаксызлык саналмаса, ул поэманы иҗатымдагы иң әһәмиятле әсәрем, дип исәплим. «Казан утлары»нда чыккач, поэма өстендә эшләүне дәвам итеп, аерым бүлекләр яздым, әле һаман да камилләштерәсе урыннары бар шикелле, әмма язылу аралары озыная бара: торгынлык чорларында бер көрешкән чагында Мансур Вәлиев: «Иблис» поэмасына җентекле, ачыктан-ачык анализ ясап булса икән...» дип әйтеп куйса да, еллар үткәч, Гәрәй Рәхим, китабыма язган баш сүзендә поэма хакында, кыска гына булса да, үз фикерен әйтте.

Мансур Вәлиев әрнүендә хаклык бар иде — поэма өстеннән Мәскәүгә, Үзәк Комитетка, Уфадан,召 пединститут студентлары һәм укучылар исеменнән аноним хат язып, авторны һәм журналны җавапка тарттырырга теләүчеләр дә булмады түгел. Ул иптәшнең кем икәнен белдем, минем белән һаман дус булып йөри.

Уфада яшәгән күп кенә каләмдәшләремнең «Казан утлары»ын алдырмаулары мине бик аптырата, ә чит журналда басылган әсәрен үрнәгендә иҗади осталыкка өйрәнү белән бергә (аңа урыс әдәбияты аша да өйрәнеп була, әлбәттә), туган тел нечкәлекләрен тоя-тоя сабак алу да зур бәхет бит!

«Казан утлары» журналы «Казан» дип кенә, утсыз гына аталган хәлдә дә аның уты, җылысы, яктылыгы ерак-еракларга барып җитәр иде. «Казан утлары» чын-чыннан милли ут, милли аһәң, милли горурлык!

*Уфа.*

---

*Безне котлыйлар*

## Сезнең бәйрәм — безнең бәйрәм

Кадерле татар туганнар!

Егерменче гасырның башларында шанлы вә шөһрәтле Казан чуваш әдәбияты һәм сәнгатенең бишеге булды. Чуваш телендәге беренче китаплар шунда басылды, беренче чуваш театрлары шунда оештырылды. Егерменче-утызынчы-кырыгынчы елларда Ф. Бурнаш, З. Бәшири, М. Җәлил, Х. Туфан, Г. Кутуй, К. Нәҗми, Н. Баян, Г. Минский, Ш. Мөдәррис тәрҗемәләрендә «Казан утлары»нда («Безнең юл», «Совет әдәбияты»), К. Иванов, Н. Шелеби, С. Эльгер, Н. Васянка, П. Осипов, И. Максимов-Кошкинский, П. Хузангай, Я. Ухсай, В. Краснов-Асли, В. Митта, А. Калган, И. Тукташ, Н. Шубоссинни әсәрләре дөнья күрделәр. Егерме өч яшендә фаҗигале үлем белән үлгән чуваш шигъриятенең чәчәге Михаил Сеспельнең шигырьләре К. Латыйп тарафыннан тәрҗемә ителеп, «Казан утлары» битләрендә басылды. Без ут күршеләрегез өчен татар халкының сөекле журналына беркайчан да сукмак өзелмәде. Без — әдипләр моның белән горурланабыз һәм чын күңелләрдән Сезгә олы рәхмәтләребезне әйтәбез. Киләчәктә дә бер-берләребезне сөендереп яшәрбез дигән теләктә калабыз.

Сезнең бәйрәм — безнең бәйрәм. Уртак бәйрәм белән, кадерле каләмдәшләр!

Чуваш язучылары исеменнән:

**Г. КРАСНОВ,** Чувашия Язучылар Союзы рәисе, **Ю. СЕМЕНДЕР,** «Ялав» журналының баш мөхәррире, **Х. АГИВЕР,** «Тыван Атыл» журналының баш мөхәррире, **А. АРТЕМЬЕВ, Л. ТАЛЛЕРОВ, Н. ТЕРЕНТЬЕВ, Х. УЯР,** чуваш халык язучылары, **В. ДАВЫДОВ-АНАТРИ,** чуваш халык шагыйре.

*Чабаксар шәһәре.*

**Гариф Ахунов**

# ӘДӘБИ МӘККӘБЕЗ ЯШӘСЕН!



Татар әдипләренең кыйбласы, Мәккәсе булган «Казан утлары» журналына җитмеш яшь тулды. Ул — элек СССР дип аталган илдә нәшер ителә башлаган журналлар арасында иң беренче сафта тора. Россиянең дә, башка республикаларның да журналлары арасында «Казан утлары» белән ярыша ала торган ике генә басма бар. Аларның берсе — «Октябрь», икенчесе — «Сибирские огни».

«Казан утлары»н мин унике яшемнән укый башладым, инде менә илле биш ел буена кулымнан төшермим. Беренче мәртәбә мин аны Көтек авылында әдәбият яратучы бер абзыйдан алып укыган идем, шунда ук мин аңа таң калдым. Үсмер чагымда, кайчан да булса мин анда әсәрләремне бастырырмын, аннан да бигрәк, ун ел буена шушы журнал редакциясендә эшләрмен, әдәби хезмәткәрдән алып баш мөхәррир дәрәҗәсенә хәтле күтәрелермен, дип башыма да китерми идем. Язмыш исә, рәхмәт яугыры, бу бәхетне һәм гаять зур җаваплылыкны насыйп итте.

Шунлыктандыр, «Казан утлары»ның яшәве, эчтәлегенең елдан-ел баюы, татар әдәбиятының күпчелек очракта иң яхшы үрнәкләрен дөньяга чыгарып халыкның рухын күтәрүе, эстетик зәвыгын тәрбияләве мине чиксез шатландыра.

Әйе, шатландыра һәм... соңгы вакытта куркуга салган хәл дә бар. Нигә? Ни өчен куркуга төшәм? Без бик авыр, бик болгавыр заманда яшибез. Гәзитләрдә һәм радио-телевидениедә көннән-көн куркынычрак хәбәрләр, йөрәккә шом сала, җанны өшетә торган хәбәрләр әйтеп торалар. Икмәккә бәя күтәрелүгә дә, кием-салым кыйммәтләнүгә дә — әгәр алар вакытлыча булса — түзәргә мөмкин әле. Ә менә кәгазь бәһасе күккә сикерүдә, алай гына да түгел, кәгазь кытлыгы килүгә түзәргә мөмкин түгел. Кәгазь кытлыгы — котылгысыз рәвештә! — гәзит-журналларның ябылуына китерәчәк. Беренче чиратта — Рәсәйнең элекке колонияләрендә, ягъни бездә.

Бу инде милли аңны, милли рухны сытуга бәрабәр! Рәсәй «демократ»ларыннан бүген барысын да көтәргә була. Элекке автономияләргә бәйсезлек бирмәс өчен, аларның мәдәниятен үстермәс өчен, «демократ»ларның кыланмышлары чиктән ашты.

«Казан утлары»ның җитмеш еллыгына карата уй-фикерләремне яза башлаган көнне мин Александр Сергеевич Пушкинның һәлакәтен күрсәтүгә бәйле нәфис фильм карадым. Патша чиновникларының бөек Пушкинга булган мөнәсәбәтләреннән, аны куралмауларыннан тәннәр чымырдады.

«Әдәби талант — ул хакимлек, ул власть», — ди Пушкинның якын дусты шагыйрь Василий Андреевич Жуковский.

Моны ул бөек шагыйрь белән сәубуллашырга килгән «кара халык»ны Пушкин яшәгән йорт яныннан куып җибәрергә кушкан баринга әйтә.

«Әдәби талант — власть». Ә властьны безгә, әдипләргә, бирергә теләүче бармы? Үз теләкләре белән әдипләргә властьны кем бирсен?!

«Безнең юл» журналын ачкан чакта Галимҗан Ибраһимов аның озын гомерле булуын, татар әдәбиятының көзгесе булуын теләгән. Аңардан соң инде ничәмә буын мөхәррир безнең бу рушан көзгебезне тутыктырмас өчен күпме көч сарыф иткән!

Җитмеш елда «Казан утлары»ның 835 саны басылды, ул хәтта Бөек Ватан сугышы елларында да чыгудан туктамады. 835 сан — җитмеш елда татар халкының мәдәни үсеш тарихын чагылдырган 835 том. 15 меңнән артык әсәр. Алар арасында — 300 повесть һәм роман, меңләгән хикәя һәм шигырь, тәнкыйть мәкаләләре, культурабыз үсешенә бәйләнешле проблемалы хезмәтләр, халыкның йөрәк тибешен чагылдырган сәнгатьчә очерклар һәм кайнар публицистика!

Кинәт, көтмәгәндә, журналыбыз чыгудан туктаса? Кәгазь кытлыгын сылтау итеп! Моңа юл куярга ярамый! Без Татарстан хөкүмәтенең капкасын гел кагып, әдәби Мәккәбезгә куркыныч янаганын аның исенә төшереп торырга тиешбез.

Югыйсә бит әнә Татарстан китап нәшрияты ябылу алдында. Кәгазь булмау аркасында, быел 170 китапның, инде типографиягә бирелгән китапларның басылмавы мәгълүм булды.

Татарстан Министрлар кабинетының «Казан утлары» журналын үз канаты астына алуы күңелдә өметләр уята. Хөкүмәтнең журналны оештыручылардан берсе булуы — журналның туктамаячагына гарантия.

Ә без, Татарстан язучылары һәм башка өлкәләрдән күтәрелә торган әдипләр, журналны сәнгатьнең югары законнарына таянып иҗат ителгән әсәрләребез белән югары кимәлдә тотарга, аңа һәр яктан булышырга сүз бирсәк икән.

Теләгебез бер генә — котлы булсын «Казан утлары»ның бәйрәме! Бу бәйрәм кадерле журналыбызга озын гомер алып килсен! Амин.

---

## *Безне котлыйлар*

### Хөрмәтле «КАЗАН УТЛАРЫ»

Милләтебезнең артык озын булмаган вакытлы матбугаты тарихында сезнең җитмеш ел буе өзлексез мәгърифәт нуры чәчеп торуыгыз, һичшиксез, милли мәдәниятебезгә гаять зур хезмәт.

Ирекле, демократик бер илдә журналларның йөз елдан артык яшәве гадәти бер хәл. Ләкин «Казан утлары» чагыштыргысыз дәрәҗәдә кыен, хәтта, дәүләт терроры, деспотизм шартларында, халкыбызның һәм, бигрәк тә, зыялыларының өлешчә юк ителүе шартларында чыгуын дәвам итте. Сталинчылык үзәрлекләвен башыннан кичермәгән бәхетле җәмгыять кешеләре моның ни дәрәҗәдә авыр булганлыгын аңлый алмаслар. Әмма мин социаль-мәдәни тетрәнүләр фаҗигасен башыннан кичергәндә дә бирешмәгән, сау-сәламәт яшәргә тырышкан һәм шактый дәрәҗәдә шуңа ирешкән журналыбызның эшчәнлеген зур каһарманлык, могҗиза саныйм.

Милләтебез уяну, яңадан терелү дәверенә кергән шушы көннәрдә «Казан утлары»на уңыш тулы озын гомерләр телим. Редакция хезмәткәрләре, редколлегия әгъзалары, шатлыгыбыз һәм горурлыгыбыз булган басманың барлык авторлары рухи тормышыбызны киләчәктә тагын да ялкынлырак дөрләтсен, милли бердәмлегебезне ныгытуга лаеклы өлеш кертсен иде. Чөнки татар халкы бу эшне аеруча бер өмет белән укымышлыларыннан көтә. Чит илләрдәге милләттәшләребез өчен сез иң караңгы заманнарда да ватаныбыз һәм милли мәркәзебез символы, иманыбызны саклый торган юаныч булдыгыз һәм шулай булып каласыз.

Матур эшләрегездә Алла ярдәмчегез булсын!

**Гали АКЫШ,**
Бөтендөнья татар лигасы рәисе.
Мюнхен, Алмания.

* * *

Без — Төркиядә көн күрүче кардәшләрегез — туганлык җылысын, газиз телебезнең төмен һәм аһәнен «Казан утлары» аша тоеп яшибез. Иншаллаһ, киләчәктә дә шулай булыр. Күптин-күп, чуктин-чук сәламнәр юллап, илләребез арасында туганлык элемтәләренең һаман үсәсенә өмет итеп, **ФӘРИТ, РӘШИДӘ, РУШАН, ЙОЛДЫЗ БИЧУРИЛАР.**

Төркия.

**Мөсәгыйт Хәбибуллин**

# БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ...



Кулыма каләм ала башлагач та мин үз халкымның тарихы белән кызыксына башладым. Кул астымда булган урыс язучыларының тарихка багышланган әдәби әсәпләрен укып чыктым һәм бер нәрсәгә тәгаен инандым: һәммә урыс язучысы да, кайсы гасырда гына тарихи әсәр язмасын, татарларны каһәрләмичә калмаган. Үзара сөйләшкән кебек, һәммәсе татар халкын яманлый: алар баскынчылар, алар явызлар, алар чәчәк аткан Рәсәйне бөлгенлеккә төшергәннәр, янәсе. Ә үзләре гүяки фәрештәләр, чит халыкларга яу йөрмәгәннәр, башка халыкларны рәнҗетмәгәннәр, киресенчә, артта калган халыкларга азатлык китергәннәр, аларның культурасын үстерүдә ярдәм иткәннәр.

Бу ачы хакыйкатьне ачыклау өчен миңа борынгы Византия империясе тарихы, әрмән хроникалары, гарәп сәяхәтчеләренең язмалары, Кытай елъязмачыларының мәгълүматлары, фарсы тарихчыларының әсәрләре белән танышырга туры килде. Үзебезнең «Казан утлары» журналында әледән-әле басыла килгән тарихи әсәрләрне укыдым һәм укыган саен күзем ачыла барды. Бит урыслар безне гелән нахакка яманлыйлар икән ич! Тарихта бөтенләй алай булмаган. Урыслар үз яулары белән төрки халыкларын азат итмәгәннәр, киресенчә, иректән мәхрүм иткәннәр, аякларына гына түгел, күңелләренә дә богау салганнар: көчләп чукындырганнар, арка тирелэреннән каеш телгәннәр, тәгаен вәхшиләр исәбендә татар халкын кырырга, җир йөзеннән юк итәргә керешкәннәр. Һәм бик ихтимал, кырып та бетергән булырлар иде, әгәр бу чорда куәтләнеп, көчәеп киткән Төркия солтаны урыс кенәзләрен һәм христиан дин әһелләрен кисәтеп куймаса. Көннәрдән бер көнне Рәсәй кенәзенә мондыйрак хат килеп төшә: «Сез ары таба да мөселманнарның арка тиреләреннән каеш телгәләргә исәп тотсагыз, без дә үзебез буйсындырган христианнарның аркаларыннан каеш телә башларбыз»,— диелә кисәтү хатында. Моның өстенә, изүгә һәм җәберләүгә түзә алмыйча баскынчыларга каршы буйсындырылган халыклар баш күтәрә башлый. Урыс кенәзләре буйсындырылган халыкларга кайбер ташламалар ясарга мәҗбүр була.

Алтмышынчы елларда мин Казан дәүләт университетына читтән торып укырга кердем. Һәм тарих буенча түгел, ә татар теле һәм әдәбияты бүлегенә. Миңа җиде класска кадәр генә ана телендә белем алырга, ары таба гел урыс телендә укырга туры килде. Ана телебездә әйбәт кенә сөйләшсәм дә, миңа милли телнең эчкәре яшерен вә серле зәбәрҗәт-гәүһәрләрен күрү тимәгән иде. Мин аңа университетта ирештем. Мине укыткан тел галимнәребез доктор исеменә лаек булдылар. Рәхмәтем зур минем ул мөгаллимнәргә.

Мин инде тарих белән тәгаен җенләнә башлаган идем, язмыш мине Урта Азиягә илтеп ташлады. Миңа анда Рудаки исемендәге мәктәптә тарих фәне укытырга туры килде. Шул ук вакытта Урта Азиянең бай китапханәләрендә казынырга мөмкинлек туды. Монда да мин «Казан утлары» журналыннан аерылмадым. Ул — беренче ярдәмчем булды.

Мәктәптә укыганда шуңа инандым: балалар ата-аналарының тарихларын белмиләр. Минем класста: үзбәк, татар, таҗик, урыс, украин, казакъ, кыргыз, хәтта удмурт, чуваш милләтеннән дә балалар бар иде. Ләкин аларның берсе дә үз халкының тарихын белми, хәтта урыслар да. Гомумән, ата-бабаларының тарихы белән кызыксынмыйлар иде. Шунда мин үземә янә бер ачыш ясадым: балалар тарихны, нигездә, үзләре укыган тарихи әдәби әсәрләр буенча хәтерләрендә ныграк калдыралар икән. Дәреслекләрдә бирелгән тарих фәненә, гомумән, җитди фән итеп карамыйлар. Шуның өчен мин дәресләремдә күбрәк тарихи темага язылган әдәби әсәрләр турында сөйли идем. Моның, әлбәттә, нәтиҗәсе дә

булмый калмады. Соңыннан класстагы егерме җиде баладан уникесе төрле институтларга — тарих факультетына керделәр.

Мин үзем дә нәкъ шул чорда тарихи әсәр язарга керештем. Әлбәттә инде, татар-болгар халкының борынгы бабасы булган, заманында Азов диңгезе буенда Бөек Болгар дәүләтен төзегән, Византия империясе белән тыгыз элемтәдә булган Кубрат ханны төп героем итеп алдым. «Кубрат хан» романым 1985 елда «Казан утлары»нда дөнья күрде. Аннары бер-бер артлы «Илчегә үлем юк» романым, «Таң ата» хикәям басылып чыкты журналда. Бөек Болгар дәүләтен монголлар яулаганчы чорга караган «Шайтан каласы» романым да «Казан утлары»нда дөнья күрергә тиеш.

Бүген минем язу өстәлемдә яңа бер роман туып ята — исеме «Иван Грозный һәм Сөембикә ханбикә» булыр сыман...

Тарихи романнарыма «яшел урам» ачканы өчен мин «Казан утлары» журналы редакциясенә чиксез рәхмәтлемен. Гомумән, җитмеш ел буена «Казан утлары» журналы татар халкының йөзе, уе-хисе, күңел юанычы булды. Шул ук вакытта бу журнал аның ошбу фаҗигале еллардагы тарихы да иде. Теленнән, иманын, гореф-гадәтен, уй-хыялыннан мәхрүм ителгән, кыйбласыннан язган татарның бердәнбер куанычы «Казан утлары» журналы иде. Татар халкының тарихын язу тыелды. Ләкин бу журнал, кыенлыкларга карамастан, әледән-әле тарихи әсәрләр дә бастыра килде. Большевиклар гаепләләрне эзләделәр, редактор йөзендә дошман табып, аларны биялэй кебек алыштыра тордылар. Хәлбуки, «Казан утлары» журналы татар халкының кыйбласына әверелгән иде инде. Редакторлар алышынып кына журнал йогынтысы белән туган милли аң, милли хис, милли рухи үсеш, милли азатлык хәрәкәтен туктату мөмкин эш булмады.

Шулай да татар язучылары озак еллар тарихи темага әдәби әсәрләр язарга кыймый яшәделәр. Тарихи әсәр язып, журналга беренче булып Нурихан Фәттах әфәнде килә. Кульязма өлкә комитеты белән редакция арасында килеп сара-сара таушалып, хәтта кайбер битләре дә югалгач кына, ниһаять, «Итил суы ака торур» дигән тарихи роман укучыга барып ирешә. Шул әсәрдән соң татар әдәбиятында гүяки революция була. Журнал татар халкының тарихына игътибарын тагын да арттыра. Татар халкының тарихы турында фәнни мәкаләләр, язмалар чыга. Ниһаять, «Кубрат хан» романы да нәкъ менә «Казан утлары» журналында басыла. Кечкенә чишмә булып мөлдерәп чыккан татар халкының тарихына булган юнәлеш әүвәл инешкә, аннары елгага әверелә. Җыеп кына әйткәндә «Казан утлары» журналы, ул ошбу кара җитмеш елда татар халкы өчен, «Корьән» кебек изге китапларны алыштыра килде дисәк тә һич хата булмастыр. Һәм ары таба да шулай булып кала күрсен.

Минем фикерем шулдыр: без үз тарихыбызны үзебез язарга тиеш. Чөнки тарихы булмаган халыкның киләчәге дә булмас, диләр. Тарихсыз халык — тамырсыз агач кебек ул.

---

## *Безне котлыйлар*

### Утларыгыз мәңге балкысын!

«Казан утлары» Бөек Төрки каганлыгы заманында калыплашкан, Алтын Урда дәверендә дөнья күләмендә танылган олы мәдәниятебезне, Орхон ташъязмаларыннан, Йосыф Баласагунлы, Хуҗа Әхмәт Ясәви белән Кол Гали мирасыннан башланган, Абай белән Тукай, Исмәгыйль Гаспралы белән Әхмәт Байторсын, Галимҗан Ибраһимов белән Мәгъҗан Җомабаевлар бүгенге көнгә җиткергән олы әдәбиятыбызны ары табан үстерүгә саллы өлеш кушсын! Татар халкының Татарстанны тулысынча бәйсез җөмһүриятка әйләндерү юлындагы көрәше уңыш китерсен! Тарих кабатлана, төрки халыкларның бөек берлеге гамәлгә ашсын!

**Мохтар МАГАУИН,**
«Җулдыз» журналы баш мөхәррире,
Казагыстанның Абай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты

Ләбибә Ихсанова

# АРТТА КАЛГАН КӨННӘР ИСТӘЛЕГЕ



Халкыбыз язмышын 70 ел буена уртаклашып килгән «Казан утлары»н көтеп алына торган абруйлы, зәвыклы журнал итеп күрәсе килү табигый. Әйтергә кирәк, редакциядә төрле елларда төрле буын язучылар эшләсә дә, куелган таләпләр үзгәрмәде. Әдәбиятыбызның киләчәген алдан күреп яшәү һәм шул максаттан чыгып, сәләтле каләм ияләрен журнал тирәсенә туплау булды ул. Җитмешенче елларда миңа, җаваплы сәркатип сыйфатында, бер-бер артлы өч редактор белән эшләргә туры килде. Берсе тәнкыйтьче, икенчесе шагыйрь, өченчесе прозаик буларак, аларның һәркайсының үз жанрына өстенлек бирү ихтималы да бар иде. Әмма алар өчесе дә укучыларга бик тә билгеле талантлы язучылар иде. Һәм һәр талантлы кеше кебек киң күңелле дә булдылар. «Казан утлары» башлыча әдәби журнал булса да, аның һәр санында сәнгать һәм мәдәният яңалыклары, тарихи белешмәләр, юмор-сатира, хәтта балалар өчен дә әсәрләр бирелеп килде. Журналның шулай планлаштырылуын укучылар яратып кабул итте, районнарда үткәрелгән очрашулар вакытында, мин журналны соңгы битләреннән башлап укырга яратам, дигән сүзләрне дә ишеткәли идек. Ә соңгы битләрен, гадәттә вак хәрефләр белән җыела торган, төрле характердагы материаллар ала иде.

Язучының иҗат процессы игенченең иген үстерүе белән бер ул. Ә игенче ашлыгын амбарга салганчыга кадәр, уңыш шөп булды, дип әйтергә яратмый. Язучы да шулай ук. Әсәре редактор кулына килеп кергәнче күп борчулы көннәр, айлар кичерә. Кайвакыт елы килмәгән чаклар да була һәм редакция өстәле бушап калган ындыр табагын искә төшерә. Ә халыкта, изге урын буш тормый, дигән сүз бар. Ул нәрсә белән булса да тулырга тиеш. Һәм менә шул «нәрсә белән булса да»ны булдырмау өчен редакция хезмәткәрләренә һәм редактор кешегә күп көч куярга туры килә.

Республикада барган гигант төзелешләр белән истә калган җитмешенче елларда, кызуында язып калыйм дип, ашыгыбрак эшләнгән роман, повесть һәм шигъри әсәрләрне журнал битләренә барыбер алырга туры килә иде. Чын сәнгать әсәре дип әйтерлекләре әлегә тумаган, аның өчен вакыт арасы, уйлану, белгәнеңне йөрәк һәм акыл аша үткәрү кирәк. Ә андыйларны көтәргә вакыт юк. Укучы КамАЗ төзелеше, яңа калалар салу, «Дуслык» нефтьүткәргече турындагы әсәрләрне көтә, диделәр. Әнә шулай, тартмаларга салып куйган каталоглар кебек, әдәбият эшче темасына, колхозчы темасына, фән һәм башка темаларга бүленгәләп беткән заманда, кеше язмышын сөйләгән кулъязмалар да килгәли иде. Үзенә күрә бер вакыйга иде ул, әсәрне кулъязма хәлендә үк укырга теләүчеләр була, бәхәсләр дә куба һәм, әлбәттә, күп кеше катнашы белән редколлегия утырышы уздырыла. Шулай итеп, әсәр журналга бик теләп кабул ителсә дә, аның дөньяга чыгуы проблемага әйләнә. Каләм остасы тарафыннан язылган саллы, фикерле, әдәбиятыбызның алтын фондына керерлек андый әйберләрне цензураның кыл иләге аркылы үткәрү кыен иде ул елларда.

Ярый әле аерым сүзләр, аерым җөмләләр турында гына бәхәс барса. Кыенга туры килсә дә җайларга мөмкин. Хәтта олы бер кисәген төшереп калдырганда да кайбер әсәрләрнең зыян күрмәгән чагы була. Ә шундый язучылар бар: аның һәр сүзе уйланган, һәркайсы үз урынында, берсе дә фикерсез, буш сүзләр түгел. Оста үрелгән челтәр кебек, бер күзәнәген алдыңмы, бөтенләй сүтелеп бетүен көт тә тор. Җитмәсә бу операция эшнең башында түгел, җыелып, биткә салынып беткәч, нәкъ менә басу машинасына бирер алдыннан эшләнә. Әйтерсең лә бәхәсләргә вакыт калдырмас өчен юри шундый тәртип булдырганнар. Йә син шушы кыска гына вакытта цензорны ышандырып үз фикереңне үткәрәсең, яки җыелеп, тиз генә ул битләрне икенче материал

белән алыштырасың. Чөнки типография көтеп тормый, аның үз графигы бар, вакытында биреп өлгермәсәң, журналыңны машинадан алып ук куя, укучылар көтеп тора дип уйлыймыни алар.

Әле дә хәтеремдә, Әмирхан Еникинең бер хикәясе белән шундый хәлгә очрадык. Цензор хикәядән мәчет манарасын кисү күренешен алып ташларга кушты. Ә моны әсәргә зыян китермичә генә эшләү һич мөмкин түгел иде. Иң аянычы шунда: аның цензор фикере өчен икәнен авторга әйтмәскә, ә четерекле хәлдән чыгу юлын үзебез табарга тиеш булабыз. Ул елларда редакторны яки редакция хезмәткәрләрен эшләнгән эшләрне әнә шулай үз куллары белән җимерергә мәҗбүр итәләр иде. Йөрәгең, акылың белән син әсәр яклы, аның камиллегенә инангансың, ә менә шул кемгәдер ошамаган өчен генә, үз принципларыңнан чигенеп, авторны рәнҗетергә мәҗбүрсең.

Азмы-күпме тәҗрибә булганлыктан, ниндирәк фикерләрнең якты дөнья күрә алмаслыгын чамалаганга күрә, әсәрне редакцияләү вакытында ук автор белән уртак бер фикергә килешенә идек. Ә менә татар авылларындагы мәчет манараларын кисү яки сугыш елларында ач-ялангач кешеләрне окоп казырга куу кебек хәлләрне дә язарга ярамавын һич төшенә алмадым. Мин кечкенә чакта авылыбызда ике мәчет утыра иде. Бабайларга кунакка барганда түбән оч мәчетенең сары буяулы рәшәткәләрен кулым белән сыпырып үтәргә ярата идем мин. Мәчет бакчасындагы алмагачларның яз башында ап-ак чәчәккә күмелеп утыруларын хәтерлим. Утызынчы еллар башында манарасын кисеп төшергәч, ул әллә ничек боегып, тәбәнәкләнеп калды. Шушы кызганыч күренештән йөрәкләре авыртканмы әллә авыл халкының рәнҗүеннән куркыпмы, югары оч мәчетенең манарасын кисәргә куллары бармады. Үзендә гыйбадәт кылу туктатылса да, ул шулай айсыз манарасын күккә чөеп, хәзерге көннәргә кадәр басып калды.

Авыл халкы күз алдында булган хәлләр бит болар. Олысыннан кечесенә хәтле аны белә. Кемнән яшереп маташабыз? Ул чагында редактор өйдә булмагандыр, мөгаен, бу төенне чишү җаваплы сәркатип өстенә төште. Дөресен әйтим, никадәр тырышсам да цензорны җиңә алмадым мин, гадәт буенча авторны аңар җибәрергә тиеш булмасам да, Әмирхан абыйга барыбер дөресен әйттем...

Бәхеткә каршы, ул көннәр инде артта калды. Илебездә сүз иреге, матбугат иреге булдырылды. Хәзер кешеләр авызларыннан чыккан сүзләре, язучылар каләмнәреннән төшкән фикерләре өчен үзләренең вөҗданнары алдында гына җавап бирәләр. Бу, билгеле, мәртәбәле журналыбызның йөзен тагын да күркәмрәк итәр, аның дуслары бик күп булыр дигән ышаныч бирә. Мин аның озын гомерле булуын телим.

---

## *Безне котлыйлар*

### Кадерле «Казан утлары»!

Җитмеш яшең котлы булсын! Җитмеш еллык тарихның ничек үткәнен яхшы беләбез. Золым һәм ялган хөкем сөргән шушы елларда «Казан утлары»ның үз укучыларына хакыйкатьне ачык әйтәсенә, төрки халыкларның зур өлешен тәшкил итүче татар илтәшләребезнең иҗтимагый аңын үстерүгә хезмәт итүенә иманыбыз камил. «Казан утлары» сәхифәләрендә басылган иң яхшы әсәрләр үзбәк халкының да милкедер, чөнки үзбәк һәм татар халыклары фәкать теле, гореф-гадәтләре, дини ышанулары белән генә түгел, ачы язмышы белән дә бер-беренә якын тора.

«Казан утлары» һичкайчан сүнмәсен! Журнал яктысында хакыйкать вә гаделлек балкып торсын!

**Үткер ҺАШИМОВ,**
«Шарк юлдузи» айлыгының баш мөхәррире,
Үзбәкстанның халык язучысы.



«Казан утлары» — озак еллар дәвамына татар халкының бердәнбер калын әдәбият-сәнгать журналы булып килде. Журнал гына түгел, ул безнең милли академиябез. Әдәбиятыбыз елъязмасы һәм татар әдәбиятының чын мәгънәсендәге күптомлы антологиясе дә иде. Шушы олуг әдәби һәм гыйльми үзәктә эшләүгә мин унбер елдан артык гомеремне бирдем...

Хәер, бирмәгәнмен, ә киресенчә, алганмын булса кирәк. Әдәбият һәм сәнгатебез тарихында җуелмас эз калдырган могътәбәр затлар Х. Туфан, Б. Урманче, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, С. Хәким, Ш. Маннур, Н. Дәүлиләр белән мине журнал таныштырды. Җ. Вәлиди, Г. Газиз, Н. Думави хакында иң әвәлге хезмәт һәм фикерләремне халкыма «Казан утлары» җиткерде. Беренче хикәя, беренче повесть һәм беренче романнарым дөнья күрү шатлыгын да сез — журнал укучылар белән уртаклаштым. «Казан утлары» безгә очарга дип канат бирде, әмма туган туфрактан аермады, киресенчә, аны яратырга гына өндәде.

«Казан утлары»нда Зәки Нури, Ләбибә Ихсанова, Ренат Харис, Әхсән Баян һәм Кояш Тимбиковалар белән бер коллективта эшләү, бәхәсләшүләр дәреслекне, матурлык һәм кешелеклелек асылын аңларга өйрәтте.

Дөньяның кай төбәгенә барып чыксам да, анда мин «Казан утлары» журналын һәм укучыларын күреп куанам. Журналның колачы, укучылар даирәсе сокландыра, хәйран калдыра, күпләрне хәтта көнләштерә дә торгандыр. Һич арттыру түгел, хакыйкатьтә шулай.

Үткән тарихы хөрмәткә лаек журналның. Киләчәге тагын да зуррак. Мин шуңарга ихлас ышанам.

Журналыбызның укучыларына һәм аның тату коллективына бәйрәм тәбрикләүләре юллап,

**Ринат МӨХӘММӘДИЕВ,**
Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе.

---

*Безне котлыйлар*

## Кадерле каләмдәшләр!

Барчагызны — «Казан утлары»ның барлык хезмәткәрләрен дә, журналның меңәрләгән-меңәрләген укучыларын да олы юбилей белән ихлас котлыйбыз!

Кот һәм ут сүзләре мәгънәви яктан да, тамырдаш булулары белән дә бер-берсенә бик якын. Эшләгән эшләрегез һәрвакыт котлы булсын, йөрәкләрегездә мәңгелек иҗат уты сүнмәсен, сүрелмәсен. Күпме дәверләр инде без — ут күршеләрбез. Ә күрше хакы — тәңре хакы! Күңелләребездән гел ут алырга язсын, әмма бер-беребезне утка салырга гына язмасын.

Җитмеш — әле җитез чак, алысларга җитер чак!

Урал таудай олы уңышлар, Агыйделдәй бормалы-бормалы иҗади уйлар, Иделдәй ташкын хисләр теләп,

«АГЫЙДЕЛ»ЧЕЛӘР.
Өфе каласы.

# Нажар Нәҗми

## Шагыйрь итмәскә...

Язам, язам... Нигә язам икән?
Түгелме ул юкка — тиктәскә?
Мин тумыштан, бәлки, шагыйрьмендер...
Тырыштылар шагыйрь итмәскә.

Бала чагым. Әти үлгән. Ачлык.
(Ачлык елы килгән өч яшьтә).
Шул елда ук үтерергә иткән
Язмыш мине — шагыйрь итмәскә.

Яшьлек, яшьлек... Тәүге иҗат юлым...
Шигъри буын әле нәп-нечкә.
Сугыш чыкты: минем кебекләрне
Үтерергә — шагыйрь итмәскә.

Тере калдык. Тормыш дигәннәре
Булмаса да тик син дигәнчә,
Гомеремне шигырьләргә бирдем
Кулымнан һәм каннан килгәнчә.

Язганымны «Вак!» диделәр ваклар,
Йөрәксезләр әйтте: «Акыл юк!
Зур заманда мәхәббәтне җырлап
Вакланырга, имеш, хакым юк».

Вакланмадым түгел, вакландым мин —
Күңел юлын киңнән тар итеп,
Ялганлыкка ихлас ышанудан
Җырладым мин юкны бар итеп.

(Вакландым мин — бик тә үкенечле,—
Мин күз йомдым, йоммас урында.
Һәр талантсыз әдәбият кортын
Үз күрдем мин — күрмәс урында).

Әхлакый бу җинаятьтән, шөкер,
Котылдым мин соңлап булса да,
Заман чире күңел юлларыма
Үз тозагын корып торса да.

Торылмады айт дигәнгә, тайт дип,
Вөҗданымны алдым иптәшкә.
Койрык болгау минем канымда юк —
Тырыштылар шагыйрь итмәскә.

Булды заман: иҗатчының данын
Күрделәр тик алтын бизәктә.
Бизәксезләр, имеш, ярты-йорты —
Тырыштылар шагыйрь итмәскә.

Әй син, вөҗдан! Әй син, тәңре уты!
Биреләдер алар сүнмәскә.
Халкы өчен җанын бирүчене
Мөмкин түгел шагыйрь итмәскә.

*1985. Железноводск.*

# Гамил Афзал

## Алтын Урда

Сахраларда көзге җилләр сөйләр,
Ачы җилләр сөйләр япан кырда:
— Нигә сине бик әшәке, диләр,
Алтын Урда?

Толпар тояклары дөп-дөп итә
Борынгыдан калган моңлы җырда;
Ә халыклар хак-гаделлек көтә,
Алтын Урда!

Кайда рәхәт — дөнья тыныч булган,
Ак бәхетләр килгән кайсы чорда?
Ирек-бәхет юлы — кара урман,
Алтын Урда!

Кылыч болгап илләр иңләгәнсең,
Без күрмәгән, без белмәгән чорда;
Беркемнең дә диненә тимәгәнсең,
Алтын Урда!

Кыпчак белән урыс туганлашкан,
Походларда йөргән япан кырда.
Явызлык һәм ялган хәттин ашкан,
Алтын Урда!

Дәстәрханда — кымыз, казанда — ит,
кунак булып килгәч, бие, җырла...
Татар-монгол изүе булмаган бит,
Алтын Урда?!

# Илдар Юзеев

* * *

Ычкынырмын, ахры, бер көнне мин
Җирнең серле тарту көченнән:
йомшак җилдән,
нечкә билдән,
чәчәк исеннән...

Китәрмендер, ахры, бер көнне мин,
Ташлап китәрмендер барын да:
якты кичләр,
татлы хисләр,
сөйгән ярым да...

Китәрмендер, ахры, бер көнне мин,
Онытырлар йөз яшь тулганда:
газиз дуслар,
явыз дошман,
якын туган да...

Китүләргә кадәр бу дөньядан,
Җан шатлыгы белән тартылыйм:
йомшак җилгә,
нечкә билгә,
искә-төскә,
дуска-ишкә,
тәмгә-ямьгә,
тәнгә-шәмгә —
Ярсу дәртем белән атылыйм!

# Марс Шабаев

## И татар гынам...

*А татарчонку хочется напиться...*
Дм. КЕДРИН

Шагыйрь теленә кергәнсең икән,
И татар гынам, татар баласы!
Хәмерләр эзләп йөрергә кая —
Бер сынык эзләп читкә баргансың.
Чәчелгәнсез дә дөнья буйлатып,
Милләтнең эшчән ир-егетләре,
Чәчрәгән сезгә авыр тормышның
Шәрабе түгел, гел күбекләре.
Шундый булган ул синең сәрхүшлек,
Дөнья ачысы сине исерткән.

Куган чактамы берәр ишектән
Аһ-зарларыңны шагыйрь ишеткән.
Бәлки, син аңа, телең сындырып:
«Куалар... вот как...» — дигәнсеңдер дә,
Ул «водка» диеп аңлап калгандыр...
Юк, үпкәләмим аңа мин бер дә.
Төрле тел түгел, бер үк телдә дә
Кеше бер-берсен аңламаганда,
Рәсәй илендә, кая барсаң да,
Кан-яшь эчкәнсең син ул заманда.
Шулай йөргәнсең кагылып-сугылып,
Тик бетмәгәнсең сынып-сыгылып...
Синең мескенлек, синең сәрхүшлек
Чит-ят җирләрдә калсын егылып.
И татар гынам, татар баласы,
Чәчелгәнсең лә син туган җирдән...
Тел очындагын әйтмәгән шагыйрь:
Хөрлек хәмерен эчәсең килгән.

## Фәнис Яруллин

### Әйтегез, әгәр белсәгез

Әйтегез, әгәр белсәгез,
Әйтсәгез — сезгә рәхмәт:
Кайларда йөри каңгырып
Җаннан куылган шәфкать?

Чырайлар шундый караңгы,
Елмаюны югалттык.
Кайсы елгаларга акты
Йөздән куылган шатлык?

Әйтегез, кая югалды
Инсафлы гореф-гадәт?
Кемнәр почмаганда үлде
Өйдән куылган әдәп?

Тәннәр керле, җаннар керле,
Пычракка тәмам баттык.
Нинди юллар тузанында
Күмелеп калды пакьлек?

Һәрбер түрә каршысында
Йөзләрне җиргә ордык.
Нинди учакларда янды
Безнең горурлык, зурлык?

Көн тудымы — күңелләрдә
Сораулар тора артып:
— Ник бу җитмәүчән дөньяда —
Берданбер — Вөҗдан артык?
Берданбер — Намус артык?

## Мөдәррис Әгъләмов

### Иҗат

Төннәремдә кинәт килеп керә,
күзләремдә
йокысызлык тулы
һәм уята мине сүлпән генә,
кагылып иңнәремә,
йокысызлык кулы.

Ябыштырып куя ак кәгазьгә —
син беразга
һушсыз калган кебек...
Уяна бер сабый синең җанда,
бөре язда
сулыш алган кебек.

Ул бит сабый,
шигъри бөре генә...
Иренендә —
сөтле кояш нуры.
Гөнаһ кылмаган ул әле бер дә,
күзләренә
карый әле туры.

Ул бит — иҗат, ул бит — сабый бала,
башын сала
башка терәк юктай...
Иртән дәшә: — Әссәләмегаләйкем!
Җырлый һәркөн
Муса Маликовтай.

Җитә вакыт... туу, әйе, гөнаһ,
шуңа елап,
киләбез лаф орып —
Әлмәндәрдәй килеп чыга кинәт
Әлдермештән
Шәүкәт Биктимеров.

Иҗат — гөнаһ, иҗат — хата безнең.
Үзебезнең
уяну да гөнаһ...
Йокысызлык булып килеп керә
төннәренә,
кергәч — синең кунак.

Рәхим итсен, әйдә, түрдән узсын,
азсын-тузсын
үз дәүләте юктай —
шаккатмыйча хәтта алкышка да
алтмышта да
Илһам Шакировтай.

Юккамыни әнә туа елап
икенче кат
халкым милләт булып,
шуңа иҗат-гөнаһ килеп керә
күзләренә
йокысызлык булып!

## Зөлфәт

### Ялгыз сандугач

Безнең өскә гүя ниндидер көч
Авыр, кара йолдыз кабызды —
Өер-өер ач бүреләр улый
Һәм сандугач сайрый — ялгызы...

Тәкъдирме бу?
Явыз ихтыярмы?
Безнең утны кемнәр сүндерде? —
Үз нәҗесе белән уйный Ватан.
Барып җиттек:
Ватан тилерде.

Үксүеме, сайравымы — белмим,
Әллә инде җанын юата —
Котырган ил сандугачы сайрый
Япа-ялгыз гына
Куакта.

Кара гарасатлар кайнаганда
Нинди зәгыйфь бу өн, нинди саф!
Җиһан үзе җимерелер сыман
Шул сандугач тик бер ялгышса...

Туплandылар кыргый өерләргә
Адәм балалары юлларда.
Шулай уңайлырак — ботарларга,
Шулай уңайлырак — уларга.

Күзләр — куздай!
Сырт йоннары торган!
Тешне кычыттыра мең афәт —
Портретың шушы,
Яңа заман,
Шушы, бәндәм, безнең кыяфәт.

Шул булырмы соңгы сурәтебез
Безнең — сөя белгән халыкның?
Син кайлардан килдең, кара йолдыз?
Нигә безнең күктә калыктың?

Ач өерләр туеп ял итәрләр,
Ырылдашып җирдә җан кыйгач.
Һәм шуларны
ярлыкауны сорап
Өзгәләнер ялгыз сандугач...

## Рашат Низамиев

### Бүгең!

*Нинди була утның үлгән мәле,*
*Нинди була гүзәлләрнең тәне,*
*Нинди була хакыйкатьнең тәме —*
*Ахыргача белгәнем юк әле...*

Үзең теләп, үзең сорап түгел,
Ходайныңдыр, бәлки, көче белән —
Яшәп карасын, дип, төрле холык,
Төрле гакыл безгә иңдерелгән.

Кемдер өчен күкнең биеклеге
Соры болытларга чаклы гына.
Ап-ак каен — кемдер өчен «утын»,
Күпләр исә
Табынып яши аның аклыгына.

Вәхши затлар, кара күзлек киеп,
Чыгып баса кояш каршысына.
Берәү ялгыш ботак сындырса да,
Урын тапмый яши намусына.

Өйрәтәләр: кеше күңелендә
Яхшылыклар уты мул, янәсе.
Ник соң өстен чыга көчлеләрнең:
«Мин көчлемен!» — дигән фәлсәфәсе?

Тигез түгел дөнья: көтмәгәндә
Коендыра язмыш — бозга мана...
Җитмеш җиде катлы иләк аша
Узгармакта безне бу замана.

Хакыйкатьнең хакыйкатен эзлим:
Нәрсә соң ул — Туу, Яшәү, Үлем?
Ак һәм кара төсләр уртасыннан
Җавап табу кирәк миңа бүген!

## Нурия Измайлова

* * *

*(Гата Камский турында уйлап)*

«Хор» дигән сүз бездә юк бугай.
Күмәк җыр сәнгате үсмәгән.
Җырда да, кырда да, кайда да
Үзеңә ышан да — вәссәләм!

Үз хәлең житмәсә, тотынма,
Бер көтү килмәсләр ярдәмгә.
И татар! Ходайның каргышы
Төшәрлек гаебең бар мәллә?!

Ни кардәш, ни күрше, ни дуслар...
Дошман ук түгелләр, тик ятлар.
Үзебез яттан да ятырак —
Бер юлдан баралмый өч татар!
Үзеңне үзең дә сөймәгәч,
Кем сөяр дә сине, кем яклар...

Ул ятлык-ялгызлык эчләргә
Рәнжеш һәм чәм булып тулган шул.
Горурлык та кебек... Тик тышка
Усаллык булыбрак чыга шул.

Һәм үксеп елыйсың тик эчтән,
Күз яшен чыгармый кырыслык.
Елыйдыр юату көткәннәр,
Ә безнең андыйга өмет юк.
Жәлләтә белмәгән татарга
Ни кала? Дөреслек, тырышлык...

Кумәклек, кемгәдер кирәклек
Хакимлек итә бу дөньяда!
Күмәкләп йөргәннәр рәтендә
Теләсәк дөньяга чыгарга,
Талант һәм көч бездән ун тапкыр,
Йөз тапкыр күберәк сорала!

# Газинур Морат

## Җан сурәте

Күбәләккә генә әверелә калса
Фани дөнья кичкән һәр бәндәнең җаны,
Нинди мәгънәсез булыр иде хәят!
Нинди мәгънәсез булыр иде дөнья!

Ә Табигать, шөкер, гадел хөкем итә,
Шөкер, Табигатьнең кануннары башка:
Кемнең җаны әверелә гөл-чәчәккә,
Кемнең җаны әверелә ташка.

Кемнең җаны әверелә утка,
суга,
Кемнең җаны әверелә үрмәкүчкә,
Кемнең җаны әверелә кыя-тауга,
Очар кошка,
йомранга,
йә кәлтәгә...

Мәгънәлерәк булсын дип җирдә яшәвем,
Мәгънәлерәк булсын дип җирдә үлемем.
Җан сурәте —
илаһ Табигатькә
Сәҗдә кылам бүген.

## Ләис Зөлкарнәй

### Бичура

Тәрәзәгә кадакланган
Бишекнең такталары.
Ишетелә тутык бикнең
Ишекне каккалавы.

Бичура, и Бичура,
Ишек катыннан ура —
Хуҗаң җаны урап кайткан,
Ник кертмисең, Бичура?

Арка эзен саклаган мич
Ничә ел ягылмаган.
Үлемтеккә дигән сандык
Һаман да ябылмаган.

Бичура, и Бичура,
Бирнәле сандык юра.
Ничә еллар япа-ялгыз
Ник яшисең, Бичура?

Сыкылаган нигезләрдә
Чикерткә җырлый алмас.
Хуҗалардан калган бишмәт
Җаныңны җылыталмас.

Бичура, и Бичура,
Булма инде бичара —
Күршедәге ятим йортта
Яшидер Бибичура.

Күрше йортның мичләре дә
Ничә ел ягылмаган,
Ничә еллар өстәленә
Ашъяулык ябылмаган.

Бичура, әй Бичура,
Бикәчең — Бибичура.
Бичарадан ничара,
Бишек яса, Бичура.

Бичура — Бибичура,
Бичура — Бибичура,
Тәрәзәдәге такталардан
Бишек ясый Бичура.
Бичура — Бәбичура...

## Рөстәм Султи

### Егерме ике

Дары күмеп, кала алганым юк,
Җаннар кыеп, каннар койганым юк,
Нәфрәтләрсез бер көн торганым юк,
Кулда — каләм. Миңа — егерме ике...

Октябрь бу. Казан урамнарын
Кара каннар белән юган фасыл —
Табигать тә ымлый...
Залим яшьтәш
Вәйран кылган тарихларым асыл!

Явыз Иван таптап, изеп узган
Кол кавемнең бер баласы кана.
Миндә, ахры, шәһит ханнар җаны —
Бәргәләнә, ярсый, газаплана.

Мәскәүлеләр эргәсенә утлы
Шигырь күмдем.
Юк, күммәдем дары!
Миңа инде егерме ике җиткән!
Миңа әле егерме ике бары!..

# Ринат Мөхәммәдиев

# СИРАТ КҮПЕРЕ

РОМАН

Әле өстәл янында утырган чагында ук Ильяс Алкинның, ничектер, куырылып, басынкыланып калганлыгын күреп аптырабрак куйган иде Мирсәет. Югыйсә, Вәлиди белән уртак тел табып, аңлашып яшиләр күренә. Ә барыбер ул үз-үзеннән канәгать түгел. Хәер, Мирсәет өчен монда аңлашылмаган нәрсә юк, ул бит бу киң маңгайлы пәһлеван егетнең бөтен татар дөньясын үз авызына каратып торган көннәрен белә. Зур корабка диңгез киңлекләре кирәк, дигән кебек, һичкемнән сер түгелдер, Ильяс Алкин монда вакытлы кеше.

Авылны чыкканчы уйланып килсә дә, Алкинны тынычландырып, аның күңелен күтәрерлек, ни дә булса уйлап таба алмады Мирсәет. Бер җылы сүз әйтү теләге, аны шатландырырга, һич югында тынычландырырга омтыласы килү зур иде дә бит, булмады.

— Чик буена килеп җиттек,— дип, дилбегәдән тартып атны туктатты Алкин.— Алга таба үзегез кайтырсыз. Урманны кичкәнче атлы сугышчылар озата барыр.

Һәм җәт кенә чанадан сикереп төшеп, кулын суздь Мирсәеткә. Солтангалиев тә төште чанадан. Юлчыны озата барырга тиешле җигүле ат, тынгылыкта калдырыйм үзегезне, дигән сыман, башын икенче тарафка борды һәм бераз тартылып куйды. Зәки Вәлиди егетләре — ат менгән башкорт сугышчылары — кузгалганнар иде инде.

Читәннәрне күмгән кар көрте янәшәсендә күзгә-күз текәлеп карап торды алар. Буран көчәйгәннән-көчәя бара. Акылыгызга килегез, сез бит бер үк халык балалары дип әйтергә теләдеме, учлам-учлам кар сипте ул аларның йөзләренә.

— Йә, Ильяс,— дип дәште Мирсәет.— Нишлибез ары таба?

— Син беләсең булыр. Мин нәрсә?...— диде Алкин, очып китмәсен дигәндәй, баш очында торган бүреген батыра төшеп.— Канатсыз кош хәлендә ич мин хәзер.

— Вәлиди ничек? Ул ни уйлый?...

— Икеләнә... Төннәрен йоклый алмый ул да.

— Ни сәбәпле?...

— Егетләре... Алмадай егетләр кырыла ич, әнә... Тегеләре дә тарта — йолка, болары да аса-кисә, башкорт авыллары кысыр алмагачтай калып бара.

— Менә шуңа күрә дә,— дип, күптәнге танышының җилкәсенә үз итеп кулын салды Мирсәет.— Кызыл Армия ягына чыгарга кирәк. Килешәсеңме?

---

Дәвамы. Башы журналның 4 нче санында.

— Килешмим. Әмма, башка юл да күрмим. Бөтен дөнгез актарылганда аның уртасында тыныч кына яшәү мөмкин түгел, әлбәттә.

Моңсу гына хушлаштылар. Ильяс Алкин, кырт борылып, кире китеп барды. Мирсәет утырган җигүле ат буран эченә кереп югалды.

Юл җиңел булмады. Кичен кайтып җитәргә исәп тоткан Солтангалиев Уфага икенче көнне иртән генә килеп төште. Губерна комитетына килде ул туп-туры. Анда телеграмма күрсәттеләр. Үзәк мөселман хәрби коллегиясен, ихтыяҗы булмау сәбәпле, бетерү турында хәбәр җиткерелгән. Троцкий һәм Сталин имзалары.

Арттан килеп башына күсәк белән тондыргандай тәэсир итте бу хәбәр. Бер көн элгәре бу хакта ишеткән булса, белмим, Зәки Вәлиди белән сөйләшә-килешә алган булыр идеме икән ул? Кемгә һәм ни өчен кирәк булган шундый ыгы-зыгыны кузгату. Сталин һәм Троцкийларны бит әле юлга чыгарга әзерләнгән көндә генә күрде. Тиң итеп, якын күреп сөйләште һәр икесе. Әшендә нинди кыенлыклар килеп чыкса, ярдәм кулы сузарга әзер икәнлекләрен белгерттеләр. Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең үз рәисе бар ич. Киңәшсәләр, һич югында хәбәр итсәләр икән... Юк! Башка сыймас дәрәҗәдәге хыянәт бит бу...

Үз-үзенә урын таба алмыйча, туры элемтә бүлмәсенә атылып бәреп керде ул.

*«Иптәш Сталин. Кече Башкортстан вәкилләре, аерым алганда, Вәлидов һәм Алкин белән минем арада сөйләшү булды. Милли мөстәкыйльлек гарантияләнгән тәкъдирдә, килешү өстәле янына утырырга алар әзер. Мәскәүдән җавап көтәбез.* **Солтангалиев**»*.*

Сталин көннең иртәнге яртысында эш урынында була. Җавап көттермәде. Мирсәеткә шундук озын ак кәгазь тасма китереп бирделәр.

*«Иптәш Солтангалиевкә. Сез алынган эшнең ярты юлда калмавына ышанабыз. Ни таләп итсәләр, шуны вәгъдә итегез. Максат бер, башкорт сугышчылары Советлар тарафында булырга тиешле. Уңышлар телим.* **Сталин**»*.*

Гаҗәп. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе хакында ләм-мим сүз катмаган Сталин. Бу нәрсә, аның белән сукыр тәкәле уйнарга җыенуларымы әллә?! Солтангалиевне ярым-йорты сөйләшү, юмалаулар белән генә алдап булмас. Телеграфчы кызга мөрәҗәгать итте ул янә.

*«Иптәш Сталин. Уфага Үзәк мөселман хәрби коллегиясен тарату турында хәбәр килгән. Әлеге коллегиянең рәисе бүгенгәчә Солтангалиев иде. Мәсьәләне шул рәвешле хәл итүегез аек акылга сыймый. Катгый рәвештә таләп итәм, карар кире кагылырга тиеш.* **Солтангалиев**»*.*

Бу юлы да җавап озак көттермәде.

*«Солтангалиевкә. Аңлаштык дип саный аласыз. Карар кире кагылыр. Сез дигәнчә булыр. Уфадагы эшләрне җайга салгач, Казанга юл тотыгыз.* **Сталин**»*.*

Күңелдә төер калды калуын, әмма әлеге хәбәрләшүдән соң, бер кадәр тынычлана төште Мирсәет. Көндезен Уфада урнашкан хәрби берләшмәләрне йөреп чыкты, сугышчылар белән очрашып әңгәмәләр кылды. Чөнки хәл итәсе мәсьәләләрнең очы-кырые юк, Уфа губерна комитетында татар-башкорт мәсьәләләрен кайгыртыр кадрлар калмаган. Ә аяк чалырга, каршы төшәргә атлыгып торучылар — буа буарлык.

Уфа губернасы революцион комитеты рәисе белән Мирсәет Солтангалиев арасында киеренке әңгәмәләр көн саен диярлек кабатланып тора. Кече Башкортстан җитәкчелеге белән килешүе хакында да хәбәр итә.

— Кызыл Армия ягына чыксыннар, мин каршы түгел,— ди ревком рәисе Нимвицкий.— Әмма аларның җәзасыз калуы белән килешмим.

Мирсәет, бу мәсьәләгә мөнәсәбәттә үзәкнең башка фикердә торуын, бүгенге шартларда «җәза» дигән сүзнең файдасыз икәнлеген аңлатырга омтыла. Әмма Уфа губерна комитеты рәисе сүзендә нык тора.

Соңгы очрашуларның берсендә Совнарком вәкиле, Эчке эшләр халык комиссары урынбасары Б. Эльцин да катнаша. Ике тарафны да якынайту нияте белән, соңгысы тәкъдим кертә:

— Солтангалиев иптәш белән килешәм, әлегә «җәза» турында сөйләшергә ашыкмыйк,— ди ул.— Ә киләчәктә күз күрер.

— Юк,— ди Солтангалиев.— Куенда таш яшереп килешү өстәле янына утырмыйлар. Башкорт сугышчыларын алдау Совет хөкүмәтенең дәрәҗәсен бөтен Көнчыгыш халыклары каршысында юкка чыгарачак. Бу — бер булса, икенчедән, гади сугышчыларның ни гаебе бар?!.

— Бәлки сез милләтче башкисәрләрнең үзләрен генә түгел, Зәки-«хан»ны, Дутов «патша»ны һәм үзен «император» итеп төшләрендә күргән Колчакны да акларга җыена торгансыздыр?— дип, чеметеп ала Нимвицкий.

— Колчак һәм Дутов өчен мин җавап бирмим. Әмма, килешү булган тәкъдирдә, Зәки Вәлидигә бармак белән дә орыну ярамый, иптәшләр,— ди Мирсәет. Һәм Кече Башкортстан җитәкчеләре иминлеге өчен җаваплылыкны үз җилкәсенә алуын белгертә.

Бер-берен аңламаган ике телдә сөйләшүгә охшаш була бу. Милли автономия хакында ишетергә дә теләми Уфа җитәкчеләре. Гомумән, милли мәсьәләнең большевиклар өчен кирәкмәс, чит-ят нәрсә санауларын яшермиләр. Казандагы фикердәшләрен дә уздыра икән Уфа җитәкчеләре. Әнә кемнәр эшли милли төбәкләрдә! Ә Мирсәеткә исә, үзара гаепләшүләргә күчми генә әңгәмәне ерып чыгу кирәк. Тешен кысып түзсә-түзә, әмма якындагы көннәрдә Кече Башкортстан вәкиле белән килешү өстәле янына утырырга кирәклекне аңлатуга ирешә ул.

Вәлиди ышанмый, күрәсең, Уфада гыйнварның утызынчы көненә билгеләнгән сөйләшүгә үзе килми. Муллаҗан Халиковны җибәрә. Сөйләшү көнозын дәвам итә, Кече Башкортстан тарафыннан берьялгызы булуына да карамастан, Халиков нык тора, Совет хөкүмәте белән килешүләр өстәле янына утырганчы үтәлергә тиешле алты шарт куя. Уфа җитәкчеләре теләсә дә, теләмәсә дә, ул шартларны кабул итәргә мәҗбүр. Чөнки Сталин Солтангалиевтән яшерен телеграмма алган була, бер көн элек кенә. Уфа җитәкчеләренең милли мәсьәләгә битараф кына түгел, тискәре мөнәсәбәттә торулары, һәм, әгәр шул карашларын үзгәртмәсәләр, революция эшенә күп зыян килү ихтималын искәрткән була Мирсәет Солтангалиев.

Утызы көнне иртән Б. Нимвицкий һәм Б. Эльцин белән бергә, большевикларның Уфа губерна комитеты рәисе Сезенков та Мәскәүдән катгый кисәтү хәбәре алалар: «Колчак тарафында булган Вәлиди сугышчыларының Советлар ягына чыгуына тоткарлык ясаган һәр иптәш хәрби трибунал каршысында җавап бирәчәк».

Тагы берничә көннән, Сезенков, Эльцин һәм Нимвицкий имзалары белән Кече Башкортстанның килешүгә омтылышы бар дигән телеграмма В. И. Ленинның үзенә җибәрелә. Бу хәбәрләшүне бер тарафтан — М. Солтангалиев, икенче тарафтан И. Сталин дикъкать белән өештырып һәм күзәтеп торалар.

Февральнең алтынчы көнендә Уфа губернасының революцион комитеты исеменә Үзәктән җавап килә:

*«Халиков иптәшнең җаеннан торыгыз. Башкорт полклары уртак фронт белән Колчакка каршы күтәрелгән тәкъдирдә амнистия вәгъдә итәргә. Башкортларның милли азатлыгына Совет хөкүмәте тарафыннан ирек гарантияләнә. Әлбәттә, башкортлар арасындагы контрреволюция башлангычларын тамырдан кисә, пролетар ышанычлылыкка ирешә бару зарур. Ленин.* **Сталин**».

Тагы өч көннән Көнчыгыш фронтының 5 нче армиясе политбүлегенә башкорт гаскәриләренең Кызыл Армия белән бер сафка басып Колчакка каршы көрәшергә әзер булуы хакында хәбәр җиткерелә. Шул рәвешле, бер айдан да азрак вакыт эчендә Мирсәет Солтангалиев үзенә йөкләтелгән гаять катлаулы бурычны үтәп чыга.

* * *

Уфа вокзалы кайнап торган умарта күчен хәтерләтә. Хәрби составлар арлы-бирле йөреп тора. Кая карама, кызылармиячеләр. Берән-сәрән генә булса да төенчекле юлаучылар да күзгә чалынып ала. Тик аларга монда игътибар итүче юк. Юл һәм хәрәкәт тулысынча хәрби мәшәкатьләр ихтыярында.

Казанга юл тотарга тиешле состав паровозга тагылган. Гайрәтле айгыр сыман соңгы мәртәбә кешнәп куясы һәм тояк асларыннан кайнар пар бөркеп кузгаласы гына калган. Үзен озата килүчеләр белән берәмберәм хушлашып чыккач, вагон баскычына күтәрелде Мирсәет. Ни өчендер, кәефе артык шәптән түгел, канәгатьсезлектәнме, моңсулык бастымы үзен — төгәл генә әйтүе дә кыен. Ни өчен канәгатьсезлекме? Чөнки әле яңа гына кайбер урыннарда Кызыл Армия тарафына чыккан башкорт сугышчыларын коралсызландыра башлаганнар дигән хәбәр җиткерделәр үзенә... Ә моңсулык — Фатыйманы сагынудан. Аны берьялгызын калдырып киткәнгә ни гомер, әле һаман Мәскәүгә әйләнеп кайтыр ара күренми. Яшь кәләше зарыгып аны Мәскәүдә көтә торгандыр, ә ул Казанга китеп бара...

Чү! Үзенә кул болгап озатып калучылар арасында, бераз читтәрәк, нindидер таныш сурәт төсмерләнеп киткән сыман булды түгелме соң?!. Кем булыр икән ул?... Әллә бер-бер якын кешесен хәтерләтүче генәме?...

— Сәхипгәрәй,— дип кычкырып җибәрде ул үз-үзен белешмичә.

Вокзал читендә, арырак басып торучы аның күптәнге танышы Сәетгалиев түгел идеме соң... Казанга ак чехлар якынлашып килгәндә, суга төшкән балтадай, эзсез югалган кенennән күргәне юк иде аны. Ак чехлар кергәч ул бер маржа өендә качып яткан дигән имеш-мимеш йөрде ул чакта. Соңрак аны Самарада, Уфада күрүчеләр булган. Ни сәбәпледер, ул суырылып калган, йончыган күренә. Өстәвенә таякка таянган. Үзен танучы булмас диеп, читтән күзәтеп торуы булдымы икән, Мирсәетнең дәшүе булды, теге аркасы белән борылып китәргә итенде.

Поезд әле кузгалмаган, җәт кенә кире сикерде Мирсәет һәм бер-ике сикерүдә тегене куып та җитте.

— Сәхипгәрәй,— дип, беләгеннән тотып туктатты ул аны.— Ни булды сиңа? Кайларда югалып йөрисең?

Карышмады, танымаганга сабышмады Сәетгалиев. Туктады һәм йөзе белән борылды.

— Исәнме, Мирсәет?!. Менә сине күрергә дип килгән идем, әле...

— Ә ни өчен әле син бу хәлдә, нигә безнең арада түгел?

Сәетгалиев өметсез карашын, бер Мирсәеткә, бер үзенең аяк очына төбәп алды. Чарасыз калып торды бермәл. Аннан, акланырга теләгәндәй, кабалана төшеп сөйләргә керешге:

— Мин — беткән кеше Мирсәет. Тиф бәреп екты үземне. Ятмаган булнисем, күренмәгән доктырым калмады... Бер татар авылында мөгаллимлек иттем...

— Казанга кайтасыңмы әллә?... Анда шифаханәләр дә бүтән, белгечләр дә...

— Клячкинның үзендә ятып карадым... Файдасы булмады. Аннан бит...

Мирсәет үз итеп, аның җилкәсенә кагылып куйды шунда. Бу кызгану хисе иде, әлбәттә. Ни дияргә, нәрсә киңәш бирергә белми торды ул.

Үч иткәндәй, нәкъ шул чакны соңгы кисәтүем дигән сыман, паровоз кычкыртып куйды.

— Күңелеңне төшермә,— диде Мирсәет, аның күзләренә туры текәлеп.— Казандагы иптәшләрдән дә уңайсызланма, аңларлар... Гафу да итәрләр...

— Эшем дә юк, ашым да. Кемгә кирәк инде мин хәзер?!. Өстәвенә яманатым таратканнар...

— Ул нинди яманат тагы?!

Җәт кенә Мирсәетнең күзләренә карап алды Сәетгалиев: «Шаярамы бу, әллә үпкәләү, ачулануның ни икәнлеген белмиме?». Әңгәмәдәшенең ихласлыгын тоеп, ул үзе дә күңелендәген әйтте:

— Мирсәет, ни йөзем белән кайтыйм ул Казанга?!. Иң авыр чакта ташлап кач та, инде бер гаепсезгә сабышып кайтып төш. Булдыра алмыйм мин алай...

— Юк,— диде Мирсәет, ныклы фикергә килеп, һәм тавышын күтәрә төште. Янәшәсендә басып торган озата килүчеләргә мөрәҗәгать итте.— Иптәшләр, сезнең каршыгызда күренекле революционер, большевик Сәхипгәрәй иптәш Сәетгалиев басып тора. Ул бүгеннән үк Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә эшкә билгеләнә. Аның сәламәтлеген кайгырту, кирәксә, кымызга җибәреп кайтаруыгызны үтенәм...

Озата килүче җаваплы иптәшләр бер-беренә карашып алдылар. Әмма Солтангалиевнең шаяртмавын белгәч, ризалашмый чаралары юк иде, баш кактылар. Һәм арадан берәве, Якуб Чанышев иде булса кирәк, Сәетгалиевне култыклап ук алды. Инде кузгалып китеп барган үз вагоны артыннан йөгерде Мирсәет, тимер баскычка сикерде.

Мирсәетнең «Сәетгалиев иптәшне кайгыртыгыз!»— дип, кычкырган авазы, паровоз артыннан бөркелеп калган пар сыман һавада эленеп торды.

* * *

Кояш риясыз балкып көлгән яз башы иртәләрендә Казан каласы аеруча матур була. Күпме михнәт вә фаҗигаләр кичергән шәһәр самимиләнеп, сафланып кала шул мәлдә. Менә бүген дә, Бишбалтаны үтеп, Казан елгасы аша салынган тимер юл күперенә килеп чыккач та, Мирсәетнең болай да җилкенеп кайткан йөрәге кысып-кысып куйды. Башын чак кына янтайта төшеп сәламләгән Сөембикә манарасы, Кремльнең ак диварлары, ерактан ук күз нурын җәлеп итеп торган мәчет манаралары — һәммәсе якын аның өчен... Гаҗәп хәл бит — туып-үскән җире түгел, гаиләсе юк монда, туган-тумачасы юк, әмма һәрчак шушы юлдан Казанга кайтып керү киеренке һәм моңсу бер тантанага әверелә дә куя. Һичничек тынычландырам димә йөрәкне, мөмкин түгел ул, бернишләтеп булмый...

Вокзалдан үзен турыдан-туры Губкомга илтүләрен үтенде ул. Казан губерна башкарма комитеты рәисе итеп әле соңгы араларда гына билгеләнгән Малютин иптәш эш бүлмәсендә иде инде. Мирсәетне күргәч, ихлас куанды, хәтта кочаклап һәм үбеп тә алды ул аны.

— Хуш киләсез, иптәш Солтангалиев. Гаять вакытлы килдегез, көттердегез. Әйдүк, рәхим итегез.

Утырыштылар. Кунак хөрмәтенә тиз арада кайнап торган тимер чәйнек куелды өстәлгә, ике кружка һәм икмәк телемнәре... Шул рәвешле, икәүдән-икәү генә губком рәисе белән иртәнге чәй эчеп, хәл-әхвәлләрне белешеп утырдылар. Малютин күбрәк зарланды. Кадрлар җитмәүдән, үзара татулык булмаудан зарланды. Рус һәм татар большевиклары арасында гына түгел, татарлар һәм руслар үзара да әллә ничәшәр төркем һәм төркемчәләргә бүленеп беткән икән. Әле соңгы араларда гына,

Питердан ирле-хатынлы Антипов һәм Ратнерлар килгәч, бу каршылык аеруча кискенләште. 2 нче армиянең хәрби-революцион Советы әгъзасы Штеренберг та алар ягына күчкән. Кыскасы, Малютин иптәшнең генә түгел, гомумән, Казан губернасының сәяси вә икътисади хәлләре гадәттән тыш киеренке, ә тагы да төгәрләк әйтсәк, мөшкел була ул көннәрдә.

Эшчеләр арасында болганыш һәм канәгатьсезлек артканнан-арта бара. Ыгы-зыгы һәм болганышлардан тәмам гаҗиз булган крестьяннар ачыктан-ачык Советларга каршы күтәрелергә әзер. 2 нче армиядә дә эшләр шәптән түгел, кайбер полкларда кырык-илле кеше торып калган. Алары да дөньяларын онытып кәрәшкә күтәрелергә атлыгып тормый, таралышу, гаиләләренә кайтып китү ягын кайгырталар... Ә бит Үзәктәге кайбер иптәшләр революция язмышы хәл ителгән Көнчыгыш фронтта нәкъ менә шул 2 нче армиягә зур өметләр баглап тора.

Малютинга телеграф тасмасы кертеп бирделәр. Үзе танышып чыкканнан соң, Губком рәисе дәшми-нитми генә аны Солтангалиевкә сузды:

*«Колчак Уфаны алды. Кызыл Армия тәртипсез рәвештә Казанга таба чигенә. Ашыгыч чаралар күрегез.* **Троцкий**».

— Димәк, безгә дә чигенү җаен кайгырта башларга кирәк,— дип, башын кашып куйды болай да кәефе булмаган Малютин.

Мирсәеткә аның паникага бирелүе ошамады. Уфаның Колчакка күчүе яңалык түгел иде, беренчедән, әле ике көн әүвәл, бу хакта аңарга Зәки Вәлиди хәбәр җиткерде:

*«Без Ленинга ышандык, ә безгә ышанмыйлар. Башкорт сугышчыларын коралсызландыру, кавалерияне атсыз калдыру кемгә кирәк булды икән?— дип ачынып язган иде Вәлиди Мирсәеткә юллаган шәхси хатында.— Советлар өчен, күрәсең, Колчакны туктату түгел, азатлыкка омтылган башкорт егетләреннән үч алу әһәмиятлерәк булгандыр! Муса Мортазинның, кире уйлап, үз сугышчылары белән яңадан Колчакка барып кушылуы да очраклы түгел...*

*Хәтереңдәме икән, Мирсәет, мин сиңа бер талантлы шагыйребезнең шигырьләрен укыткан идем... Шәехзада Бабич. Теге, гәҗит чыгаруда катнашып йөргән бәләкәй гәүдәле, шадра егет. Менә шул, иштемәсәң-ишет, ул шагыйрьне дә бер гаепсезгә харап иттеләр. Җигүле ат белән гәҗит басу машиналарын алып кайтып барган җирдән, 1 нче армия кызыллары тотып, кыргыйларча җәзалап үтергәннәр үзен. Тере килеш ат койрыгына тагып таш юлдан өстерәп йөреткәннәр. Авыр туфрагы җиңел булсын бахырның, шагыйрь егетебез Зилаир дигән урыс авылы янында ятып калды.*

*Менә шулай, Мирсәет, Уфаны да калдырып, ары чигенәбез. Күңелдә тынычлык юк, ялгыштым ахры... Чигенәбез дә чигенәбез. Соңы ни белән бетәр, белгән юк. Хәзергә хуш!* **Зәки Вәлиди**».

— Юк, иптәш Малютин,— дип каршы төште Мирсәет, Губком рәисенең шул рәвешле фикер йөртүен туктатырга ашыгып.— Мин монда чигенергә дип, Казанны акгвардиячеләргә калдырып өчен кайтмадым. Уфа белән Казан арасын үтәр өчен Колчакка, ким дигәндә җиде көн кирәк булачак. Бу аз гомер түгел...

— Ни эшләргә боерасыз?— дип, Солтангалиевнең күзләренә текәлде Малютин. Аның да бу кыен хәлдән чыгасы, бер-бер чара күрәсе килә иде, әлбәттә. Юлын гына күрми.

— Чара шул,— дип, тавышын күтәрде Мирсәет, ике уйлар урын калдырасы килмичә.— Бүген үк төштән соң Губерна комитетын җыясыз. Шунда ук 2 нче армиянең Хәрби-революцион советы әгъзаларын чакыртырга. Һәммәсен дә!...

Килешүен белдереп, баш какты Малютин.

— Чакыртырбыз. Тик әлеге дә баягы үзара тарткалашуга гына кайтып калмасак ярар иде...

— Калмаслар! Андыйлар була икән, Хәрби трибунал каршында җавап бирерләр. Иптәш Троцкийның әмере шундый.

Өйләдән соң очрашу турында килешеп, Мирсәет китеп барды. Губком рәисе исә ашыгыч киңәшмәне оештыру-чакырту мәшәкатьләренә керешге.

Тагы бер сәгать-сәгать ярымнардан Солтангалиев шәһәрнең татар эшлекләләре белән очрашып сөйләште. Очрашты һәм хәйран калды: Губерна житәкчеләре арасында бер генә татар большевигы да юк. Җаваплы урыннарны бирү кая, аларга хәтта ышанмыйлар, үзләрен Губком утырышларына да чакырмыйлар икән. Губерна партия оешмасының Татар бюросына болын кадәр бинада рәтле-башлы урын табылмаган, бәдрәф чигендәге почмакта көн яктысы төшми торган ялгыз бүлмәгә кертеп тутырганнар үзләрен. Билгеле инде, эш кайгысы калдырылмаган берәүдә дә.

Мирсәетнең «революция язмышы куркыныч астында» дигән чакыруына исләре китмәде. Дәррәү күтәрелеп зарланырга керештеләр:

— Йосыф Ибраһимов, Шамил Усманов һәм Крымов иптәшләр фронтка киткәч, безгә көн калмады, Мирсәет туган. Казанда бар дип тә белүче юк үзебезне, без монда килмешәк хәлендә торып калдык,— дип зарланды, үзен Юныс Вәлидов дип таныштырган яшь бер иптәш.

Аны икенче бер агай күтәреп алды. Бусы да таныш түгел иде Мирсәеткә. Бергә эшләгән көрәштәшләре кайсы — кайда, хәрәкәттәге гаскәри берләшмәләргә таралып беткәннәр. Һәлак булганнары да байтак.

— Авыз ачып сүз әйтергә өлгермисең, сине «милләтчелек»тә гаеплиләр. Булмый, иптәш Солтангалиев, булмый мондый шартларда эшләп. Урыслар безне кешегә дә санамый башлады.

— Урысның гаебе юк,— дип, каршы төште әлеге дә баягы Юныс атлы егет.— Урысларга да көн күрсәтмиләр бит, әнә. Өерләре белән Малютинга ташландылар. Көн-төн талыйлар аны да... Малютин — намуслы кеше!

Мирсәеткә күптән мәгълүм һәм таныш нәрсә иде бу, аңарга аңлатып торасы юк.

— Ярар,— диде ул, зарланучыларны кырт кисеп.— Боларын әлегә калдырып торыйк... Республика игълан ителгәч тә һәммәсе акрынлап җайга салыныр. Хәзергә илне дөнья империалистлары ялчылары — актвардиячеләрдән тазарту зарур. Колчак Казанга килә... Нишлибез?!.

Сөйләшү, ышандыру җиңел булмады үзләрен, «җирле шовинизм» татар большевикларының үзәкләренә үткән, җелекләрен корыткан булып чыкты. Әмма инкыйлабка, Ленинга ышанычлары сүнмәгән икән — Мирсәет ни кушса, шуны үтәргә әзер булып аерылыштылар.

Өйләдән соң, килешенгән вакытта, Казан губерна комитеты президиумының киңәйтелгән утырышы ачылды. Кереш сүз белән губком рәисе иптәш Малютин чыгыш ясады. Мирсәет сүзгә катышмый гына тыңлый иде әлегә. Авыз суларын корытып, бер сәбәпсезгә, бәхәсләшергә, акыл сатарга керештеләр. Губернадагы хәлләр турында уйлаучы да юк, эшчекрестьян ник берәве ялгышып кына искә алсын икән!... Революция язмышы хакында да сөйләмиләр, Казанга якынлашып килгән Колчакны да искә төшермиләр. Сәясәт тә сәясәт... «Уңнар» вә «суллар» һәм дә килеп «милләтчеләр» дә «интернационалистлар»... Гинцбургны Ратнер алыштыра, Ратнерның тәмамлавы була сүзне, 2 нче армия вәкиле Штеренберг күтәреп ала. Үзара да чәкәләшкәндәй итәләр. Кулларын болгый-болгый янып, кайнарланып та сөйлиләр бит әле тагы. Акыллы сөйлиләр, белеп саталар акылны. Марксны да искә төшерәләр, Каутскийны да, Троцкийга, Зиновьевка мөрәҗәгать итәләр. Ленин кадәр Лениннан хата эзлиләр. Акыллылар!...

Түзеп-түзеп утырды да, сикереп торырга мәҗбүр булды Мирсәет.

— Җитәр, иптәшләр,— диде ул, тавыш күтәрүдән үзен чак тыеп.— Акыл сата, теоретик бәхәсләр корып утыра торган заман түгел. Итәккә ут капкан, әнә, Колчак Камага якынлашып килә. Без бүген ашыгыч

чаралар күрү хакында уйланырга тиеш. Уйланып кына калмыйча, ул чараларны тормышка ашыру юлларын билгеләргә һәм шушы сәгатьтән үк оештыру эшләренә керешергә кирәк. Иптәш Ленин һәм иптәш Троцкий бездән шуны көтә.

Тынып калдылар бермәлгә. Шул тынлыктан файдаланып, Малютин әле бүген генә Үзәктән килгән Ленин һәм Троцкий мөрәҗәгатьләрен игълан итте.

— Бүген мин татар коммунистлары белән очрашып сөйләштем. Алар эшчеләр арасында мобилизация игълан итәргә, авылларга чыгарга булдылар...

Мирсәетне бүлдереп, шунда берәве ярага тоз сибеп куймасынмы. Хатын-кыз тавышы. Ратнер иде бугай.

— Татарның коммунисты ни дә, коммунист булмаганы ни аның. Милләтчеләр инде...

Елмаеп, шаяруга сылтап әйтелгән сүз түгел. Күз йөртеп чыкты Мирсәет, һәммәсе җитди вә тыныч. Малютин иптәш кенә, кәефе кырылып һәм Мирсәетне рәнҗетүче өчен уңайсызлык хисе кичереп, өстәлгә китереп суга.

— Ратнер иптәш, кайда булуыгызны онытмасагыз иде.

Чигәсенә чүкеч белән кундырдыларммыни, калтыранып куйды Солтангалиев, җавапсыз кала алмады.

— Кызганыч,— диде ул.— Шундый сүзнең үзен большевик санаган кеше авызыннын чыгуы кызганыч... Инде мин дә җавап бирергә тиешледер. Миңа сезнең арада утырырга оят бүген. Казан губерна комитетының кинәйтелгән президиумына кертергә бер татар большевигы таба алмагансыз! Казанмы бу, түгелме?!. Губкомның Татар бюросына шәһәрдә бер бүлмә таба алмагансыз, шулмы оят түгел?!. Ә тыңлап торсаң гаепне бик матур тагасыз, кайбер иптәшләрнең «милләтче» һәм «шовинист» дип кемнәрнедер гаепләп уңга-сулга селтәнгәнен уңайсызлык кичереп тыңладым мин. Иген игеп тамагыбызны туйдырган татар агае өчен уңайсыз булды миңа, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр бөкересен турайтмыйча станок артында торган рус эшчесе өчен уңайсыз... Алар һәммәсе «шовинист» һәм «милләтче» булгачтын, сез кем буласыз соң, Ратнер ханым?!.

Телгә оста, сүз эзләп күршегә керә торган түгел, шундук җавап кайтарды, югалып калмады хатын:

— Интернационалист булабыз!— диде. Хатын-кызларга хас ник бер уңайсызлык кичерсен.

Авыр булса да йотты Мирсәет. Хатын-кыз белән сүзгә килү ир-атны бизәми. Шуның өстенә, Үзәктән килгән вәкил дә бит әле ул. Аның тәкъдиме белән, президиум эш планы кабул итте. Җаваплы иптәшләр арасыннан шәһәрдәге һәр завод яисә фабрикага агитаторлар билгеләнде. Мобилизация игълан ителде. Дошман тылына яшерен агитаторлар җибәрергә карар кылынды.

Иртәгесен Казанга хәрби комиссар Лев Троцкий килеп чыкты. Ул Мирсәет Солтангалиевне 2 нче армиянең Хәрби-революцион Советы әгъзасы итеп билгеләде. Кичен смена тәмамланып килгән мәлдә, Алафузов фабрикасы эшчеләре каршысында чыгыш ясады Мирсәет.

Ялкынланып, ихлас күңелдән бирелеп сөйләде ул. Әгәр дә мәгәр Совет хөкүмәте җиңелүгә дучар була калса, гади эшче, рус һәм татар хезмәт ияләре өчен моның нинди зур бәлага китерү ихтималын искәрткәндә хәтта үзенең күзләренә кайнар яшь тулды.

Шунда яшьле күзләрен җиң очы белән сөртә-сөртә эшчеләр арасыннан олы гәүдәле, өлкән яшьләрдәге, сакаллы бер агай килеп басты Мирсәетнең янәшәсенә. Рус эшчесе иде.

— Улым,— диде ул, борынын тарта-тарта.— Күптән елаганым юк иде. Ә син мине елаттың. Ышандырдың мине. Инде шуны әйт син безгә, шул Колчакка каршы көрәшкә күтәрелерлек ник кешеләрегез тагы бар-

мы? Булса, үзем беренче булып язылам Кызыл Армиягә. Барыбыз да язылабыз, шулай бит, җәмәгать.

Куллары тоташ сөялдән генә торган карт эшченең мөрәҗәгать итүе булды, шундук үзен кулга күтәреп алдылар. Урыс, татар һәм чуваш егетләре һәммәсе: «Мин дә язылам», «Мине дә языгыз», ди-ди кулларын күтәрде, алга омтылдылар.

Шундый ук митинглар башка завод-фабрикаларда да узды. Бер көн эчендә Кызыл Армиягә ун мең чамасы эшче язылды Казанда.

Тагы ике көннән Мирсәет Солтангалиев, Лев Троцкий белән бергә, Нократ елгасына төбәп, алгы сызыкка юл тоттылар. Кызыл Армия, Мамадыш белән Малмыж арасында Нократның бирге ягында ныгытмалар корып, дошманны туктатырга хәзерләнә. Бу бәрелештә һөҗүм итеп килүче Колчак гаскәрләре туктатылмаган тәкъдирдә, вакыйгаларның алга таба ничек дәвам итәчәген һичкем әйтә алмый иде...

Нократка барып җиткәч, Мамадыш каршындагы Тузанлы Тау түбәсенә менеп (хәзер бу тауны җирле урыс кешеләре Пузанка дип йөртә), 2 нче армиянең күзәтү урынында тукталды алар. Троцкий тумышыннан хәрби булган диярсең, шундук дошманның һөҗүм итүе ихтимал булган юнәлешләрне төгәл ачыклап күрсәтте. Чигенеп килүче гаскәрләргә кайдан һәм ни рәвешле елга аша кичү оештырып, авангардиячеләрне ничек алдау яисә тозакка эләктерү юлларын билгеләргә кереште. Бу төбәккә тәүге кабат килеп чыккан Хәрби комиссарның шул мәлдәге гөманлаулары ни дәрәҗәдә нигезле булачагын әле вакыт күрсәтер, хәзергә белүче юк.

— Табигать шәп икән ич бу якларда,— дип мөрәҗәгать итте ул Мирсәеткә, үзенең Нократ болыннарына соклануын яшерә алмыйча.— Карагыз әле, кара, Солтангалиев иптәш, мондый киң манзара кайда бар ул тагы. Бу төбәктә шундый тау һәм бу дәрәҗәдә гүзәл болыннар бардыр диеп уема да китерә алмаган булыр идем. Кавказың, Швецарияләрең бер читтә торсын ә?!

— Әйе,— дип баш какты Мирсәет. Хәрби комиссарның шул рәвешле хискә бирелгән чагын тәү кабат күрүе иде әле аның. Баксаң, аның да йөрәге бар, ул да шигъри җанлы кеше икән ләбаса.— Бу якларның табигате чынлап та матур ул, Лев Давидович. Тик шул җирдә гомер кичерүчеләрнең күз алдындагы табигать белән хозурланыр арасы булганы юк, шунысы кызганыч.

Кинәт аңарга йөз белән борылды Троцкий.

— Син үзең дә бу төбәктән түгелсеңдер ич, Мирсәет?

Троцкийның аңарга, беренче мәртәбә үз исеме белән мөрәҗәгать итүе иде.

— Юк, Лев Давидович. Мин Уфаның да аргы ягыннан. Бу яклардан түгел. Хәер, тамырның кайдан башланганлыгын кем белә...

— Беләсеңме ни өчен сораган идем... Әлегедәй иркен, бай табигать кочагында туган кешеләрнең күңеле дә юмарт һәм кешелекле була торгандыр. Физик яктан да мәһабәт, нык булулары табигыйдыр.

— Ә сез беләсез... Мамадыш ягында үскән бер пәһлеванны сез беләсез, Лев Давидович.

Җанланып китте Троцкий. Нәкъ сабый инде менә.

— Кем ул? Кем?

— Хәтерегездәме, Зәки Вәлиди белән бер офицер кергән иде яныгызга? Мәскәүдә. Наркомвоенморда...

Хәтерләмимме соң!... Троцкий барын да белә, барын да хәтерендә тота. Бүген дә Кызыл Армиядә хезмәт итүче һәр командирның дип әйтерлек исемен, әтисе исемен күңелдән әйтеп бирә ала диләр аның хакында.

— Ә-ә, тегене мыеклы, таза егетме?...— дип эләктереп алды Троцкий.— Кем әле, Алкинмы?... Исеме дә сәер генә, гади генә үзенең... Ильяс,

шулай бит, ә?!. Фрунзе иптәш мактап сөйли аның хакында. Хәзерлекле һәм кыю командир, диләр... Ул Мамадышта туганмы?...

— Тууын белмим. Казанда булса кирәк. Әмма чыгышлары белән бу төбәктән. Ильяс Алкинның миңа сөйләгәне бар, ул Мамадыш өязендәге утарларда үскән. Димәк, Мамадыш суын эчкән...

Елмаеп куйды Троцкий.

— Димәк, без дә баһадирлар булып китмәгәек... Без дә Мамадыш суын эчтек бит, ә, Мирсәет?...

Нәкъ шул мәлдә алар икәү генә басып торган күзәтү урынына Троцкийның ярдәмчеләреннән берәве ашыга-кабалана килеп җитте. Һәм кәгазь кисәкләре сузды.

Үзалдына бер кат күз йөртеп чыккачтын, Мирсәет тә ишетсен диптер инде, кычкырып укырга керешә Троцкий:

*— «Казандагы пехота командирлары курсын туктатырга вакыт» булса кирәк! Анда патша генераллары Тальковский һәм Фирдәвес иптәшләр, Кызыл Армиягә кадрлар хәзерләү хәйләсе белән, милләтчелек коткысы таратып ята икән дигән хәбәрләр бар. Фронтка озатыгыз үзләрен. Сезгә мөрәҗәгать итүемне Ильич сорады.* **Стасова»**.

Хәбәрне укып чыкты Хәрби комиссар һәм Мирсәеткә текәлде.

— Бу сезнең Мөселман хәрби коллегиясе эше иде булса кирәк?

— Әйе,— диде, һәм, әйтер сүз таба алмый, телсез калып торды Солтангалиев.

— Карарның проекты әзер. Кул куям.

Сынаулы карашын Мирсәеттән алмый гына, түш кесәсеннән кызыл карандаш тартып алды Троцкий.

— Нинди карар?

— Ябу һәм барысын да фронтка җибәрү турында.

— Ашыкмавыгызны үтенәм, Лев Давидович. Мөселманга һәм татар-башкортка караган бар нәрсәне тыю, ябу белән генә шөгыльләнәбез болай да. Командирлар курсы эшләргә тиеш, ул гына да түгел, Әстерханда һәм Мәскәүдә яңа курслар ачарга җыенабыз.

— Ә Стасовага ни диярбез?— дип, ирония катыш елмаеп куйды хәрби комиссар.— Бу — бер. Икенчедән, патша генералы Тальковский кем була, «милләтче»ме?.

— Стасова эше түгел бу, беләсез, Лев Давидович. Ә пехота курслары җитәкчесе генерал-майор Искәндәр Тальковский һәм политик комиссар Измаил Фирдәвескә килгәндә, шуны әйтә алам — намуслы кешеләр...

— Намуслы кешеләр,— дип, үзалдына кабатлап, уйланып торды Троцкий.— Намусны тотып карап булмый аны. Стасова артында кем торганлыгын сез яхшы беләсез!...

— Беләм... Колчакны тар-мар иткәч тә Ильичның үзе белән сөйләшеп аңлашырбыз.

Кулындагы кәгазьләрне кире ярдәмчесенә сузды Троцкий.

— Архивка.

Ярдәмче китеп барды. Троцкий белән Солтангалиевкә иярләнгән атлар китерделәр. Бу хәвефле чорда Мамадышта төн куну урынлы булмас дигән нәтиҗәгә килеп, аларны шәһәрдән җиде-сигез чакырымдагы татар авылы Түбән Ушмыга озаттылар.

Ә иртәгесен, Троцкийның әмере белән, Мирсәет Солтангалиев Малмыж тирәсендә урнашкан 21 нче дивизиягә кызылармиячеләрнең рухын күтәрү өчен җибәрелә. Бу дивизия аеруча авыр хәлдә була ул көннәрдә. Ә Мамадышта Тузанлы Тау түбәсендә ныгытмалар корган Азин дивизиясе ышанычлы күренә иде.

Троцкий белән иртәнге җиделәр тирәсендә Түбән Ушмы авылы башындагы зират читендә, салкын сулы чишмә суын эчкәннән соң, кул бирешеп саубуллаштылар. Мирсәет Солтангалиев Малмыжга юл тотты.

Тагы нәкъ ун көннән Мәскәүгә Ленин һәм Сталин исеменә телеграф хәбәре салды ул:

*«Колчак Нократтан уза алмады. Казанны бирмәдек. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе рәисе, 2 нче армиянең Хәрби-революцион Советы әгъзасы* **Мирсәет Солтангалиев»**.

Нәкъ шул ук сүзләр язылган тасма Троцкий исеменә дә юллана. Әмма Хәрби комиссар ул көннәрдә үзе дә Советларның язмышы хәл ителгән Көнчыгыш фронтта, Нократ-Чулман төбәгендә була әле.

* * *

Мәскәүгә, Фатыймасы янына август ахырларында гына әйләнеп кайта алды Мирсәет. Фатыйма тиздән бәби табарга тиеш. Әнисе, әле булса, үз рөхсәтеннән башка большевикка чыкканы өчен, кызын гафу итмәгән. Фатыйма йомышы төшкәндә үзе барып-кайтып йөрсә дә, әнисенең алар фатирына шул көнгәчә килгәне юк икән. Көмәнле яшь хатынга энеләре-сеңелләре ярдәм иткән.

Көнчыгыш фронттан җиңүче сыйфатында кайтып кергәндә Солтангалиев, кайтканының икенче көнедә үк күңелендә җыелып, тупланып килгән борчуларын уртаклашу нияте белән Кремльгә, Ленинның үзе янына юл тотты.

Кабул итү бүлмәсендә утыручы иптәш, Солтангалиевкә, иң элек, Үзәк Комитет секретаре Стасовага мөрәҗәгать итеп карарга киңәш итте. Шундый тәртип кертелгән, Ильичка керергә теләүчеләрнең күплегеннәндер, алар иң элек Стасова яисә Новгородцева белән очрашып, үзләренең асыл ниятләрен ачып салырга тиешле икән.

Стасова үзе генә иде. Солтангалиевне ул байтактан бирле, яхшы танышлар. Мирсәетнең, үз итеп, елмаеп биргән сәламенә, шундый ук җавап ишетергә өметләнүе табигый иде. Әмма, ни хикмәт, Стасова керүчегә каш астыннан сөзеп карады. Хәтта утырырга урын да тәкъдим итмәде. Креслосыннын кымшанмый гына салкын тавыш белән дәште ул аңарга.

— Ни кирәк, Солтангалиев иптәш?

Мирсәет бу салкынлыкның сәбәбен аңламады, билгеле. Моны нигә юрарга да белмәде. Чөнки аның Көнчыгыш фронтны житәкче-политик кадрлар һәм кызылармиячеләр белән тәэмин итүдәге зур эшчәнлеге Үзәктәге һәммә иптәшкә мәгълүм булырга тиеш иде. Ничә кат чолганышта калып, ничә мәртәбәләр үлемне җиңеп чыккан фронтовик, хәрби оештыручы, абруйлы дәүләт эшлеклесе дә бит әле ул!..

Мирсәетнең үзенә дә коры, рәсми сөйләшүдән башка чара калмаган иде:

— Иптәш Стасова, Владимир Ильич мине кабул итә аламы?

— Юк!

Кайчан, ни сәгатьтә, дип тә сорамыйча, әнә шул рәвешле кистереп үк куйды Үзәк Комитетның җаваплы хезмәткәре. Монысы инде һичнинди кысаларга да сыймый торган нәрсә иде.

Мирсәет дәшәр сүз тапмады бүтән, кырт борылып, кире чыгып китәргә иде исәбе. Шунда сорый куйды Стасова:

— Нинди эш белән керергә җыенган идегез Владимир Ильич янына?

— Мин аның үзенә сөйләрмен.

— Сөйләрсез... Әмма мин белергә тиеш. Ильич үзен яхшы хис итми соңгы араларда.

— Казанда татар батальонында чыккан бунт хакында доклад белән керәм. Ул моның белән үзе кызыксыну белдерде. Башка мәсьәләләр дә бар...

Стасова йөзен чытып куйды хәтта. Атналар-айлар дәвамында Кремльдән чыкмый утырган ханым өчен вак, игътибарга лаек булмаган мәсьәләләр иде, күрәсең, болар.

— Тагы шул бер балык башын чәйнәп йөрисез икән,— дип сукранды ул үзалдына.

— Аңламадым?!. Ни диярга теләвегез бу?

— Нигә кирәк булды ул милли хәрби берләшмәләр?!. Сезнең телегездә гел шул. Милли партия, милли республика һәм милли армия. Кайчан туктыйсыз шул милләтчелек авыруыннан, ә, иптәш Солтангалиев?!.

Тәмам кызып, урыныннан сикереп торып чәпчергә тотынды Үзәк Комитет секретаре.

Үзен тыныч тотарга омтылып, берни аңламаган атлы булып җавап кайтарды Мирсәет:

— Милли армия нигә кирәк булды дисезме? Игътибар белән тыңлагыз, җавап бирәм: милли армия безгә башта ак чехларга каршы көрәшү өчен кирәк булды, ә соңгы арада Мәскәүгә ыжгырып килүче Колчакны туктату өчен. Сез утырган Кремльне дә сакладык берочтан. Ишетмәгән булсагыз, игътибарга алуыгызы үтенәм, иптәш Стасова, Колчакны туктаткан Көнчыгыш фронтның нәкъ яртысы татар-башкорт сугышчылары иде!

Фактлар Үзәк Комитет секретарен тынычландыра төште. Кире барып урынына утырды ул. Әмма Мирсәеткә урын тәкъдим итмәде.

— Шулай да, иптәш Солтангалиев, сез милли мәсьәлә белән артык мавыгасыз кебек. Үзегез дә белешмичә милләтчелек упкынына тәгәрисез...

— Әшем шул. Мин Милләтләр эше халык комиссариатында эшлим. Ә менә «упкынга тәгәрәү» дигән сүзегезне аңламадым. Каян алдыгыз аны?..

Төбәп бирелгән сорауга җавапсыз кала алмады Стасова. Хатынкызларга гына хас чарасыз кабалану белән алды аны.

— Бу минем үз фикерем,— диде ул, як-ягына каранып.— Һәм ул башка кайбер иптәшләрнең бәясе белән тәңгәл килә.

— Мисал өчен?

— Иптәш Ялымовны алыйк, мәсәлән. Ул да чыгышы белән азчылык вәкиле. Әмма, сездән аермалы буларак, ул чын интернационалист. Аның өчен, гомумән, юк ул милли мәсьәлә.

— Алай икән,— дип сузып куйды Мирсәет үзалдына.

Соңгы арада әллә каян гына мәйданга чыгып, кыска вакыт эчендә шактый ук күтәрелгән — Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмасында Үзәк бюро рәисе урынбасары дәрәҗәсенә ирешкән бу иптәш яхшы таныш иде аңарга. Ялымовның бөтен карьерасы милли мәсьәләләрне инкарь итүгә нигезләнгән. Үзен «интернационалист» санаган — милләтсез, денсез адәмнәр дә бар шул. Булганнар һәм булырлар да. Гомер итүләре дә каршылыксыз, җиңел була аларның. Ил, халык язмышы хәл ителгән олы вакыйга, җитди бәхәсләрдән һәрчак читтә торырлар, әмма аның каравы дан-дәрәҗә бүлешкәндә өлгерләр. Тик барыбер, кагыйдә буларак, матур төгәлләнми торган була андый язмыш. Телсез-денсез яшәп, шул яшәүне язмыш диеп атап булса әгәр?!.

Мирсәет өчен шундук бары да аңлашылды. Владимир Ильичка язылган хатының ни өчен җавапсыз калуы да аңлашылды. Һәм үзенә һәрчак хәерхаһ булган Стасованың ни сәбәпле аны күргәч тә кара көюе аңлашылды. Чөнки Ялымовның Мөселман хәрби коллегиясен бетерү юнәлешендәге эшләре дә, милли автономия мәсьәләсенә тискәре караштa булуы, мөселманнар арасындагы контрреволюциягә каршы көрәш максатыннан төзелгән гадәттән тыш комиссияне тиз генә таратып ташлавы — һәммәсе мәгълүм иде Солтангалиевкә.

Мирсәетнең тәкъдиме белән Ялымов бераздан Төркестанга эшкә җибәрелә. Аның кандидатурасын Сталинга тәкъдим итеп, болай ди Солтангалиев:

— Барсын, милли мәсьәләнең ни икәнлеген үз күзләре белән күреп кайтсын. Большевикка һәммәсен белеп тору кирәк.

Мирсәетне ярты сүздән аңларга күнегеп килгән Сталин, серле генә елмаеп ала шунда.

— Хәйләкәр син, иптәш Солтангалиев. Хәйләкәр...

Әмма үзе тәкъдимне кире какмый. Төркестанда Ялымовның нинди эшләр майтаруы тарих сәхифәләрендә мәгълүм түгел. Ни генә булмасын, «милли мәсьәлә»нең барлыгын һәм житдилеген үз жилкәсендә татыган, аңлагандыр ул. Чөнки соңрак, партиядә «чистартулар» барган бер чорда, аңарга да «буржуаз милләтче» ярлыгы тагыла. Ул елларда язмыш кемне генә һәм кай тарафларга гына китереп ташламаган...

* * *

Гражданнар сугышы белән бүлгәләнгән, желеге суырылган Советлар Россиясе 1919 ел көзенең соңгы көннәрен вакларга керешкән иде. Көнчыгыш фронттан, Оренбург һәм Уфа тарафларын чираттагы мәртәбә әйләнеп кайтуына Мирсәетне Мәскәүдә куанычлы хәбәр көтә икән: Фатыйма аңа кыз бала алып кайткан.

Табигый ки, Фатыйма әниләре янына күчәргә мәжбүр булган. Мирсәет ишектән килеп кергәнче үк бала елаган аваз ишетте. Ни хикмәт, әбисе дә аны беренче мәртәбә үз итеп, жылы каршылады. Үпкә-рәнжүләре, әби булу шатлыгыннан, онытылган. Кияүне ишектән кермәс борын ук табын түренә чакырдылар. Ә кулына ак биләүгә төрелгән кызыл борынлы бәби тоттырдылар.

— Әнә, әтиең кайткан, кызым,— диде, өйдәге татулыкка һәммәсеннән дә болайрак куанган Фатыйма. Ул тал чыбыгы сыман сылуланып калган, күзләре зур, бит урталары алсуланып тора — тагы да матураеп киткән.

Мирсәетнең дә авыз колакта. Тик кулындагы орчык сыман бала белән генә ни эшләргә белми, үчти-үчти итәр иде, бигрәк бәләкәй, кул арасыннан төшеп китәр төсле.

— Кайчан таптың, күптәнме?— дип сорады ул, ниһаять.

— Инде унбишенче көн белән барабыз,— диде Фатыйма, күзләрендә, ирен очларында балкыган шатлыгын уртаклашкан сыман.

— Алай бик дәү булгач, исеме дә бардыр инде бу кызчыкның?

— И-и Мирсәет,— дип, елмайды, килеп иренең жилкәсенә башын куеп сырпаланып торды Фатыйма.— Әтисеннән сорамыйча кызга исем кушалар димени инде...

Мирсәетнең күптән уйлап йөргән исеме һәммәсенә ошады, кызга Гөлнар дип исем куштылар. Гөлнар — ут чәчәге дигән сүз. Утлы елларда туган чәчәк ләбаса.

Шул бәхеттән башы күккә тиеп йөргән көннәрендә Ленинның кабул итү бүлмәсенә чакырттылар үзен. Солтангалиевнең Ильич белән күрешеп-сөйләшергә атлыгып яшәгән көннәре иде. Канатланып, ашкынып барды ул юлбашчы янына.

Кабул итү бүлмәсендә тоткарланмады диярлек. Ильичның телефоннан сөйләшеп бетергәнен генә көтте.

Юлбашчы, гадәтенчә, ишек катына диярлек килеп каршы алды аны. Йомшак күн креслодан урын тәкъдим итте.

— Йә, иптәш Солтангалиев, сөйләшик,— диде Ленин, әңгәмәдәшенә дикъкать белән карап.— Мин үзем дә күптән күрергә тели идем сезне, вакыт кына житми торды. Мөселманнар арасыннан берләнбер күренекле революционер, жәмәгать эшлеклесе бит сез хәзер.

— Алай ук булмаса да...— дип, үзалдына итагатьлелек күрсәтергә керешкән Мирсәетне, ярты сүздән өзде юлбашчы.

— Уңнан да ишетәм сезнең хакта, сулдан да ишетәм. Һәм әйтергә кирәк, төрлечә сөйлиләр...— Дәртләнеп, ашкынып сөйли иде ул, үзен бүлдерергә, бер-бер сүз белән кысылып алырга җай калдырмый сөйли:— Димәк, сез мөстәкыйль фикер йөртәсез, мөстәкыйль карарлар кабул итәргә сәләтле дигән сүз бу. Гаҗәпләнер урын юк моңа, шәхес буларак күзгә ташланмаган кеше турында сөйләмиләр.

Ул да түгел, фикерендә кискен сикереш ясап, сорап куйды Ильич:

— Якубов иптәш белән ни булды?... Казандагы ул восстаниене китереп чыгарган сәбәпләрне ачыклый алдыгызмы?

— Восстаниенең төп сәбәбе урындагы иптәшләрнең милли гаскәри берләшмәләр төзүгә тискәре мөнәсәбәтеннән килә, Владимир Ильич. Фронтка китәргә тиешле кызылармиячеләрне башта атналар буе ач тотканнар. Аннан, сезне ач тотучы — үзегезнең политик бүлек мөдире Камил Якубов иптәш, дип сүз җибәргәннәр. Нәтиҗәсен беләсез, Камил Якубов бер гаепсезгә шәһит китте... Безнең милли кадрлар әнә шундый шартларда эшли һәм дөньядан китә! Вахитовның үлеме дә бик серле иде...

Кулларына таянган килеш, күзен кыса төшеп тыңлап утырган Ленин кинәт җанланып китте.

— Ә бәлки, ул мөселман хәрби частьларын тарату кирәктер?

— Тарату җиңел эш, Владимир Ильич. Тик ул көчләрне яңадан җыеп алып булырмы соң? Ак чехларга каршы көрәшкәндә кирәк идегез, Колчакны туктатканда ярап тордыгыз, инде хәзер таралыгыз, дияргәме? Юк, алай уйнау ярамас ир-егетләр белән. Советларга булган ышанычны югалтмау зарур бүген. Гомумән, милли мәсьәләгә мөнәсәбәттә, сүздә — бер, эштә икенче булулардан арынырга кирәк безгә...

— Кызыл Армиягә язылган ул ир-егетләр патша колы түгел. Алар азат гражданнар бүген. Ә болар — революция казанышы. Димәк, Советларга булган ышанычка куркыныч янамай... Шулай фикер йөртүдә логика бармы, иптәш Солтангалиев?...

— Бар. Әмма татар-башкорт халкын, шәхси азатлыктан бигрәк, милли азатлыкка булган омтылыш Советларны яклап кулга корал алырга этәрде. Хикмәт әнә шунда, Владимир Ильич! Кызганычка каршы, күпләр моны күрми. Яисә күрмәгәнгә, аңламаганга сабыша. Мөселман хәрбиләренең Колчакка каршы көрәштә күрсәткән батырлыклары ул турыдан-туры милли азатлык вәгъдә иткән Татар-Башкорт республикасы игълан ителүе нәтиҗәсе булды.

— Кызык... Әнә ничек...— дип, үзалдына уйланып утырды Ильич. Ул үзе сөйләргә атлыгып тормый, Солтангалиевнең фикер йөртүен тыңларга әзер иде. Әмма берничә сүздән гыйбарәт сораулары белән, Мирсәетне эчкерсез сөйләшүгә этәрә тора үзе.— Ә ул Татар-Башкорт республикасын тормышка ашар хыял дип санамыйсызмы?

Башка кеше әйтсә бер хәл, әмма Ленинның үзеннән мондый сорау көтмәгән иде Мирсәет. Җавабы да, шуңарга, шактый ук кинаяле булды:

— Советлар иленең мәртәбәле җитәкчеләре кул куйган Декрет хыял буларак кабул ителмәде, Владимир Ильич. Аны гамәлгә ашыру бүген көн тәртибендә тора. Уфада булсын, Казанда булсын — ул хакта һәркем кызыксына...

— Ә менә Зәки Вәлиди иптәш башкача уйлый...

— Аның ничек уйлаганы миңа да мәгълүм... Ул Кече Башкортстан мәнфәгатьләрен кайгырта, ә Татар-Башкорт республикасы төзелүгә каршы түгел. Минем башта тагы да кызыклырак проект бар әле тагы. Иртәме-соңмы, вакыйгалар безне шул юнәлешкә этәрмәгәе дим...

— Йә-йә, ул нинди проект тагы?— дип, кызыксыну белдерде Ленин.

— Без әлегәчә татар һәм башкорт халыклары турында сөйләшәбез. Ә бит аларга терәлеп үк торган Төркестан да бар әле. Анда казакъ, үзбәк, таҗик, кара-кыргыз һәм каракалпак халыклары яши. Бәлки бүген үк аерым автономияләр тәшкил итә алмаса да, иртәме-соңмы, алар да

милли үзбилгеләнү турында уйга биреләчәк. Һәм, табигый рәвештә, бер дин тотучы тугандаш төрки республикалар каршында федерация булаpакмы, конфедерация булаpакмы, берләшү ихтыяҗы тууы ихтимал. Моңардан курку ярамас, киресенчә, шуңа әзер торырга кирәк.

— Ә моңардан ни максат?...

— Максат шул, Владимир Ильич, милли-азатлык хәрәкәтләренә уңайлы шартлар булдыру Советлар Россиясенең дөньякүләм абруен күтәрәчәк. Көнчыгышта — Төркия, Әфганстан һәм Иран кебек мөселман илләрендә генә түгел, колониаль изелүдә булган һәммә дәүләтләрдә — Һиндстанда, Кытайда һәм ерак Африка вә Латин Америкасы илләрендә социализм идеяләренә омтылыш вә ышаныч тудырачак.

— Сезнең белән сөйләшү кызыклы икән, иптәш Солтангалиев,— дип, әлегәчә ияген учлап утырган кулларын маңгаена күчерде Ленин.— Һәм ул хыяллар тормышка да ашмаслык түгел, бер уйласаң. Тик миңа сорау туа: кадрлар... Ул кадәр көч һәм кадрларны каян табарга соң?!.

— Кадерләрен белү кирәк, кадрлар бар!

Ленин, Мирсәет сөйләгәннәр белән мавыгып, үзалдына фикер йөртүен дәвам итә иде:

— Кадрлар да табылыр иде, дисең. Тик тагы бер житди нәрсәне хәтердән чыгармыйк әле без. Сез искә алган Көнчыгыш илләрендә пролетариат юк. Ә революциянең төп хәрәкәтләндерүче көче кем?... Пролетариат! Һәм сыйнфый көрәш!

— Каршы төшәргә рөхсәт итегез, Владимир Ильич. Сыйнфый көрәшкә караганда, колониаль илләр өчен милли-азатлыкка омтылу хәрәкәте күпкә әһәмиятлерәк. Һәм бу омтылышка дөрес юнәлеш биргәндә, ул үз юлындагы теләсә нинди каршылыкларны да алып ташларга сәләтле. Бәлки, безгә «сыйнфый көрәш» теориясе белән үзебезне чикләмәү хәерлерәктер?!.

Бу уңайдан Ильич үзенең фикерен ачык кына әйтеп бетермәде. Тулы бер сәгатькә сузылган бу сөйләшү әле тагы дәвам иткән булыр иде. Ленинның да сораулары калгандыр, Мирсәетнең исә киңәшәсе мәсьәләләре тагы да күбрәк иде. Тик шулвакыт сәгать унга билгеләнгән киңәшмә турында Ильичның хәтеренә төшерделәр.

Якын-тирәдә, янә бер ара табып, очрашырга вәгъдәләшеп аерылышты алар.

* * *

Эш бүлмәсенә кайтса, үзен көтеп утыручылар арасында шәриктәше, инде хәзер танылган шагыйрь булып житешкән Сәгыйть Сүнчәләйне күреп хәйран калды.

— Менә бу очрашу... Нинди язмышлар китереп ташлады үзеңне?— дип, кочагына алды аны Мирсәет.

Озаклап сөйләштеләр, хәл-әхвәл белештеләр. Ә аерылыр алдыннан Сүнчәләй аңардан үзенең шигырьләрен русчага тәржемә итеп бер-бер үзәк басмаханәдә нәшер итүдә ярдәм кылуын үтенде. Вакыты булгач та булышырга вәгъдә бирде Мирсәет.

Инде ишек катына житкәннәр иде. Шулчак Мирсәетнең хәтеренә Сталинның бер үтенече килеп төште.

— Карале, Сәгыйть дус,— диде ул.— Төркиягә барып, дөнья күреп кайтасыңмы әллә?!.

Тәкъдим кызык тоелды. Дөнья күрмәгән татар шагыйрьне андый тәкъдимнән баш тартамы соң!

— Хәзер мин сине иптәш Сталин белән очраштырам,— дип, шундук телефон трубкасына үрелде Солтангалиев.— Ул миннән төрекчә яхшы белгән ышанычлы кеше табуымны үтенгән иде. Төркиядә консуллыкта эшләү өчен булса кирәк.

— Төрекчәсен сукалармын анысы,— дип, икеләнә калды Сөнчәләй.— Ә менә Сталин янына керү булмый ул миннән.

Шул арада, сабыйлыгы чыгып бетмәгән яшүсмер сыман, ялт кына кире ишек катына үтеп, Сүнчәләйнең аркасыннан кагып куйды Солтангалиев.

— Иптәш Сталин сине көтә. Кара аны, төрек кызларына миннән сәлам әйтергә онытма...

Тәкъдимнең нинди җитди һәм җаваплы булуын әле яңа чамалап алган Сәгыйть Сүнчәләйне Сталин кабинеты янына өстерәп диярлек алып барды ул һәм, ишеген ачкач, аркасыннан этеп кертеп җибәрде.

Ике ай, ай ярым вакыттан Мирсәетнең өй адресына яңа — 1920 нче ел белән котлап җибәрелгән чәчәкле-чуклы төрек открыткасы килде. Сәгыйть Сүнчәләйдән.

Әмма ул бәйрәм котлавын алганга кадәр әле Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының 2 нче Бөтенроссия Корылтае узасы бар. Анда инде ел ярым чамасы вакыт элек игълан ителгән Татар-Башкорт республикасы язмышы хәл ителергә тиеш була. Әлбәттә, әлеге Корылтайны оештыручы югары җитәкчелек — Ленин, Сталин һәм башкалар өчен бу күптәннән хәл ителгән мәсьәлә. Тик сәяси максатлардан чыгып, ашыгычлык белән игълан ителгән Декрет белән нишләргә?! Солтангалиев тирәсенә тупланган зур төркем, Казан, Уфа һәм Мәскәү коммунистлары аны чын-чынлап тормышка ашыру нияте белән йөриләр. Халыкның үз ихтыярына куйсаң, шулай ук ни белән бетәсен әйтеп булмый. Әнә ич, татар-башкорт кына түгел, чуваш һәм мари вәкилләре дә шул республиканы яклап тавыш бирә икән. Бердәнбер юл кала, Үзәк фикерен аяк астына салып таптамастай иптәшләрне күбрәк җәлеп итеп, Корылтай уздырырга. Һәм аны да Казанда яисә Уфада түгел. Мәскәүдә дә түгел,ерактарак, әйтик, Питерда уздырырга дигән ният була. Шулай да Корылтай Мәскәүдә уза.

Ноябрь ахырында ачылган әлеге Корылтайга илнең төрле төбәкләреннән «ышанычлы» вәкилләр җыела. Төп докладны Мирсәет Солтангалиев ясый.

Кырык биш минут чамасы сузылган чыгышында ул әлеге мәсьәләнең бөтен тарихын, каршылыкларын, сәяси вә икътисади әһәмиятен күздән кичереп чыга. Һәм сүзен йомгакларга җыенганда ачыктан-ачык сорау куя:

«Ни өчен соң әле Татар-Башкорт республикасы төзергә кирәк булды? Зәки Вәлиди тәкъдим иткәнчә, Башкорт республикасын үзаеры, татарныкын үзаеры гына оештырганда гаделрәк килеп чыкмыймы? Әмма Зәки Вәлиди дә, бу тәкъдимне күтәреп алган башка җаваплы иптәшләр дә бик яхшы аңлый дип беләм мин. Моңардан җүнле-башлы нәтиҗә чыкмаячак. Чөнки уйлап карагыз: татар республикасы оештырыла икән, аны кайда оештырырга? Әлбәттә, татарлар торган җирдә диярсез. Әмма безгә яхшы мәгълүм, бары тик татарлар яши торган өязләр Казан губернасында ике-өч булса, Уфа губернасында — берәү. Шуңардан чыгып хәл итсәк, автономияле Кече Башкортстан килеп чыгар һәм автономияле Татар республикасы. Ә шул ике кече автономия арасында халкы тоташтан татар яисә башкорт булган зур-зур кисәкләр торып калачак. Нәтиҗә нидән гыйбарәт була шулай иткәч? Татар белән башкорт халкы арасында мәңге хәл ителмәслек чияләнгән төен торып кала. Моның киләчәктә ике тугандаш халык арасында бик күп низаглар китереп чыгаруы ихтимал. Чөнки ул җирләргә алар икесе дә мәңге омтылып, тартылып яшәячәк. Һәм һәр икесенең шуңа хокуклары да бар. Әниләренең күкрәкләрен бүлешә алмый бер-беренең йөзен тырнаган игезәк сабыйлар хәлендә торып калачак дим...»

Солтангалиевнең «Яшәсен Татар-Башкорт республикасы!» дигән лозунг белән тәмамланган чыгышы көчле алкышлар белән каршы алына.

Икенче докладны Микъдат Борындыков ясый. Ул да Татар-Башкорт республикасы ягында.

Өченче докладчы — Сәхипгәрәй Сәетгалиев. Ул әнә шундый! Кай арада сәламәтләнеп аякка баскан да, кай арада шул дәрәҗәгә ирешкән.

Мирсәеткә, әле Корылтайга килгәнче үк, Сәетгалиевнең соңгы арада гына Сталин янында булып чыгуы турында хәбәр иткәннәр иде. Шуның өстенә, аның Корылтайга китәр алдыннан Уфада Зәки Вәлиди белән очрашып, аңарга Татар-Башкорт республикасына каршы чыгарга вәгъдә иткәнлеге дә мәгълүм.

Сәетгалиев, чынлап та интернационализм турындагы ялтыравык лозунгларга таянып, гомумән, теләсә нинди милли республикаларга да кискен каршы сүз сөйли. Әмма шунысы гаҗәп, тавыш бирүгә килеп терәлгәч, башкаларга ияреп, ул да Татар-Башкорт республикасын яклап кул күтәрә.

Корылтай 1919 елның 3 декабрендә күпчелек тавыш белән «Совнаркомның Татар-Башкорт республикасы төзү турындагы декретын тормышка ашырырга» дигән карар кабул итә.

Анда Кече Башкортстанның да мөстәкыйльлеге гарантияләнә. Татар-Башкорт Совет социалистик республикасына керү-кермәү аның үз халкы ихтыярына бирелә.

Әмма, имәндә икән чикләвек, диярсең. Нәкъ менә татар һәм башкорт халыкларына берниндн мөнәсәбәте булмаган бер төркем делегат, Корылтайның карары белән килешмичә, аны ташлап чыга. ВҮК органнарында эшләүче В. Лукашевич, А. Микоян, Н. Нариманов (әзербайҗанлы), Гайдарханов (Төньяк Кавказдан) һәм төркестанлы Х. Ибраһимовлардан гыйбарәт була бу төркем.

Бигрәк тә Көнчыгыш вәкилләренә һич мөнәсәбәте булмаган Лукашевичның монда үзен хуҗадай хис итүе, кирәкле-кирәксезгә тыкшынуы канәгатьсезлек тудыра.

Гадәтенчә, кайнарланып чыгыш ясаган Измаил Фирдәвес, мавыгып китеп, аны хәтта «Корылтайның бушлай кушымтасы» дип тә рәнҗетә яза. Лукашевичның Үзәк Бюрога кандидат итеп күрсәтелүе гайре табигый була, әлбәттә.

Лукашевичны үткәрмиләр. Әмма ул ОГПУ органнарында Көнчыгыш районнар белән эшләү дәверендә, шул чакта каршы тавыш бирүчеләргә һәм, әлбәттә, Фирдәвескә үзенең кем булуын бер генә мәртәбә искә төшермәс әле...

Аларның Үзәк Комитетка язып биргән дәгъва кәгазендә Мирсәет Солтангалиев Корылтай делегатларына басым ясауда гаепләнә. Башка дәлилләр табылмый.

Әмма 1919 елның 13 декабрендә РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросының Ленин җитәкчелегендә үткән утырышы түбәндәге карарны кабул итә.

*«Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Бөтенроссия съезды делегатларының байтак өлеше, шул исәптән Башкортстан коммунистлары каршы булуы сәбәпле, Татар-Башкорт республикасын булдырмаска һәм Милләтләр эше халык комиссариатының 1918 елның 22 мартында Татар-Башкорт республикасы турында кабул иткән декретын кире кагарга.*

*Партия әгъзаларына алга таба Татар-Башкорт республикасын яклап агитация алып бармаска тәкъдим итәргә.*

*Татар республикасы хакындагы мәсьәләне башка вакытта карарга. Әлбәттә, татар коммунистларыннан шул хакта гариза килгән очракта гына карарга.*

*Үзәк Комитет секретаре өчен Елена Стасова».*

Һәм шуның белән вәссәлам. Тегe, кем әйтмешли, эшең бетте, кодагый! Тарихка тагы бер тамга салынды.

* * *

Политбюроның Татар-Башкорт республикасы язмышына нокта куйган утырышы һәм аның нәтиҗәләре хакында Көнчыгыш фронтка китеп барган Солтангалиев юлда, Самарага килеп төшкәч кенә ишетә.

Шундук Сталин белән турыдан-туры элемтәгә керә ул. Үзенең соңгы дәрәҗәдә ачынуын белгертә. Җаваплылыкны үз өстенә алмый Сталин, Ленинга һәм Политбюро утырышында чыгыш ясаган иптәшләргә аудара.

Шулай ук Самарада булган Троцкийдан рөхсәт алып, кире Мәскәүгә әйләнеп кайтырга мәҗбүр Мирсәет. Әмма Ленин янына үтеп керә алмый, әлеге дә баягы Елена Стасова ишеккә аркылы баса, каршы төшә.

Соңгы чара кала: хат язу. Һәм, Лев Троцкийның Мәскәүдәге элемтәчеләреннән файдаланып, хатны шул көндә үк Ильичның үз кулына тапшырттыру.

Өстәл янына утырды. Каршысында Политбюро утырышының стенограммасы. Ак кәгазь һәм каләм:

*«РКП(б) Үк Политбюросына.*
**ип. Ленинга.**

*РКП(б) Үк Политбюросының шушы елның 13 декабрендә үткән утырышында Татар-Башкорт республикасының дошманнары Эльцин һәм Исрафилбәков сөйләгән уйдырмаларга фактик төзәтмәләр.*

*Ип. Б. Эльцин, башкортлар тулысынча Татар-Башкорт республикасына каршы, дип күрсәткән. Һәм шунда чуваш һәм марилар да каршы диелгән.*

*Бу дөреслеккә туры килми.*

*1. а) Уфа, Пермь һәм Самара губерналарында яшәүче, автономияле Башкортстанга кермәгән башкортлар Татар-Башкорт республикасы яклы. б) Автономияле Башкортстанның да ярлы-ябагайлары Татар-Башкорт республикасына кушылуны хуп күрә. в) Петроград фронтындагы Башкорт дивизиясе һәм Башкорт бригадасы тулысынча Көнчыгыш коммунистлары корылтае резолюцияләрен яклап чыктылар.*

*2. Чуваш, мари (чирмешләр) һәм керәшен татарлары, үзләренең җаваплы партия эшлекләләре йөзендә, Татар-Башкорт республикасы ягында. Үзәк бюрода шуны раслый торган официаль мәгълүматлар бар.*

*Ип. Исрафилбәков (Татар-Башкорт мәсьәләсенә һичнинди мөнәсәбәте булмаган очраклы Кавказ эмигранты) әйткән, имеш:*

*1. Корылтайда доклад ясаучылар, әгәр Татар-Башкорт республикасы мәсьәләсе үтмәсә, Татар-Башкорт хәрби көчләре фронтны ташлап китәчәк, дип куркытканнар.*

*2. Корылтайда катнашучыларның күпчелеге элгәреге сул эсерлар һәм яшь коммунистлардан гыйбарәт булган.*

*3. Докладчыларның да берсе сул эсерлардан.*

*4. Тавыш бирүдә битарафлык күрсәтүчеләр һәммәсе Татар-Башкорт республикасына каршы булган.*

*Хакыйкатьтә болар һәммәсе ялган.*

*1. Татар-Башкорт хәрбиләрен фронттан чыгару турында сүз чыгаручы да булмады. Киресенчә, Үзәк мөселман хәрби коллегиясе вәкилләре «акгвардиячеләрне тар-мар иткәнгә кадәр аяусыз көрәшергә» дигән лозунг игълан итте.*

*2. Элек сул эсер булган Татар-Башкортлар Корылтайда ни рәвешле күпләп катнаша алсын икән?! Мәгълүм ич, РКП(б) ҮКның карары белән партия стажы 1919 нчы елга кадәрге иптәшләр генә делегат булып сайлана алды. Ә Татар-Башкорт сул эсерлары, мәгълүм булганча, коммунистлар партиясенә агымдагы елның февраль-март айларында гына күчте. Корылтайда катнашса да, күп дигәндә, кайчандыр сул эсер булган өч-дүрт иптәш катнашкандыр. Алары да активлык күрсәтмәде.*

*3. Доклад ясаган Солтангалиев, Борындыков һәм Сәетгалиевләрнең берсе дә һәм һичкайчан сул эсер булмады. Солтангалиев белән Сәетгалиев исә РКП(б)га Октябрь революциясенә кадәр кергән.*

*4. Битараф калучылар 14 кеше иде. Шулардан «Гуммәт» фиркасе әгъзасы Әфәндиев Корылтайда Татар-Башкорт республикасын яклап чыгыш ясады. Кече Башкортстан вәкилләре алдан ук тавыш бирүдә катнашмаска килешеп килгәннәр иде. Аларның берсе дә Татар-Башкорт республикасына каршы сөйләмәде, киресенчә, моны якладылар.*

*Корылтай рәисе һәм Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмалары Үзәк бюросының Вакытлы рәисе: М. Солтангалиев».*

Әлеге хат, әлбәттә, язылган көнендә үк Владимир Ильичка барып ирешә. Юлбашчының аны дикъкать белән укыган булуы да хакыйкать. Кызыл һәм зәңгәр карандашлар белән сызылган юллар һәм бихисап тамгалар шул хакта сөйли.

Әмма бу мәсьәлә уңаеннан язылган әлеге хат кына түгел, дистәләгән-йөзләгән күп кенә башка документлар да җавапсыз кала. Политбюроның 13 декабрьдә кабул ителгән карарына каршы чыгуда, мәсьәләгә кире әйләнеп кайтуны таләп итүдә Солтангалиев берьялгызы булмый. Мисал өчен, Мидхәт Борындыков белән Измаиль Фирдәвес Үзәк Комитетка кереп, партия билетларын өстәлгә ташлау белән дә янап карыйлар.

Мәскәүне алай гына куркытып буламы соң?! Мәскәү — күз яшьләренә ышанмый ул.

* * *

Татарстан автономиясе игълан ителү үзеннән-үзе һәм җиңел генә булган, диючеләр нык ялгыша. Татар халкы элек-электән яшәп гомер иткән мәйданнарның өчтән бер өлешен милли республика дип таныту да әйтеп бетергесез зур, тавык та чүпләп бетерә алмаслык күп каршылыкларга дучар ителә.

Мирсәет Солтангалиев җилкәсенә төшә йөкнең авыры. Сәетгалиев, Борындыков, Фирдәвес, Борһан Шәрәф һәм Шамил Усманов кебек дистәләгән җәмәгать эшлеклеләре баш күтәрми эшли, төрле ыгы-зыгы, ясалма киртәләр чоңгылына кереп чума.

Әле шул чорда, ягъни 1920 елның март-апрель айларында ук, Солтангалиевнең Татарстан республикасын оештыру мәсьәләләре әйләнәсендә барган бәхәсләрдә кайбер җитәкчеләр белән җитди конфликтка керүе мәгълүм була. Хәтта аны эшеннән алалар икән, Солтангалиевне үтергәннәр икән, дигән төрле имеш-мимешләр тарала Казанда.

21 апрель көнне Шамил Усманов Мәскәүгә Сәхипгәрәй Сәетгалиев исеменә телеграмма сугарга мәҗбүр була:

«Монда Сезнең һәм Солтангалиевнең кулга алынуы турында гайбәт таратыла. Татарстан җөмһүриятенең хәле турында бернинди дә хәбәр булмавы бу гайбәтнең көчәюенә китерә, деморализацияли. Мондый хәбәрләрнең провокация икәнлеген раслаучы телеграмма җибәрүегез сорала».

Һәр җөмләсе, һәр сүзе һәм тыныш билгесенә кадәр авыр бәхәсләрдә туган декрет, ниһаять, игълан ителә. Татарстан автономиясе төзү турындагы бу тарихи документ 1920 елның 27 маенда В. Ленин, М. Калинин һәм А. Енукидзе тарафыннан имзалана.

* * *

Җәйге чиллә вакытында Мәскәүдә сулыш алырга да авырлашып киткән бер ара була. 1920 ел бу җәһәттән аеруча хәтергә уелып калырлык. Кояш аяусыз кыздыра. Яңгыр тамчысы төшмәгәнгә атналар, айлар

тулды. Яфраклар вакытсыз саргаеп көйде. Ник бер җил исеп куйсын икән дә, җанга, табигатькә иркенләп сулыш алырлык бер халәт тусын икән...

ундый көндә иртәдән-кичкәчә дүрт стена эчендә кабинет саклап утырырга мәҗбүр Солтангалиев. Ул җәйдә, ни сәбәпледер, Сталин шактый озакка югалып тора Мәскәүдән. Украинада Троцкийга каршы оештырылган фетнәне оештыручы Сталин булган икән, дип, имеш-мимешләр дә сөйләделәр. Янәсе, шуның өчен, Кавказга сөргенгә сөрелгән икән. Юк сүз, әлбәттә. Ә аның урынбасары булган Каменский авырып киткән. Шул сәбәпле, Милләтләр эше халык комиссариатында Мирсәет, вакытлыча, Сталинны алыштырып торырга мәҗбүр була.

Соңгы арада Төркиянең күренекле әдәби һәм гыйлем иясе Зыя Гөкальп белән хат алыша башлаган иде ул. Йосыф Акчура биргән аның адресын. Беренче хатны укыгач та, гаять кызыклы һәм бай рухлы кеше буларак җәлеп итте аны Гөкальп. Әле менә бүген иртән генә чираттагы хатын алды аның, шуңа җавап сырлап утыруы. Әмма кәеф яклары барыбер әллә ни шәптән түгел.

Ишек шакыдылар.

— Мирсәет Хәйдәргалиевич, сезне битләрен сакал-мыек баскан ниндидер сәер бер иптәш сорый,— диде секретарь кыз.— Мосафир булса кирәк. Үзенең кем булуын әйтми. Нәрсә диим?...

— Керсен.

Ишектән керүчене танып, хәйран калды Солтангалиев. Зәки Вәлиди иде бу.

— Сталин юк икән. Синең янда утырып чыгыйм бераз,— дип, кергән шәпкә түргә узды Вәлиди.

Үпкә белдерер, чытык чырай күрсәтер сәбәпләре байтак булса да, сиздермәде, йөзенә чыгармады Мирсәет. Мөмкин кадәр итагатьлерәк булырга омтылып, ике кулын сузып сәлам алды, урын тәкъдим итте.

— Әйдүк, рәхим итегез, Зәки әфәнде! Соңгы араларда нишләптер сирәкләдегез.

— Сирәкләү генә түгел, табанны ялтыратыр вакыт җитте,— диде ул, ишектән килеп кергәндәге кырыслыгын югалтмыйча.

— Йә, Зәки әфәнде, мондый чуллэдә ни язмышлар юлга чыгарга мәҗбүр итте үзегезне? Сөйләгез, бәлки мин ярдәм итә алырмын.

— Өметләнмим. Әмма ике-өч авыз сүз алмашып алырга була.

Өстәл артындагы урынына кереп тормады Мирсәет, Вәлидинең каршысына ук килеп утырды.

— Сезнең белән, Зәки әфәнде, сөйләшәсе сүзләр байтак. Кайсыннан башлыйк икән соң? Әллә, юлдан килгән кеше буларак, әүвәле чәйләп алабызмы?...

— Рәхмәт. Чәй эчкән бар ла ул.

Шаярып әйтелгән сүз түгел иде бу. Маңгаена катлы-катлы җыерчыклар чыкты аның. Утыз яшьлек ир-ат үзе. Баксаң, чигәләренә дә «кырау» төшкән икән.

— Тыңлыйм, Зәки әфәнде.

Вәлиди, утыргач җиреннән, киерелеп, башын артка ташлап алды. Бу аның күптәнге гадәте.

— Алдадылар. Сүзләрендә тормадылар...— диде ул. Рәнҗетелгән, җаны әрнегән кеше генә шулай сөйли. Шаярмый Вәлиди.— Ленин да, Сталин да — ике чабата бер кием булып чыктылар. Үзләренә кирәк чакта тау вәгъдә иттеләр, хәзер чүпкә дә санамыйлар безнең ишеләрне.

— Ялгышмыйсызмы, Зәки әфәнде?!. Андый гомумиләштерүләр ясарга ашыкмагыз.

— Мин аларга ышандым...— дип, янә беркат башын чайкап торды ул. Күзләрендә әрнеш, еламый гына.— Сугышчыларымны бирдем. Колчакны кудык. Партияләренә кердем. Ни сорасалар, шуны эшләдем... Ә алар?!. Алар, автономия дигән сүз белән алдады.

Жанланып куйды Мирсәет. Аның да җанынннан сирпелеп чыкты сүзләр.

— Үзегез сорадыгыз. Үзегез теләдегез ич, Зәки әфәнде. Мине тыңламадыгыз. Берөзлексез аяк чалу, таяк тыгу булды шөгылегез.

— Тыкмадым! Минем ышанганым шул иде, Мирсәет,...— Уйга калып торды Зәки Вәлиди. Тагы нидер әйтергә тели, әмма әйтә алмый газаплана кебек иде ул.

— Сөйләгез, Зәки әфәнде, сөйләгез. Беләсез, мин сезгә һәрчак ышандым. Иң авыр көннәрдә дә каты бәрелмәдем үзегезгә. Кул бирмәм, дигән сәгатьләрем булды. Әмма тешне кысып түздем.

— Шулай да бер гаебем бар синең алда,— диде Вәлиди, тавышын бермә-бер салмакландыра төшеп.

— Беләм, Зәки әфәнде. Сез ул гаептән инде һичкайчан арына алмаячаксыз. Татар белән башкорт арасына сез тарихта җуелмаслык ызан ясап калдырдыгыз.

— Түгел лә...— дип, кабаланып кулын селтәде Вәлиди.— Ызанны аны бетереп тә була... Белмисең шул, синең каршыда минем зур гаебем бар.

— Ул нәрсә тагы?

— Мин бит... Мин бит...— дип, тотлыгып торды ул. Һәм пышылдауга күчеп, әйтеп салды.— Сталин кушканча эшләдем боларны.

— Нәрсә? Кече Башкортстан да аның кушуы буенчамы?!.

— Түгел лә, Кече Башкортстан — минем үз улым кебек ул. Тимә аңа.

— Соң, шулай булгач...

— Хәтерендәме, узган ел ахырында Көнчыгыш коммунистларының Корылтаен уздырдыгыз?... Минем кушу буенча тавыш бирүдән баш тартты Башкортстан вәкилләре. Ә миңа моны Сталин тәкъдим итте. Политбюро утырышы белән дә шул ук хәл... Аңладыңмы?!.

— Төшендем. Бик зур хата ясагансыз.

— Беләм, Мирсәет, синең каршыда гаебем зур минем. Шуңа да яныңа үзем килдем.

Мирсәет хәтереннән үткәннәрен барларга кереште. Хакыйкать белән Вәлиди сөйләгәннәрнең очы-очка ялгана иде.

— Минем каршыдагы гаебегезне тану бер хәл, Зәки әфәнде. Мин гафу да итәрмен. Ә менә халык каршындагы, гомер-гомергә бер ана балаларыдай дөнья кичергән татар һәм башкорт хезмәт ияләре алдындагы хата гафу ителерме?!. Әйтеп булмый.

Кинәт, урыныннан сикереп торып, үз-үзен кая куярга белмичә ишекле-түрле йөренергә кереште Вәлиди. Гайрәте ташып тора. Ә җаны яралы.

— Мин ихлас күңелдән ышанган идем, Мирсәет. Кече Башкортстанны башкорт кавемен саклап калуның бердәнбер юлы дип белгән идем. Иген игеп, киек-җәнлек атып, алтын сатып ипле генә яшәтәсем, данын күтәрәсем килгән иде башкортларның. Булмады шул... Алдадылар... Алдадылар. Бәгыремә хәнҗәр кадасалар, җиңелрәк кабул итәр идем. Эх...

— Башкортстан бар, Зәки әфәнде. Ниһаять, менә Татарстан да игълан ителде...

— Кече Татарстан,— дип, төзәтмә кертте Вәлиди.

— Шулай килеп чыга. Кече Башкортстан... Кече Татарстан... Минем башка килмәгән булыр иде әле бу сүз.

Вәлиди һаман ишекле-түрле йөренә. Урын таба алмый үзенә.

— Исеме генә республика ич аларның,— дип, кул селтәде ул, ниһаять.— Тегеләй итмә, болай итмә. Бер хокукың булмасын! Автономия шул буламы? Күз буяу гына ич ул. Әнә, бездә иң элек Исмагиловны бутадылар тизәк белән. Аннан — миңа җитте чират. Үзләренә йомышка ярый торган Шәмигуловны китереп куйдылар...

— Сез шуңарга омтылдыгыз, шуңарга ашкындыгыз, Зәки әфәнде.

Мирсәетнең каршысына килеп, ниһаять, тукталып калды Вәлиди. Аның күзләренә текәлде. Гайрәтле, көчле иде үзенең күз карашы.

— Авыр миңа, Мирсәет. Мин бу рәвешле, кул кушырып, күзгә төтен җибәрүче Ленин, Сталиннардан мәрхәмәт көтеп утыра алмыйм.

— Нишлисең, Зәки әфәнде, гомер кичерү — сират күпере аша узу, димәсләр иде аны. Безнең дә, әнә, бәлки шул күпердән узган мәлебездер.

— Кылдан нечкә, кылычтан үткер сират күпере ашамы?!. Без синең белән шул күпернең кыл уртасында хәзер. Һәм янәшә, Мирсәет...

— Янәшә булырга тиешле идек! Чынлыкта без сират күперенең икебез ике очында инде хәзер. Янәшә түгел, Зәки әфәнде. Әмма, яшәргә, үз-үзебезнең хак булуыбызны исбат итәргә кирәк әле. Сират күпере аша узса да, меңнән бере генә узар диелгән түгелме?!.

— Без тарих сынавын уза алмадык, дип әйтергә җыенасыңмы?!.

— Түгел, Зәки әфәнде. Сират күпере һәм тәмуг аша узар юлыбыз хакында фикер йөртә идек...

— Йә, йә,— дип, кызыксыну белдереп алды Вәлиди.

— Шуны әйтергә телим, без, бәлки, уза да алмабыз ул күпер аша. Ә халкыбыз ул күперне, иртәме-соңмы, бер кичәргә тиештер бит?!. Сез ничек уйлыйсыз, Зәки әфәнде?...

— Шулай уйлыйм: бер кеше саташса — ул уза. Әмма бөтен ил һәм милләтләрне саташтыру — җинаять... Җинаять әлегә дәвам итә.

— Туктагыз,— дип, тавышын күтәрде Солтангалиев.— Җитәр!

— Болары калып торсын, хәзергә җитәр. Мин бит янына киңәш сорап кердем, Мирсәет. Башкорт һәм казах-кыргыз арасына урыс өлкәсе ясап киртә корырга җыеналар ич, әнә. Ата-бабадан килгән уртак далага хуҗа булырга икән исәпләре... Төркестанга качып, яңадан көрәш башларгамы? Ишеткәнсеңдер, Морзабулатов та Урал тауларына качты. Әйт, нишлим икән?

Сорау җиңел түгел. Үзенне Вәлиди хәленә куеп карамый торып, җавап бирергә ашыгу ярамый иде бу очракта. Сорауга сорау белән җавап кайтарды ул:

— Сталинга да шул сорауны бирергә җыенган идегезме?

— Юк. Аңарга Вәлиди кирәк түгел инде хәзер. Вәлиди үз җырын җырлады алар өчен... Мин аның күзенә карар өчен килдем. Очратсам да, бер сүз әйтмәс идем, күзенә генә караган булыр идем. Уңайсызланыр идеме икән бер?!. Бармы икән аның ояты?!.

— Булмас эш белән мавыкмагыз, Зәки әфәнде. Алай эшләргә киңәш итмәс идем.

— Ни киңәш итәр идең?

— Белмим, Зәки әфәнде. Үзеңә кара.

— Эх,— дип, бер көрсенде дә шунда, күз ачып йомганчы, ишек катында куеп кергән юл капчыгын кулына эләктереп, кабалана-кабалана чыгып та китте Зәки әфәнде. Башка бер сүз дә әйтмәде.

Мирсәетнең тукталырга, алай кызу баштан хәл кылмаска әйткән сүзләрен тыңлар, колагына эләр хәлдә түгел иде инде ул...

Мирсәет: «Китмә!» — дип әйтергә тиеш булгандыр, бәлки. Әмма, теле әйләнмәде алай дияргә. Ни өченме? Чөнки аңарга Зәки Вәлидинең бүген булмаса, иртәгә, кулга алынырга тиешлеге яхшы мәгълүм иде. Тиешле органнарга әмер җиткерелгән. Эзлиләр, таба гына алмыйлар иде үзен. Кайда икәнлеген белмиләр. Бусы — бер булса, икенчедән, сул татар коммунистларының Оренбург группасы тарафыннан да Вәлидигә инде хөкем чыгарылган иде ул көннәрдә. Аны бүген булмаса, иртәгә почмактан атып үтерүләре ихтимал. Хөснулла Тарпищевның Ибраһимов фамилияле бер танышына Самарадан Мәскәүгә җибәрелгән хатында бу операциянең бөтен нечкәлекләренәчә җентеклэп язылган. Куркынычсызлык органнары кулына кергән ул хатны Мирсәет үз кулында тотып укыды.

Ни намусы җитеп «китмә!» дип әйтә ала иде соң ул аңарга... Шул китүдән кайтмады Зәки Вәлиди.

* * *

Бер-ике көннән Кавказдан әйләнеп кайткан Сталин Мирсәеттән кат-кат Вәлидине сорап аптыратты.

— Табарга кирәк. Аны кулдан ычкындырырга ярамый,— диде ул һаман, Уфадан килгән телеграмма нөсхәсен кулында болгап.— Мә, укы. Ашыгыч рәвештә җир тишегеннән булса да табып кайтаруыбызны үтенәләр. Халык таләп итә. Милләтчеләрне үз кулы белән сытарга әзер безнең алдынгы карашлы пролетариат...

— Ярдәм итә алмыйм. Белмим,— шул булды Мирсәетнең җавабы. Чынлыкта да белми иде ич ул аның кайда икәнлеген.

Атналар, айлар үткәч кенә, суга төшкән балтадай югалып торган Зәки Вәлидинең Төркестанга барып чыгып, тагы Советларга каршы көрәшүчеләр сафына килеп кушылганлыгы мәгълүм булды.

* * *

— Нинди борчуларың бар, Мирсәет? Ни уйлап ятасың, төнозын йокламыйсың...

— Катлаулы һәм хәтәр елларга кереп барабыз, Фатыйма. Уйлана башласаң, чәчләрең үрә торырлык...

— Нәрсә, кем өчен борчыласың?— дип сорады да, янә үрелә төшеп, янәшәдә генә эленеп торган бишектә изрәп йоклап яткан сабыеның өстен ябып куйды Фатыйма.

— Ярар, Фатыйма, синең башны да катырмыйк әле. Үземә дә җитеп ашкан. Җимерәбез дә җимерәбез... Шул, җимерергә һәм сугышырга өйрәндек, башкача куандырган эшебез юк... Патшаны төшердек төшерүен, әмма идарә итү ысуллары элеккечә үк торып калды. Куркыту һәм мәҗбүр итү... Тыю һәм чикләүләр... Кайчан ахыры булыр боларның?!. Хезмәт иясе һәм милләтләр турында кайгырту—сүздә генә... Штыклы мылтык демократиясе килә илгә. Менә нәрсә куркыта, Фатыйма...

— Безгә тимәсләр әле,— шул булды яшь хатынның сүзе. Тагы ни дия ала соң ул?!. Үрелеп, бишеккә күз төшереп алды...

Таң беленеп килә. Әле күзләренә йокы кергәне юк. Кулларын башы астына салып чалкан ятты да, күзләрен йомды Мирсәет. Үз-үзен битәрләп куйды, Фатыйманы үзе өчен дә бигүк аңык булмаган уйлары белән борчымаганда да яхшы буласы икән. Һаман Рауза белән бутый иде бугай ул аны. Раузаның белмәгәне, ишетмәгәне юк, һәр күренешкә үз карашы була торган иде. Сәясәттә киңәшче дә, фикердәш тә иде бит ул Мирсәет өчен... Ә Фатыйма аның нәкъ киресе, сәясәткә, гомумән, катнашырга теләми, сәясәтне ир-ат эше диеп кенә саный. Һәм ул хаклы да булса кирәк! Аның каравы кайгыртучан ана һәм ир кадерен күреп, өйгә җан җылысы өреп яши белә торган хатын иде Фатыйма.

Күз йомылса да, йокы керми. Үзе дә белешмәстән, әле соңгы көннәрдә генә Үзәк Комитетта булган сөйләшү һәм бәхәсләрне барларга керешкән түгелме соң... Болары да хәтер иләге аша беренче кат кына узмый.

Татарстан игълан ителгән көннәрдә Уфа губернасының автономияле Башкорт республикасына кермәгән өязләре хакында сүз булган иде. Аларда яшәүче халык, нигездә, татарлар. Димәк, нинди күзлектән чыгып карасаң да Татарстанга кертелергә тиешле иде алар. Мирсәет шуны яклап ахыргача тырышты.

—Тау кәҗәсе сыман үҗәт син, Солтангалиев,— дигән иде аңарга шул чакта Сталин.— Халыкның фикерен белербез дә, һичшиксез, хәл итәрбез, син дигәнчә булыр.

Инде күпме гомер узып бара. Ә йөк һаман шул урында, кымшатырга да теләүче юк. Бөре һәм Бәләбәй өязләре бу мәсьәләнең тизрәк хәл

ителүен көтә. Ә Мирсәетнең ашыктырырга теләп әйткән һәр тәкъдиме, иске чабата сыман, күптән туйдырып бетергән. Бер үк сүзләр белән каплана да куела.

— Бер ара табылыр әле. Кая ашыгасың шулай?!

Хуш, Совнарком карарында искәртеп үтелгән бу мәсьәлә иртәмесоңмы бер хәл ителер, боерган булса. Ә менә төрле сылтаулар табып, Бакуда узачак Көнчыгыш халыклары Корылтаена үзен җибәрмәүләрен ничек аңларга?... Бөтен Көнчыгыш вәкилләре тарафыннан Үзәк бюро рәисе итеп сайланган кешенең Корылтайга бармый калуы җәмәгатьчелек тарафыннан ничек кабул ителер?!.

Ярар, ул хакта уйламавың яхшы. Гарьлегеңнән, күңел рәнҗүеннән шартлап үләрлек!

Башкортстандагы вакыйгалар тагы да хәвефле һәм тагы да аянычлырак. Морзабулатов восстаниесе үскәннән-үсә барып, гаять зур мәйданнарны биләп алды. Бу бит Урта Азиядәге басмачылык хәрәкәтенә әверелеп бара... Әнә, нинди нәтиҗәләргә китерә ул гади халык ихтыяҗы белән санашмау, милли мәсьәләне бар дип тә белергә теләмәү!... Ә югыйсә һәммәсе Советлар ягында иде бит, революцияне яклап утка-суга кергән егетләр...

Фетнә диләр... Юк, фетнә түгел бу. Түзәр әмәле калмаган башкорт халкының үз-үзен һәм табигый хокукларын яклап көрәшкә күтәрелүе. Әлеге хәрәкәтнең башында торучы Морзабулатовны Мирсәет күреп, танып белә иде ич. Килде-китте кеше түгел, үзвакытында авыл мөгаллиме булган, унҗиденче елдан коммунист, БашЧеКаның җаваплы хезмәткәре иде.

Инде хәзер Зәки Вәлиди ачуын, Морзабулатовка булган үчне бер гаепсез башкорт мужикларын тураклап кайтаралар. Тездән кан ерып барган Поленов һәм Руденко экспедицияләре шуннан гайре түгел ләбаса...

Башкорт халкының язмышы, ул күргән бәла-казалар өчен дә әрни иде Солтангалиевнең җаны. Юк, үзе башкорт арасында туып-үскәнгә генә түгел. Вакытында, юмалап-ышандырып ул йөрде ич. Революция язмышы кыл өстендә торган чакта, Зәки Вәлиди аның сүзләренә ышанып, Ленин белән килешүләр өстәле янына утырды. Башкорт егетләре Колчакны кыйнады...

Әле кичә генә Польша фронтыннан Мәскәү аша кайтып баручы Муса Мортазин белән очрашуы да шул борчылулары нәтиҗәсе. Һичкемгә әйтмәде, белгертмәде ул моны, Казан вокзалында икәүдән-икәү генә күрешеп сөйләштеләр.

Муса Мортазин ул тарафларда билгеле кеше. Аның сүзе үтә. Юкка гына «башкорт батыры» дип, олылап искә алмый торганнардыр үзен. Буе ике метрга ашкан пәһлеван гәүдәле зат бер ул гына түгел.

— Кайт, аңлат, зинһар,— дип, гозерләп үтенде ул Муса Мортазиннан.— Баш күтәрүчеләр сине тыңламый булмас, башкорт халкын һәлакәткә илтә торган эш бу. Мөмкин кадәр тизрәк килештер үзләрен. Совет хөкүмәтеннән битәр, бу солых, бу иминлек иң беренче чиратта башкорт өчен кирәк.

Аз сүзле кеше Мортазин. Әмма әйтте исә, кисте дигән сүз. Бу юлы да тыңлап торды-торды да...

— Аңладым,—диде.— Кулдан килгәнчә тырышырмын.

Тагы ике-өч айдан шул сөйләшүнең бер нәтиҗәсе дә булыр. Урал итәкләренә кайтып төшкәч тә Муса Мортазин башкорт мужикларыннан партизаннар отряды оештырып җибәрә. Гаделлеге мәгълүм кеше буларак, ышаналар аңа, ияръләр. Һәм ул берәр мәртәбә Морзабулатов егетләрен дә акылга утыртып ала, экспедиция сылтавы белән башбаштаклык иткән, чаманы онытып җибәргән кызылармиячеләрне дә үзе белән исәпләшергә мәҗбүр итә. Совет хөкүмәте белән башкорт халкы арасында, шул рәвешле, янә солых төзелә, мәгънәсез кан коюларга чик куела.

* * *

Гаҗәп кеше бу Сталин. Үзе Төркиягә җибәрелергә тиешле төрек коммунистларын, төрле сылтау табып, һаман тоткарлап килде. Мостафа Сөбхигә ышанмавы белән аптыратты. Инде барысы да көйләнгәч, Төркиягә җибәрәсе урынга, үзләрен, әле Кырымга озатып, әле Төркестанга, әле Бакуга күчереп, бер сәбәпсезгә тозлап яткырдылар. Инде хәзер, эш узгач, төрек мәсьәләсендә елгырлыгын житенкерәмәде дип, Солтангалиевне битәрли. Ә чынлыкта, киресенчә, Мирсәет Сталинны битәрләргә тиеш булгандыр бу очракта. Чөнки, башка һичкем түгел, Төркия, Иран һәм Әфганстан кебек илләрдә барган азатлык хәрәкәтләренә нәкъ менә ул — Сталин битарафлык күрсәтте.

— Иптәш Сталин, безнең татар халкының бер матур әйтеме бар. «Үткән эшкә — салават» диләр. Салават күперен тота алмаган кебек үк, үткән-булган вакыйгаларны да кире кайтарып булмый дигән сүз бу. Димәк, безгә бүгенгесе хакында уйларга кирәк.

— Үз татарыңны тыгасың һаман,— дип, битараф рәвештә, чебен кугандай сәламәт кулын селтәп куйды Сталин.— Төркия хакында сүз бара.

— Төркиядә солтанатны яшь төрекләр алмаштырды, иптәш Сталин. Белүемчә, хөкүмәт башына килгән Мостафа Кемалның сәясәте халык массалары тарафыннан хуплау таба. Димәк, безгә Кемал әфәнде белән эшләргә туры киләчәк. Ирандагы Кечек-хан хәрәкәтенә дә битарафлык күрсәтеп, хаталанабыз кебек.

— Буржуаз-милләтчеләрне якларга, хупларга чакырасызмы?!.

— Халык массалары кемгә ияр, без шул житәкчегә йөз тотарга тиеш диеп беләм.

— Тиеш...— дип, янә, ияләнгән гадәтенчә кулын гына селтәде Сталин.— Акыл сатарга яратасың. Менә нәрсә, анда Ленин тирәсендә ниндидер төрек һәм әфган милләтчеләре бутала башлады. Шулар белән безгә элемтә урнаштыру кирәк... Бу эшне син, бары тик син генә башкарып чыга аласың, Мирсәет.

— Ярый, иптәш Сталин, мин кызыксынырмын...

Күңеленнән уйлап куйды: әллә Ленин өстеннән контрольлек кылучы итәргә җыенамы ул аны?!. Үзе өчен кирәк булганда гына, әңгәмәдәшенә, шул рәвешле, якын итеп, исеме белән дәшә торган гадәте бар Сталинның.

Әңгәмәне тәмамланганга санап, чыгу юлына юнәлгән Солтангалиевне бераз тоткарларга кирәк санады Сталин. Чөнки үзе өчен әлегә бигүк ачык булмаган нәрсәләр күңеленә тынгылык бирми иде, күрәсең.

— Мирсәет, син ничек уйлыйсың, иптәш Ленинның төрек мәсьәләсендә активлаша төшүе ни сәбәпле булыр?!.

— Ильич өчен җавап бирә алмыйм, иптәш Сталин.

— Шулай да?...

— Монда гаҗәпләнер урын юк, дип беләм, иптәш Сталин. Төркия — безнең ут күршебез.

— Күршеләр аз түгел алар...,— дип, әңгәмәдәшенә куәт биреп торды Сталин, тагы да ачыграк җавап көтте.

— Көнбатыш тарафта — империалистлар. Аңлашылса кирәк...

— Көньякта һәм Көнчыгышта да күршеләр аз түгел. Төркия шуларның берсе генә... һәм иң зурысы да түгел.

— Зурлык яисә кечкенәлек чагыштырма төшенчә, иптәш Сталин. Төркиягә мөнәсәбәтле ул кызыксыну табигый булса кирәк. Һәм менә ни сәбәпле.— Кулындагы бармакларын бөгә-бөгә санарга кереште Солтангалиев:— Беренчедән, Төркиядә милли-азатлык хәрәкәте көчле. Димәк, бу безне Көнбатыш империализмына мөнәсәбәттә берләштерә торган фактор. Икенчедән, Россиянең өчтән берендә диярлек төрки милләтләр

яши. Бу шулай ук искә алынырга тиешледер. Өченчедән, Төркия — Кара диңгез дигән сүз, ул чит мәмләкәтләр белән элемтә юлы... Әлбәттә, башка сәбәпләр дә җитәрлек, әмма болар белән исәпләшмәү бүгенге шартларда мөмкин түгел...

Дикъкать белән тыңлап торды, югыйсә. Күңеленнән, карале син моны, дөрес фикер йөртә, дөрес аңлата бит, дип хуплап та барды әле. Әмма Сталин үзе булып калды. Бу очракта да рәхмәттән качу юлын тапты бит әнә. Үзалдына мыгырданып, битараф кына әйтеп куйды:

— Бер яңалык та ачмадың. Болар миңа күптән мәгълүм иде...

Хәер, Мирсәет үзе дә яңалык ачам дип сөйләмәгән иде бит.

* * *

Сталин белән ике арада булып узган шул сөйләшүдән соң атна-ун көн үттеме икән, Солтангалиевне Ленин янына чакырттылар.

Очрашып, ике-өч авыз сүз белән хәл белешкәч тә Владимир Ильич аңарга чакыруының сәбәбен аңлатты.

— Иптәш Солтангалиев,— диде ул, гадәтенчә, әңгәмәдәшенә сынаулы, хәйләкәр карашын төбәп.— Тагы ярты сәгатьтән миндә Төркиядән килгән вәкилләр булачак. Шул сәбәпле үтендем керүегезне. Иң элек киңәш-табыш итеп алыйк. Һәм берочтан тәрҗемәче буларак та ярдәмегез кирәк булыр...

— Кулдан килгән кадәрле ярдәм итәргә әзермен, Владимир Ильич,— дип, үзенең бик теләп ризалашуын белгертте Мирсәет.

Гадәттә, Төркия, Әфганстан вә Иран вәкилләре килгән чакта, алар белән тәрҗемәче сыйфатында Габдерәшит казый Ибраһимов яисә Муса Бигиевнең чакыртылуы мәгълүм иде аның өчен. Ленинның мондый йомыш белән Солтангалиевкә беренче тапкыр мөрәҗәгать итүе.

— Кемнәр килгәнлеге мәгълүмдер бит, Владимир Ильич?

Сорау урынлы иде, күрәсең. Җанланып аңлатырга керешде Ленин:

— Әнә, хикмәт нәкъ шуңарда да инде. Кемнәр килгәнлеге мәгълүм дә, түгел дә кебек шул бер үк вакытта. Гомумән, без бит төрекләрне, шул исәптән, Төркияне дә бик аз беләбез. Белгән атлы булсак та, бик гадиләштереп, әйтер идем, примитивлаштырып күрергә, аңлатырга омтылабыз. Үзебезне һәркемнән югарырак, акыллырак санау, бөекдержавачылыктан арына алмыйбыз.— Ильич үзенең каршысында яткан бер кәгазь кисәген сузды Мирсәеткә.

— Исемнәре мәгълүм, таныша торыгыз. Әмма асылда кем булуларын әйтү кыен... Булган мәгълүматларның да очы очка ялганмый кебек.

Исемлекне күздән кичереп чыкты Мирсәет. Исемнәре колакка чалынган кешеләр күренә, әмма ашыгып нәтиҗә ясарга һәм шул нәтиҗәләрен Ленинга сөйләргә кирәк тапмады. Үзе мөрәҗәгать итте сорау белән:

— «Мәгълүматларның очы очка ялганмый» дигәнне ничек аңларга, Владимир Ильич?..

— Бик гади итеп. Бер карасаң, һәммәсе «кемалчы»лар, ә икенче яктан, үзләрен социалист яисә коммунист дип тәкъдим итәләр. Беренчеләренең ни рәвешле төрек коммунистларын Кара диңгез төбенә батырганлыгын сиңа сөйләп торасы юк.

— Әйе,— дип, башын түбән иде Солтангалиев. Мостафа Сөбхи һәм аның фикердәшләрен югалту ачысы әле дә йөрәген чеметеп-чеметеп куя иде.

— Мостафа Кемал кешеләре арасында коммунистлар булмас. Әмма яшь төрек җөмһүриятенең большевиклар Россиясе белән тату яшәргә омтылуына мин ышанам. Күреп сөйләшми торып, нәтиҗәләр ясау мөмкин түгел, Владимир Ильич.

— Килешәм,— диде Ленин, гоманлап утыруны шулай ук артык эш санап.— Әмма сиңа тагы бер соравым бар әле. Әйтә алмассыңмы: без бу

«кемалчы»ларны нинди дә булса идея белән үзебезгә җәлеп итә алабызмы?

— Алабыз,— дип, алдын-артын уйламастан әйтеп салды Мирсәет. Шуннан соң гына беркадәр уйга калып торды. Күңелендә йөрткән, үзе өчен ифрат дәрәҗәдә кадерле һәм әһәмиятле булган бер уй-фикере белән уртаклашырга ният итте ул, ниһаять.— Әле соңгы араларда гына бер төрек галименең яңа хезмәте белән таныштым мин, Владимир Ильич. Зыя Гөкальпның төреклекнең асылы хакындагы хезмәте белән.

— Йә, йә, дәвам итегез,— дип ашыктырды, кызыксынуын белдерде Ильич.— Төреклекнең асылы нидән гыйбарәт була икән?..

— Бүгенге Россиядә бик күп төрки халыклар яши. Алар төрле дәвер һәм төрле язмышлар белән бер уртак тамырдан чыгып аерылган, сибелгән. Дөрес, бездә бу уртаклык, рух һәм тарих уртаклыклары хакында сөйләү гадәткә кермәгән. Аерымлыклар хакында сөйләү, үзгәлек эзләү дәрәҗәле эш бездә. Әмма төрекләр башка... Россиядә яшәгән һәммә төрки халыкларны үз туганнары дип саныйлар алар... Әйтик, Татарстан, Башкортстан артыннан башка төрки халыклар да — Казах, Үзбәк, Төрекмән, Кыргыз, Әзербайҗан, Якут һәм Чуаш республикалары игълан ителеп, шулар һәммәсе Советлар Россиясе эчендә бер төрки конфедерациягә берләштерелсә, Төркия безнең мәңгелек юлдашыбызга әверелер иде.

— Әйе, әйе,— дип куйды Ленин.— Сезнең бу хакта миңа сөйләгәнегез бар иде кебек инде. Бу юлы да кистереп җавап бирүемне көтмәгез. Һәм сезгә дә, иптәш Солтангалиев, милли хисләр һәм милли тамырдан элегрәк, сыйнфыйлык һәм барлык милләт хезмәт ияләренең пролетар бердәмлеге хакында ешрак уйланырга киңәш итәр идем.

Бер мәлгә тынлык урнашып торды. Солтангалиевнең үз сүзләренә мөнәсәбәт белдерүен көтә иде Ильич. Ә Мирсәетнең исә үз уйларында чуалган чагы.

— Ник дәшмәдең, иптәш Солтангалиев, әллә сез башка фикердәме?— дип, сорарга кирәк санады Ленин.

— Килешәм, Владимир Ильич. Әмма туганлыкны һәм милли хисне сыйнфыйлык төшенчәсе яисә шактый абстракт булган интернационализм сүзе белән капма-каршы кую яисә алмаштыру дөрес түгелдер дип саныйм.

— Сезнең сүздә дә хаклык бар. Ләкин без, иң элек, большевик бит.

— Иң элек Кеше! Һәм шуннан соң гына большевик, Владимир Ильич...

Ленин Мирсәетнең логикасын ошатыпмы, әллә үҗәтлегенә сокланыпмы, башын чайкап куйды, мөлаем елмайды. Ни уйлаганлыгын һич белəм димә...

Шул мәлдә ишек ачыла төшеп, кунакларның кабул итү бүлмәсендә икәнлекләре хакында хәбәр иттеләр.

— Нәкъ бер минуттан керергә рөхсәт,— диде Ильич, катгый итеп.

«Бер минут» дигәне шул икән, Мирсәеткә бирәсе соравы калган.

— Мостафа Кемалга сәяси оппозиция бармы, булса аның башында кем тора, белмисезме, иптәш Солтангалиев?— дип, өстәл тартмасыннан ашыгычлык белән ниндидер кәгазь эзләргә кереште Ильич.

— Яшь төрекчелек хәрәкәтенең үзе эчендә ул каршылык. Аның башында Кара Бәкер-паша тора дип беләм.

— Әйе, шул үзе,— дип, җанланып куйды Ильич. Югалткан кәгазен эзләүдән туктады. Мирсәет авызыннан ишеткән исемне иҗекли-иҗекли кабатлап каршысындагы көндәлеккә теркәп куйды.

Ул арада, теге минут узган иде, күрәсең, Төркия вәкилләре килеп керде бүлмәгә. Алар дүртәү иде. Һәммәсе кара костюм, буйлы ап-ак күлмәктән. Якалары кушылган җирдә килешле кара күбәләк. Хәрби кием һәм френчтан башканы белмәгән большевиклар даирәсе өчен боларның киенүләре ук гайре табигый иде, әлбәттә.

Керүчеләр, берәм-берәм килеп, иң элек Владимир Ильич белән, аннан, шул ук тәртиптә Мирсәет белән ике куллап күрештеләр. Үзләре белән таныштырдылар.

— Йосыф-бәй.

— Доктор Фуад.

— Хәлил-паша.

— Әнвәр Бәрәкәтулла...

Боларның дүртенчесен — Әнвәр Бәрәкәтулланы күреп белә иде инде Солтангалиев. Ул Габдерәшит Ибраһимовның якын танышы һәм мәсләктәше. Байтактан Мәскәүдә бөтерелә.

Владимир Ильич кунаклар урнашып, үзләренә олы хөрмәт һәм итагатьлелек күрсәтеп чәй тәкъдим ителгәч кенә урынына утырды. Әңгәмәне башлап җибәрде. Мирсәет сөйләшүгә катышмады, бары тик тәрҗемә итү белән генә мәшгуль булды.

Әмма тора-бара аның өчен, тәрҗемә ителми калган, күп кенә башка мәгълүматлар да ачыкланды. Баксаң, бу рәсми делегация түгел икән. Мостафа Кемалның ышанычлы вәкиле буларак, тагы атна-ун көннән Бәкер Сәми-бәй киләчәк. Ә монда катнашучылардан исә Йосыф атлысы гына Мостафа Кемал яклы сөйләшә. Ә Фуад һәм Хәлил-паша күбрәк Кара Бәкер-паша тарафдарлары булып чыга икән. Бәрәкәтулла исә, Мәскәү хәлләрен белгән кеше буларак, сәяси әңгәмәгә артык катнашмады.

— Яңа Төркия тышкы сәясәттә Мостафа Кемал-пашаның «Өйдә — солых, дөньяда — солых» дигән сүзләре нигезендә яшәргә җыена. Күршеләр арасындагы сугышта җиңүче булмый. Большевиклар Россиясе белән дә Төркия имин вә аңлашып яшәүне кайгыртачак,— дип игълан итте Йосыф-бәй.

— Үзебезнең Көньяк күршебез Төркиянең тыныч һәм тату яшәүгә йөз тотуын без һәрьяклап хуплыйбыз. Мостафа Кемал әфәндегә шул хакта җиткерүегезне үтенәбез,— диде Ленин, ишеткәннәреннән күңеле булып.

Гомумән, әңгәмә ипле һәм үзара дустанә мөнәсәбәт шартларында узды.

Ленинның Кремльдәге кабинетыннан Солтангалиев кунаклар белән бергә чыкты. Доктор Фуад үзенең Мирсәеткә Төркиядән алып килгән сәламнәрен тапшырды.

— Сезне Төркиянең дәүләт даирәләрендә дә яхшы беләләр,— диде доктор, әлеге очрашуга ихлас куанып.— Йосыф Акчура әфәнде сезнең хакта бик яхшы фикердә.

— Алай икән, димәк, сез Акчура әфәндене күреп үк беләсез? — дип, җанланып китте Мирсәет.

Төркиядән килгән вәкилләр өчен исә Мирсәетнең соравы гаҗәп тоелды.

— Ничек белмәскә. Йосыф Акчура Төркиядә бик тә мәгълүм зыялы вә могтәбәр затларның берсе. Аны белмәгән адәм юктыр. Ул Мостафа Кемал-пашаның иң якын аркадашларыннан,— дип, бер-берен бүлдереп аңлатырга кереште кунаклар.

Мирсәет өчен яңалык иде болар. Акчураның укымышлы зат булуын белсә дә, ул кадәр үк дип уйламый иде.

— Сез үзегез дә төрек халкының үз улыдай якын кеше безгә,— дип, янә Мирсәеткә олылау сүзләре тезеп китте доктор Фуад.— Без сезнең исем белән, Россиядә шундый дәрәҗәгә вә хөрмәткә ирешүегез белән горурланабыз. Һәм бер җай чыгуга ук Төркиягә кунакка чакырабыз... Бу хакта сезгә Зыя Гөкальп әфәнде дә хәбәр итүебезне үтенде.

Мирсәеткә янә дә гаҗәп тоелды.

— Димәк, сез Зыя әфәндене дә беләсез?..

Бер-берләренә карашып, тагы елмаешып алды Төркия вәкилләре.

— Милләт язмышы өчен җан аткан һәммә кеше Төркиядә иң олы

дан вә дәрәҗәгә лаек,— дип аңлатучы бу юлы Йосыф-бәй иде.— Зыя Гөкальп һәм Йосыф Акчура әфәнделәр нәкъ шундый. Үзләрен төрек санаган һәр адәм белер аларны.

«Алай икән! Бездә исә милли хисне дөньяга чыгармауны хуп күрәләр. Чыгардыңмы, синe гаеплиләр, шундук яманат тагалар үзеңә. Милләтне кайгырту, милләткә хезмәт итү дәрәҗә саналган илләр, җирләр дә бар икән ләбаса бу дөньяда!..» Бу — Мирсәетнең күңеленнән йөгереп үткән уйлар иде. Ул хакта тел тибрәтергә базмады, әлбәттә.

Шунда доктор Фуад сорап куйды аңардан:

— Ә сез коммунист бит әле, шулаймы, Мирсәет әфәнде?

— Әйе, чын коммунист... Нәрсә, әллә коммунистларны бик өнәп бетермисезме?

— Түгелен-түгел, әмма...— дип, танышларына карап елмаеп алды доктор.— Шулай да коммунист коммунист инде ул.

— Ни генә димәгез, коммунизм — кешелекнең киләчәге, туганнар,— дип әйтми булдыра алмады Солтангалиев. Һәм шаярган атлы сорап куйды:— Төркиядә дә Совет хакимияте урнаштыру мәсьәләсе көн тәртибенә килүе ихтимал көннәрнең берендә. Сез ничек уйлыйсыз?..

Сәерсенеп, үзара карашып алды төрекләр. Әмма арадан берәве, әлеге дә баягы доктор Фуад шаяруны аңлаган булып чыкты.

— Бөтен дөньяда коммунизм төзесәгез, без генә торып калу килешмәс, шулай бит, ә,— дип көлдерде ул янәшәсеннән атлап килүчеләрне.— Ул очракта уйлап карарга ярый... Әмма иң соңгы очракта гына, шулай бит...

Җавапның бусын ишетмәгәнгә сабышты Солтангалиев. Һәм сәясәт хакында бүтәнчә сүз кузгатмаска тырышты. Файдасыз!

...Тагы берничә айдан Мәскәүдә Төркиянең илчелеге ачыла. Бу тантана уңае белән чакырылган санаулы гына кунаклар арасында Мирсәет Солтангалиев тә була. Гомумән, егерменче еллар башында Төркия һәм Совет Россиясе арасында төзелгән һәммә килешү вә мөнәсәбәт ачыклауларның үзәгендә кайный ул. Төрекләр арасында «Төркиянең якын дусты» дигән бәя казанса, Үзәк өчен Көнчыгыш мәсьәләләре һәм аеруча Төркия буенча иң дәрәҗәле сәясәтче санала.

Шулай да... Мирсәетнең Төркия белән Советлар иле арасында яхшы күршелек мөнәсәбәтләре урнаштыру юлында җан атып йөрүе кайберәүләрнең эчен пошырган, күрәсең.

Көннәрнең берендә Солтангалиевнең Милләтләр эше халык комиссариатындагы эш кабинетына Осман Дивеев килеп керә. Кырымда эшләүче «сул» коммунист буларак, билгеле кеше, әмма аралашкан янсә кайчан да булса сер бүлешкән якыны түгел.

Тәкъдим ителгән урынга утырганчы ук Мирсәеткә комплимент вә төрле мактау сүзләре тезә башлады тегe. Аның бер сәбәпсезгә шулай боргалануы, ялагайлануы алдан ук сагайтып куйды. Чөнки яхшы мәгълүм, нинди дә булса адәм янына килеп сине урынлы-урынсыз мактарга керешсә, җүнлегә түгел. Белеп тор, ул синнән йә ни дә булса алырга, каерырга дип килгән, йә куеныңа кара елан булып уралырга йөрүче. Осман Дивеев хакында алай уйларга нигез булмаса да, юкка түгел иде бу.

Ниһаять, Мирсәетнең бөтен Көнчыгыш халыклары өчен горурлык булуын кат-кат искәртеп, һәммә төркиләр исеменнән мең рәхмәтләр житкергәненең соңында бер мәлгә тукталып торды Дивеев. Әмма озакка түгел.

— Мирсәет туган, мин сезгә үз йомышым белән түгел,— дип, пышылдауга күчте ул, олы сер сөйләгәндәй аның колагына таба үрелә төшеп.

Солтангалиев исә, киресенчә, тавышын күтәрә төште.

— Тыңлыйм. Кем йомышы белән?.. Кем җибәрде сезне монда?..

Сорау, көтелмәгән булдымы, сискәнеп китте чакырылмаган кунак. Як-ягына карангалап алды. Фикере дә бер мәлгә чуалып алгандай булды.

— Кем җибәрсен! Юк, юк, мин үзем килдем.— Күзләрен челт-челт

йомгалады. Һәм шунда гына, үзенең чынлап та кеше йомышы белән килүен искә алып, ихтыяр көчен җыйды.

— Кем йомышы белән килдегез дим, иптәш Дивеев?

— Менә, каушап калдым бит әле, Мирсәет туган. Сезне олылаудан, буй җитмәс каһарман санаудан ул шулай...

Тагы төчеләнә башлады... Мирсәетнең тешенә тия иде инде бу төчелек.

— Тыңлыйм сезне.

Янә пышылдауга күчте Дивеев:

— Мине сезгә, Мирсәет туган, Төркиянең илчесе Мохтар-бәй җибәргән иде. Ашыгыч рәвештә очрашырга тели ул сезнен белән.

Аркасыннан, ни сәбәпледер, кырмыскалар йөгерешеп узгандай булды. Куркудан да түгел, чөнки куркыр сәбәбе юк. Нидер сизенү иде булса кирәк бу.

Җавап көттермәде, шундук ярып салды Мирсәет:

— Мохтар-бәй минем кайда эшләвемне белә. Ә нигә аңа сезне җибәрү кирәк булды икән?.. Минем ишек һәрчак ачык.

— Юк, юк,— диде, теге кабаланып.— Ул сезнең белән икәүдән-икәү, кеше-кара күзенә чалынмый торган җирдә очрашырга тели.

— Кабинеттан да тыныч җир юк сөйләшү өчен. Күрәсең, синең белән дә без монда икәүдән-икәү генә.— Урыныннан торып, ишекле-түрле йөренергә кереште Солтангалиев. Үзен шулай беркатлыга санап, тикшерергә ният итүләренә эче пошты, ышанмауларына гарьләнде.

Осман Дивеев исә җавап көтә. Үз ролен яхшы уйнаган актер кебек, канәгать кыяфәттә утыруын белә әнә.

— Сезнең эшләрегез күптер, Мирсәет туган. Бер-бер яшерен урын һәм вакытын әйтегез дә, мин китәрмен. Мохтар бәйгә ни диим?..

Аның каршысына ук килеп тукталды Солтангалиев. Күзләренә текәлде. Тегенең исә күзләре терекөмеш сыман читкә йөгерде, ул карашны күтәрә алмады.

— Сине кем җибәрде?!— дип, кинәт тавышын күтәрде Мирсәет.

Дивеев калтыранып куйды.

— Юк, юк, һичкем җибәрмәде... Ә-ә, Мохтар-бәй йомышы белән килдем.

— Ахмак,— дип кычкырды Солтангалиев.— Мохтар-бәй, күрергә теләсә, мине җир тишегеннән таба. Әйт, сине кем җибәрде!

Дивеев кызарып чыкты, куркуга калды. Бүртенде.

— Һичкем җибәрмәде.

Ишеккә аркылы барып басты Мирсәет. Кобурасын ачып, кулына пистолетын алды. Һәм тавышын беркадәр баса төшеп, әмма катгый итеп кабатлады.

— Әйт, кем җибәрде!.. Өчкә тикле саныйм... Бе-ер... Ике-е...

Җан кадерле ул! Сикереп торды Дивеев, күзләре — маңгайда. Ялварырга кереште.

— Юк, санама, әйтәм... Ата күрмә... Ата күрмә, зинһар... «Ике»дә тукта... «Өч» димә... ГПУдан җибәрделәр.

Пистолетын кире урынына тыкты Солтангалиев. Һәм чакырылмаган кунак өчен ишекне киереп ачып куйды.

— Бар, югал күземнән! — диде ул, тешен шыгырдатып. Артык берни әйтә алмады. Йодрыкларын каты йомарлап, тәрәзәгә барып капланды.

Урамда 1922 елның буранлы-карлы феврале хөкем сөрә иде.

* * *

Борчу һәм бәхетсезлек берьялгызы йөрми диләр. Нәкъ шул көнне, аңарга Урта Азиядән бер хат килеп төште. Мирсәет өчен таныш булмаган мөгаллимә ханым язган. Мәктүптә, моннан берничә айлар элек

Төркестанда Рауза Чанышеваның, ягъни беренче хатыны тифтан вафат булуы хакында хәбәр ителгән. Җиде яшьлек кызлары Рәсидә караучысыз торып калган.

Кыска гына хатны кат-кат укып чыкты Мирсәет. Бугазына килеп тыгылган авыр төер сулыш алырга ирек бирмәде, күзләренә килгән кайнар яшь тамчыларын да тыя алмады ул. Ишеген эчке яктан бикләде дә буранлы урамга чыккан салкын тәрәзәгә барып капланды. Алай да шул тәрәзә бар. Тәүге мәхәббәте булган Раузаның үзе өчен ни дәрәҗәдә кадерле булганлыгын шунда гына аңлады диярсең... Үлем хәбәре — барын, хәтта хыянәтне дә оныттыра икән. Һәм еракта япа-ялгыз торып калган, инде менә ничәнче ай әтисез-әнисез яшәргә мәҗбүр булган кызы Рәсидәне кызгану да бар иде ул күз яшьләрендә. Рәсидә...

Солтангалиев шундук Төркестан белән элемтәгә кереп, кызын Мәскәүгә кайтару хәстәренә керешә. Шулай итеп, Фатыйма белән Мирсәетнең гаиләсе тагы бер кешегә ишәя төште.

* * *

Мирсәет Солтангалиев кабинеты. Эш өстәлендә — шахмат тактасы. Тактаның бер ягында — Мирсәет, икенчесендә — Лев Троцкий. Шахмат уйныйлар. Һәр йөрештән соң Троцкий вәкарь белән кемнәндер көлеп, шаяртып ала. Мирсәет тә үзен иркен тота, Троцкийга тиң итеп.

Т р о ц к и й. Йә, дустым, синең йөреш. Татар барда хәтәр бар диләр иде кебек... Күрсәтегезче, нинди мәкерле уй икән такыр башыгызда...

М и р с ә е т. Баш такыр түгел-түгелен... Мәкергә дә бирелгән юк... Шулай да исәп бирешергә түгел. Әйтик, кайсыдыр ки, менә болайрак йөреп куйсак, «хәтәр бар» дигәнегез хак булып куймагае...

Т р о ц к и й *(бераз уйга калып тора)*. Мөселманнар һөҗүм итә дисең инде. Кара инде, кысырыклый ук башлаганнар түгелме соң үземне? Солдатлар шәп, такыр башлы булсалар да, солдатлар шәп шул сезнең. Чарасыз калдыралар түгелме?..

С о л т а н г а л и е в. Хәрби комиссарга шулай ярыймы, Лев Давидович, Самара өчен көрәшкәндәй хис итегез үзегезне. Сез — полководец.

Т р о ц к и й. Әйе, полководец. Әмма пешкалар, синеңчә әйтсәк, солдатлар, бик пассив. Самара өчен көрәшкәндә Идел егетләре ут иде шул минем. Татарлар аеруча шәп сугышты...

С о л т а н г а л и е в *(җәт кенә җавап йөрешен ясап куя)*. Инкыйлаб һәм азатлык өчен булганда көрәштек һәм көрәшәбез дә анысы.

Т р о ц к и й *(башын югары чөеп, муен астын кашып ала. Бу аның гадәтенә кергән хәрәкәт)*. Сез көрәштегез, бәхәсләшмим, хак сүз. Һәм көрәшерсез дә... Ышанам. Ә без аның каравы, менә шах бирәбез.

М и р с ә е т *(сискәнгәндәй урынында кыбырсып куя. Аның өчен бу көтелмәгән йөреш була)*. Ничек, каян килгән «шах» булды әле ул?

Т р о ц к и й. Хәрби стратегия җимеше, иптәш Солтангалиев! Ягез, мөселманнар комиссары ич сез, югалып калмагыз алай. Мөселманнар комиссары ни әйтә?..

Урындыгына сөялеп атынырга ук керешә эреләнеп киткән Троцкий. Аягын аякка атландырып куллары белән хром итек кунычын сыпыргалап куя. Минем эш эшләнгән инде. Әйдә, иптәш, ват башыңны.

С о л т а н г а л и е в. «Шах» дисез инде алай булгач. Кызганыч, солдатлар шәп иде ич, солдатлар... Сул флангтан кысырыклап ук баралар иде.

Т р о ц к и й. Солдатлар көрәшә, комиссарлар җиңү яулый, Солтангалиев иптәш... Әлегә шах кына...

С о л т а н г а л и е в. Дөрес аңласам, Лев Давидович, тиздән мат

игълан итәчәкмен диган сүзегезме? Ашыкмагыз, сабыр итегез, безнең солдатлар ни дип әйтерләр бит әле. Җиңелү белән килешерләрме?.. Әгәр дә мәгәр без, әйтик, менә мондыйрак күчеш ясап алсак.

Бу йөрешен шактый уйлана һәм сагая төшеп ясый Мирсәет.

Т р о ц к и й. Гаҗәп түгел. Солдатларыгыз — үҗәт. Ә король һәм офицерларыгыз — битараф.— Кет-кет көлеп ала.— Нәкъ үзегезчә килеп чыга.

С о л т а н г а л и е в. Җиңелергә теләми татар егетләре. Җиңелүнең ни икәнлеген белми...

Т р о ц к и й *(янә бөтен игътибарын шахмат тактасына юнәлтеп эшкә керешә. Ләкин тел тегермәне тартудан туктамый).* Җиңелергә телиме-юкмы, әмма ярык тагарак янында утырып калачаклар. Җиңелү белән килешү-килешмәү — сезнең эш, анысы. Тырмашыгыз әйдә. Сез тырмашкан арада, без, гадәттәгечә, югарырак үрмәли торыйк булмаса. Әйтик, менә болайрак итеп. *(Үз хәрәкәте һәм сүзләреннән үзе үк кәефләнеп, филен, кулына алып, баш өстендә болгап торганнан соң, иң югары башка менгезеп утырта ул. Аннан канәгать кеткелдәп сакал очын сыпыргалап куя).*

С о л т а н г а л и е в. Уйлап җиткермәдегез кебек, хөрмәтлем. Уңга-сулга күз төшерергә оныттыгыз кебек.

Т р о ц к и й *(шундук сүз кыстырып ала).* Югарыга үрмәлим дисәң, уңга-сулга каранмыйлар. Мир... (махсус озак кына пауза ясап тора) Сәет дустым. Башта менеп кунакларга кирәк, аннан инде карангаласаң да ярый. Артыңнан үрмәләүчеләр булса, ике уйлама — тибеп очыр. Янәшәңдәгеләргә терсәк белән төрткәләп ал. Белеп торсыннар кем икәнлегеңне... Югарыдагыга башыңны как, тешеңне күрсәтергә өлгерерсең, ашыкма.

С о л т а н г а л и е в. Бу кадәресе шахматка кагылышсыз кебек, Лев Давидович.

Т р о ц к и й *(кабынып китә).* Шахмат һәм революция — бер үк законнарга буйсына, дустым Мирсәет. Кем көчле — шул түгел, мәкерлерәк булганы өстен чыга. Аннан килеп, шахматта да, революциядә дә гавәм, сезнеңчә әйтсәк, солдатлар сугыша, кан коя. Ә Корольләр җиңә.

С о л т а н г а л и е в. Сезнең бу фәлсәфә эшче-крестьяннар революциясенә кагылмый торгандыр, шәт...

Т р о ц к и й *(янә урындык аркасына ятып чайкалып куя. Мирсәеткә сынаулы карашын төбәп елмаю чыгара йөзенә).* Эшче-крестьян ничек эшләгән булса, шулай ук эшләячәк. Иң зур байлык — куллары. Корсагын тутырганчы ашарына да бирсәң, патшадан да, революциядән дә берни таләп итми ул. Хезмәт кешесенә күп кирәк түгел аңа. Ә эшләмәгәнгә кирәк, күпме генә алмасын, һаман җитми...

С о л т а н г а л и е в. Революция патшаны төшерде. Патша юк. Без һәммәбез эшче-крестьян вәкилләре...

Т р о ц к и й. Патша юк, әмма тәхет өчен көрәш дәвам итә. *(Карашын ераклыкка төбәп, чын-чынлап уйга калып тора).* Көрәшнең кыза гына барган чагы, Мир...Сәет. Шахмат уены дәвамлы, әле партия тәмамланмаган. Кем «шах» игълан итәр дә, кем «мат» куячагын белгән юк әле, Мир...

Шулвакыт ишекне аягы белән төртеп ачып, кабинетка Сталин килеп керә. Исәнләшми, сәламләшеп тормый, тәрәзә катына, түргә уза һәм төребкәсен имә-имә ераклыкка текәлеп тора. Әйтерсең лә ул чит кеше кабинетына кермәгән, әйтерсең лә бүлмәдә аңардан башка һичкем юк.

Мирсәет, хуҗа буларак, дәшми кала алмый, әлбәттә.

— Утырыгыз, иптәш Сталин, ял итеп алыгыз,— диярргә мәҗбүр.

Ә теге исә, паровоз сыман, куе төтен белән генә җавап бирә. Күренеп тора, Солтангалиевнең Троцкий белән шахмат уйнап утыруы ошамый аңарга.

Троцкий үзен, берни булмагандай, элеккечә иркен тотуында дәвам

итте. Дөрес, аның да сүзләрендә, кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла, дигәндәй, Сталинга төбәлгән ым пәйда булуын Мирсәет сиземләмәде түгел.

— Партия дәвам итә. Кем җиңәчәген әлегә әйтеп булмый,— дип сөйләнде ул. Янәсе, үзалдына.— Шахмат ул, Мир...Сәет, гаҗәп уен... Үзен җиңүчегә санап борын чөючеләр шундый оттыралар ки кайчак... Шундый оттыралар...

Сталин, муенын иплe генә борып, тырнаклары астындагы җанварга караган арысландай, карашы белән өстәл янындагыларны айкап алды. Әмма дәшмәде. Үзенә игътибар яисә киная юклыгына ышангач, янә элгәрегe ноктасына текәлде.

— Шахматта оттыру нәрсә?.. Революция оттырмасын. Бөтендөнья революциясе...— диде Солтангалиев.

Ни генә димә, яннарына килеп керүче Мирсәетнең дә, Троцкийның да сүз сөрешләренә шактый тәэсир ясады. Алар үзләре моны сизә идеме икән, юкмы?.. Һәрхәлдә, Сталин аларның ихлас түгеллекләрен ачык тойды.

Хәер, Лев Троцкий, аңлы рәвештә, ишектән керүчене оскыртырга атлыгып тора иде кебек.

— Һәр кешене үзең белән тиңләргә ярамый, Мир...Сәет,— диде ул.— Оттыру ул һичкайчан һәм бирәүгә дә җиңел түгел. Әйтик, кайберәүләр ни өчен шахмат тактасыннан өркәләр дип уйлыйсың?! Оттырудан куркалар чөнки. Җиңелүдән... Дәрәҗә төшүдән. Җиңмиләр дә... Җиңелмиләр дә...

Солтангалиев әйтте:

— Шахматта җиңелдем дип кенә төшә торган дәрәҗә — дәрәҗә булмый торгандыр,— диде.

Мирсәетнең кинаясез, бер ихласлык белән әйтелгән сүзләрен көтеп кенә торган диярсең, Троцкий шундук аны күтәреп үк алды.

— Ә кайберәүләрнең дәрәҗәсе шул чамадан артык та булмый, Мир...Сәет. Мин беләм андыйларны.— Һәм шундук, канәгать киерелә төшеп тамагын кырып куйды.— Әллә бер дә очратканың юк идеме андыйларны?..

Сталинга ишарәләве, гадәтенчә, аның белән булышуы икән — әле яңа төшенеп алды Мирсәет. Сталинның мин-минлеген һәм гел юктан гына да кәефе кырылучанлыгын белгәнгә күрә, аны үртәүче Троцкийга җитди караш текәде ул. Тәрәзә каршында үзләренә арка белән басып торучыга ымлап, миһербанлыкка чакырды аны: «Минем кабинетта чагында гына булса да газаплама инде үзен», янәсе.

Ул да түгел, Сталинны күргәч тә тынычлыгын югалткан Троцкий (үзе бу халәтен күрсәтергә теләми иде ул, әлбәттә), шахмат тактасында, берничә җавапсыз йөрештән соң, шактый ук катлаулы хәлгә юлыкты. Мирсәеттә дә мин-минлек юк түгел, Сталин барында оттыручы, җиңелүче булып күренәсе килми иде аның.

Шахмат тактасы артында да, тормыштагыча, үзен иркен тоткан Троцкийның исә үз-үзенә ышанычы чамасыз. Җиңелүдән котылуның ничек тә бер җаен табарына өметен өзми.

Көтмәгәндә-уйламаганда янә һөҗүмгә күчте ул. Әмма бу юлы шахмат тактасы артында түгел, кинаялап сөйләшүдә тиңе булмаган телен эшкә җикте.

— Нәрсәдер, уен бармый башлады бит әле, Мир...Сәет.

Ә Солтангалиевнең исә кәефе начар түгел.

— Ә мин болай үзем зарланмыйм...

Троцкий артистлардан да болайрак осталык белән башкарырга керешә ниятләгән ролен. Киерелеп алды, йөзен чыткан булды. Тактадагы партиягә кул селтәде тәмам.

— Бүлмәң кысан димме, сулыш алырга кыенлашкан кебек.

Сталин, тирән итеп суырган төтенен күкрәгеннән кире чыгарырга

онытып, бермәл югалып торды сыман. Әмма һичнинди аваз чыгармады.

— Бүлмә иркен, миңа һава житә,— диде Мирсәет. Ләкин шундук, беркатлыга сабышып, форточканы ачып килде.— Тәмәке төтененнән түгелме?..

— Төтендә түгел хикмәт... Сөремле агачы кала ич... Форточканы түгел, тәрәзәләренне киереп ачканда да җанга тынгылык иңмәс,— ди-ди кыбырсынды Троцкий аның саен. Бугазларын ышкыган атлы булды, борын очларын сыпыргалады ул. Мирсәет чынга алды үзен.

— Күңел болгана, Мир...Сәет, косасы килә, үләм,— дип сикереп торып басты Троцкий.

Әллә тәмәке исеннәнме дисәң, беренче генә кат түгел, утырышлар, кагыйдә буларак, тәмәке төтене эчендә уза иде ул елларда. Ул да түгел, Троцкий, шак-шок басып, ирен читләрендәге көлемсерәүне Мирсәеттән яшермичә, туры чыгар юлга төбәлде.

— Яхшы гына уйнап утыра идек, югыйсә,— диде ул, Мирсәеттән гафу урынына.— Бүлмәңә, әллә ниткән, кисәү агачы ташладылар. Мондый шартта шахмат уйнап булмый, Мир...Сәет. Исән чакта китеп котылыйм, сулыш буыла юкса.

Ишек сыкрап ачылды һәм шапылдап ябылды. Сталин, ничек басып торган булса, шулай торуын дәвам итте. Әйтерсең, берни ишетмәде һәм аңламады. Тагы ике-өч мәртәбә төрәбкәсен суырып төтенен өргәннән соң гына, йөзе белән борылды бүлмәгә. Карашын Мирсәеткә төшерергә ашыкмады. Гүя үзалдына дәште. Әмма бүлмәне яңгыратып дәште:

— Үз-үзеннән качты. Җиңелүдән... Котылгысыз җиңелүдән.

Шахмат тактасына күз дә салмады Сталин. Сүз ул хакта түгел иде, әлбәттә. Сталин өчен шахмат вак эш, юк нәрсә ул. Әнә, аның күзләре билгесез ераклыкка төбәлгән, ул — уйлый. Партия язмышы, ил язмышы... Халыклар һәм милләтләр язмышы өчен кайгырту сыйган аның ярым кысыла төшкән күзләренә.

Форточкадан өермә булып бәреп кергән кайнар җил төребкәдән күтәрелгән төтенне ишеккә таба куалады. Борынын тартып куйды Сталин. Ютәлләп алды.

Шахмат тактасын җыеп куйгач, Мирсәет Сталинга янә урын тәкъдим итте.

— Форточканы ябыйк,— диде Сталин, салмак кына.— Троцкийның исе чыгып бетте булса кирәк.

Дәшмәде Мирсәет, арысланнар сугышканда катышмау кулай икәнлекне ул яхшы белә. Троцкийга кушылып Сталинга мөнәсәбәтен белдергәне булмаган кебек, Сталинга кушылып Троцкийны да гаепләргә сәбәбе юк аның. Һәр икесенә бер дәрәҗә дустанә мөнәсәбәтне кулай күрә.

Урын тәкъдим иткәндә битарафлык күрсәткән Сталин, ниһаять, кабинет түрендә торган креслога барып түнде.

Мирсәет тә, өстәл астындагы урындыкны тарта төшеп, аның каршысына утырды.

— Борчуларыгыз бармы, иптәш Сталин. Кәефегез кырылгандай күренә.

— Коммунистларда кәеф кайгысы булмый,— дип кистереп куйды Сталин шундук.

Мирсәет ни дияргә белми, сүз таба алмый иза чикте бермәл. Гомумән, Сталин белән әңгәмә кору җиңел эш түгел. Уен-көлке, шаяруның ни икәнлеген белми. Хәл-әхвәл сорашмас, киңәш бирмәс.

Тимер кебек салкын караш, тимер сыман җансыз, әмма саллы сүзләр. Кушаматка алган Сталин фамилиясе шул кадәр дә җисеменә килешеп торыр икән.

Дәшмәү, бер ноктага текәлеп салмак кына төребкә имеп утыру — Сталинның стихиясе, яшәү рәвеше. Аның моңарга ияләнәсе юк. Ә менә сүзсез, шөгыльсез утырырга мәҗбүр булган Солтангалиев ни эшләсен?! Җитмәсә, үз кабинетында...

— Чәйләп алабызмы әллә, иптәш Сталин,— дип дәште ул. Урыныннан җәт кенә торып почмактагы нәни тартма өстендәге савыт-сабаларны барларга кереште.

Әмма тәкъдименә җавап ишетмәде. Хәтта ым кагып ризалашырга яисә кире кагарга да кирәк дип тапмады Сталин. Ничек утырган булса, шул хәлендә утыруын дәвам иттерде, керфек тә какмады.

Мирсәет чәй хәстәрләвендә булды. Әле генә Троцкий белән шахмат уйнап утырган өстәлгә кырлы стаканнар китереп куйды, җыйнак савытка салынган бал утыртты.

— Менә, башкорт балы да җибәргәннәр иде әле, иптәш Сталин,— дип, янә оеп калган халәткә җан кертмәк булды.

— Кырмыскалыдан... Туган яктан килгән бал. Картайган көненд әти умарта тота башлаган.

Үзен ишетүче, һич югында ишеткән атлы итүче, рәхмәт әйтүче генә булмады.

Тимер чәйнек белән шалтыр-шолтыр килеп, җәт кенә кайнар суга барып килде Мирсәет. Үләннәр салып чәй пешерде. Бүлмәгә хуш ис таралды...

— Хәзер, иптәш Сталин, үзегезне дөньядагы иң тәмле чәй белән сыйлыйм... Бу чәйдә җиде төрле үсемлек чәчәге генә бар. Зәңгәр мәтрүшкә... Сары мәтрүшкә... Бөтнек... Ромашка... Гөлҗимеш... Юкә... Кура...

Ә Сталин исә идәнгә төребкә көлен кага, Мирсәетнең сүзләрендә гаме юк. Кесәсеннән очлы тимерчыбык чыгарып, төребкә тишекләрен каезлый-чистарта. Бер-ике мәртәбә өреп тә ала төребкә тишегенә.

— Әле алар гына түгел, тагы әллә нинди үлән яфраклары да кушылган бу чәйгә. Рус телендә ничек аталганнарын гына белмим. Һәммәсе— үзебезнең Кырмыскалы болыныннан, Тау Сеңер урманыннан... Туганнарым җыеп җибәргән, иптәш Сталин.

Кырлы стаканнарга хуш исле пар бөркеп торган кайнар чәй агыза Мирсәет. Балны кунакка табанрак шудырып куя.

— Табигать чәен чәчәк балы белән дә эчеп куйсагыз, бер сырхау да якын килмәс үзегезгә, иптәш Сталин. Рәхим итегез... Сезгә салкын тигән, йөткерәсез...

Алдына куелган бал кашыгы янына шапылдатып төребкәсен ыргыта Сталин. Зәгыйфь кулын френч кесәсенә яшереп, икенчесен хуш ис бөркеп торган стаканга суза.

Мирсәет тә, ниһаять, күңеле булып өстәл янына утыра. Рухланып сөйләргә кереш, үзенең сүзләре белән танылган революционерны, остазын җылы әңгәмәгә чакыру аның исәбе.

— Үзебезнең Кырмыскалы су буйларын, Тау Сеңер күлләрен, андагы табигатьнең хозурлыгын юксынып яшим мин, иптәш Сталин. Болыннарындагы чәчәк исләрен, урман шавын, күл өстендәге төнбоекларын хәтерләп өзгәләнәм. Чирәменнән яланаяк йөгергән чакларны сагынам, көтү көткән җәйләүләрне, печән чапкан аланнарны... Бөтендөнья революциясендә җиңеп чыккачтын да мин, һичшиксез, туган төбәгемә кайтачакмын. Туган җиреннән аерылган кеше, аны яратмаган, бәрәзлексез сагынып яшәмәгән кеше бәхетле саный алмый торгандыр ул үзен...

Ул арада Сталин бер-ике мәртәбә чәй йотып куя. Әмма Мирсәетнең сүзләренә колак салганга охшамый, битараф.

— Сезнең дә шундый хисләргә бирелгән чакларыгыз буладыр, иптәш Сталин?! Грузия яисә Гори дигән сүзләрне ишеткәч тә йөрәгегез сулкылдаган чаклар... Балачак узган туган яклар үзенә бер могҗиза ич ул...

Кинәт... Чираттагы мәртәбә чәй кабып алгач, ниһаять, Сталин да әңгәмәгә кушылды дисә... Иңле, карлыккан тавыш ишетелде:

— Ярату хисе эчәк авыруыннан да яманрак нәрсә, иптәш Солтангалиев. Дөньядан ваз кичкән бәндәләр һәм француз буржуасы шөгыле белән мавыккансыз.

Көтелмәгән мондый борылыштан, сискәнеп, югалып калгандай булды Мирсәет. Сталинның, дәшми-дәшми тыңлап торгачтын да, уйламаган җирдән, шул рәвешле, бер-бер дорфа гыйбарә әйтеп ташлый торган гадәтен белә, югыйсә. Әмма бу юлы, туган якның шагыйрәнә табигатен хәтерләп хозурланган, хыялда гына булса да балачак сукмакларыннан йөгереп узган мәлдә, андый сүзләр көтмәгән иде ул аңардан. Үз колагы ишеткәннәргә ышана алмый торды.

— Мин — болай, сагынудан гына, иптәш Сталин,— дип, үз-үзеннән акланган сыман тартынып куюын да абайламый калды.

Өстенлеген расларга җай чыгуын абайлап алган Сталин һөҗүмгә күчкән иде инде.

— Ә нәрсә белән кушып ашыйлар соң ул сагынуны? Карт бүреләр генә ул, җәйге урманны, яшь җегәрле чакларын сагынып улый.

— Төребкәсенә тәмәке тутырды ул, аннан ашыкмый гына төтәтеп җибәрде. Эчкә алып, берничә тапкыр төтен өрде. Буыла-буыла йөткергәләп алды.— Идел буе ачлыктан тилмерә... Йөзәрләп, меңәрләп үләләр... Мужикның ашарына юк, ягарына юк. Авыл урамнары мәет белән тулган... Ә халык комиссариатының җаваплы хезмәткәре Мирсәет Солтангалиев монда — җылы кабинет эчендә — Троцкий белән шахмат уйный, башкорт балы кабып чәйләп утыра.

Бәгырьгә үткәзеп, йөрәкне телгәләрлек итеп сөйли белә Сталин. Кызгану хисенең ни икәнлеген онытып сөйли. Һәм шул ук вакытта, фактларга борының белән төртеп сөйли. Әмма Мирсәет тә дәшми кала алмый әлеге мәлдә.

— Хуш, иптәш Сталин, хак сөйлисез... Сез минем әле бүген генә шул яклардан йөреп кайтуымны беләсез. Әмма ни өчендер кабул итәргә кирәк санамадыгыз. Ильич ишегенә Стасова аркылы баскан. Троцкий — бу эшләргә катнашым юк, ди...

— Ильич белән Троцкий өчен мин җавап бирмим... Сөйләгез... Тыңлыйм...

— Казан, Чистай, Мамадыш, Алабуга дигән калаларны ишеткәнегез бармы икән?.. Җәяүләп уздым араларын. Җигәргә дип, атланырга дип бирелгән атларны житәкләп йөрергә куркыныч — егылалар. Аякларын күтәрер хәлләре юк. Ә кешеләр?! Кешеләрне нинди чиккә житкергәннәр? Күрәләтә ачтан үтерәбез халыкны. Салкын көзгә кергәч тә башланган ачлык. Иң олы сый — черек бәрәңге кәлҗемәсе! Алабута кушып пешерелгән ипи кыерчыгы — сабыйларның иң зур хыял! Агач каерысы кимереп, бөре җыеп көн күрә бик күпләр. Картлар-карчыклар, сабыйлар ачтан күбенеп үлә. Ашыгыч ярдәм кулы сузмыйбыз икән — халык кырылачак, иптәш Сталин. Шахмат уены — җанны кая куярга белмәүдән...

— Килешәм,— дип, шундук ризалашуын белдереп куя Сталин.— Ярдәм итәргә кирәк. Үзегез әйткәнчә, ашыгыч ярдәм күрсәтергә.

— Ничек? Ни рәвешле күрсәтергә ул ярдәмне?

— Сез — комиссариат вәкиле, коллегия әгъзасы. Ярдәмне дә сез күрсәтегез, иптәш Солтангалиев. Халкыгыз ачтан җәфа чигә...

— Америка эшчеләре, чит ил пролетариаты җибәргән ярдәмнән баш тартмаска иде, иптәш Сталин.

— Буржуйлар икмәге белән ирекле халыкны туйдырыргамы?! Барып чыкмас, иптәш Солтангалиев. Алган кадәресе дә житеп ашкан. Ленин йомшаклык күрсәтте! Әле Төркиядән дә ярдәм сорарга диярсез сез тора-бара. Беләм мин сезне — барыгыз бер иш сез, ислам дине тотучылар. Башыгыздан пантюркизм һәм панисламизм коткысын бәреп чыгару өчен ким дигәндә бер гасыр ара кирәк булачак әле сезнең...

— Иптәш Сталин,— дип, гаҗәпсенүен белдереп, дәшми генә карашын текәп тора Мирсәет беркавым.— Без сезнең белән Милләтләр эше буенча комиссариат житәкчеләре! Халыклар турында начар сүз сөйләмәскә килешкән идек. Хәтерегездәдер, шул исәптән төрки халыклар турын-

да да... Сүз, ялгышмасам, милләтләр хакында түгел, ачлыкка мөнәсәбәтле булса иде кирәк... Тамак кайгысы, ачлык — милли чикләрне белми.

Үз чиратында Сталин да әңгәмәдәшенә тимер салкынлыгы бәреп торган карашын төбәде, боларны мин сезнең авыздан ишетәмме, янәсе. Бераздан гына әйтеп куйды:

— Революция принципларын икмәккә алмаштырмыйлар, Солтангалиев.

— Ярдәм кулын халык массалары, пролетариат суза. Андый ярдәмнән баш тарту мәҗбүри түгелдер, дип уйлыйм, иптәш Сталин. Халык массалары язмышы үлчәүгә салынган... Эшче һәм крестьяннар язмышы... Ачлыктан кем интегә? Иң түбән катлау вәкилләре — авыл мужигы, картлар һәм сабыйлар...

— Ә кулакларның ашарына бармы соң?!

— Бар... Булырга тиеш,— дип җавап кайтарды Мирсәет. Гәрчә авылларда күзгә бәрелеп торган тигезсезлек күренешләрен сирәк очраткан кебек иде ул. Авыл халкы булганын үзара бүлешә, әле бер-беренә мәрхәмәт хисен югалтмаган иде халык.

— Булгач... Кулаклардан тартып алсыннар. Пролетариатка һәм ярлы крестьяннарга ярдәм йөзеннән, кирәксә, тагы солдатлар җибәрә алабыз. Штык — иң гали хөкемдер, соң чиктә...

— Авылларны канга батырудан файда юк, иптәш Сталин. Чистайда гына да, әнә, кулакка санап алты йөздән артык ач мужикны чыгарып атканнар. Башта чакыртканнар, үзләре өчен кабер казытканнар, аннан атканнар. Бу — явызлык, алай гынамы, кешелексезлекнең соңгы чигендәге вәхшилек.

— Революция корбаннарсыз булмый, иптәш Солтангалиев. Алты йөз кеше атылган булса, миллионнар безнең иманга кайтарылгандыр. Кайчак гыйбрәт — иң нәтиҗәле коткыдан да болайрак нәтиҗә китерә.

— Курку, куркыту юлы беләнме?

— Төп максатка ирешү юлында чараларның һәммәсе дә яхшы.

— Максат — халыкны ачлыктан иза чиктерүдә, үтерүдә түгелдер ләбаса, иптәш Сталин? Авыл кешесенең үзе үстергән икмәкне дә туйганчы ашарга хокукы булмагач, азатлык, ирек, җир дигән вәгъдәләребезнең хаҗәте каламы?! Революцияне кем өчен ясадык соң без?...

— Эмоциягә биреләсез, иптәш Солтангалиев, вак буржуа чире белән авырыйсыз. Икмәк армия өчен, пролетариат өчен... Ә мужик өчен кайгырмагыз, ул үз җаен үзе карар. Россиядә мужик халкына кытлык булганы юк. Һәм булмас та...

— Иләктәге соңгы мыскал онын, савыт төбендәге соңгы арышын тартып алу, болай да очын-очка ялгый алмый газапланган мужикны корал көче белән талау — гади генә итеп әйткәндә дә, кешелексезлек, иптәш Сталин. Мин үз фикеремдә калам.

Сталин шундук нәтиҗә ясап куярга кирәк таба:

— Әмма ЦК башка фикердә! Революцион пролетариат мәнфәгатьләреннән ерагайганнан-ерагая барасыз, иптәш Солтангалиев.— Байтак кына сүзсез торганнан соң, ул янә салпы якка салам кыстыра:— Мин боларны сезгә үз итеп, якын итеп әйтәм, Мирсәет. Троцкийдан сез андый киңәш ишетмәссез. Хәтта Лениннан да...

Мирсәет, байтак ара уйга чумып торгачтын, канәгатьсез генә рәхмәт белдерә.

Сталин, гүя шул мизгелне көткән, әңгәмәдәшен кыен хәлдә калдыру — аның яраткан шөгыле. Һәм шул нәтиҗәгә ирешкәч кенә, ул төп сөйләшүгә күчә. Бу юлы да үз сәгатен көткән булып чыкты.

— Сезне анда Сәетгалиев иптәшкә каты бәрелгәнсез дип ишеттем,— диде ул, кинәт, сүз арасында гына кызыксынгандай итеп.

Алай икән! Менә ни өчен, гомер булмаган хәл, аның кабинетына үзе килеп кергән икән Сталин. Димәк, Сәетгалиев аның белән элемтәгә кергән булып чыга.

— Каты бәрелеп кенә калмадык, иптәш Сталин, Совнарком рәисе Сәетгалиев иптәш эштән азат ителде. Татарстан республикасының партия оешмасы карары нигезендә, күпчелек тавыш белән эштән алынды Сәхипгәрәй Сәетгалиев.

— Сез бу карарны дөрес эш һәм партиянең соңгы сүзе дип табасызмы?

— Бөтен партия исеменнән хөкем йөртә алмыйм, иптәш Сталин, әмма Сәетгалиев иптәшне, килеп туган шартларда, үз урынында калдыру мөмкин түгел иде. Татарстан коммунистлары бертавыштан Мохтаровка ышаныч белдерделәр...

— Мохтаров... Мох-та-ров...,— дип, бу фамилияне хәтерендә калдырырга теләп үзалдына кабатлап торды Сталин.— Ә шулай да Татреспублика җитәкчеләренә ЦК фикерен санга сугу зыян итмәгән булыр иде... Сезнең өчен бигрәк тә, иптәш Солтангалиев. Минем сезгә булган мөнәсәбәтемне беләсез!

Чынлап та, Үзәктәге югары даирә җитәкчеләренең һәммәсе белән яхшы танышлыгы булуга да карамастан, Сталин белән Мирсәетне байтак кына вакыйга һәм икесе генә белгән серләр якынайтып тора иде. Сталинның холкында каты бәрелә торган гадәт бар-барын, әмма, соң чиктә, Мирсәеткә зыян китергәне юк иде ич әлегәчә. Ул үзе дә Сталинның дустанә мөнәсәбәтен гаять югары бәяли.

— Сезгә хөрмәт һәм рәхмәт хисләрен югалтканым юк, иптәш Сталин. Әлеге вакыйганың шәхси мөнәсәбәтләргә кагылышы булмас диеп беләм.

— Коммунистлар арасында шәхси мөнәсәбәтләр булмый, Мирсәет. Партия мәнфәгатьләре бар нәрсәдән югарырак!

— Килешәм, иптәш Сталин. Әмма...— дип, икеләнеп, уйланып кала Мирсәет бермәлгә.— Әмма кеше язмышы, халык язмышы бизмәнгә салынганда, бәлки бәхәсләшергә дә ярыйдыр.

Сталин тыңламады булып чыкты Мирсәетнең сүзләрен. Үзалдына, битараф кызыксынып куйды ул нибарысы:

— Кайдан таптыгыз ул Мохтаровны?

— Кәшшаф Мохтаров — тәҗрибәле һәм мәгълүм кеше, иптәш Сталин. Аны Татарстан партия өлкә комитеты тәкъдим итте. Моннан өч ай чамасы элек Өлкә комитетының җаваплы секретаре иптәш Канатчиков бу хакта минем янга махсус килде. Сәетгалиевтән зарланды. «Иртән бер-бер нәрсә вәгъдә итсә, кичен шуның киресен эшли — булмый аның белән»,— диде.

— Ә минем белән киңәшеп тормагансыз!..

— Сез командировкада идегез... Кавказда... Без Догадов белән Молотов янында булдык.

— Молотов ни диде?

— Яхшы булыр, хәл итегез, диде...

— Ишкән икән ишәк чумарын!

Шунда, кинәт урыныннан торып, ишекле-түрле йөренеп килде Сталин. Һәм, өстәл янында тукталып, телефон төребкәсенә үрелде.

— Сәетгалиев иптәшне чакырыгыз! Мин Солтангалиев кабинетында. Әйе, монда керсен... Хәзер үк...

Мирсәет өчен бөтенләй көтелмәгән яңалык иде бусы. Әле яңа аңлашылды. Димәк, Сталинның аның янәшәсенә керүе очраклылык түгел. Ул аны Сәетгалиев белән күзгә-күз очраштырып нидер ачыкларга җыена. Тик бер нәрсә анык түгел, ни өчен дип әле үз кабинетына чакырмады ул аларны? Ни сәбәпле Мирсәетнең эш бүлмәсенә кеше чакырырга ният кылган — яхшымы бу, ямангамы?

Ул арада аргы яктан берәү кыяр-кыймас кына ишекне шакыды һәм сак кына ача төшеп, башын тыкты. Бу — Сәхипгәрәй Сәетгалиев. Мирсәет өчен аның гадәтләре яхшы таныш: ата мәче сыманрак, җыйнак һәм мәкерле дә булыр ул бер үк вакытта.

— Иптәш Сталин, керергә рәхсәтме? — дигән тавышы ишетелде үзе күренгәнгә кадәр.

Сталин дәшмәде, байтак ара онытып торган тәребкәсен яңартып җибәрүе белән мәшгуль иде. Мирсәет чакырырга мәҗбүр булды «чакырылмаган кунак»ны.

— Керегез... Рөхсәт. — Ул аңар үзе утырган урындыкны тәкъдим итте. — Утырыгыз.

Сталин ишектән керүчегә күтәрелеп карарга ашыкмый иде әле. Аягын аякка атландырып креслода көе аркасын турайтты. Байтак көттергәннән соң гына, бөтенләй башка юнәлешкә текәлгән җиреннән сүз башлады. Иҗекләп сөйләгәндәй, иңле, акрын сөйли иде.

— Солтан-галиев иптәш... Сәет-галиев иптәш... Икегез дә иптәш... Ә үзара иптәш түгелсез. — Бүлмәдә чебен безелдәгән аваз да юк. Киеренкелек. — Берегез Солтан, берегез Сәет, икегез дә Галиев. Туганнармы әллә сез — мин шулай уйлый идем... Халкыгызның исеме калса, тарихчылар бутап йөртер әле үзегезне...

Димәк, Солтан белән Сәет килешмиләр... Сәет — икмәк җыйган, Солтан — ошатмаган. Сәет — баш бирмәгән... Солтан — эштән алган. Ә Галиләр?! Галилек — онытылып торган, югалган... Хикәят кызык килеп чыга, шулай бит, ә, Мирсәет?! Син язучы да ич әле безнең, кусн дәфтәреңә теркәп куярга онытма моны.

Мирсәет әйтте:

— Хикәятегез ярарлык, иптәш Сталин, әмма хакыйкатьтә вакыйгалар башкача... Һәм күпкә житдирәк... — диде.

Солтангалиевкә сүзен тәмамларга да ирек бирмичә, шым гына утырган җиреннән, кинәт артын корт чаккандай, Сәетгалиев сикереп торды.

— Ул... Ул... — дип кабаланудан тотлыга-тотлыга сөйләп китте. — Ул партия политикасын аңламый, бозып күрсәтә. Революция язмышы түгел, татар мужигы кадерлерәк аңарга.

Сталинның әле һаман Сәетгалиевка күтәрелеп караганы юк. Әмма әңгәмәдән читтә калырга да җыенмый иде.

— Кабаланмый гына, иҗләп кенә сөйләгез, Сәетгалиев иптәш. Мәсьәлә сез уйлаганнан да житдирәк булырга охшап тора. Тыңлыйбыз.

С ә е т г а л и е в. Мин — партия солдаты. Мин партия кушканны үтәдем, иптәш Сталин. Революциягә икмәк кирәк булганга.

М и р с ә е т. Авылларда җыен җыеп, тапшырыр икмәге булган кешеләрне сәгатьләр буена тезләндереп тотарга партия куштымы?

С ә е т г а л и е в. Тезләнсә... Алар Совет хакимияте каршында баш иде. Нәрсә булган!?

М и р с ә е т. Балалары, хатыннары карап торганда мужикларның ыштаннарын салдырып, шомпол һәм таяклар белән кыйнарга да партия куштымы?

С ә е т г а л и е в. Аның каравы, яшергән җирләреннән янчык-янчык икмәк табып китерделәр. Ирләрен коткарасы килгән хатыннар, аталарын кызганган балалар икмәк ташыды.

М и р с ә е т. Сабыйлар авызыннан өзеп китерелгән икмәк! Ә Арчада берьюлы утыз крестьянның башын чабып өздерү нигә кирәк булды?

С ә е т г а л и е в. Гыйбрәт өчен. Арчалыларга ул гына аз әле... Аның каравы, юктан бар ясап, ике олау икмәк төяп озаттык. Ил төкерсә — күл була ул.

М и р с ә е т. Тамактан өзеп, чәчүлеккә дип саклаган орлыклары... Инде Чистайдагы вакыйгага килик. Чистайда ниләр майтардың?..

С ә е т г а л и е в. Мин түгел, иптәш Сталин, — ул кабаланып, зур гаептән арынырга ашыгып, акланырга керешге. — Мин түгел. «Тройкалар». «Тройкалар» оештырып икмәк җыярга дигән әмерне Мәскәүдән төшерделәр. Минем гаеп юк монысында. Ул барысын минем өскә өймәкче була, иптәш Сталин.

Сталин әле һаман гүя аларның сөйләшүенә битараф кала бирде.

Мирсәет. Бер Чистай өязендә алты йөз крестьянның башына җиту дә партия өченме? Партия кушуы беләнме?!

Сәетгалиев кабаланырга керешге. Тотлыга-тотлыга сөйләп китте:

— Крестьян түгел, үлчәп сөйләшегез, Мирсәет иптәш — кулаклар! Кулак иделәр алар барысы да, революция дошманнары.— Сталинның каршысына ук килеп тезләнә ул шунда.— Мишәрләр алар, мишәрләр, иптәш Сталин. Ә мишәрләр — барысы да кулак. Үзе дә мишәр булганга яклый ул аларны, иптәш Сталин. Хатыны да мишәр. Миллионерлар һәм буржуйлар — һәммәсе мишәр. Шуңарга яклый ул аларны.

Сталин, күз карашын төшермәстән, кулы белән битараф ишарәләп, каршысында тезләнеп торучының күтәрелүен үтенә.

— Революция солдаты,— дип әйтеп куя үзалдына. Әллә мактый, әллә мыскыл итүе, алла үзе генә белә. Сәхипгәрәй Сәетгалиев тезләнгән җиреннән торып, читкә тайпылгач, шул ук битарафлык белән сорарга кирәк таба.— Ә кем ул — мишәр? Нәрсәсе белән аерыла ул татардан?

Сәетгалиев бу сорауга ничек җавап бирергә белми аптырый калды, бахыр. Рәтле-башлы аңлатма тапмагангадыр, әйтеп салды:

— Мишәрләрме?.. У-ух, ми-шәрләрне! — дип, махсус киеренкелек тудырды элек.— Мишәрләр — шундый татарлар алар, иптәш Сталин, менә шундый татарлар алар.— Йодрыкларын болгап, иреннәрен кысып аңлатырга тырыша иде ул. Гөнаһ шомлыгы, ни дияргә генә белми. Сүз таба алмый.— Татарларның нәкъ әнә теге халык... үткеннәре, елгырлары, усаллары була ул мишәрләр. Әйтик, иптәш Троцкий кебекләре...

Җавапның соңгы өлеше Сталинның күңеленә хуш килде, әлбәттә. Сәетгалиев хәйләкәр, белеп сөйли.

— Татарның иптәш Троцкий кебеге... Хе, иптәш Солтангалиевне Троцкий белән шахмат кына берләштерми икән, димәк...

Сәетгалиев сөйләгәннәрне гади бер әкәмәт итеп кенә тыңлаган Сталинның битарафлыгы Мирсәетнең болай да юк кәефен тәмам соңгы чиккә җиткергәндер. Әмма үзенең эчке халәтен күрсәтә торган урыны түгел. Шулай да күңелендәге әйтми кала алмады ул.

— Кеше гомерен чүпкә дә санамыйсыз. Партиянең, Советларның тамырына балта чабуга тиң ич бу. Ничек шуны аңламаска мөмкин?! Бер сыер бөтен көтүне буйый, дип юкка әйтмиләр икән...

— Халык әйтсә — хак әйтә,— дип, сүз кыстырмасынмы Сәетгалиев шунда.— Тик ул тычкак сыер кайсыбыз икәнлекне генә ачыклыйсы кала.— Һәм үз-үзеннән канәгать булып, кеткелдәп тә ала.

Мирсәет, аның бу дорфалыгына, үзенең бөркет карашы белән генә җавап бирә. Сүз көрәштерү файдасыз Сәхипгәрәй Сәетгалиев белән.

Шунда кемдер ишек шакый. Кабинетка элемтә бүлегендә эшләүче кыз килеп керә.

— Мирсәет абый, сезгә телефонограмма... Казаннан.

Кыз өстәлгә ике метр чамасы озынлыктагы ак кәгазь тасма китереп сала. Һәм шунда гына бүлмәдә башка кешеләр дә барлыгына игътибар итеп, элемтәче кыз алар белән дә исәнләшеп чыга.

— Исәнмесез, иптәш Сталин.— Икенче читтә кызның гәүдә чигелешләре һәм таза балтырларына ач күз белән багып торган Сәетгалиевне дә сәламли.— Исәнмесез.

— Сәлам, чибәр туташ... Әллә минем белән исәнләшми дә китәсезме дигән идем. Мин — эштән куылган большевик Сәетгалиев булам.

Кыз, җитди рәвештә, янә бер мәртәбә Сталин һәм Мирсәеткә табан карап ала да ишеккә юнәлә. Аның һәр хәрәкәтен Сәетгалиевнең майлы карашы озатып кала.

Мирсәет тасмага үреләм дигәндә, Сталин өлгерлек күрсәтә. Өстәл өстеннән идәнгә шудыра-шудыра укып чыкканнан соң дәшми-нитми, битараф кына, кире урынына куя.

Ниһаять, чират Мирсәеткә җитә. Ул кычкырып укый телефонограмманы: «Мәскәү. Милләтләр эше халык комиссариаты әгъзасы Солтан-

галиевкә. Ильичтан телеграмма алдык. Хезмәт һәм Ил иминлеге Советы исеменнән кичекмәстән Самара губернасына биш йөз мең пот солы җибәрергә диелгән. Бу — ачтан интегүче республиканың бөтен булган фондыннан да артыграк дигән сүз. Ленин исеменә, үти алмыйбыз, дигән җавап юлладык. Башкача чарабыз булмады. Мәсьәләне аңлату юлында ярдәм итәрсез, дигән ышаныч белән, Татсовнарком рәисе Мохтаров. 21 июнь, 1921 ел»

Сәетгалиев, шатлануын яшерә алмый, урыныннан ук сикереп тора.

— Менә, әнчек, кара син аны... Филгә өрергә дә курыкмый, имеш. Көчле, янәсе...— Бүлмә буйлап әрле-бирле йөренергә керешә, дәртләнүен яшерә алмый.— Ха, Ленинга каршы бара диген, ә. «Совет Труда и Обороны» карарын үтәми диген, ә... Ишеттегезме, иптәш Сталин, күрдегезме инде, ниһаять, сезнең сөекле Солтангалиевегез кемнәргә йөз тота?!

Сталин дәшмәүне артык күрә.

Мирсәет тә тегенең сөйләгәннәренә колак салмый. Ипле генә килеп телефонга үрелә.

— Аня, хөрмәтлем, телефонограмма кабул итегез. Ашыгыч рәвештә ирештерү зарур. Тыңлыйсызмы?.. «Казан. Татсовнарком рәисе иптәш Мохтаровка. Өстегезгә алган җаваплылыкны хуплыйм. Ленин хәлне аңлар. Эшләгез. Июньнең 21 нче көне, 1921 ел. Солтангалиев». Хәзер үк юллагыз, ярыймы, Аня-матурым... Рәхмәт.

Сталин дәшмәвендә дәвам итә. Колагы ишеткәннәрдән бер тын хәйран калып торган Сәхипгәрәй Сәетгалиев үзен кайгыртуында:

— Ишеттегезме, иптәш Сталин. Алар шулай — күт белән ыштан кебек, бер-берсен яклау дигәндә һичнидән тайчынмыйлар.

Мирсәет янә телефон төребкәсенә үрелә. Бу юлы инде аның беркадәр тартына төшүе, икеләнә калуын да сиземләү кыен түгел.

— Иптәш Стасова белән тоташтырыгыз әле.— Шактый озаккарак сузыла тоташтыру мәшәкатьләре.— Елена Дмитриевна... Бу тагын бер мәртәбә Мирсәет Солтангалиев иде әле. Иптәш Ленинның мине кабул итүен үтенәм... Бүген үк кирәк иде шул... Иртәгә, сәгать унга. Килештек... Елена Дмитриевна, тагы бер генә минутка... Әйе, тоташтырсагыз, Владимир Ильичка хәзер үк телефон аша бер-ике авыз сүз әйтергә кирәк иде... Ашыгыч сүз... Әйе, кичектерергә ярамый торган... Иртәгәсенгә кадәр дә кичектерергә ярамый торган... Көтәм.

Мирсәет үзен Ленин белән тоташтыруны көтә, колагында телефон төребкәсе. Сәетгалиев, хәйләкәр песи сыман, телефон төребкәсеннән яңгыраячак сүзләрне ишетү максаты белән, якынгарак елышырга итенә. Сталин — битараф, төребкә суыруын белә.

— Эреләндең, Мирсәет, минем белән киңәшергә дә кирәк тапмыйсың хәзер,— дип мыгырданып ала шулай да.

Аргы очтан Ильич тавышы яңгырап ишетелде. Элемтә яхшы, булмәдәгеләрнең һәммәсенә ишетеләдер төсле иде ул.

— Тыңлыйм, Мирсәет Хәйдәргалиевич. Ни әйтергә тели идегез?

— Владимир Ильич, мин әле генә Идел буеннан, Татарстаннан йөреп кайттым.

— Татарстанда хәлләр зарланырлык түгел диеп беләм. Ничек анда, миңа сөйләгәннәре дөрестер бит?!

— Түгел, иптәш Ленин, сезгә дөрес булмаган информация җиткерелгән. Идел буендагы ачлык Татарстанда аеруча куркыныч чагылыш тапкан...

— Ничек? Ничек! Әле миндә бер атна чамасы гына элек Татсовнарком рәисе Сәетгалиев булып киткән иде. Ул зарланмады. Хәтта, кирәксә, тагы икмәк чыгарырга вәгъдә бирде. Совнарком рәисенә ышанмаска минем хакым юк...

— Сәетгалиев хәзер Татсовнарком рәисе түгел. Миңа мәгълүм булганы кадәре генә дә быел Татарстанда ачлыктан кырык меңнән артык

кеше үлгән. Ашыгыч ярдәм күрсәтмәсәк, ачлык корбаннары йөз меңнәргә, миллионга җитәчәк. Мужикның чәчәренә орлык юк. Яз башыннан җиргә бер тамчы яңгыр төшмәгән, туфрак кайнар көлне хәтерләтә.

— Мин берни аңламыйм, Солтангалиев иптәш. Кем хаклы, ә кем хаклы түгел монда?! Әле бит Самарага икмәк озатырга тиеш иде алар...

— Самарага икмәк озатылмаячак, Владимир Ильич. Чөнки ул икмәк юк. Ул уңайдан Татсовнаркомның яңа рәисе Мохтаров белән безнең арада сөйләшү-аңлашу булды. Җаваплылыкны мин үз өстемә алам.

Аргы яктан Ильичның гаҗәпсенгән авазы яңгырады:

— Аңламадым... Берни аңламадым. Беренчедән, ничек итеп булмаган икмәкне бар, дип әйтеп була. Икенчедән, Хезмәт һәм Ил иминлеге Советы карарын үтәмәскә, дөрес түгел дип табарга кемнең хакы бар...

Берара тынлык урнашып торганнан соң аргы яктан янә Ильич тавышы ишетелде.

— Ярый, Мирсәет Хәйдәргалиевич, сез иртәгә минем янга керегез әле. Безгә кичекмәстән очрашырга кирәк. Мин Стасовага әйтермен...

— Без инде, килештек, Владимир Ильич. Иртәгә сәгать 10 да мин сездә булачакмын.

— Яхшы. Иртәгәсе көнгә кадәр!

— Сау булыгыз, Владимир Ильич.

Мирсәетнең дулкынлануы янә йөзенә чыкты.Кайнарланып урыныннан сикереп торды ул һәм бер почмакка китеп ельшкан Сәхипгәрәй Сәетгалиев каршысына барып басты. Бүрегә ташланган тау бөркете сыман, ул менә-менә аның өстенә очып кунар төсле иде. Тегене тәмам почмакка кысрыклады. Йодрыклары каты йомарланган, тешләрен кысып дәште ул аңарга:

— Кайдан, ничек табарга җыена идең ул 500 мең пот ашлыкны? Ашарга булмаганда... Чәчәргә булмаганда... Ярты Татарстан кырылып үлеп беткәннән соң.

Куркак куян хәленә төшкән дәүләт эшлеклесе Мирсәетнең җилкәсе аша, Сталин мондамы әле дигән сыман, шул тарафка каранды. Күрде һәм тынычлана төште.

— Чамалабрак, Солтангалиев иптәш, мин сиңа Оруджиев түгел. Бәйләнмә миңа...

— Бәйләнмим. Мин синнән сорыйм. Әйт, егерме беренче ел кышыннан соң кайдан, ничек табарга җыена идең син ул ярты миллион пот ашлыкны?

— Тырышып еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга. Казанда һәм өяз шәһәрләрендә яшерелгән запас бар иде әле минем.

— Ә халкың ачтан кырылганда кайда идең? Сабыйлар бер кабым икмәк юклыктан күбенеп кырылганда син кайда идең?

— Мин — дәүләт эшлеклесе. Мин ЦК каршында гына җавап бирергә тиешле... Ә кемнең нәрсә ашавында минем эшем юк.— Почмактан чыгарга итенеп талпынып алды Сәетгалиев.— Кит әле, юл бир. Юл бир диләр сиңа...

Мирсәет юл бирми. Җилкәсе белән этеп үк кысрыклый тегене. Әле һаман аңлый, төшенә алмый иде ул, шуңа төпченүен дәвам иттерде.

— Шундый кышта ярты миллион пот ашлык яшереп яткырдыңмы?

— Алай ук түгел инде,— дип куя Сәетгалиев, битараф кына.

— Ә Ильичка күпме вәгъдә иттең?

— Соң, ярты миллион пот инде...

— Кайдан табарга җыена идең? Җитмәгән өлешен дим...

— Бәйләнмә әле, кешечә сорасаң, аңлатырмын. Җибәр, чыгар мине бу почмактан.

— Соңгы мәртәбә сорыйм, Сәхипгәрәй, син мине беләсең,— дип, кобурасына кулын куеп ала Мирсәет.— Яшерелгән икмәгең күпме иде?

Сталинга күз төшереп ала Сәетгалиев. Ә Сталин дәшми, карашы читкә төбәлгән.

— Өч йөз илле мең поттан артыграк.
— Биш йөз меңгә ничек тутырырга җыена идең?
— Әмин, Владимир Ильичка ачыктан-ачык әйттем, ГПУдан өстәмә көчләр бирсәгез — табам, дидем. «Анысыннан гына эш тормас»,— диде иптәш Ленин.
— Нәрсә, ГПУның яз көнендә уңыш җыя торган басуы бармыни?...
— Булмаса, таптыра торган көче бар. Әмәлен беләләр.— Һәм битараф кына өстәп куярга да кирәк тапты тагы:— Татар мужигының чабата астында гына булса да яшерелгән запасы була аның, беләбез...
Тамаша кылып утырган Сталинга күз читен төшереп алгач, Мирсәет Солтангалиев үзләренә генә аңлаешлы булган татар телендә мөрәҗәгать итә:
— Әйт әле, үз халкыңа нәфрәт, аның язмышына төкереп карау каян килде ул сиңа, Сәхипгәрәй?... Синең «тройка»ларың көзен дә, кышын да, язын да бары тик татар авылларын талаган, диләр... Дөресме шул?...
Сәетгалиев урысча сөйләшүен дәвам итте, тавышын күтәрә төште хәтта. Аның һәр сүзе Сталин колагы өчен иде.
— Булса соң, мин бит синеңише «милләтче» түгел. Интернационалист мин, революционер — шуңа күрә ээәрлеклисез сез мине. Сез барыгыз да милләтче — Мохтаровың да, Юныс Вәлиди дә, Шамил Усманов та. Барыгыз бер иш.
— Партия өлкә комитетындагы рус иптәшләр дә шуңа сөймиме үзеңне?...
— Ишетәсеңме?! Мин — интернационалист!
Мирсәетнең нәфрәте чамасыз, күптән ташып чыккан, әмма үз-үзен кулда тотарга кирәк икәнлекне дә яхшы белә. Сәетгалиевнең ана телендә аңлашырга теләмәвен дә тиешенчә кабул итеп, үзе дә русчага күчте.
— Соңгы бер ел эчендә Татарстанда яшәүче руслар дүрт процентка, чуваш һәм башка милләт вәкилләре ун процентка кимегән булса, татарлар арасында бу сан... күпмегә тигез дип уйлыйсың?! Татарлар, рәсми мәгълүматлар күрсәткәнчә, утыз процентка кимегән. Әнә шул егермеегерме алты процентка тиң аерма синең намусыңда, Сәхипгәрәй Сәетгалиев. Ишетмәсәң — ишет!
Сәетгалиев, җәт кенә Мирсәетнең култык астыннан шуып, «ирек»кә атылып чыкты, ниһаять. Билгеле инде, теленә дә ирек ачыла төште.
— Мин — интернационалист!...— дип кабатлады ул ватык тәлинкә сыман.
Мирсәет, ниһаять, аның бу кыланышына нәтиҗә ясады.
— Милләттәшләрең — балалар, хатын-кызлар, карт-карчыкларның баш сөякләреннән үзенә һәйкәл торгызган интернационалист син!
Нindидер фикергә килепме, әллә куркудан гынамы, Сталин утырган кресло артына барып басты Сәхипгәрәй. Башын кашып алды. Җитди сүз әйтергә җыенуы икән:
— Әйтсәм, әйтим, тыңла, Солтангалиев, һәм хәтереңә киртләп куй: дөнья революциясе ясаганда нindидер бер татар милләтенең тарихта эзсез югалуы — ул баш китәрлек бәла түгел. Сезнең, милләт-милләт дип, лаф оруларыгыз чит минем өчен. Ышанмыйм мин татарның киләчәгә булуына. Марҗага өйләндем шуңа. Балаларыма урыс исеме куштым. Мин — интернационалист!
— Җитәр,— дигән тавыш Сталин авызыннан чыга. Сәетгалиевкә үзенең кабул итү бүлмәсенә керә торырга куша ул.
Җиңүче сыйфатында, кабинет ишеген каты бәреп чыгып китә Сәетгалиев.
Сталин, читкә китеп баскан, маңгаен учлап уйга чумып торган Мирсәет янына килеп, аның җилкәсенә дустанә кулын сала.
— Борчак пешми икән сезнең. Ә ул...— дип, ишеккә таба ымлый аннан.— Шәхес! Революция эшенә чын-чынлап бирелгән шәхес икән бит.
— Шәхес түгел, клоун ул! Дөньяга ялгыш туган бер бәндә.

С т а л и н. Хәтерендәме икән, 1920 елның башларында ЦКда Татар республикасы игълан итү турында сүз булгач та мин синнән сораган идем...

М и р с ә е т. Хәтеремдә. Сез миңа Татарстанга Совнарком рәисе булып барырга теләмисеңме, дидегез. Мин уйлана калдым.

С т а л и н. Юк, теләмим, диден һәм Сәетгалиев кандидатурасын үзең тәкъдим иттең.

М и р с ә е т. Нишлисең, адәм хатадан хали түгел, иптәш Сталин.

С т а л и н. Димәк, син үзең дә Сәетгалиевне югары бәяли идең.— Һәм чыгар якка юнәлеп, ишеккә барып җиткәндә генә туктала төшә ул.— Мирсәет, син юлга чыккан җиреңнән бер-бер истәлек, бүләксез кайтмый торган идең минем янга. Бу юлы әллә Троцкийга биреп өлгердеңме?... Соңгы араларда суына төштең әле син миңа. Татарстаннан буш кул белән кайтмагансыңдыр, шәт...

Мирсәет, беркавым югалып, икеләнеп торганнан соң, өстәле янына тәвәккәл генә барып, аның аскы капкачын ачты.

— Буш кайтмадым, иптәш Сталин.— Өстәлгә гәҗиткә төрелгән ике олы төргәк чыгарып куйды ул.— Сезгә дә бар, Лев Давидовичка да кала. Кайсысын телисез, сайлап алыгыз.

Сталин кире борылып килә һәм өстәл өстендә янәшә торган төргәкләрнең әле берсен, әле икенчесен күтәреп карый — сайлый. Һәм зуррагын култык астына кыстырып, киредән чыгар юлга юнәлә.

— Ат башы кадәр алтын диген, ә,— дип, шаярган атлы була үзалдына.

— Бүгенге Татарстан өчен аеруча хас истәлек,— ди Мирсәет. Һәм Сталин артыннан ишек ябылгач, үзалдына кәефсез генә мыгырданып куя.— Әйе, Идел-Чулман буйларына алтын чәчкәннәр...

* * *

Мирсәетнең бүләк дигәне ни булды икән? Сталин аны соң гына, кабул итү сәгате тәмамланып, кабинетында берьялгызы калгач, урамда караңгылангач кына ачып карар ара таба. Ача һәм чак аумый кала. Гәҗит эченә төрелгән бүләк — баш сөяге. Кешенеке!... Ил белән, алай гынамы, дөнья белән идарә итәргә җыенган адәмнең шулчак ни уйлаганын, нинди нәтиҗәләр ясаганын белсә дә, алла үзе генә белгәндер.

Әлеге «бүләк» хакында Сталин булсын, Солтангалиев булсын, үзара күпме очрашып та алга таба ләм-мим сүз кузгатмадылар. Әмма һәр икесе аны онытмады. Оныту мөмкин идеме соң?!

* * *

Сәхипгәрәй Сәетгалиев Сталин яныннан асыл кош тоткандай канатланып чыкты ул көнне. «Революция эшенә бирелгән синдәй коммунистлар сирәк татарлар арасында,— диде Сталин әлеге әңгәмәне йомгаклап.— Партия каршында үзеңнең чын интернационалист икәнлегеңне чираттагы мәртәбә исбат иттең. Борчылма, синдәй егетләр эшсез калмас!»

«Интернационалист» дигәне аеруча хуш килгән иде аның күңеленә. Гомере буе үзен милләтчелектә гаепләүдән курыкты бит ул. Чөнки милли эшлекләләрдән теләсә кайсын шул бер сүз белән урыннарына утырта торган заман иде. Үз халкың мәнфәгатьләрен кайгыртып «кыл кыймылдаттыңмы» — син «милләтче». (Хәер, шул елларда гынамы икән?!. Кызганычка каршы, ул куркыныч шәүлә — милләтчелектә гаепләнү куркынычы — урындагы түрәләрнең байтагын әле дә кулсыз-аяксыз гына түгел, телсез итә.)

— Татарлар сезгә мәңге рәхмәтле булачак, иптәш Сталин,— диде Сәетгалиев, ишек катына җитеп аерылышкан мизгелләрендә.— Безне

Республикалы иттегез, автономияле. Теге милләтчеләр аяк чалмаган булса, әле мин күпме сорасагыз — шул кадәрле икмәк тапшырачак идем. Рәхмәт, иптәш Сталин, сез безне Республикалы иттегез...

Урамга чыккач та: «Сталинны ышандырдым,— дип нәтиҗә ясады ул үзалдына.— Инде бер-бер сәбәп табып, Ильичның да күзенә чалынырга иде бит.» Кремльнең итәге булып сузылган Александров бакчасы буйлап ялгызы атлап барганда үзе өчен гаҗәп уңышлы тоелган уй килде аның башына. Ильичка хат юлларга кирәк. Зарланып, сукранып түгел. Кемнедер гаепләп тә түгел, чөнки аңардан хәзер шуны көтәләр. Ә үзенең политик фикерләре, кайбер күзәтүләре белән уртаклашырга. Әлбәттә, аны укыгач та Ильичта ул хатның авторына соклану хисе туарга тиеш. «Әнә ич, милли кадрлар ничек үскән, коеп куйган интернационалист икән бу Сәхипгәрәй Сәетгалиев. Моңарчы бәяләп җиткермәгәнбез түгелме без аны?!»— диярлек булсын.

Шундук бакчаның аулак бер почмагында посып торган эскәмиягә утырып, куен дәфтәренә тарихи тезисларын язарга кереште ул.

«Дүрт сорау» дигән баш куйды. Әле сораулары нинди булачагын тәгаен күзалдына китереп җиткермәсә дә, исем күңеленә хуш килде. Философларча чыга ич! Күп сүз кирәкми, хат эшлекле булырга тиеш, аның авторы кебек...

*«Владимир Ильич!*

*Үземне озак вакытлар борчып йөдәткән дүрт сорауга җавап бирүегезне үтенәм:*

*1. Россия Федерациясендә зур булмаган автономияле республикаларның булуы зарурмы? Бу сорауга җавабыгыз иң элек Татарстанга мөнәсәбәтле кызыксындыра.*

*2. Зарур булса, озаккамы, башкача әйтсәк, нинди мәсьәләләрне хәл иткәнче һәм нинди максатларга ирешкәнчегә кадәрле?*

*3. Үзенең дәрәҗәсе, әзерлеге белән күпкә югары торган, элгәре хакимлек кылган милләт коммунистлары изелгән милләт коммунистлары һәм хезмәт ияләренә мөнәсәбәттә тәрбияче һәм мөгаллим булырга тиешле саныйм. Ә тора-бара мөгаллим вә тәрбиячеләр үз урыннарын шәкертләренә тапшырырга тиешлеме?*

Шушы өч сорауны язып тәмамлагач, озак кына уйга бирелеп утырды Сәхипгәрәй. Ул күтәргән сорауларны кат-кат укып, шул сорауларны күңелендә йөртүче, үзе белән ихластан фикер уртаклашырга, киңәшергә җөрьәт иткән интернационалист, коммунист хакында Ильичның ни уйлаячагын күзалларга тырышып азапланды. Сораулар, үзе көткәндәгедән дә шәп чыкты кебек. Һәрхәлдә, юлбашчының аңарга булган ышанычы кимемәячәк. Әмма дүртенче сорау да бар бит әле. Беренчедән, «дүрт сорау» дигән исемнән баш тартасы килми иде аның. Өч саны — бик гадәти. Өч сорауны теләсә кем язарга мөмкин. Икенчедән, күңелендә бушану җитенкерәми әлегә, мәсьәләгә якынрак килеп,ниләргәдер, кемнәргәдер ишарә ясыйсы, кыскасы берьюлы ике куянны атасы иде бит. Дүртенче сорау ифрат авыр туды.

*4. Һәммә автономияле республикада, аеруча Татарстанда, чит милләт коммунистлары (татарлар) арасында бер-береннән аермачык аерылып торган ике агым (группачылык) яши: берәүләре сыйнфый көрәш, әлеге сыйнфый көрәшне торган саен үз милләтләре* (хатның оригиналы урыс телендә язылган. Сәетгалиев үз милләтен бу очракта һәм тагы берничә урында «туземное население» дип атый.— Автор) *арасында да тирәнәйтә бару юлында. Ә икенчеләре — вак буржуаз милләтчелеккә йөз тота. Соңгы дүрт ел бу аерымлыкны ачык күрсәтте. Беренчеләр РКП(б) һәм аның җитәкчелеге тарафыннан нык ярдәм, яклау табарга тиешле дип санап, мин ялгышмыйммы? Икенчеләре исә пролетар революциясе эшенә кулай булган кадәрле генә вакытлыча файдаланырга тиешле һәм, әлбәттә, чын интернационализм юнәлешендә тәрбияләнүгә дә мохтаҗлар. Әмма боларын Татарстанда килеп чыккан кебек, беренчеләреннән кулайрак күрү ярамас. Сез ничек уйлыйсыз?»*

Сүзгә-сүз дип әйтерлек тәрҗемә итеп китерелгән әлеге хат — тарихи факт. Һәм ул хатның шул көннәрдә үк Ильичның эш өстәленә барып ирешүе дә мәгълүм. Ленин, әлбәттә, игътибарсыз калдырмаган аны — дикъкать белән укыган, һәр сорау каршысына үзенең кыска, әмма бер үк вакытта гыйбрәтле дә булган җавапларын язып чыккан.

Беренче сорауга җавап: «Әйе» дигән бер сүздән гыйбарәт. Икенчесенә — «Әле озакка»; өченчесенә — «Педагог һәм няня» түгел, ә ярдәмче дүртенче сорау каршында «Ике агым» хакында төгәл, кыска, ачык күрсәтмәләр бирүегезне үтенәм» дигән сүзләр язылган.

Ильич әлеге хат белән танышканнан соң күп гомер узмый, ә Сәхипгәрәй Сәетгалиевне инде Кырым автономияле республикасының Совнарком рәисе итеп билгелиләр. Татар коммунистларыннан Үзәк өчен аңардан да кулайрак кеше табылмый. Сталин гына түгел, Ленин да «чиертә» Сәетгалиев кармагына.

Кырымга китәр алдыннан Сәхипгәрәй янә беркат Сталинда булып чыга һәм, Ленинга тапшыруын үтенеп, Елена Стасовага чираттагы мәктүбен калдыра. Бу юлы инде ул сорау бирүче сыйфатында түгел, югарыда искә алынган «дүртенче сорау»га ачыклык кертүне бурыч итеп куя. Әлбәттә, Сталин янында сөйләшүләрдә булсын, хатларында булсын, Сәетгалиевнең төп максаты — үзен «нахакка рәнҗетүчеләр» белән мөнәсәбәт ачыклауга кайтып кала. Татарстан партия оешмасында үзенә ышанычсызлык күрсәткән «уң» һәм «сул» коммунистларның һәммәсенә өлеш чыгарыла анда. Татар большевикларына интернационализм тойгысы җитенкерәмәү искәртелсә, руслар — шовинизмда, купчелекне тәшкил иткән яһүдләр — ике араны, үзара капма-каршы кую, бутауда гаепләнә. Ә боларның һәммәсенә тискәре йогынты ясап, партия оешмасыннан «чын интернационалистларны» кудыруны оештыручы — Мирсәет Солтангалиев. Әнә ничек килеп чыга!

Әлбәттә, Ленин һәм Сталин Сәетгалиевне тыңлап кына, аның кулы белән язылган хатларны укып кына, үзләренең Мирсәеткә булган мөнәсәбәтләрен үзгәрткәннәрдер, дип әйтергә нигез юк. Шулай да... Сөйләү һәм ышандыру сәләтенә шактый гына ия булган Сәхипгәрәй Сәетгалиев чәчкән орлыклар кайчан да булса бер шытым бирмәс дип кем әйтер!?.

Кырымга китәргә тәмам җыенгач, Совнарком бинасыннан тимер юл вокзалына чыгып китәр алдыннан, Сәетгалиев Мирсәет белән дә кереп хушлашырга кирәк таба.

— Синдә тырышлык, үҗәтлек җитәрлек — юлыңа ак җәймә,— ди аңарга Мирсәет, кулын биреп.— Әмма халыкка якынрак булырга тырыш. Халык изгелекне онытмый. Тагы бер үтенечем бар, Сәхипгәрәй. Кырымга баргач та Фирдәвес белән булышуыңны дәвам итә күрмә. Иске үпкәләрне онытырга вакыт.

Сәхипгәрәй үзенә шундый эчкерсез, җылы мөнәсәбәт көтмәгән була, күрәсең. Югалып кала бирмәл. Елмаерга да, бер-бер төртмә сүз әйтергә дә җөрьәт итми.

— Миңа шундый эш тәкъдим итәрләр дип көтмәгәнсеңдер?— дип сорап куя, эчкерсезләнеп. Ләкин шул урында туктала белми.— Сәхипгәрәй Сәетгалиевнең кем икәнлеген белмисез шул әле сез,— дип, тавыш күтәрергә кирәк таба. Аннан кискен борылып, чыгар юлга юнәлә.

Чынлап та Сәхипгәрәй Сәетгалиевнең кем икәнлеген, аның үзен дә алда нинди язмыш көткәнен дә белми әле Солтангалиев ул вакытта.

* * *

Күңеленә шик-шөбһә төшсә, Мирсәет үз-үзен кая куярга белми башлый. Тынычрак, иплерәк булып, җиде кат үлчәгәч кенә бер кат кисеп яшәргә кирәклеген дә белә. Бу хакта Мулланур Вахитовның да күп мәртәбәләр искәрткәне бар иде аңарга. Әмма нишлисең, табигатьне

үзгәртү мөмкин түгелдер, күрәсең. Күкерт кабыныргa өлгергән ир-атны йөгәнләрлек көч табылмады, бу юлы да Мирсәет шалтыратып, алдан килешеп тормый гына Сталинның үзенә керергә булды. Керергә һәм һәммәсен уртага салып сөйләшергә, аңлашырга кирәк аңар хәзер.

Иң ашыгыч эшләрен бер кат барлап, шалтыратасы җирләренә шалтыратып чыккач ук, Мирсәет Партия Үзәк Комитетына, берничә ай элек кенә Генераль секретарь итеп билгеләнгән Сталин кабинетына юнәлде.

Бәхетенә каршы дип әйтергә кирәктер, кабул итү бүлмәсендә Товстуха иде. Гәрчә ишек катында утыру аның вазифасы булмаса да, бу көтелмәгән очрашу түгел иде Мирсәет өчен. Иван Павлович Товстуха — Сталинның аеруча җаваплы һәм яшерен эшләрен генә башкаручы секретаре. Аңарга утыз биш яшьләр чамасы, буйга — озын, гәүдәгә — чандыр. Басып торганда ул, беркадәр, сорау билгесен хәтерләтә. Куе кашлар астыннан төбәлгән карашы берөзлексез әңгәмәдәшенең күзләрендә булыр. Үзе аз сүзле, әмма башкаларны бүлдермичә тыңлый белә. Бөдрәләнә төшкән озын кара чәче һәм кара мыек йөртүен дә искә алсаң, Товстуха Сталинның дүрт секретаре арасыннан, тышкы кыяфәте белән уңай якка аерылып тора.

Товстуханы Сталинның иң мәкерле һәм астыртын секретаре дип саныйлар. Аның белән эш итү түгел, хәтта очрашудан да сагаеп йөрүче кешеләр барлыгын белә Мирсәет. Әмма үзе алай санамый иде. Товстуха аңарга ачыктан-ачык зыян күрсәткән кеше түгел. Очрашканда кочаклашып күрешмәсәләр дә, сәламләшеп яшиләр иде кебек. «Бәхеткә каршы» дип әйтү дә шуңа, Товстуха әле соңгы көннәргәчә Милләтләр эше халык комиссариатында эшләде. Анда да Сталинның секретаре иде.

— Иптәш Солтан-Галиев...— дип, теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалып, өстәл артыннан каршы чыкты Товстуха, сәлам бирде.

— Исәнме, Иван Павлович...

Күрешкән мәлдә Товстуханың ирен читләрендә чалымланып алган яктылык, болыт артына кереп качкандай, шундук юкка да чыкты.

— Ни эшләр китерде үзеңне?— диде ул, соң дәрәҗә эшлекле һәм кырыс сөйләшүгә күчеп. Товстуханың үзенә кайчан да булса шулай югарыдан торып мөрәҗәгать иткәнен хәтерләми иде әле Мирсәет.

— Иптәш Сталинга җитди йомышым бар...

— Җитди йомыш,— дип кабатлады секретарь аның артыннан.

— Әйе, ашыгыч рәвештә күрешеп аңлашырга кирәк иде безгә.

— Ашыгыч рәвештә...— дип, бу юлы да Мирсәетне кабатлады Товстуха. Әмма, бу аның әңгәмәдәшен үртәргә омтылудан түгел. Мирсәетнең моңа нигез биргәне юк. Ниндидер уйга бирелгәнлегеннән, икеләнүеннән, чарасызлыгыннан килә иде булса кирәк. Аның белән очрашудан шулай коелып төштеме ул, әллә бер-бер күңелсезлек килеп чыкканмы — ул кадәресе Товстуханың үзенә генә мәгълүм.

— Керергә рөхсәттер ич,— дип, китель якаларын хәстәрләп алды Мирсәет, кабарып торган куе чәчләрен ун бармак белән артка сыпырып куйды. Ыспайлык һәм пөхтәлек аның канына сеңгән.

Чабышкка әзерләнгән аттай бер урында тыныч кына басып тора алмый тынгысызланган Солтангалиевтән карашын алмыйча күзәтеп торган секретарь яңак читләрен бөкшәйтеп елмайгандай итте.

— Утырып торыгыз... Иптәш Сталин кабул итә алмый әлегә. Теләсә-теләмәсә дә үзенә тәкъдим ителгән, кара күн белән тышланган имән урындыкка барып утырырга мәҗбүр булды Мирсәет. Бүлмә почмагында торган мәһабәт зур сәгатькә күз төшереп алды.

Бертын ниндидер кәгазьләр арасында актарынып алганнан соң Товстуха янә йончыган күзләрен урындыкта утыручыга текәде.

— Иптәш Солтан-Галиев. Генеральный секретарь сезне үзе чакырып китердеме?

Әйе, дип җавап кайтарырга кирәк булгандыр, бәлки. Шулай да Мирсәет үзен юк-бар ялганнардан югарырак тотарга өйрәнгән.

— Хәбәрләшми генә килдем.

Мирсәетнең бу җавабында: «Сиңа, нәрсә, иптәш Сталин белән безнең арадагы якынлык, эшлекле мөнәсәбәтләр мәгълүм түгелмени? Шулай икәнлегеп яхшы беләсең!...» — дигән кинаяне тою өчен әллә ни зур сизгерлек кирәк түгел иде. Кемдә-кемдә, Товстухада чамадан артып киткән андый сәләт, «Ау эте» дигән үчек — кушамат юкка гына бирелмәгәндер үзенә.

Килеп туган киеренкелекне, үзенә күрә киметмәкче булып, һәрхәлдә, яман ният белән түгел, шаяруга омтылып, теленә килгән мәкальне искә төшерде ул:

— «Чакырылмаган кунак — татардан да яманрак» диләрме әле, иптәш Солтан-Галиев?

Товстуханың бу җорлыгы Мирсәетнең күңеленә хуш килмәде, әлбәттә.

Үзенә дә тозлап-борычлап бер-бер мәкаль белән җавап бирергәме әллә дигән ният туып алды. Әмма, урыны ул түгел, бер юлга калып торсын...

— Әйе, безнең татар дусны да, дошманны да үзен танырга өйрәткән халык, — дию белән чикләнергә булды.

...Инде, ким дигәндә, ун-унбиш минут чамасы вакыт узды. Генеральный секретарь ишегеннән керүче дә, чыгучы да күренми. Товстуха янә сейфтан ниндидер бәйләмнәр чыгарып, кәгазь барлау белән мәшгуль. Мирсәетнең эче поша, куллары-аяклары кыбырсый — вакытны, шул рәвешле, заяга уздырырга күнегелмәгән. Моңарчы һичкайчан Сталинның кабул итү бүлмәсендә тоткарланып торганы юк иде әле аның.

Тагы бермәл утыргач, урыныннан торып, өстәлгә якынлашты ул. Икеләнергә урын калдырмаслык итеп, Товстухага мөрәҗәгать итте:

— Иптәш Сталинга хәбәр итүегезне үтенәм, Иван Павлович, минем ашыгыч эшләрем бар.

Товстуха өстәл өстенә җәеп салган кәгазьләрен, кеше күзенә күрсәтүдән куркып, ашыга-кабалана кара папкага яшерү белән мәшгуль иде. Солтангалиевнең урыныннан кузгалуын сизми калган идеме, хәтта колак очларына кызыллык чыкты. Үз партиядәшеннән шул тикле яшерен нинди кәгазь-документлар булырга мөмкин икән...

Кинәт кабул итү бүлмәсен яңгыратып телефон шалтырады. Уңайсызлану хәленнән чыгып, трубкага үрелде Товстуха:

— Товстуха тыңлый... Әйе... Төшендем... Иптәш Сталин бик җитди мәшгуль... Кешесез калдыра алмыйм... Каннер кайда?... Ә Мехлис?... Мария Игънатьевна менсен алай булгач...

Мирсәеткә, төребкәнең аргы ягында кем булу һәм аның ни дигәнен ишетмәсә дә, сөйләшүнең мәгънәсен тоемлау кыен түгел иде. Товстуханы, күрәсең, ашыгыч эш белән чакыралар. Ә Сталин аңарга, иң ышанычлы ярдәмчесе буларак, кабул итү бүлмәсендә сакта торырга кушкан. Каннер, Мехлис һәм Мария Игънатьевна Гляссер — болар шулай ук Үзәк Комитет Секретарьлары. Сталинның янәшәсендә эшләүчеләр, Товстуханың сүз сөрешеннән яхшы аңлашыла, «Хуҗа» ишеген саклауны әлеге сәгатьтә ул бары тик шушы өч кешегә генә ышанып тапшыра ала икән. Гәрчә бу турыдан-туры аларның вазифалары булмаса да...

Кабул итү бүлмәсенә итагатьле исәнләшеп, Мария Игънатьевна Гляссер килеп керде. Товстуха папкаларын, өстәлдәге кәгазьләрен култык астына кыстырып, Мирсәет белән хушлашырга да онытып, нечкә сыйраклары белән эре-эре атлып, каядыр ашыгып китеп барды.

— Иптәш Солтан-Галиев... Мирсәет, — дип, икәүдән-икәү генә калгач тагы да мөләемләнә төшеп кабат сәлам бирде Гляссер. Ул озак еллар Ленин белән эшләгән, тәҗрибәле партия юлбашчысының иң ышанычлы кешеләреннән берсе. Мирсәет аңардан үзенә аерым бер җылы мөнәсәбәт тоеп яши иде. Күргән саен Казан һәм андагы таныш-белешләре хакында сораштыра...

Гляссер ханымны Мирсәет ихластан аягүрә торып сәламләде.

— Менә нинди очрашу... Сезне күрүемә бик шат, Мария Игънатьевна. Үзегез ничек, исән-сау гынамы?..— диде ул. Мөгаен, соңгы көннәрдә беренче мәртәбә аның йөзенә елмаю чаткысы шул мизгелдә төшкәндер.

Гомумән, Мирсәетнең хатын-кызга карата итагатьле булуын Мария Игънатьевна белә иде. Тәбәнәк кенә гәүдәле бөкере хатынга шуннан да артык җылы сүз, игътибар белдерү мөмкин дә булмагандыр. Өстәвенә төскә-биткә дә, ачы катык кабып йөзен чыткан кешене хәтерләтә бит әле ул.

— Күптән утырасыңмы?— дип сорап куйды Гляссер. Бу аның сөйләшүгә күчүе иде. Аның күзләрендә, карашында ирләрнекеннән дә болайрак җитдилек һәм тирән акыл бар. Никадәрле генә эшлекле булмасын, кешеләргә хөрмәт белән карарга күнеккән.

— Ярты сәгать чамасы булыр, Мария Игънатьевна.

— Нәрсә, иптәш Сталин шул гомер тоташ телефоннан сөйләшәме?— Үзе дә гаҗәпләнеп башын чайкап куйды.— Сезне шулай көттерергә...

— Мин ул кадәресен белмим, Мария Игънатьевна.

— Товстуха «хуҗа» телефоннан сөйләшә, берәүне дә кертергә ярамый, диде миңа. Көткәч-көткәч, тагы бераз гына сабыр итегез булмаса...

— Владимир Ильичның исәнлеге ничек, күргәнегез бармы?— дип, форсаттан файдаланып сорамый булдыра алмады Солтангалиев.

Бу бинада ул хакта ачыктан-ачык сөйләшергә ярамый дигәнне аңлатып, як-ягына каранып күзләрен кысып алды Гляссер.

Аннан дәү башын ун бармагы белән кочаклап, башын чайкап күрсәтте. «Начар шул, бик тә начар, кызганычка каршы, Ильичның хәлләре» — диюе иде бу аның.

Төшендем, чынлап та кызганыч, дигәнен аңлатып, Мирсәет тә үз чиратында баш какты. Генеральный секретарьның кабул итү бүлмәсендә ике большевик, җаваплы партия работнигы арасында шул рәвешле сүзсез аңлашу булып алды. Ни өчен сүзсез, ни өчен бу хакта аларның берсе дә чишелеп китеп сөйләшә алмый соң?.. Ул кадәресен үзләре генә белә — Үзәк партия аппаратында гомер булмаганча киеренкелек, бер-береңә ышанмаучылык шартлары тудырылган иде соңгы араларда. Өстәвенә, яшерен тыңлау җайланмалары! Кайда гына юк алар...

Шулай да Гляссер — кыю хатын. Күпмедер ара узгач, сак кына барып, Генеральный секретарь кабинетының ишеген ачып колак салырга җөрьәт итте. Тавыш-тынсыз гына тыңлап торды бермәл, һәм ишекне нинди саклык белән ачкан булса, шундый ук саклык белән ябып куйды.

— Ул телефоннан сөйләшми,— диде, Солтангалиевкә якынрак килеп. Трубка суырганы, сулыш алганы ишетелә, әмма ул һичкем белән сөйләшми.

— Димәк, керергә рөхсәт,— дип, Гляссерга текәлле җәт кенә торып баскан Мирсәет. Китель чабуларын тартып куйды, гадәтенчә чәчләрен сыпырып алырга да онытмады.

— Хәбәр салып тормыйм, сез күптәнге танышлар ич... Керегез, иптәш Солтангалиев.

Гляссер ханым аны ишек катында бер киеренкелек белән озатып калды. Сталинның үзенә карашы җылы һәм ихлас түгеллеген, акыллы хатын буларак, аңлый иде бугай ул. Владимир Ильич белән озак еллар тату, уртак тел табып эшләгән кешеләрнең һәркайсына шундый мөнәсәбәттә иде бу яңа «хуҗа».

Ике кат ишекне узып кабинетка кергәч тә түрдәге өстәлгә таба җил-җил атлап киткән Мирсәет гаҗәп күренешкә тап булып, кинәт ярты юлда туктал калды.

Кәнәфигә чалкан ята төшеп, Сталин ишеккә арты белән утыра. Колагында телефон трубкасы. Дөньяда гаме юк, бөтен игътибары телефонда. Генеральный секретарь кемнедер зур дикъкать белән тыңлап

утыра. Владимир Ильич авырый. Үзәк Комитетта бердәмлек юк. Шундый көннәрдә Бөтендөнья революциясе язмышы өчен җаваплылыкны үз җилкәсенә салган кеше ич Сталин. Партия өчен җаваплылыкны. Иксез-чиксез киңлекләргә сузылган Ватан өчен җаваплылык. Дистәләгән, йөзләгән милләт язмышы өчен җаваплылык. Кем белә, бәлки татар яисә башкорт халкы язмышы хакындагы борчу шундый тирән уйга салгандыр аны бу мизгелдә.

Иптәш Сталинга җиңел түгел, аның хәленә керә белүче юк?!. Мирсәет тә әнә, ничәмә-ничә кабат әләгешеп алды аның белән соңгы араларда. Бөтен ил ыгы-зыгы килә, көрәшә. Хәтта үз грузиннары булып, алардан да тынгылык юк Сталинга. Җиңел түгел, юк, җиңел түгел...

Шул рәвешле, исәнләшми, күзгә чалынмыйча, кабинет уртасында басып тору да килешә торган хәл түгел. Иптәш Сталин бит әле аның монда кергәнлеген белми. Уңайсызлана төшеп, тагы да беркадәр өстәлгә якыная төште ул. Ике-өч адым ара калгач янә тукталырга мәҗбүр булды. Ниһаять, Генеральный секретарьның йөзе инде аңарга яртылаш күренеп тә тора. Әмма телефонның аргы ягындагы әңгәмәдәшен шул тикле дикъкать белән тыңлый ки, иптәш Сталин хәтта күзләрен йома төшкән.

Кырыс холыклы бу кешенең шул дәрәҗәдә игътибарлы чагын очратканы юк иде әле аның.

Сулыш та алмый тыңлый... Онытылып тыңлый Сталин. Янына керүчене абайлау кая, дөньяда башка һичкем юк аның өчен. Шунда гына бераз ашыкканлыгын, үзенең вакытсызрак килеп кергәнлеген аңлады Мирсәет. Әмма монда кергәч, дәшми-исәнләшми кире чыгып китүе дә дөрес булмас. Көтәргә булды, бүлдермәскә... Һәм, ирексездән, Генеральный секретарьның өстәленә күз ташлады ул. Өстәлнең урта бер җирендә яткан төребкәгә, тәмәке тартмасына һәм ерак бер читтә тәртип белән өелеп куелган эш кәгазьләренә. Узган керүендә дә шундый ук тәртиптә өелеп тора иде ул кәгазьләр, әйтерсең, Генеральный секретарь соңгы атналарда кагылмаган да үзләренә. Ә өстәлнең бирге башында — телефон аппаратлары. Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...

Чү! Ничек була, ничек аңларга соң моны — телефон аппаратларының төребкәләре һәркайсы үз урынында... Сталинның кабинетында дүрт телефон булуы һәркемгә мәгълүм. Үзәк Комитетның эчке элемтәсе. «Түбәнге Кремль» һәм «Югары Кремль» дип атала торган телефоннар да тоташтырылмаган. Болар өчесе дә коммутатор аша эшли торган элемтә, әңгәмәдәшең белән телефончы кызлар тоташтыра. Дүртенчесе, югары даирәләр — Политбюро һәм Үзәк Комитет әгъзалары. Наркомнар кабинетында әле соңгы арада гына урнаштырылган элемтә. Аны «вертушка» дип йөртәләр. Анысы инде автомат рәвештә тоташа, бернинди телефончылар да сөйләшүгә колак сала алмый. Иң зур серләр, яшертен әңгәмәләр бары шул телефонга сыя. «Вертушка» дигәненең дә төребкәсе үз урынында...

Мирсәет янә Генеральный секретарьга текәде карашын. Ул гүя җансыз сын иде. Телефон төребкәсенә башын салган да, дөньясын оныткан. Тыңлый...

«Ә бу төребкәнең аппараты кая соң?» — дигән сорау кабынды кинәт. Ышанырга да, ышанмаска да белгән юк, кара чыбыкның икенче очы ярымачык өстәл тартмасына кереп югалган. Бу нинди элемтә тагы?!. Бу нинди телефон? Кем белән сөйләшә ул? Хәер, Генеральный секретарьның әле дәшкәне юк, ул кемне шулай йотлыгып тыңлый? Кремльдә башка бернинди элемтә юклыгы һәркемгә мәгълүм ич.

Ниһаять, бу йончыткыч тынлыктан, дәшми-хәбәрләшми торудан тәмам гаҗиз булып, үзенең монда икәнлеген искәртергә теләп, йөткергән атлы булды ул. Сталинның сискәнгәнен яисә, чарасыз калган чагын күргән кеше булдымы икән?!

Генеральный секретарь, башын әле генә якты дөньяга чыгарган йомран сыман, йөткерүчегә йөгерек караш ташлады. Баш какмады ул

аңар, исәнләшмәде, танымаганга сабышты. Күзләрен кыса төшеп текәлеп торды бераз: «Каян килеп чыктың әле син?... Ни рәвешле үтеп кердең монда?» — дия иде ул гүя. Болай да кырыслыктан сирәк арына торган карашында Мирсәет өчен бөтенләй чит һәм аңлашылмаган кыргый нәфрәт, мәкер...

Тораташ булып катып калды Мирсәет, әлеге карашның мәгънәсен аңлый алмады. Һәм ул моны һичкайчан аңламаячак та. Ничек итеп Генеральный секретарь үзенең ничә еллар дәвамында аралашып яшәгән партиядәшенә, большевикка шулай карый алсын икән?!

Сталин янә, берни булмагандай, телефон төребкәсенә сеңде. Гел көтелмәгән тарафтан ишек ачылган аваз ишетелде. Кабул итү бүлмәсеннән хром итекләрен шыгырдатып җәт-җәт атлап Генеральный секретарьнең уң кулы саналган кечкенә гәүдәле, бөдрә чәчле Каннер килеп керде. Күрәсең, хуҗа кеше нинди дә булса кнопкага басып чакырырга өлгергән иде аны.

Килгән шәптән Мирсәетне иплә генә култыклап алды Каннер һәм ишеккә таба ымлап, чыгарга әйдәде. Зур дәүләт эшләре турында сөйләшү белән мәшгуль булган иптәш Сталин, Милләтләр эше халык комиссариаты Коллегиясе әгъзасы Мирсәет Солтангалиевне үзе янына кергән җирдән ничек итеп кире алып чыгып киткәннәрен гүя абайламый да калды.

Кабул итү бүлмәсенә чыгып, артыннан ике кат ишек ябылгач кына, үзенең ни дәрәҗәдә кыен хәлдә торып калганлыгын, ни дәрәҗәдә рәнҗетелгәнлеген аңлады Мирсәет. Гляссер ханым бераүгә дә күтәрелеп карамады, иңбашына салынган шәл читенә күзләрен сөртә-сөртә иплә генә китеп барды. Каннер аңа бер-бер дорфа сүз әйтергә өлгергән, күрәсең...

— Төшенә алмыйм, нәрсә булды? Мария Игънатьевнаны кем рәнҗетте? — дип, Каннерга текәлде Мирсәет.

Сер бирмәде Каннер, башын күтәреп үзенең һәр очрак өчен дә әзер торган ялагай елмаюы белән җавап кайтарды. Сталинның секретарьлары арасында ул үзенең үтә мәкерлеге, үҗәтлеге белән аерылып тора иде.

— Ничек соң, иптәш Сталин белән сөйләшә алдыгызмы?

Мирсәет сизеп тора, Каннер аларның үзара ләм-мим сүз алмашмаганлыкларын яхшы белә. Әмма ул әңгәмәне башкача кора алмый, кешене ничек кенә булса да түбәнсетергә, уңайсыз хәлдә калдырырга омтылышы канына сеңгән.

Дәшмәде Солтангалиев. Дәшсә, иплә сүз әйтерлек хәлдә түгел иде.

— Сүз уңаеннан сорыйм әле, иптәш Солтангалиев, «Хуҗа» кайсы телефоннан сөйләшә иде?

Бу сорау түгел, тозак! Колагы ишеткәннән тетрәнеп куйды Мирсәет. Димәк, нindидер сер бар монда!.. Ул белмәгән сер бар. Бераү дә белмәгән һәм белергә тиеш булмаган сер.

Гляссер ханымны да тикмәгә генә елатмаган Каннер.

— Игътибар итмәдем,— диде ул гамьсез генә. Үз-үзен кулга алырга өлгергән иде инде.

Каннер иркен сулап куйды:

— Урын тәкъдим итәргә дә онытып торам икән... Утырыгыз, утыр, иптәш Солтангалиев. Сез инде үпкәләмәгез, иптәш Солтангалиев.— Һәм шунда ук, сүз уңаеннан гына дигән сыман, искәртергә кирәк тапты.— «Хуҗа»ның бүген мәшәкатьле көне иде. Бәлки, очрашуыгызны бер хәерле сәгатькәчә кичектереп торырсыз.

Үзе дә шундый нәтиҗәгә килеп өлгергән иде инде Мирсәет. Каннерның да тел төбендә нәрсә барын чамалады — Генеральный секретарь бүген башка эшләр белән мәшгуль, ул бераүне дә кабул итәргә җыенмый. Хәерлегә булсын... Күңел төшенкелеген озатып калучыга сиздермәскә тырышып, тәвәккәл адымнар белән нык басып, кабул итү бүлмәсеннән чыгып китте Солтангалиев.

Кремль ишегалдына чыккач та тирән сулыш алып, күңел төшенкелегеннән арынырга теләп, башын югары чөйде ул. Аны гына көтеп торганнар диярсең, кинәт чиркәүләрнең ап-ак манаралары очыннан дәррәү карга көтүе күтәрелде. Шәрран ярып кычкыра, кара өермә булып әйләнә-бөтерелә башлады кошлар. Кайберләре, югарыда пыр тузу белән генә канәгатьләнмичә, кызу тизлек белән очкан көйгә таш сыман түбәнгә ташлана, һәм инде җиргә төшеп җитә дигәндә генә, йөрәк яргыч аваз чыгарып, кире югарыга җилпенергә керешә. Каргаларга ни булган, каргалар ни әйтергә тели?! Кемне нәрсәдән кисәтергә тели каргалар?!. Карашын икенче читкә, Спасс манарасына таба борды ул, әлеге хәвефле ыгы-зыгыдан тизрәк арынырга ашыкты. Үч иткәндәй, Спассны да. Кара карга төркеме урап алган. Бер-берен уздырырга теләп «карр-карр» кычкыралар, канатлары белән шап та шоп салкын аяз күкне кыйныйлар. Әллә аңардан көлә, аны мыскыл итәме соң болар: «Нәрсә, революционер, бөтендөнья инкыйлабын ясадыңмы?! Ясарсың, бар! Карр... Карр...»

Карга тавышыннан гаҗиз булган Мирсәет ике йодрыгы белән колакларын каплады. Кремльнең кызыл йолдызы тирәли дөнья бетереп очкан кара кошларны күрергә теләмичә, четердәтеп күзләрен йомды. Яктылыкка арка куеп, маңгаен Кремльнең салкын таш диварына сөяде. Карга тавышы ишетелми, күз алдыннан да югалды кара каргалар. Әмма шундук икенче күренеш гөлт итеп кабынды аның күз алдында: Кабинетының түрендә аңарга арка куеп большевиклар партиясе Генеральный секретаре Иосиф Виссарионович Сталин утыра. Таш сын кебек кымшанмый утыра. Гүя Сталин түгел, бу аның таш сурәте. Колагында телефон трубкасы. Трубкага тоташкан кара чыбык өстәл тартмасына кереп югала. Өндә идеме бу, әллә төштә генәме?

...Вакыт үтәр. Чиркәү һәм манаралар өстендә чыр-чу килеп очкан каргалар тавышы тиз юылыр Мирсәетнең хәтереннән. Ә өстәл тартмасына кереп тоташкан серле телефон трубкасына башын салып, арка белән утырган Сталин сурәте аны гомере буе әзәрлекләр. Гомере буе җавап эзләр ул бу күренешкә. Әмма таба алмас. Үзе хөрмәт иткән, озак еллар аралашып яшәгән көрәштәше турында начар уйлый алмас ул һичкайчан да... Андый уй керсә — ул аны үзеннән куар, сүз ишеттерсәләр — ышанмас, каршы төшәр...

* * *

Хакыйкатьтә исә хәлләр болайрак була.

Егерменче еллар башында партия һәм дәүләт җитәкчеләренең телефон аша үзара сөйләшүләреннән кайбер мәгълүматларның телдән-телгә таралу очраклары ешая. Коммутатор аша сөйләшүләр генә канәгатьләндерми башлый югары даирәләрне. Шуннан арыну максаты белән, Ленин инициативасы белән, Көнбатыштан илгә беренче автомат элемтә системасы кайтартыла. Ә моны тормышка ашыру һәм урнаштыру эшенә Сталин һәм аның секретарьларыннан берсе Каннер алына. Махсус исемлек белән санаулы гына югары җитәкчеләр кабинетына урнаштырыла телефон. Бу эшнең техник ягын башкарып чыгу өчен Чехословакиядән югары квалификацияле белгеч (ул үзе коммунистлар партиясе әгъзасы) чакырыла. Соң дәрәҗә яшертен конспирация шартларында башкарыла бу эш. Үзәк автомат станция Үзәк Комитет бинасында күпчелек җаваплы җитәкчеләр утырган бишенче катта урнаштырыла. Инструкциядә каралган эшләр тәмам булгач, Чехословакиядән килгән белгечкә Каннер тарафыннан катгый приказ бирелә:«Элемтә начарайса яисә бозыла-нитә калса, төзәтү өчен» янәсе, контрольлек итү җайланмасы кирәк. Ниһаять, катгый таләп һәм мәҗбүр итүләр нәтиҗәсендә, чех белгече тарафыннан 1922 елда теләсә кемнең сөйләшүен яшертен тыңлап тору җайланмасы файдалануга тапшырыла.

Әлеге яшертен эш тәмамланган сәгатьтә үк Каннер Сталинның үзе исеменнән ГПУны җитәкләгән Ягодага шалтырата. Имеш, Политбюро Чехословакия коммунистлары партиясеннән ашыгыч телеграмма алган. Төгәл мәгълүмат һәм ышанычлы дәлилләр нигезендә, бу элемтәне урнаштырырга килгән белгечнең шпион булуы ачыкланган. Шуның өчен бу белгечне кичекмәстән кулга алырга һәм атарга кирәк. ГПУның «шпион»нарны бернинди суд һәм тикшерүләрсез атарга өйрәнеп килгән чоры була бу.

Кулга алынучының коммунист икәнлеген белгәч, шулай да Ягода, соңыннан ул-бу булмасын дип, Сталинның үзенә шалтырата. Сталин, белгечнең шпион булуын, ул үзе урнаштырган элемтә аша раслый.

Чехословакия коммунистын шундук подвалга төшереп аталар. Каннердан аның шпион икәнлеген раслый торган документлар гына күренми. Ә Ягода төгәл эшләргә күнеккән. Атна-ун көн узгач, ул Каннерга мөрәҗәгать итәргә була:

— ГПУдан шалтыраталар. Иптәш Каннер, теге чех коммунистының документлары нигәдер килеп җитми.

Ике уйлап тормый Генеральный секретарь ярдәмчесе:

— Аны әйтәсең икән. Шпионнар Чехословакия компартиясенең иң югары даирәләренә үрмәләгән булып чыкты. Шуңа күрә ул документлар соң дәрәҗәдә яшертен, без аларны сезгә җибәрә алмыйбыз. Политбюро архивында сакларга кирәк таптык,— дип җавап кайтара.

— Иптәш Сталин ул хакта беләме? — дип төпченә Ягода.

— Белә...

Бу хакта Политбюро архивында һичнинди документ булмый, әлбәттә.

Шул рәвешле, Сталинның бары тик үзе һәм мәкерлекнең аргы ягына барып чыккан секретаре Каннер гына белә торган яшертен тыңлау җайланмасы булдырыла. (Сүз уңаеннан: Каннер гомере буе Сталинга тугры була, аның иң яшертен һәм кара эшләрен оештыруга, башкаруга зур өлеш кертә. Ә 1937 елда «На всякий случай» дигәндәй, Сталин аның үзен дә бер сәбәпсез генә аттырып үтертә. Нинди генә ышанычлы булуына карамастан, шаһитләрне исән калдырырга күнекмәгән «Юлбашчы»).

Хәзер инде Сталин үзенең төп политик дошманы Троцкий ниләр уйлый икән, кемнәр белән һәм нәрсә хакында әңгәмә кора, дип баш ватып тормый. Өстәл астына кулын гына тыга. Зиновьев һәм Каменевның да үзе артында ниләр уйлаганлыклары мәгълүм аңа хәзер. Чөнки тегеләр һәммәсе «вертушка»ның иң камил автомат икәнлеген беләләр, ышаналар һәм аның аша сөйләшүләрне ничек тә булса тыңлау ихтималы бардыр дип уйларына да китерә алмыйлар. Власть өчен, урын өчен көрәшнең һәр сулышын, кемнең ничек уйлаганын, кем белән һәм ниләр сөйләшкәнлеген, ният иткәнлеген хәзер бер ул — Сталин гына алдан күреп, белеп тора. Менә нинди көчкә ия булды ул хәзер! Әгәр Ленин үзе терелеп чыга-нитә калса, ул аның өстеннән дә контрольлек итү мөмкинлекләренә ия булды хәзер.

Шул дәрәҗәдәге яшертен сергә Солтангалиев ничек ачкыч таба язып калды соң?.. Бу — очраклылык, миңгә бер тапкыр гына туры килергә ихтимал булган очраклылык иде. Сталин «бишенче телефон» белән «сөйләшкәндә» ишек катындагы Каннердан башка кешегә ышанмый. Ул, бары тик ул гына утырырга тиеш андый сәгатьләрдә.

Ә теге көнне ике кат имән ишек артында ялгызы гына калып «Хуҗа» «эшкә» керешкәч тә, үч иткәндәй, Каннерга Кремль ашханәсендә мөдир булып эшләгән якын танышы шалтыратты. Нократта тотылган чуртан китергәннәр. Чуртан туңдырмасы Каннерның иң яраткан ризыгы һәм ул аның өчен җанын тәслим кылырга да әзер. Бер-бер мәгъшукасы шалтыратса, «Вакытым юк, соңрак» — дип шундук төребкәнә кире куйган булыр иде. Ишегалдында алтын өләшәләр дисәләр, шулай ук авыр булса да түзәр иде әле. Әниең шифаханәгә эләккән, хәзер үк килеп җит, дисәләр

дә, кичегә төшү җаен карар иде. Ә чуртан турында ишеткәч,— анысы да Вятканыкы, Нократныкы бит әле,— Каннер дөньясын онытты, зиһене томаланды. Алдын-артын уйлап тормастан, ышанычлы хезмәттәше Товстуханы чакырды ул, бер ярты сәгать чамасы утырып торуын үтенде. Һичкемне, хәтта Ленин үзе торып килсә, аны да кертмәскә кушты. Товстуханың үзенә дә башын тыгарга ярамаганлыкны кисәтте һәм йөгерде. Ашханә складына чуртан артыннан йөгерде.

Мирсәет Солтангалиев ашыгыч йомыш белән, гөнаһ шомлыгы, нәкъ менә шул чакта килеп кергән иде. Сталинның кабул итү бүлмәсенә. Товстуха, әлбәттә, Сталинның ни белән мәшгуль булуын белми һәм уена да китерә алмый иде. Ә Гляссер ханым турында әйтеп тә торасы юк.

Мирсәет артыннан күзәтү ГПУ тарафыннан болай да югары дәрәҗәдә оештырылган була. Ә инде 1922 елдан башлап аның һәр хәрәкәте, һәр сөйләшүе, һәр язган хаты җиде кат иләк аша уздырыла башлый. Кем белә, моңарга әлеге бәхетсез очраклыкның да өстәмә сәбәп булуы бик ихтимал.

* * *

Югарыда искә алынган очраклы бер вакыйга — сүзсез очрашу шулай да эзсез калмый. 1922 елның 23 июнендә Үзәк Комитет оештыру бюросы бер мең коммунистны урындагы партия-сәясәт эшен аякка бастыру өчен ерак төбәкләргә җибәрергә карар кыла. Валериан Куйбышев тарафыннан тупланган бу исемлек Мирсәет Солтангалиевтән башлана. Үзәктә кырыкмаса-кырык җаваплы вазифасы бар дип тормыйлар, үзе белән дә киңәш-табыш итәргә кирәк санамыйлар, ул «провинция»гә җибәрелә. Татарстанга дип уйласагыз, ялгышырсыз. Төркестанга яисә Башкортстанга да түгел. Тифлиска!

— Грузияны кадрлар мәктәбе диләр иде... Нәрсә, инде эшләр кеше калмадымы? — дигән сорау белән мөрәҗәгать итә Мирсәет.

— Бар,— дип җавап кайтара Сталин.— Кадрлар бар. Әмма Үзәк Комитет шулай кирәк тапты.

— Мин грузин телен белмим ләбаса.

— Өйрәнерсең!

Партиядәге тәртипләрне яхшы белгән Солтангалиев бәхәс куертып тормый, эшләрен һәм гаиләсен Мәскәүдә калдырып, бер тәүлек дигәндә, Тифлиска юл тота.

Әмма Куйбышев кулы белән эшләнгән бу сәяси сөрген озын гомерле булмый. Күп кенә милләтләрнең Үзәккә килгәч тә баш орыр, моңзарларын тыңлар кешенең Мәскәүдән китеп баруы канәгатьсезлек тудыра. Үзәк Комитет исеменә татар, чуваш, Идел буе немецлары, калмык, башкорт халыклары исеменнән Солтангалиевне «таптырган» хатлар, вәкилләр килә башлый. Төркестан республикасы, Карачай-Черкәс һәм Мари өлкәләре катгый рәвештә Мирсәет Солтангалиевне Мәскәүгә кайтаруларын таләп итәләр.

Ул гына да түгел, Көнчыгыш хезмәт ияләренең Коммунистик университетында укучы партия эшлекләләре юксына Солтангалиевне. Азия һәм Африка, Якын һәм Ерак Көнчыгыш илләреннән килеп укучы дистәләгән кеше үзләренең яраткан лекторлары һәм бу уку йортын идарә итүче «өчлек»нең бер вәкиле булган Мирсәетнең Мәскәүдән җибәрелүенә ризасызлык белдерәләр. Ризасызлык белдерүчеләр арасында күп кенә илләрнең күренекле сәяси лидерлары һәм дәүләт җитәкчеләре булып танылачак мәшһүр адәмнәр була.

Мәсьәләне кичекмәстән хәл итү ихтыяҗы килеп туа. Троцкий һәм Каменев җаваплылыкны үз өсләренә алырга теләмиләр. Сталинга күрсәтәләр. Сталинның да авторитетка вә дәрәҗәгә сусаган чагы. Ул бөтен гаепне Үзәк Комитет секретаре Куйбышевның хаталарына сылап куя да,

Мирсәетне Мәскәүгә чакыртып, үзе исеменнән Тифлиска телеграмма суктыра. Башкача чара тапмый, мәҗбүр була...

Шул рәвешле, Тифлиска китүенә өч ай чамасы вакыт узарга өлгерми, Мирсәет Солтангалиев Үзәк Комитетның чакыруы белән яңадан Мәскәүгә кайтып төшә.

* * *

1922 ел. Декабрьнең 26 нчы көне. Мәскәү. Советларының X Бөтенроссия съездының дүртенче эш көне. РКП (б) әгъзаларының фракция утырышы ачыла. Көн тәртибендә, нибарысы бер, әмма берәгәйле мәсьәлә: СССРның формалашу принциплары.

Шул урында нәни генә искәрмә биреп китү урынлы булыр. Съезд чираттагы эш көнен башлап җибәргәнгә кадәр көн тәртибендәге мәсьәлә буенча иң элек партия әгъзалары аерым җыелып фикер алыша. Болай караганда фракция утырышы гына дип аталса да, төп мәсьәлә һәм принциплар шушында хәл ителә. РКП (б) фракциясе кабул иткән тәкъдим — партия әгъзалары өчен катгый канун.

Партиядәшләр бәхәсле мәсьәләләрне бары шушында гына уртага салып тикшерергә хокуклы. Ә инде съездга чыккач фракция фикере шик астына алына алмый, партия әгъзасымы син, әллә партиясез депутатмы, килешергә мәҗбүрсең. Килешми чараң юк! Соңгы елларгача дәвам итеп килгән «партиячел демократия!»нең нигезләре әнә кай вакытларда ук нигезләнгән була инде.

Советларның X Бөтенроссия съездының РКП (б) әгъзалары фракциясе утырышы ачык дип белдерелә. СССР төзелүнең үзәк мәсьәләләре турында сүз белән И. В. Сталин чыгыш ясый. Милли мәсьәләдә үзен зур белгеч санаган докладчы әле ай-ай ярым чамасы гына вакытлар элек катгый рәвештә унитар дәүләт төзү һәм «автономияләштерү» идеяләре белән саташа иде. Илдә мөстәкыйль республикалар була алмый, алар турыдан-туры РСФСР га буйсынырга тиешләләр, дип саный иде Сталин. Аның ул хактагы чыгышлары Ленинның да каты тәнкыйтенә дучар булды. Милли дәүләтчелек мәсьәләләренә мөнәсәбәте булган һәркем моны яхшы хәтерли иде әле.

Бүген исә, докладчыны танырлык түгел, ул нык үзгәргән. Татарстан Совнаркомы рәисе Кәшшаф Мортазин үзенең янында утырган Мирсәеткә әледән-әле сынаулы карашын ташлады: «Безнең Генераль секретарьга ни булган, җен алмаштырганмы әллә үзен?!»

Солтангалиев исә, ботын-ботка атландырып утырган да куен дәфтәрен тез башына куеп, ашыга-кабалана язу белән мәшгуль. Докладчы фикерләрен теркәп барамы ул шулай, әллә булачак чыгышы тезислары өстендә эшлиме — үзе генә белә.

— СССРны бертигез хокуклы дүрт республика игълан итәчәк,— дип кабатлады Сталин, сүзен йомгакларга җыенып.— РСФСР, Украина, Белорусия һәм Кавказ республикалары федерациясе. Үзәк Башкарма Комитеты (ВЦИК) һәм Халык Комиссарлары Советын бары шул дүрт республика вәкилләре кадрлар белән тәэмин итәчәк. СССР төзелү — дөньякүләм тарихи вакыйга, шуңа да бу көннәрдә коммунистларның бер платформада, катгый бер фикердә торуы зарур.

Доклад тәмамлангач та зал бермәлгә киеренкелектә торып калды. Күпләр өчен җитди яңалык һәм көтелмәгән фикерләр бар иде Сталинның бүгенге чыгышында. Бер тирәдәрәк тупланып утырган төрки халык вәкилләре кайсы-кай яктан Солтангалиевкә чыш-пыш сорау бирергә керештеләр. Мирсәет исә дәшмәде, ишеткәннәрен анализлый, нинди дә бер фикергә яисә карарга килә алмый газапланган чагы иде аның. Колагы ишеткәннәрне ни дип тә юрарга белмәде.

Киңәшмәне алып баручы моны игътибарсыз калдырмады:

— Нәрсә анда, татарлар бер-бер җитди тәкъдим кертергә җыенамы?

«Татарлар» дигәне, беренче чиратта, Мирсәеткә кагыла иде, әлбәттә. Аның милли дәүләтчелек мәсьәләләрендә үзенчәлекле фикер йөртүе, әзерлекле булуы залдагы коммунистлар өчен яхшы мәгълүм. Әмма Мирсәет кузгалырга ашыкмады. Аңарга ярдәм йөзеннәнме, Кәшшаф Мортазин торып басты:

— Иптәш Сталин,— дип башлады сүзен Татсовнарком рәисе.— Бу юнәлештә Бөтенсоюз Татар иҗтимагый үзәге кайбер чаралар күрә, әмма болар гына һич тә җитәрлек түгел.

Гомумән, безгә бүген татар халкы тарихын җентекләп өйрәнер көн килде. Ә аны газеталар тарихын, алардагы язмаларны өйрәнми торып тормышка ашырып булмаячак.

Ераграк тарихка күз салыйк. Кайсы төбәкләрдә генә чыкмаган татар газеталары! Хәтта чит илләрдә дә. Әйтик, Беренче бөтендөнья сугышында немецларга әсирлеккә эләккән татар солдатлары өчен газеталар басылган. Бөек сугыш чорында да әсирлектәге татар солдатлары өчен берничә газета-журнал чыгуын беләбез. Төркиядә җитмешенче еллар уртасына кадәр «Казан» дигән журнал чыгып килде. Финляндия һәм Кытайда да андый басмалар бар иде. Ә соң аларны өйрәнгәнебез бармы? Өйрәнсәләр дә, мөгаен, КГБ хезмәткәрләре генә өйрәнгәндер. Ә аларның максаты билгеле — дошманнарын юк итү, ике фикергә урын калдырмау. Бер генә мисал. Оренбург каласында 1906 елдан бирле «Вакыт» газетасы чыгып килә. «Әйтергә кирәк, тарихи, әдәби, информатив материалларның байлыгы буенча бу газета татар газеталары арасында иң югары урында тора иде. Нәширләрнең (Рәмиевләрнең) акчага бай булулары газетаны полиграфик яктан да затлы итеп чыгарырга мөмкинлек бирә. Газета 12 ел буена халкыбызга игелекле хезмәт күрсәтеп, барлыгы 2309 сан чыгып, 1918 елның 26 гыйнварында яшәүдән туктый»,— дип язды бу хәлләр турында күренекле әдибебез Мөхәммәт Мәһдиев 1991 елның 26—31 октябрендә чыккан «Яңа Вакыт» (Оренбург) газетасында. Газетаның туктатылуы турында аның мөхәррире Ярулла Вәли 1918 елның 28 гыйнвар санында түбәндәге белдерүне ясый: «1918 ел, 26 гыйнвар иртәсе сәгать унда Оренбург мөселман Военно-революционный комитет (хәрби комитет) тарафыннан унике ел милләт ничек болай булды инде, башка милләт вәкилләре дә тәкъдим итә алмый дигән сүзме?... Автономияләр — икенче сортлылык, хокуксызлык белән канәгать булырга тиеш булып чыгамы? Бу, минемчә, ленинчыл милли политика принципларына ятышмый кебек... Сүземне тәмамлар алдыннан тәкъдим кертәм: бу мәсьәләгә Ильичның мөнәсәбәтен белергә кирәк. Ильичны чакырырга дип тәкъдим кертәм.

— Әйе, Ильичны чакырырга... Ленинны...

— Ленинның үзеннән ишетсәк кенә килешәбез,— дигән авазлар ишетелә залның арткы почмакларыннан.

Көтелмәгән урында чыккан ыгы-зыгы Сталинны янә торып басарга мәҗбүр итте.

— Төтен чыга, ә паровоз тик тора,— дип башлады ул сүзен, шаярган атлы булып.— Безнең вакыт чикле, бу урынсыз ыгы-зыгы нигә кирәк булды?! Аңламыйм...

Арткы рәтләрдәге канәгатьсезлек тавышлары янә кабатланды.

— Ашыга торган чакмы! — дип кычкырды кемдер.

— Төрки халыклардан бишенче республика төзергә кирәк... Башкалар белән тигез хокуклы итеп,— дип, йодрыгын баш өстендә чөеп торып ук басты икенче берәве.

— Безгә нәрсә, урыслашырга каламы? — дигән аваз ишетелде каршы як почмактан.

Сталин аягурә торып баскан да күзәтә. Кай тарафтан катырак кычкырсалар — ялт кына башын шунда таба бора. Оясыннан әле генә тамак ялгап чыккан тук йомранмыни...

Ул да түгел, иң алгы рәттә хром итекләрен ялтыратып Сталинның күзенә керердәй булып утырган Сәетгалиев калка урыныннан. Ул шактый ук тазарган. Кырым һавасы килешкән үзенә. Җәенке яңаклары алсуланып тора. Озын-йомшак чәчен ул колагына төшереп майлап тарап куйган.

Сталин белән күзләре очрашкач та, Генераль секретарьның аңардан акыллы сүз көтүен күреп, залга таба борыла төште ул.

— Бу нәрсә, коммунист иптәшләр,— диде Сәхипгәрәй Сәетгалиев тамагын кыра төшеп.— Партиягә, аның мәшһүр лидеры, тәҗрибәле остазыбыз иптәш Сталинга булган хөрмәтне шулай белдерәбезме?!. Без һәммәбез патша тарафыннан изелгән халык вәкилләре идек. Хан заманында ук яуланып, җиңелгән, югалуга дучар ителгән халык вәкилләре. Революция һәм шул революцияне җиңүгә китергән партия безне азат итте. Ул гына да түгел, безгә бабаларыбызның төшенә дә кермәгән, автономия бирде. Кырым республикасы, Башкортстан, Төркестан һәм Татарстан — бу республикалар кайдан килде соң безгә, уйланыгыз... Иптәш Сталин һәм иптәш Ленинга рәхмәтле булырга чакырам мин сезне.— Күз чите белән, борыла төшеп, президиум өстәленә карап алды ул шунда. Тыңлыйлар... Генераль секретарь да тыңлый. Тагы да дәртләнеп китеп, үз кулын баш өстендә болгый-болгый тәмамлады чыгышын:— РСФСР эчендә булу безнең өчен иң зур дәрәҗә ул, иптәш Мохтаров! Дөнья революциясе җиңгәч, тагы ике-өч елдан, милләтләр бетәчәк: интернационализм гына чәчәк атачак җир шарында. Вәт, шул!

Үз-үзеннән канәгатьлеге күзләренә чыккан Сәетгалиев сүзен тәмамлагач та лып итеп кире урынына утырды. Баш очында йодрыгы гына бермәлгә эленеп калды булса кирәк.

Кырым Совнаркомы рәисен аягүрә торып тыңлаган Сталин, йомгакларга ашыкты:

— Нәрсә, коммунист иптәшләр, шуның белән канәгатьләнеп торабызмы?

— Юк,— дигән таныш тавыш ишетелде арткы тарафтан.— Иптәш Ленинны көтәбез.

— Ильич авырый. Кызганычка каршы, ул фракция киңәшенә килә алмый,— дип, тынычландырырга ашыкты Сталин.

— Телефоннан сөйләшеп карарга кирәк, киңәшергә...

Сталин үзен тыныч тотты, бер сорауны да җавапсыз калдырырга ярамый торган чак.

— Әле ярты сәгать кенә элек Ильичтан хәбәр алдык, коммунист иптәшләр, ул безнең ниятне хуплый...

— Солтангалиев иптәш сөйләмәде бит әле,— дип сүз кыстырды шунда кемдер.

Сталин, гүя, аңламады. Башкортстан делегациясе утырган тарафка текәлде ул, тавыш шул яктан ишетелгән иде.

— Әйе, Башкортстан вәкилләре сүз әйтергә җыенамы? Рәхим итегез.

Берәү дә торырга, чыгыш ясарга атлыгып тормый иде.

— Нәрсә, сүз әйтергә теләүче юкмы? — дип кабатлады Сталин.

— Әдеһәмов иптәшнең дә юкмыни әйтер сүзе?!

Зал өстеннән җәяүле көлемсерәү йөгереп узды. Әдеһәмовның урынлы-урынсыз чәчрәп чыга торган гадәте бар, Сталин шуна ишарә ясады.

Башкортстанның Мәгариф эшләре буенча халык комиссары Әдеһәмов сүз әйтергә җыенмаган иде җыенуын, инде бик кыстагач, торып басмыйча чарасы юк.

— Мирсәет Солтангалиевне тыңлап карыйк, иптәш Сталин. Ул сөйләгәннәр уйлаганга тәңгәл килә торган иде гадәттә,— диде Әдеһәмов, һәм кире урынына утырды. Телгә салыныр чак түгел.

— Әйе, Солтангалиевкә сүз бирегез,— дип куәтләде төркестанлылар да.

Тагы кемнәрдер хуплады шул ук тәкъдимне.

Сталин авыз эченнән мыгырдана-мыгырдана кире утырырга мәҗбүр булды:

— Соң, тыңлап карыйк алайса... Солтангалиев мондамы?

Әйтерсең, Мирсәетнең монда булу-булмавын да белми иде Сталин. Югыйсә, әле бер сәгать чамасы гына элек фойеда очрашып кул кысышкан, бер-ике сүз белән хәл-әхвәл сорашкан иделәр үзләре.

Мирсәет, үз дәрәҗәсен белеп, тыйнак кына торып басты. Аңарга юл бирделәр, ул алга узды. Һәм трибунага менеп басты. Сүзен башларга ашыкмады. Гадәтенчә, үз дәрәҗәсен белеп, залны күздән кичерде.

— Нәрсә, әйтер сүзең булмаса, көчләмибез, Солтангалиев иптәш,— дип, гел урынсызга кыбырсынып алды Сталин. Читтән күзәтеп утыручыларга аның бу репликасы хәтта көлке тоелды кебек.

Трибунага менгән Мирсәетне чыгырдан чыгару җиңел эш түгел. Тын гына, сөйләргә кереште ул. Иң элек РСФСРга кергән милли республикаларның тарихына кагылып узды. Уртак язмышка ия төрки халыкларның һәммәсенең, бары үзләренә генә хас булган үткәне, кайберәүләренең бай дәүләтчелек тарихы барлыгына игътибарны юнәлтте. Сан ягыннан күпме булуларына карамастан, һәр милләтнең тулы канлы мәдәни тормышта яшәргә хокуклы булуына аерым басым ясады. Шул урында, сүзен бүлдереп, алкышка күмделәр аның чыгышын. Милли хиснең әле сәламәт чагы, күңелләрдә, тел очында буылып торган чагы...

Сталин инде байтактан кулларын кая куярга белми, утырган җирендә кыбырсынырга керешкән иде. Шуны ачык тоеп, күреп утырган Валериан Куйбышев (аның әле соңгы араларда гына Үзәк Комитет секретаре итеп сайланган чагы), Генераль секретарь алдында яхшатланып, ораторны бүлдерергә форсат тапты.

— Мәсьәләгә якынрак килик, иптәшләр, доклад тыңлар ара түгел,— дип, алкышлар тукталганны да көтеп тормастан, сүз кыстырды ул.

Куйбышевның сүзгә кысылуы Мирсәетне кайнарлана төшәргә мәҗбүр итте.

— Иптәш Сталинның милли мәсьәләләр буенча һәр чыгышын зур кызыксыну белән тыңлыйм мин,— диде ул кинәт, фикерендә кискен борылыш ясап.— Әмма аңлый гына алмыйм! Бүген исә, гүя үзен түгел, аны тәнкыйтьләргә чыккан башка бер иптәшне тыңлагандай булдым. Әле кайчан гына, сез Иосиф Виссарионович, илнең киләчәген унитар дәүләтчелектә күрә идегез. Барлык милли республикалар да автономияләштереп Россия составына кертелергә, буйсындырылырга тиешлә иде сезнеңчә.— Бу сүзләрне президиум өстәле артында утырган Сталинның күзләренә туры карап, йөзенә бәреп әйтте ул.— Бүген исә, үзегезне гүя җен алмаштырган, әле кичә генә «Россияне таркату, Россиянең бөтенлегенә кул сузу»— дип үзегез үк тәнкыйтьләгән дәүләтчелек принцибын алга сөрәсез. Сезнең тарафтан «тар карашлы милләтчеләр» дигән бәя алган Рыскулов иптәштән дә, Мдивани иптәштән дә һәм без фәкыйрегез— Солтангалиевтән гафу үтенергә кирәк санамадыгыз. Бу— бер! Хуш, анысын үзтәнкыйть рәвешендә дә кабул итәргә мөмкин.

Ике кулы гүя ике канат иде аның шул мизгелдә, колачын киң җәеп трибунаның як-ягына таянган да, менә-менә алга ыргылырга, очарга җыена иде диярсең. Профильдән күзәтеп утырган Генераль секретарьга ул, шул мизгелдә, үз өстенә очып кунарга әзер тау бөркетен хәтерләтте булса кирәк.

Куйбышев һәркемнән алданрак тойды Сталинның халәтен һәм ярдәмгә ашыкты:

— Сүзегез тәмамммы, иптәш Солтангалиев?

Мирсәетнең исә канатланып торган мәле, үзен туктатырга теләп кыбырсынучыларны ишетмәде дә. Залның игътибары аңарда. Хәтта беренче рәттә утырган Сәетгалиев тә авызын ачып тыңлый.

Тавышы тагы да ышанычлырак яңгырый барды ораторның.

— Гафу итәсез, иптәш Сталин, мин бүген дә сез сөйләгәннән соң кул чапмадым. Автономияләштерү программасыннан баш тарткан атлы күренсәгез дә, кушыла алмадым бүтәннәргә. Бер сорау бимазалый:

— Ни өчен дип әле СССР төзелү турындагы тарихи документка дүрт республика гына кул куярга тиешле? Ни өчен дип әле илебезнең туган сәгатендә үк без республикаларны хокуклылар һәм хокуксызларга аерырга тиеш?!.. Мин моны яңа төзелүче дәүләтнең нигезенә мина куеп калдыру дип саныйм. Ун елданмы, илле елданмы, иртәме-соңмы, ул мина барыбер шартлаячак. Тигезсезлеккә нигезләнеп яңа бәхетле тормыш төзү мөмкин түгел! Аңлый алмыйм, Төркестан Совет респубилкасы Грузиядән кай ягы белән ким? Аерма бар, әлбәттә, һәркемгә мәгълүм, Төркестан үзенең халкы саны һәм мәйданы белән дә берничә мәртәбәгә артыграк. Халыкара политика һәм революцион стратегия җәһәтеннән дә Төркестан әһәмиятлерәк, димәк, мөстәкыйльлеккә дә лаеграк булып чыга. Казах, үзбәк һәм кыргызларның үзбилгенәнүгә хокуклары юкмыни соң?!. Ә татар, башкорт һәм чувашлардан бу хакта сорадыгызмы?!. Ризамы алар?!. Иртәме-соңмы, без бу хатаны аңларга мәҗбүр булачакбыз, вакыйгалар бу хатага безне борыныбыз белән төртер. Әмма вакыт һәм тарихи-революцион инициатива ул арада безнең кулдан ычкынып өлгерүе ихтимал.

Аңламыйм. Һәм тагы бер кат аңламыйм! Милләтләрне, республикаларны тигез булмаган хокукка ирештереп — без аларны тарих алдында үзара каршы куябыз, чәкештерәбез. Бу ни максат белән эшләнелә?!. Ни өчен Бөтенсоюз Үзәк Башкарма комитетында һәм Халык Комиссарлары Советында барлык республикалар да катнаша алмаска тиеш! Бу ни максат белән эшләнелә?!. Грузин яисе белорус коммунистлары янәшәсендә Төркестан вәкиле, татар яисе башкорт, якут яисә калмык хокуксыз итеп хис итәргә тиешлеме үзен?!. Күкрәк кесәмдә партия кенәгәсе йөрткәндә мин бу тигезсезлек белән килешәчәк түгелмен... Сез СССР төзү идеясен бозу юлына басарга җыенгансыз, иптәш Сталин. Сез, тәкъдим иткәннәр нибарысы, Ильич алдында яхшатланып, күз буяу гына!

Катгый таләп һәм тәкъдимнәремне тыңлавыгызны үтенәм. Иң элек, милли республика һәм милли өлкәләр һәммәсе тигез хокукка ия булырга тиешле! Икенчедән, автономияләрнең хокукларын чикләү дөрес түгел. Алар СССРны төзү турындагы документка кул куеп, тигез хокуклы субъект буларак танылырга тиешле. Өченчедән, фракция исеменнән хәзер үк Ильичка чакыру җибәрик һәм СССР төзелү турындагы мәсьәләгә аның фикерен үз авызыннан ишетүне таләп итик.

Йомгаклап, тагы шуны әйтәсем килә,— Мирсәет Солтангалиев шунда бермәл уйга калып торды. Залны күздән кичерде һәм президиум өстәле артында утыручыларга текәлде. Әйтәсе сүзе гаять житди иде аның. Тавышыннан залда утыручыларның йөрәкләре тетрәнеп куйды.— Житәр, иптәш Сталин, республикаларның мөстәкыйльлеге белән уйнамыйк!

Соңгы сүзләре гүя күңел төпкеленнән, бәгыреннән саркылып чыкты аның. Залда утыручылар өнсез калды. Кул чабарга да кыючы булмады, бары президиум өстәле артында утырган Лев Троцкий гына демонстратив төстә, кәефе булып, өч-дүрт мәртәбә кулын-кулга чәбәкләп куйды:

— Ай-да, Солтангалиев, бирде бит бирәүгә кирәген...

Сталин үз-үзен кая куярга белми иде, Куйбышев та ярдәмгә килмәде бит соңгы чиктә. Телен йоткан диярсең... Ул арада трибуна артыннан чыгып залга узды Мирсәет, урынына барып утырды. Чыгышын бәяләп сүз әйтүче яисә тәбрикләп кул сузучы булмады. Хәтта янәшәсендә утырган Мохтаров та чарасыз калган кебек күренде, читкәрәк тайпылгандай итте.

Кул бирүләр, тәбрикләүләр соңрак булачак әле. Кеше-кара күрмәгән бер-бер аулак җирдә очраган һәр иптәш аның кулын кысачак, аның хаклыгы һәм кыюлыгына соклануын белдерәчәк һәм: «Бирдең бит кирәкләрен!» — дип тә өстәячәк.

Ә хәзергә дәшүче күренмәде. Җитәкчеләр ни әйтер бит әле, дип көтте коммунистлар. Җитәкчеләрнең дә югалып калган чагы.

Ниһаять, Валериан Куйбышев чакыру ташлады:

— Коммунист иптәшләр, Солтангалиевнең чыгышы уңаеннан сүз әйтергә теләүчеләр юкмы?

Зал тагы да тына төште. Куйбышев көтте. Сталин да түземсезлек белән көтте... Һәм, ниһаять, ихтыяҗны аңлап, Сәхипгәрәй Сәетгалиев күтәрелде урыныннан.

— Мин әйтергә телим бер-ике авыз сүз.

— Юк, кирәкми... Икенче кат сөйлисең бит инде,— дип аваз салдылар арткы тарафлардан.

Куйбышев, гүя ишетмәде, Сәетгалиевкә сүз бирде.

— Мин — интернационалист буларак протест белдерәм Солтангалиев иптәшкә,— дип башлады сүзен Сәхипгәрәй.— Кырым һәм Татар республикалары белән Тула губернасы арасында һичнинди аерма күрмим мин. Солтангалиевнең иптәш Сталинга каршы чыгуы нигезсез. Мин кайсыбер милли автономияләргә, интернационализм күзлегеннән эш йөртергә, ягъни республика статусыннан баш тартырга киңәш итәр идем. Бу бит өстәмә аппарат һәм өстәмә чыгымнардан гайре һични бирми.

Зал дәшмәү һәм киеренке тынлык белән җавап бирде Сәетгалиев чыгышына. Комга төшкән тамчылардай сеңде, эзсез узды аның бу сүзләре.

Шулай да дәшми кала алмады Сталин. Стакан тутырып салкын су эчте. Бер-ике мәртәбә йөткеренде. Һәм карашын залга текәде.

— Солтангалиевнең чыгышы уңаеннан ни дияргә? — уйланып торды ул бермәл. Һәм үз-үзенә ышанып сөйләргә кереште.— Бу — партиягә ялагу, дип әйтер идем мин. Инде онытылып килгән «автономияләштерү» проектын кабердән кузгатырга азаплана Солтангалиев.

— Иптәш Сталин,— дип мөрәҗәгать итте шунда урыныннан сикереп торган Исмәгыйль Фирдәвес.— Сез юмор хисен югалткансыз. Кабердәге ул проектның авторы дип без сезне белә идек.

Троцкий залны яңгыратып көлеп җибәрде һәм шунда янә кулын чәбәкләп алды. Залда чыш-пыш дулкыны уйнады.

Фикер йомгагының җеп очын югалтып торды сыман Сталин. Зәгыйфь кулын френч кесәсендә тирәнгәрәк яшерде. Әйтерсең, кесә төбендә посып яткан көнбагыш бөртеген кармалый иде ул.

— Инде, Солтангалиевнең автономияле республикаларның статусын күтәрү хакындагы тезисына килсәк, ул — ана карынында үле туган баланы хәтерләтә торган реакцион тәкъдим.

— Аңлатыбрак сөйләгез! — дип кычкырды кемдер.

— Мин ачык итеп әйттем,— диюдән башка сүз тапмады Сталин. Һәм тизрәк бу киңәшмәне йомгаклап куярга ашыкты. Мирсәетнең чыгышы тәмам коралсызландырган иде булса кирәк аны.

Алай иттеләр, болай иттеләр дә, бөтен фикер алышуны шул рәвешле ярты юлда калдырып, киңәшмәне йомгаклап та куйдылар. «СССР төзелү турындагы проектны РСФСР коммунистлары фракциясе хуплый» диген карар, инде күптән язу машинкасында басылып мөһерләнгән һәм кирәкле куллар белән дә теркәлеп куелган иде. Тавышка куеп тормадылар...

Шул ук көнне төштән соң Советларның X Бөтенроссия съезды да әлеге тәкъдимне хуплап карар кабул итә. Советлар съездында да кул күтәреп тавыш бирү кирәк табылмый. Барысы да Генераль секретарьның «мәкерле» уенда туган сценарий буенча эшләнелә.

Халыкларны берләштереп торырга һәм тигез хокуклылык гарантиясе булырга тиешле Союзга әнә шул рәвешле нигез салына...

Тагы берничә көннән соң, тәгәлрәге, 1922 елның 30 декабрендә, дөньяга СССР төзелүе турында игълан ителә. Йөздән артык милләт вәкиле яшәгән илнең төзелүе турындагы килешү кәгазенә дүрт республика — Россия, Украина, Белоруссия һәм Кавказ федерациясе вәкилләре кул куя.

Сталинның хәлиткеч җиңүе була бу. Әмма бу җиңү озаккамы?!. Ул кадәресен киләчәк күрсәтер, тарих үзе хәл итәр...

* * *

Мәскәү 1923 елны каршыларга җыена. Газеталарда бәйрәм рухы — СССР төзелү турындагы купшы игъланнар: Сталинның бәхетле көлемсерәп төшкән фоторәсемнәре: Көнбатыш Европа илләре коммунистларыннан килгән котлау телеграммалары... Илдә яңа тормыш корырга хыялланып йөргән, үз-үзен аямыйча, менә инде ничәнчә ел тоташтан революция өчен көрәшүдән башканы белмәгән Мирсәет Солтангалиев тынычлыгын югалтты. Күзләренә йокы керми. Вакыт-вакыт хәтта үз-үзен кая куярга белми.

Идел буеннан килгән хәбәрләр дә берсеннән-берсе аянычлырак. Идел буйларында, шул исәптән Татарстанда, ачлык афәтеннән арына алмый изалана халык. Яздан чәчәр орлык табылмады. Ач үлем куркусыннан башын кая куярга белмәгән мужик халкы төенчеккә соңгы чүпрәкләрен төйнәп анда бәрелергә итә, монда бәрелергә итә. Әмма авыл капкасыннан чыгып ерак китә алмый, юлда кырылып бетә.

Татарстан һәм Идел буеның башка губерналарына атап Америкадан җибәрелгән икмәк юлда тоткарлана. Мылтыклы солдаттан башка берәүгә дә буйсыну юк, тимер юлларны гүя бизгәк авыруы биләп алган. Паровозга утын җитми. Утыны булса, йөртүчесе юк. Ачыктан-ачык тоткарлык ясау, саботажлык итү очраклары да адым саен. Татарстандагы һәр вакыйганы үз йөрәге аша уздырырга күнеккән Мирсәет өчен бу хакта ишетү, болар белән килешеп яшәү аеруча кыен. Күпме җаннар башын куйды, азмы кан түгелде шул республика өчен. Әле автономия игълан ителүенә бер ел чамасы да узмады, күпме ыгы-зыгы, күпме борчылу кичерергә туры килде шул санаулы гына айлар эчендә. «Республика, республика, дип сөйләнгән идең, халкың ачтан үлә анда»,— дип күзгә төртеп сөйләүчеләрне дә очратырга туры килде инде. Өстәвенә, Татарстанның бүгенге җитәкчеләре — һәммәсе аның тәкъдиме белән урынга куелган иптәшләр. Нииндидер җанлану бар да кебек, әмма шулай да эшләр яхшыга табан дип әйтергә тел әйләнми. Ә канга тоз сибүчеләргә кытлык юк.

Әле бүген өйгә кайтырга җыенганда Валериан Куйбышев чакырып алды аны үзенә. Гражданнар сугышы көннәреннән үк яхшы танышлар булганга, бәйрәм киче итеп, үзен Яңа ел белән котлау нияте белән чакыргандыр, дип уйлаган иде. Ни дисәң дә, декабрьнең соңгы көне — утыз бере. Кич җитеп килгән чак.

Үзәк Комитет секретаре булып сайлангач та күзгә күренеп эреләнеп киткән Куйбышев исә, урын тәкъдим итмәс борын, аның авырткан җиренә кагылды.

— Тәртип урнаштырасызмы ул Татарстаныгызда, юкмы?!.— Аның беренче әйткән сүзе шул булды.

Сәер тоелды, әлбәттә. Фронтларда бергә сугышып, күпме гомер бергә аралашып яшәгән партиядәшеннән Яңа ел кичендә андый сүзләр ишетергә җыенмаган иде. Куйбышев түгел, Сталин һәм Троцкий да

кулын кысты, тәбрикләде ич аны бүген, якты йөз һәм жылы сүзләрен кызганмадылар. Ихластанмы-түгелме, анысы — башка, бәйрәм көннәрендә әхлак дигән төшенчә дә сакланырга тиешле бит әле.

Коелып төшмәде Мирсәет, сездән курка торган кулмәк куптән тузган, дигән сыман, ипле генә тәкъдим ителмәгән урындыкка барып утырды.

— Гафу итәсез, иптәш Куйбышев, ни әйтергә теләвегезне аңламадым,— диде ул, үзенең тыныч һәм сабыр икәнлеген ассызыклый төшеп.— Үз чиратымда исә, мин сезне Яңа ел белән тәбрик итәм.

Авырлык белән генә чыкты җавап сүзе:

— Рәхмәт.— Һәм шундук эшлекле рәвештә җәт-җәт ишекле-түрле йөренергә кереште Куйбышев һәм озак көттермәде, соравын яңадан кабатлады:— Мирсәет, әйт әле миңа, тәртип буламы ул Татарстанда, юкмы?

— Белүемчә, тәртип бар, ашарга гына юк Татарстанда.

— Сөйләмә... Сөйләмә.— дип, ашыгыч ярдәм эзләп эш өстәле читенә барды Куйбышев һәм кәгазь өемен күтәрде.— Менә, бер атна эчендә шул тикле хат һәм телеграммалар килгән. Һәммәсендә зарлану, канәгатьсезлек...

— Рәхмәт сүзләре көткән идегезме?!.

— Көлмә, Мирсәет, шаярырга җыенмыйм...

— Көлмим. Һәм шаярмыйм да. Бәйрәм өстенә бәйрәм дисәгез дә шатланырга сәбәп күрмим. Ачлыктан, хәерчелектән зарланалардыр?!.

— Шулай булса икән! Түгел, республикадан, чәчәк атып килгән милләтчелектән зарлана якташларың.

Бу кадәресен һич көтмәгән иде Мирсәет. Гаҗәпләнүеннән сикереп торды хәтта.

— Белүемчә, Татарстанда милләт яисә республика турында кайгыртыр ара булганы юк әлегәчә. Менә икенче ел тамак кайгысы белән изалана халык.

— Дөрес, дөрес,— дип эләктереп, күтәреп алды аны Куйбышев.

— Ачлыкның да башы шулардан, дип язучылар бар. «Татарларга республика биргән көннән бирле тамакның туйганы юк», дип язган анда берәү. Губерна чагында мондый хәлнең булганы юк иде, диләр...

— Кара син аны, минем якташлар Куйбышев иптәшкә нинди кызыклы хатлар язып ята икән,— дип өстәлгә таба якынлашты Мирсәет.— Миңа да күз йөртеп чыгарга рөхсәттер бит...

— Рәхим ит. Рөхсәт кенәме соң, хәтта күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү дә сезгә йөкләтелә, иптәш Солтангалиев. Ботканы шулай куертучыларның берсе — үзегез ич.

Өстәл читендәге кәгазьләрдән беришен аралап Мирсәеткә сузды Куйбышев. Ә үзе өстәл артындагы креслосына утырып телефон төребкәсенә үрелде.

Хатларны күздән кичереп чыккач та бераз дәшми утырды Мирсәет. Сәер тәэсир калдырган иде алар. Аңарга да килә хатлар, аңарга да язалар. Зарланучылар бар, ярдәмгә мохтаҗ булганга язучылар. Әмма Куйбышев өстәлендәге хатлар үзгә иде: адреслары белән дә... Нигә соң әле, гомер булмаганны менә хәзер генә ул проблемалар күтәрелгән һәм барысы да аңарга — Куйбышевка адресланган. Ул хатларны махсус оештырылган дип әйтмәсә дә, шундыйрак шиккә урын бар һәм ничек кенә бар иде әле.

Куйбышев ниндидер ханым белән сөйләште булса кирәк. Онытылып, рәхәтләнеп, елмаеп-көлеп сөйләште һәм купшы котлау сүзләрен дисбе итеп тезде тегеңә. Кеше сүзе, тыңламыйм дисәң дә, чалына ич ул колакка. Телефонның аргы очындагы ханым белән бәйрәмнән соң ук очрашырга сүз куешып, хушлаштылар.

— Йә, Мирсәет, ничек, таныштыңмы? — дип кызыксынырга ашыкты Куйбышев. Үзендә булган үзгәреш — кәеф күтәренкелеген яшереп азапланмады.

Нинди нәтиҗә ясарга белми уйга чумып утырган чагы иде Мирсәетнең. Турысын ярып салырга кирәк санамады әлегә. Дәшми калу да мөмкин түгел.

— Гыйбрәтле хатлар алгансыз икән...— дию белән чикләнде ул. Бераздан янә шул ук сүзләрен кабатлады.— Гыйбрәтле хатлар...

Онытa язганмын, дигән сыман, кабаланып кына үзенең ярдәмчесенә шалтыратып, йомыш кушарга өлгерде Куйбышев. «Берәр шампан шәрабы һәм тәмлерәк конфеттан ике төргәк хәстәрләргә». Әллә, ходаем, берсе миңамы, мине кайгыртуымы, дип уйлап өлгермәде Мирсәет, Үзәк Комитет секретаре төргәкләрнең берсе бәйрәмнән соң ук кирәк булачагын искәртте. Шулай итеп, бер мизгелгә кабынып алган өмет шундук сүнде. Мирсәет белән Фатыйма 1923 елны шампансыз гына каршы алырлар.

Син хатлар белән танышкан арада, дөнья кадәр эш майтардым әле, дигән сыман, кулларын уа-уа Мирсәетнең каршысына ук килеп утырды Куйбышев.

— Хатлар һәм фактлар хәтәр нәрсә,— диде ул, Мирсәетнең шулай ни дияргә белмичәрәк калуыннан үзе теләгән нәтиҗәне ясап.— Генераль секретарь белән бәхәсләшеп булса да, хатлар һәм фактлар белән бәхәсләшү читен.

«Менә ничек?! — дип уйлап куйды Мирсәет.— Сүз сөреше әнә кая таба бара!..» Димәк, җавапсыз кала торган чак түгел.

— Фактлар — факт, хатлар — хат, дип башлады ул сүзен.— Әмма һәр факт хатка сыймаган кебек, фактсыз, хакыйкатьтән ерак торган хатлар да языла икән. Мине андый хатларның булуы түгел, шуларның җепкә тезелгән дисбе төймәләре сыман, Үзәк Комитетта яңа гына эшли башлаган секретарьга җибәрелүләре хәйран калдырды...

Мирсәетнең тел төбендә ни ятканлыкны тиз тоемлап алды Валериан Куйбышев. Күз кабаклары ачыла төште хәтта...

— Бу нәрсә?!. Нәрсә дип әйтергә җыенасыз, иптәш Солтангалиев. Сез һәр факттан гаеп-кыек эзлисез!..

— Эзләмим, юк, эзләмим, иптәш Куйбышев. Әмма минем вакытвакыт кына булса да кайбер факт һәм күренешләргә үз мөнәсәбәтемне белдерә килергә хокукым бар дип беләм.

— Фактларга,— дип, басым ясарга кирәк санады Үзәк Комитет секретаре.— Әйе, фактларга мөнәсәбәт белдерү кирәкле һәм зарур эш. Ялгышмасам, сүз Татарстан һәм анда чәчәк атып килгән милләтчелек хакында барырга тиешле иде.

Уйламаган җирдән Мирсәет үзе сорап куймасынмы шунда:

— Хат авторларының берсе дә татар милләтеннән түгел. Бу гаҗәпсендермиме сезне?

Югалып калмады Куйбышев.

— Сезнең халык грамотасыз. Ул укый-яза белми...

Кычкырып көлеп җибәрде Мирсәет, күрәсең, Куйбышевтан моны көтмәгән иде.

— Көлдереп үтерәсез ич. Каян алдыгыз аны?! Бездә укый-яза белмәгән кеше юк.

Куйбышев дәшмәде, үзалдына мыгырданып кына куйды.

— Иптәш Куйбышев, әйдәгез таләпчәнлекне һәр ике як өчен дә тигез югарылыкта куеп сөйләшик әле. Юкса, гаеп ташлыйсыз да, көлдерәсез...

— Килешәм. Сез дигәнчә булсын, Мирсәет.

Куйбышев гел шулай, аңарга әле исеме белән, үз итеп, әле фамилиясе белән, ераклаштыра төшеп, дәште.

Мирсәет бәхәс өчен тәмам өлгереп җиткән иде, ниһаять. Бармакларын бөгә-бөгә исбатларга керешә ул.

— Беренчедән, Татарстан диеп ялгышасыз. Хатлар бер Казаннан гына түгел, Уфадан да, Бохарадан һәм Әстерхан шәһәрләреннән дә язылган. Ә сез Татарстан да Татарстан дисез... Бу — житдирәк уйлаганда, орфографик хата гына түгел, иптәш Куйбышев. Сезнең болай гомумиләштерүдән житди сәяси нәтиҗәләр дә ясарга мөмкин булыр иде... Хуш, монысын гафу да иттек, ди...

Мирсәетнең, шул рәвешле, житди һөҗүмгә күчүен көтмәгән иде Үзәк Комитет секретаре. Әйтер сүзе, фикерләре формалашып житкәнче үк, аңгәмәдәшен, кабаланып диярлек, бүлдерергә ашыкты.

— Тукта... Тукта, бераз ачыклап китик,— дип кулына кагылды ул Солтангалиевнең һәм нәкъ аның каршысында туктап, урындыкка утырды.— Кара-каршы утырып, күзгә-күз карашып сөйләшик, аңлашыйк булмаса. Күрәм, сез миңа политик ярлык тагарга да күп сорамыйсыз...

— Сәяси төгәлсезлеккә хакыбыз юк, дип әйтергә теләвем. Бигрәк тә милләтләр һәм конкрет халык, конкрет республика хакында фикер йөрткәндә...

— Төшендеребрәк сөйләче?..

— Төшендереп сөйлим. Сез — Үзәк Комитет секретаре — инде берничә мәртәбә. «Татарстаныгыз» дигән гыйбарәдән файдаландыгыз. Ә бит сезгә яхшы мәгълүм, Бохараның да, Әстерханның да Татарстанга мөнәсәбәте юк. Уфа каласының да нинди статуска ия булуын яхшы беләсез...— Куйбышевның ирен читләреннән елмаю дулкыны йөгереп узды.

— Без бит икәүдән-икәү, күзгә-күз карап сөйләшәбез, Мирсәет. Монда чит колаклар яисә беркетмә язып утыручы юк. Нигә безгә кәнфитләнеп маташырга. Син мине яхшы беләсең, мин дә сине яхшы беләм һәм хөрмәт тә итәм. Ачыктан-ачык сөйләшик...

— Килешәм. Ачыктан-ачык сөйләшик.

— Сез — татарлар, дип сөйләшүем махсус басым ясау өчен, әлбәттә. Мине син дөрес аңладың. Ләкин мин дә күпне күрәм, күпне ишетеп беләм. Татар Казанда гына түгел. Уфадагы вакыйгалар үзәгендә дә татар, Әстерханда да. Бохарада һәм тулаем «туземецлар» яшәгән һәр төбәктә татар эш йөртергә, иҗтимагый фикер тудырырга сәләтле халык.

— Сүзләрегезне ничек... күпсенү дип аңларгамы? Әллә татар кызылармеецлары һәм большевиклары кылган батырлыкларга бирелгән югары бәя буларак кабул итәргәме?..

— Ничек телисез, шулай кабул итә аласыз,— әйтергә теләгәнем — башка.

— Тыңлыйм,— дип, утырган урындыгында тынгысызланып атынып куйды Мирсәет һәм, ияген учлап, әңгәмәдәшенә текәлде. Димәк, моңа кадәрге сөйләшүләре хәзер әйтеләчәк сүзләр өчен әзерлектән генә гыйбарәт булган.

Куйбышев та боргаланып-сыргаланып утырудан туйган иде, күрәсең, кинәт үзалдына дулкынланып турыдан ярырга керешә.

— Иптәш Солтангалиев,— дип, рәсмиләштерергә кирәк санады иң элек.— Әйтегез әле, ни житми сезгә?.. Ничә йөз елдан соң республикалы булдыгыз. Югыйсә, Казан — иксез-чиксез Россиянең урта бер җирендә торып калган гадәти бер өлкә, губерна шәһәре генә иң. Халкыгыз да бөтен Россия буйлап таралып, чәчелеп беткән. Бүгенге Казанны мин үзем рус каласы диеп беләм... Партиягә, иптәш Сталинга рәхмәт әйтәсе, булганына риза булып яшисе урында, дөньяны болгатасыз...

Беркавым тукталып торды Үзәк Комитет секретаре. Нияте — сөйләгәннәренә Мирсәетнең мөнәсәбәтен чамалау иде булса кирәк. Тыңлап утыручы дәшмәде, күңелендә, эчтән кайнап, күтәрелеп килгән дулкынны тышка чыгармады.

— Инде республика гына аз, Идел-Урал кирәк үзегезгә, Төркестан кирәк... Союз килешүенә кул куярга... Россия һәм Украина белән тигез хокуклы булырга...— Туктап тын алды Куйбышев һәм тавышын баса төшеп, үз итеп дәшкән атлы булды.— Безгә яхшы мәгълүм, Мирсәет,

мондый вәсвәсәләрнең башында иң элек син торасың... Син сөйли беләсең, синең сүзең үтә. Бигрәк тә вак милләт һәм төрле «туземец»лар арасында сиңа иярергә торучылар байтак. Без боларның барысын да беләбез. Һәм хөрмәт тә итәбез үзеңне. Безгә иптәш Сталинның да сиңа карата үзгә, туганнарча якын мөнәсәбәттә булуы мәгълүм... Шуңа күрә дә, Үзәк Комитет секретаре буларак, мин сине үз вакытында кисәтергә кирәк таптым. Юкса, ахыры матур бетмәс бу эшнең!..

Тыңлап утыручының түземлеге, күрәсең, соңгы чиккә җитеп терәлгән иде.

— Яңа ел теләкләрегез шуның белән тәмаммы? — дип, сорау кыстырырга кирәк тапты.

— Әгәр дә дөрес аңлата алган булсам, тагы да мөһимрәге, син аңлаган булсаң — тәмам!

— Дәшмәвең мең алтын, дигән сыман булды инде бу. Безнең төрки халыкларда шундый әйтем бар, иптәш Куйбышев.

— Төрки дигән сүзең искә төшерде... Тагы шуны әйтәм, сине кайбер иптәшләр пантюркизмда да гаепләп язалар. Сак бул, Мирсәет.

— Алай икән, — дип елмайгандай итте Солтангалиев. — Тик моның нигәдер гаепкә бәгәр җирен генә күрмим. Без бит чынлап та төрки халыклар. Славяннар кебек, төркиләрнең дә үзара аралашып, туганлашып яшәүләрендә мин һичнинди яманлык күрмим. Ислам исә, сезгә яхшы мәгълүм, безнең ата-баба дине. Бу очракларда «пан» дигән өстәмәгә ихтыяҗ юк. Панславян яисә панхристиан димиләр ич! Ислам дине тотучы һәм чыгышлары белән төрки булган халыкларны үзара каршы кую һәм бүлгәләргә омтылыш — ул ясалма һәм, әйтер идем, хата сәясәт.

Куйбышев, ярдәм эзләп, өстәл өстендә чәчелеп яткан хатларны искә төшерде.

— Әнә, хатлар... хатларда да шул ук куркыныч хакында искәртелә.

— Ә-ә, хатлар, — дип, ирексездән үзеннән читкәрәк этте аларны Мирсәет. — Турысын әйтсәм — әйтим, беренчедән, бу хатлар кемдер тарафыннан оештырылганга охшаган.

— Нәрсә сөйлисең! — дип, сүз кыстырмый булдыра алмады Куйбышев.

— Икенчедән, миңа әлеге хатларны укыганчы ук күптәннән таныш фикерләр болар. Кызганычка каршы, Казанда булсын, җирле халык вәкилләренең үзаңы уянуга эчләре пошкан затлар да байтак. Халыкларның соңгы араларда милли дәүләтчелеккә омтылышлары аларны тәмам чыгырдан чыгарды, ул хатларны күздән кичереп чыккач та, милләтчелек чәчәк атуын түгел, теше-тырнагы белән империячел фикер йөртүгә ябышкан туң йөрәк салкынлыгын тойдым мин үзем. Бу хатлар партия һәм яшь Совет дәүләте файдасына язылмаган, алардан патша империясе исе килә. Һәм, гомумән, бүгенге сөйләшүдән мин үзем канәгать түгел. Халыкларның үзбилгеләнүгә булган омтылышын алай җиңел генә буып, туктатып булмаячак. Азатлыкка омтылыш һәр милләтнең генә түгел, һәр шәхеснең табигый халәте. Без, шул сәламәт омтылышка дөрес юнәлеш биреп, милли азатлык хәрәкәтен социаль революция максатында файдалана белергә тиешле. Югыйсә, җил тегермәненнән дошман ясап көлкегә калуыбыз ихтимал!

— Тукта, — дип, кинәт өстәлгә китереп сукмасынмы шунда Куйбышев. — Монда кем — сезме, әллә минме Үзәк Комитет секретаре?! Җитәкче кешене тыңлап, аңладым, дип, рәхмәт әйтеп аерыласы урында үз вәсвәсәңне сөйләп утырасың. Большевик булсаң — большевик бул, партия юнәлешендә тор. Түгел икән,, ихтыярың, Истанбулга йөз тотып, юлга әзерлән. Дустың Зәки Вәлиди артыннан, мәсәлән.

— Иптәш Куйбышев! — дип, тавышын күтәрде һәм аягүрә сикереп торды Мирсәет. Һәм күзләрен дәү ачып туры Куйбышевка төбәде. Әле генә өстәл төеп, кызарып-бүртенеп акыл саткан партия лидеры сагая

калды булса кирәк. Тынлык урнашып торды. Йончыткыч һәм авыр тынлык. Кемнең күбрәк түземлеге житәр икән, хәтта чебен очкан аваз да ишетелми. Үзәк Комитет бинасы, әйтерсең, бушап калган. Һәм тагы күпмегә дәвам итәр иде бу тынлык...

Ачыргаланып телефон шалтырады шунда. Куйбышев, дөньясын онытып, эш өстәленә ыргылды.

— Әйе, тыңлыйм, иптәш Сталин. Дикъкать белән тыңлыйм.

Үзе үрә баскан, кабаланып якаларын төзәткәли, тавышы калтырана. Мирсәеткә ул шул мизгелдә кызганыч булып күренде хәтта. Кара, ничек сөйләшә, ничек ярарга тырыша Генеральный каршысында.

— Әйе, иптәш Сталин, безнең сөйләшү тәмам. Мин хәзер үк керәм.

Димәк, дип үзалдына нәтиҗә ясарга өлгерде Мирсәет, аларның бу сөйләшүе хакында Сталин үзе дә хәбәрдар булган. Кем белә, бәлки, ике арадагы бу сөйләшүне аның тыңлап та утырган булуы ихтимал. Куйбышевның вакыт-вакыт үзен сәхнәдәге уенчы сыманрак тотып, гайре табигый сөйләшүе дә шуннан булмадымы икән?! Вакыйгалар, һәрхәлдә, шактый киеренке һәм сәер юнәлеш ала бара сыман.

Ул да түгел, төребкәне урынына куйгач та, көзге каршысына үтеп, өс-башына күз төшереп алырга өлгерде Куйбышев. Чыгар юнәлешенә борылды. Әйтерсең, кабинетта ул үзе генә, әйтерсең, алар арасындагы сөйләшүгә соңгы нокта куелган. Сәер тоелды бу Мирсәеткә. Хәтта аны беркадәр кимсетте дә түгелме икән әле.

Җәт кенә ишек катына үтеп, Куйбышевның юлына аркылы барып басты Мирсәет.

Үзәк Комитет секретаре инде күптән башка дөньяда иде гүя, күзләреннән кот качкан. Ул Генеральный янына ашкына.

— Мин ашыгам. Мине иптәш Сталин үзе көтә,— диде ул киеренке калтырауга охшаш аваз чыгарып.

Көтмәгәе. Мирсәет тә болай чыгып китә алмый.

— Хәзер китәрсең, бер генә минутка, мине тыңла,— дип туктатты ул аны.

Теге исә, гүя ишетмәде.

— Мин ашыгам... Мине иптәш Сталин үзе көтә.

— Ике генә авыз сүзем бар, тыңлагыз, иптәш Куйбышев...

Теге калтырана ук башлады, еламый гына, ватык патефон тәлинкәсемени.

— Мин ашыгам... Мине иптәш Сталин үзе көтә.

— Мине хөрмәт итәсезме-юкмы, бу — сезнең ихтыярыгызда, Куйбышев иптәш. Әмма татар халкы турында керделе-чыктылы сөйләшүләрегезне туктатыгыз, бу — бер! Икенчедән, бераү дә Истанбулга йөз тотарга җыенмый. Без — килмешәк түгел, ата-баба җирендә яшибез! Онытмагыз, Мирсәет Солтангалиев үз Ватанында һәм үзе ышанган иманда яши. Кыйбласы һәм йөзе аның бер генә! Халкын, Ватанын һәм Иманын ул берәү каршында да алыштырмады һәм алыштырмас. Хәтта Генеральныйга кирәк булганда да... Ә инде Зәки Вәлидигә килсәк, аның үз язмышы. Ул да сез теләгән сәяси уенчы яисә курчак була алмады — бар гаебе шунда. Аның хакындагы соңгы сүзне башкорт халкы әйтсен.

Шуның белән сүзем тәмам. Хушыгыз, иптәш Куйбышев. Яңа еллар мөбарәк булсын!

Әллә ишетте, әллә ишетмәде, Үзәк Комитет секретаренең үз туксаны — туксан.

— Мин ашыгам... Мине иптәш Сталин үзе көтә,— дип үз «дога» сын янә бер кат кабатлады да, Мирсәетне этә-төртә ишек аша чыгып, хушлашырга да онытып, икенче кат коридоры буйлап, Генеральный кабинетына таба йөгереп китеп барды.

Мирсәет аның артыннан исе китеп карап калды. Гаҗәп хәлләр һәм гаҗәп кешеләр була икән бу дөньяда...

* * *

Ул ашыгып кабаланып өйгә кайтырга чыкканда сигез тулып килә иде бугай инде. Димәк, Яңа елга дүрт сәгать чамасы вакыт калган. Сәгатьләр генә түгел, көннәр, айлар, еллар шул рәвешле узып тора. Эштән бушаганы юк, ә эшләнәсе һәм чират көтеп яткан эшләренең очы-кырые күренми. Соңгы араларда исә, бигрәк тә узып барган 1922 елда, аның күңелендә ниндидер канәгатьсезлек, үз-үзеннән, әйләнә-тирәсендә булган вакыйгалардан ризасызлык хисе дә артканнан-арта бара кебек. Һәрхәлдә, 1918—1920 еллардагы күңел күтәренкелеге, ашкыну юк инде ул хәзер. Ул чорда бер талпынганда бөтен илне, дөньяны колачлап алырлык дәрт, дәрман барлыгын тоя иде ул үзендә. Нинди генә кыенлыклар күрмәсен, эшләгән эш, кылган гамәлләренең нәтиҗәсе күз алдында була, тормышта ачык чагылыш таба килә иде. Дошман белән якага-яка килеп тарткалашкан көннәрдә дә, үлемнең күзенә туры карап утка кергән сәгатьләрендә дә бүгенгедәй ару-талу, бүгенгедәй өметсез төшенкелеккә бирелгәне юк иде аның. Соңгы араларда исә күңеленә шом төшкән, икеләнгән, үкенгән, офтанган мизгелләр артканнан арта барды. Гәрчә болар, гомумән, Мирсәетнең холкына балачактан ук чит, ят сыйфатлар булса да гынамы, чын мәгънәсендә, курка калган сәгатьләре дә бар бит аның хәзер.

Шунысы кызганыч, бу бер аңарга гына хас, аны гына борчый торган тойгы-халәт булса икән. Төрле милли төбәкләрдән ишетелгән моң-зар турында әйтеп тә торасы юк, хәтта үзәк аппаратта китте тузга язмаган җыен чыш-пыш. Бер-беренә шикләнеп карау һәм ышанмау дисеңме... Төркемнәргә бүленеп үзара тарткалашу портфель һәм өстәл бүлешүләр дисеңме... Үзара ышаныч булмавы һәм мөнәсәбәтләрдәге эчкерсезлекнең югалуы турында әйтеп тә торасы юк инде...

Революцияне шуның өчен ясадымыни соң алар?!. Гражданнар сугышында ятып калган корбаннар һәм түгелгән кан нәрсә өчен кирәк булды?

Хәтерләргә, искә алырга теләмәсә дә, күз алдында һаман Сталин янына ашыккан Куйбышевның агарынып чыккан йөзе, төссезләнгән карашы, ә колак очында аның калтыранып чыккан тавышы эленеп торды. Валериан Куйбышевны Мирсәет бүген генә күреп белми. Гражданнар сугышы көннәрендә төрле фронтларда һәм төрле шартларда көрешкәннәре, аралашканнары бар иде. Азмы-күпме хөрмәт итә иде әле ул аны. Бүген исә аның күз алдында Куйбышев тәмам юкка чыкты, шәхес булуыннан туктады. Большевиклар партиясенең Үзәк Комитеты секретаре ни өчен дип әле шундый мескенлеккә, шул дәрәҗәдә түбәнлеккә төшерергә тиеш үзен. Булсын, Сталин — дәрәҗәле һәм хөрмәткә лаек җитәкче дә булсын ди...

Куйбышев та төшеп калганнардан түгел иде ич. Янәшә торып, тигез булып сөйләшү, хезмәттәшлек итүгә ни җитә!

Мирсәет тә аз эшләмәде Сталин янәшәсендә. Эшләде, эшли һәм эшләячәк тә. Әмма партия лидерларына булган мөнәсәбәте нинди генә булмасын, аның каршысында югалып калганы, колларча баш игәне юк. Һәм гафу да итмәс иде ул үзенә андый түбәнлекне. Фикерләре туры килә икән — уртак тел таптылар, түгел икән — бәхәсләштеләр һәм бәхәсләшәләр. Үзара бәхәс һәм фикерләр көрәшендә хакыйкать ачыклана ич. Бер партия әгъзалары арасында үзара мөгамәлә бары шундый гына булырга тиештер дә ул.

... Мәскәү елгасы аша салынган күпернең яртысына җиткәч тә каршы якта калкып торган соры бинадан үз тәрәзәләрен эзләп тапты Мирсәет. Яктылык бар, димәк, һәммәсе дә өйдә, аны көтәләр булса кирәк. Бозлы тәрәзә аша кемнеңдер күләгәсе күренеп китте. Фатыйма булса кирәк, дип уйлап куйды ул, аш-су хәстәрләп йөрүедер. Күңеленә җылы кергәндәй

булып китте, адымнарын тагы да әшайта төште. Тәрәзәдәге яктылык та җитә икән ич кеше күңелен канатландыру, очындыру өчен.

Өйләре турысына килеп җиткәч янә бер тапкыр өченче каттагы якты тәрәзәгә күз салды Мирсәет. Һәм туктап калды. Ул гына да түгел, чигенә-чигенә юл аша ары чыгып, елга читендәге таш диварга килеп сөялде. Күзләре — якты тәрәзәдә. Тын алырга да кыенсынып, хәйран калып күзәтте ул үз тәрәзәләрен.

Көн салкын. Тәрәзәгә суык бабай боздан челтәр чиккән. Аргы яктан кемдер иреннәре белән тәрәзәдәге шул боз катламын эретү белән мәшгуль иде. Инде беренче тапкыр гына җылытуы түгел, кайнар сулыш һәм бармак эзләре тәрәзәдәге боз элпәсен чуарлап бетергән. Аны күзәтүләре, аны көтүләреме икән?.. Фатыйманың бу эш белән шөгыльләнер арасы булмас, дигән уй йөгереп узды. Сабыйларның кайсысы булыр икән бу? Әле яңа дүртенче яше белән киткән Гөлнарымы, әллә сигезне тутырган Рәсидәсеме?

Нәкъ шул мәлне, ата күңелен бимазалаган сорауга җавап бирергә ашыккан сыман, аргы яктагы сабый әле генә иреннәре белән тишкән ачыклык аша тәрәзәгә капланып урамны күзәтергә керешә.

«Рәсидә»...— дип, әйтеп куйды Мирсәет үзалдына. Әтисен көтә, күпер ягына текәлеп аны эзли. Күңеле нечкәреп китте атаның, бугазына авыр төер, күзләренә кайнар тамчылар килгәнен дә сизми калды хәтта... Рәсидәсе аның саен иреннәре белән боз җылыта һәм яңадан тәрәзәгә килеп каплана. Өй каршысында ук, түбәннән үзенә кулларын болгарга керешкән әтисен генә күрми. Карашлары еракка, күпер аша Кремль тарафына ук текәлгән.

«Рәсидәм... Ятимәм минем...» — дип кабатлады тәмам йомшарып киткән ата. Үз-үзенә, күңеленең нечкә бер төпкеленнән ургып чыккан хисләренә хуҗа түгел иде ул шул мизгелдә. Бу бала чынлап та бәгыренең иң йомшак җирендә эленеп торган бердәнбер ярасы иде бит аның. Үзеннән аерым яшәгәндә дә хәтереннән, күңеленнән чыгара алмый юксынды, өзлексез сагынып яшәде ул аны. Инде менә үзе янына алып кайткач та һаман кызганыч, һаман бәгырен өзгәли аның Рәсидәсе. Чөнки ул иң газиз кешесен югалткан — әнисез калган бала. Кыз бала өчен моннан да авыррак нинди югалту булырга мөмкин. Яхшымы-яманмы, Рауза аның әнисе иде бит. Аның җылы кулларын, «кызым» дип өзгәләнеп аркасыннан сөюләрен сагынмыйдыр дисеңмени, юксынмыйдыр дисеңмени ул баланы. Ургылып яшь ага ата күзләреннән. Гүя үз-үзенә хуҗа түгел, берни эшләтә алмый газапланды ул үзен...

Югыйсә, Фатыйма да какмый-сукмый, үз баласы сыман карый, кадерли иде бит Рәсидәне. Ә барыбер газиз ана назын һичкем алмаштыра алмас, инде һичкем бирә алмас Рәсидәгә. Бу сабыйны аңласа да хәзер, ул — аның әтисе — Мирсәет кенә аңлый алыр. Мирсәетнең исә көндәлек ыгы-зыгыдан арынып өйгә кайтып керә алганы юк,— берөзлексез юлда, берөзлексез эштә. Ул югында, көзге озын кичләр һәм кышлар буе һәрчак шулай тәрәзәгә капланып әтисен көтәдер сыман тоелды Рәсидә.

Әнә ич, әле хәзер дә кайнар тыны белән тәрәзәне эретергә, ике арада эленеп торган салкын пәрдәне алып ташларга тели. Ә ул — ата кеше — өч дистәне тутырган әзмәвердәй таза, сәламәт ир-ат балавыз сыгып үз кызының ничек газаплануын күзәтеп тора монда. Шул рәвешле, йомшарып китүенә ачуы чыкты Мирсәетнең. Уч тутырып салкын кар иелеп алды да, шул кар белән чигәләрен уа-уа, җәт-җәт атлап, өйгә ашыкты.

Ишекне Фатыйма ачты. Мирсәетнең кулына тотып кергән ак каракүл папахасын элгечкә алып куйды. Ашыга- кабалана тун төймәләрен ычкындырырга булышты, һәм иренең күкрәгенә килеп капланды...

Ишек катында беркавым тынлык урнашты. Хатынының бөдрәләнеп торган йомшак кара чәчләреннән сыйпап торды Мирсәет, аның кайнар сулышын, йөрәк тибешен тоемлады. Күңеленнән генә уйлап куйды:

нибарысы егерме өч яшь бит әле Фатыймага. Өйләнешеп бергә тора башлауларына дүрт ел тулып, инде бишенче ел киткән. Мирсәетнең нинди генә рәхәт күрсәткәне бар анарга, кайчан карама эштә, кайчан карама ил һәм халык мәшәкатьләреннән арына алганы юк. Ә Фатыйма, ир куенында иркәләнер чагында, кичләрен-иртәләрен, еш кына төннәрен дә бер ялгызы дүрт стена артында уздырырга мәҗбүр. Ул бит әле студент та, Көнчыгышны өйрәнү институтында укый. Ике бала тәрбияли. Берсе үзенеке түгел. Өстәвенә, әнисе һәм туганнары белән дә арасы көйләнеп җитмәгән. Фатиха алып тормый гына Мирсәеткә чыгуын әле булса гафу итеп бетерә алмыйлар...

Кулы белән Фатыйманы күкрәгенә кысты Мирсәет, ә карашы кызларын эзләде. Чынлап та, нигә тавыш-тыннары ишетелми соң әле боларның? Рәсидә сабыр, тартына торгандыр, ә Гөлнары әллә кайчан йөгереп килеп җиткән булырга тиеш иде бит инде. Аш-су әзерләү бүлмәсе ишегеннән әле бая гына кайсыдыр карап алган кебек иде, инде анысы да китеп югалган.

— Кызлар кая, Фатыйма, кызлар нигә күренми? — дип, сорамый булдыра алмады.

Башын күтәрә төшеп, иренә зур кара күзләрен текәде Фатыйма.

— Хәдичә белән Сәет килгәннәр иде. Мин институтка барып кайткан арада балалар белән торып тордылар. Гөлнарны үзләре белән кунакка алып киттеләр. Ә Рәсидә өйдә... Ут алганнан бирле инде сине көтә, тәрәзә яныннан китмәде.

Янә бер кат хатынының тулы алсу иреннәренә, ачык йөзенә соклanып карап торган җиреннән, кызына дәште Мирсәет:

— Рәсидә, кызым, әтиеңне каршы алырга чыкмыйсыңмыни?..

Җавап бирүче булмады. Мин монда дигән сыман, кызның борын сызгырткан авазы гына ишетелде. Кемгәдер, нәрсәгәдер үпкәләгән, димәк.

Мирсәетнең колагына үрелеп, ачыклык кертте Фатыйма:

— Сине миннән көнләшә ул. Кунакка аны да чакырганнар иде, киреләнде, бармады.

Мирсәет, ниһаять, тунын салып элде, аягын чишенде.

— Балдыз белән кайнеш килгән идемени? Үскәннәрме соң, Фатыйма?.. Аларны күрмәгәнгә дә байтак бит инде.

— Сәеткә унөч тула инде, гәүдәгә һаман шул көенчә. Ә Хәдичә, күрсәң, исең китәр, шундый чибәрләнгән... Егетләрнең күзен камаштырырлык.

Чынлап та Ирзиннарның һәр баласы — өч малай һәм ике кызлары акыл һәм тәрбияләре белән булсын, буй-сын ягыннан булсын, үзләренең яшьтәшләре арасында аерылып торганнар. Моны Мирсәет тә яхшы белә, затлы гаилә. Әмма социаль чыгышлары байлардан булганга күрә, яшәү, бигрәк тә соңгы араларда, җиңел бирелми иде аларга да. Мирсәет булып Мирсәеткә төртеп күрсәтәләр, исенә төшереп торалар иде кем кызына өйләнгәнлеген.

Фатыйма җәт кенә аш-су әзерләү бүлмәсеннән Рәсидәне җитәкләп алып чыкты.

— Әтиең кайтты ич, нигә чыкмыйсың? Нигә киреләнәсең, Рәсидә?

Фатыйма, кыз белән әтисен икәүдән-икәү генә калдырып, аш-су хәстәрләргә китеп барды, бәйрәм өстәлен кайгыртырга. Кызын кулына күтәреп сөя-сөя Мирсәет тә анарга иярде.

— Фатыйма, — диде ул, гаепле кеше сыман. — Бүген үзегезгә бәйрәм бүләге кайгыртып арам да булмады. Бер юлга гафу итәрсең, яме.

— Икмәк паегын алдым, аз булса бәрәңге бар әле. Борчылма, Мирсәет, алланың биргәненә шөкер.

Тамак кырып елмаеп алды Мирсәет. Бу аның «алла» исемен искә төшерүчеләргә җавабы иде. Фатыйма, Касыйм каласында туып Мәскәүдә үссә дә, аллаһе тәгаләне һәрдаим искә алырга күнеккән, затлы тәрбия

алган кыз. Ә Мирсәеткә исә, үскәндә дә эләкмәде андый тәрбия, хәзер дә дингә арка куюны алга сөрүчеләр арасында эшли. Кыскасы, ул — революция фанатигы — алла исемен сирәк, бик сирәк, искә ала. Гәрчә, күңелендә, бу изге төшенчәләргә карата берәүгә дә әйтеп аңлатмаган, җылылык һәм олылау яши иде аның.

Фатыйма да елмаеп җавап кайтарды. Әмма сүзләре ихластан иделәр:

— Юк инде, Мирсәет,— диде ул.— Үземә хуҗа булуын булдың, әмма аллага тимә, иманыма хыянәт итте юк.

— Ә син, кызым, ничек уйлыйсың — алла бармы ул, юкмы? — дип, шаярган атлы булып, кызының почык борынына басып куйды ата.

— Алла ул безнең бар яхшылык һәм яманлыкларыбызны күзәтеп тора, әтием,— дип әйтеп салмасынмы сигез яшьлек кыз бала.— Үз әнием дә сырхауланып ятканда «мине алла каргады» дип әйтә торган иде. Алла бар ул, әти!

Елмаерга да, көенергә дә белми аптырап калды Мирсәет. Кызыннан һич мондый сүзләр ишетермен дип уйламаган иде. Өстәвенә, Фатыйма алдында янә Раузаны искә төшерделәр.

Беренче класста укучы Рәсидәнең мәктәп хәлләре турында сораштыра-сораштыра ата белән кыз бүлмәгә уздылар.

* * *

— Мирсәет...

— Әйе, Фатыйма.

— Нигә йокламыйсың?

— Ә үзең?..

— Сине уйлап ятам. Төне буе боргаланып чыктың. Тагы борчуларың бармы әллә?..

— Үзең беләсең, Фатыйма, җан тыныч түгел. Әллә арыдым инде, эчем поша, Мәскәүдә дә хәлләр мактанырлык түгел, урыннарда да... Революция булганга алтынчы ел китте. Ә тормыш һаман бер тирәдә таптана, алга китеш юк. Кан кою, көрәшнең туктап торганы юк. Ашарына юк кешеләрнең, ягарына... Тәмам йончыды халык.

— Ә ул ыгы-зыгы бетәр вакыт бетәр дип уйлыйсыңмы?.. Минем әни әйтә, җимерүен җимерделәр тормышны бу большевиклар, ди.

— Тыңлама... һәм сөйләмә андый сүзләрне. Ялгыша ул.

— Эче пошканга сөйли торгандыр... Кешеләрнең бер-берсенә дошманлашуы, кансызлыгы, мәрхәмәтсезләнә баруына поша аның эче. Ә сиңа, синең эшеңә хәерхаһ ул үзе.

— Беләм... Минем әби яхшы кеше, киң күңелле,— дип, Фатыйманы үзенәрәк тарта төште Мирсәет.— Шундый кыз үстереп биргән әби начар була димени...

— Җитәр... Йокларга тырыш инде, Мирсәет. Черем итеп булса да алырга кирәк.

— Йокы качмас... Бүген үк Казанга китәргә кирәк, юлда йокланыр әле.

— Тагы юлга чыгасыңмы?..— дип, офтанып куйды Фатыйма.— Бергә яшәгән күк тә түгел, гомер гел аеры-чаеры үтә... Кичәгенәк санап утырдым әле, узган елның өчтән икесен юлда уздыргансың... Бу ел да шулай булырмы икән?..

— Җиңел булмас, Фатыйма. Шулай да бергә-бергә булсак, түзәрбез.

— Хәерле ел булсын... Зарлана дип уйлама. Сиңа авыр, сине кызганганга әйтүем.

— Минем уйлавымча, Фатыйма, 1923 ел хәлиткеч борылышлар елы булыр. Төркестандагы ыгы-зыгы бетәр, ачлыктан да котылырбыз. Ә иң әһәмиятлесе, Үзәк Комитет милли мәсьәләне аңлау юнәлешендә дөрес

юлга басар. Татарстан, Башкортстан һәм Төркестан республикалары тигез хокукка ия булсалар, менә күрерсең, бу факт бөтен Көнчыгыш илләрен кузгатып җибәрер. Социализм идеяләренең таралуы һәм җиңүе өчен Көнчыгышта иксез-чиксез мөмкинлекләр бар...

Иренә тагы да елыша төшеп, елмаеп алды Фатыйма:

— Төшеңдә дә, өнеңдә дә революция дип саташасың... Хәерлегә булсын!

— Шуның өчен туылган, күрәсең... Ә шулай да, Фатыйма, революция җиңеп, бу ыгы-зыгылар бер тынычлангач, язу эшенә керешәсем, язасым килә минем. Үземнең күргәннәр, баштан кичкәннәр турында язасым килә. Сизәм, теләк бар язарга, җегәр дә бар... Вакыт кына кирәк. Ул шундый роман булачак...

— Үзең өлкән булсаң да, бала-чага кебек, хыялый син, Мирсәет... Хыялыем минем...

Иренә сарылып сырпалана ук башлаган иде инде Фатыйма.

— Ә син миңа бер малай табарсың, ярыймы...

— Анысы инде синнән тора... Син бит кызлар буенча белгеч.

Иркәләнү-шаяруы, уены-чыны бергә Фатыйманың. Мирсәет тә кушыла ул шаяруга:

— Баш астына балта куеп ятыйкмы икән соң әллә булмаса...

* * *

Тагы бер көннән соң Казанда иде инде Мирсәет. Совнарком рәисе Мохтаров һәм ТатЦИК рәисе Сабиров белән көн кадагындагы мәсьәләләр һәм аларны чишү юллары турында зур киңәшмә җыеп фикер алыштылар. Казанда булсын, Татарстанның авылларында булсын, хәлләр соң дәрәҗәдә киеренке. Республикада ачлык! Зарланучы күп, киңәш бирүче дә җитәрлек. Ярдәм генә юк...

Татарстанның азык-төлек эшләре буенча комиссары Юныс Вәлидине чакыртты ул.

Юныс Вәлиди белән Казанда 1918 ел башларында ук танышкан иде алар. Утлы күмер кебек янып торган егет. Кирәгеннән артык тәвәккәл, ике уйлап тормый. Күңеленә хуш килгән фикерне шундук эләктереп-күтәреп ала. Сәетгалиев белән пычакка-пычак килеп эшләделәр. Татарстан хөкүмәтенә «уң» коммунистлар килгәч матур гына эшләп киткән кебек иде. Бүген әнә Мохтаров һәм Сабиров белән дә араларына су кергәндәйрәк тәэсир калды. Һәрхәлдә, Мирсәеткә шулай тоелды. Юныснең үзен генә чакыртуының сәбәбе дә шуннан иде.

Күрешеп кул кысышкан, ике-өч авыз сүз белән хәл белешкәннән соң ук туры, сорау белән мөрәҗәгать итте Мирсәет. Чөнки аңарга яхшы мәгълүм иде: Юныс Вәлиди турыдан ярып сөйләшүне хуп күрә, кешеләрне түрәләргә һәм үзеннән түбәннәргә бүлми. Әңгәмәдәшендә эчкерсезлек күрми икән, хет үтер син аны, янәшә утырмас, бер авыз сүз ала алмассың үзеннән дә. Үз туксаны туксан!

— Нәрсә, Мохтаров белән дә борчагың пешми башладымы әллә? — диде Мирсәет, мөмкин кадәр аны эчкерсезлеккә чакырып.

— Мохтаров кыз-хатын түгел, безгә ни, борчак куырасы юк аның белән. Ул үз эшен белсен, мин — үземнекен, — дип урындыгыннан сикереп торды Юныс Вәлиди.

Аның кире урынына утыруын үтенде Мирсәет. Үзе исә, ипле генә килеп, күптәнге танышының аркасына кулын салды.

— Кызма әле, тынычлан, Юныс. Без синең белән унсигезенче-унтугызынчы елларда мондый гына хәлләрдән чыкмадык. Түземле бул, тәҗрибәле революционер ич син...

— Мирсәет, — дип, иңбашын читкәрәк тартып, үзен кочаклаган куллардан арынды Юныс. — Без синең белән үткәндә кылган эшләрне бар-

лау өчен очрашмадык дип беләм. Хан заманындагы чибәрлеге белән карт фәхишәләр генә мактана ул... Нишләргә дигән сорауга җавап табарга тиешле без бүген...

Ипле генә үз урынына барып утырды Мирсәет.

— Тәкъдим... Нинди тәкъдимең бар, әйдә, турыдан яр.

Юныс тәкъдимен, үзенең ни уйлаганлыгын чыгарып селкергә ашыкмады, читләтә төште. Димәк, җитди, гадәттән тыш җитди сөйләшүгә әзерләнә.

— Иң элек, төп максатны ачыклап китик әле, иптәш Солтангалиев...

Үз фамилиясе искә алынуның иониягә тартым шаяру булуын аңламады түгел Мирсәет. Әмма андыйны гына кичерергә ярый бу лачын белән гәпләшкәндә.

— Максат бер генә, үзегезчә кәнфитләнеп әйтсәк, иптәш Вәлидов. Максат — халыкны икмәккә тиендерү.

— Шулай... Әгәр дә мәгәр миңа — шушы эш өчен турыдан-туры җавап бирүче комиссарга гадәттән тыш вәкаләтләр бирелми икән, эш уңайга борылмаячак. Доклад сөйләп, графинадан су эчеп, өстәл сугып кына чишә торган мәсьәлә түгел бу. Һәр яңа көн йөзәрләгән кешене алып китә. Гыйнвар урталарына кадәр Америкадан килгән икмәкне ташып өлгермәсәк, газраил урак белән түгел, чалгы белән умырырга керешәчәк...

— Соң, эш нәрсәдә? Ташырга кирәк. Икмәк — юлда.

— Беләм. Икмәк моннан бер ай элек тә, ай ярым вакыт элек тә юлда иде. Ә нигә өстәлдә, сабыйлар кулында түгел соң ул?!

— Кыш салкын. Үзең беләсең, Юныс, юллар төзек түгел, күмер юк, паровозлар җитми. Элекке машинистларның, карт белгечләрнең кадерен белмәдек, яңаларын әзерләргә ара юк... Саный китсәң, сәбәп күп инде ул.

Янә урыныннан калкынып куйды Юныс Вәлиди.

— Сәбәп кирәкме сезгә, икмәкме?..

Мирсәетнең дә түземлеге төкәнә башлады.

— Икмәк кирәк, икмәк! — дип кабатады ул, йөрәк тавышы белән.

— Соң, шулай булгач, акыл сатмасыннар, — дип өстәлгә үк китереп сукты Вәлиди. — Бер атна эчендә республиканы мин икмәкле итәм. Юллар да төзек булыр, утын та табылыр, машинист та...

Юныс Вәлидинең булмастай буш сүз сөйли торган гадәте юк. Мирсәет моны яхшы белә. Килештек дигән сыман кулын сузды ул аңарга.

— Әйдә... Тагы бер геройлык эшлә булмаса...

Кул бирергә ашыкмады Вәлиди.

— Ә Мохтаров?.. Ә Сабиров?..

— Аларның да башына тай типмәгән. Юныс, син нәрсә сөйлисең, икмәк бүген бар нәрсәдән дә әһәмиятлерәк. Икмәк һәм кешеләр язмышы... Революцияне дә шул гади хезмәт ияләре — эшчеләр, авыл мужиклары өчен ясадык бит инде.

Вәлиди утырып тора алмый иде инде. Ишекле-түрле йөренә башлады ул.

— Бу эшне бары җинаять юлы белән, җинаять аша гына хәл итеп була. Мохтаров аңа бармый һәм бармаячак.

— Җинаять! Ул нинди җинаять? — дип, гаҗәпләнеп калды Мирсәет тә. — Сөйлә, нинди җинаять ясарга җыенасың?

— Ришвәт биреп. Тимер юлчыларга шикәр бирсәң, алар көнентөнен эшләячәк. Мәскәүдән Казанга тикле юлны сатып алу өчен бер вагон шикәр җитә. Бер вагон!

— Ришвәт... Риш-вә-әт... — дип кабатлый-кабатлый арлы-бирле йөренергә керешә Мирсәет тә. Кулларын кая куярга белми башлады ул. Юныс Вәлидине күрмәмешкә салышты кебек. Һәм кинәт шартлап кабынды. Кобурасыннан пистолетын тартып алып, баш очында болгарга керешә. — Бернинди ришвәт тә юк. Большевиклар ришвәт бирми. Шундый юлга барсаң, беләсеңме... беләсеңме, Юныс иптәш Вәлиди, мин сине

беренче булып үзем, үзем стенага терәп атачакмын... Ришвәт бирәсе генә калган, кара син аны!..

Юныс Вәлиди, үзен аңлауларыннан өметен өзеп, лып итеп кире урынына барып утырды.

— Шулай шул, сез барыгыз да бериш. Кыз да булсын, буаз да булсын сезгә! Ә халык кырыла, халык ачтан үлә. Икмәк төялгән эшелоннар — тупикта.

— Бу саботаж! Саботажлык бу!.. Мәскәү — Казан арасын җәяү йөреп чыгачакмын, әмма икмәк юлда тоткарланмас, иптәш Вәлидов. Ләкин ришвәт биреп түгел!

— Мирсәет... — дип дәште Юныс Вәлиди. — Кызма зинһар, калай әтәч булмыйк. Бу унсигезенче ел түгел, наганнан курыкмыйлар хәзер. Мин дә болгап карадым ул наганны, курыкмадылар... Барысы да риза болай сөйләшкәндә. Начальниклар машинистларны чакырып сөйләшә. Утын яисә күмер булса, паровоз китәчәк тә үзе... Утын ташырга ат кирәк. Аты булса — кисүчесе... Аларын да ерып чыкканым бар, шунда шпал алмаштырырга керешәләр. Шпаллы да булдык дисәк, паровозның казаны тишелә... Сез белгәннәрне мин киптереп элгән, Мирсәет. Атсаң — атарсың, барыбер бер үләсе. Сүгенсәң — сүгенерсең, минем башка чарам калмады. Беткә ачу итеп тунны утка якмыйлар. Шикәр ашап торып булмый, бер вагон шикәр каян килеп кая китмәгән...

Мирсәет телсез-өнсез калып торды бер мәлгә. Юныс Вәлидигә ачуы зур идеме шулай, әллә тимер юлчыларгамы?.. Үзенең ярдәм кулы суза алмавына, чарасызлыгына үртәнә идеме,-аңламассың. Бүтәнчә дәшмәде, пистолетын кире урнаштырып, кобурасын төймәләп куйды.

— Мирсәет, — диде Юныс Вәлиди, икеләнергә урын калдырмаслык нык тавышы белән. — Мин барысын да үз өстемә алам. Бу сөйләшү булмады дип сана. Тимерюлчылар белән сөйләшенгән, килешенгән. Тагы нәкъ бер тәүлектән иш төялгән беренче эшелон Казанга, икенчесе Кукмарага килеп туктаячак. Халыкны коткарыйк иң элек, үлемнән йолып калыйк. Гаепләләрне тикшерергә, табарга һәм... стенага терәп атарга аннары да өлгерерсез — ихтыярыгыз. Бүгенгә әле Татарстан совнаркомының азык-төлек комиссары — мин, Юныс Вәлиди! Бернинди трибунал, бернинди пистолетыгыз белән дә куркыта алмассыз мине. Кемнең большевик, кемнең җинаятьче икәнлеген соңрак ачыкларсыз.

— Беттеме? Сүзең беттеме?.. — дип, тавыш бирде, ниһаять, Мирсәет тә. Һәм гел көтмәгәндә, тешләрен кысып, боерык тонына күчте: — Азык-төлек эшләре комиссары Юныс Вәлиди! Сиңа әйтәм, бар, эшең белән шөгыльлән. Халыкның тамагын туйдырудан да әһәмиятлерәк мәсьәлә юк бүгенгә...

* * *

Солтангалиев Үзәк Комитет тарафыннан җибәрелгән бу командировкада ун көн чамасы була. Татарстан һәм Башкортстандагы вакыйгаларны өйрәнү белән бергә, байтак кына чуваш һәм удмурт авылларын да йөреп чыга. Кая гына барып чыкмасын, җан әрнеткеч хәерчелек күренешләре белән күзгә-күз очраша. Хезмәт ияләренең тормыш-көнкүрешен яхшырту турында кайгыртып, урындагы иптәшләргә киңәшләр бирә, аларның моң-зарын үзәккә алып кайта.

Ул юлда була әле. Гыйнварның бишенче көнендә Үзәк Комитетка соңгы арада гына Милләтләр эше халык комиссарының урынбасары итеп билгеләнгән Г. Бройдодан хат-тәкъдим килеп керә. РСФСР Советларының X корылтае фракциясендәге чыгышы өчен Солтангалиевне коллегия әгъзасы вазифасыннан азат итү ихтыяҗы нигезләнә анда. Бу

мәсьәләнең иптәш Сталин тәкъдиме белән кузгатылуы да искәртелә. Оештыру бюросы әгъзаларыннан Куйбышев һәм Дзержинский хатны хупларга кирәк таба. Рыков белән Андреев бу адымны нигезле күрмиләр, хупламыйлар. Фикерләр бүленү сәбәпле, Солтангалиевнең язмышын хәл итү Сталин карамагына тапшырыла.

Әмма Сталин бу юлы да Мирсәетнең яклаучысы булып кала, Солтангалиевне «гафу» итә. Дзержинский һәм Куйбышевның нинди хәлдә калуы кызыксындырмый Генераль секретарьны. Үз дәрәҗәсе генә төшмәсен.

Шул рәвешле, Мирсәет Солтангалиев белән мәчеле-тычканлы уйнау аның гадәтенә керә бара.

* * *

Тагы ун-унбиш көннән Мирсәетнең алдына инглиз телендәге ниндидер гәҗит китереп салган Үзәк Комитет секретаре Радек болай дип сүз башлады:

— Иптәш Солтангалиев, менә буржуаз газетада сезнең Татарстан турында язылган.

— Ни дип язганнар, мин аларча белмим.

— Сездә азык-төлек эшләре белән кем шөгыльләнә анда?

Сорауны ишетүгә, яшен ташы китереп суккандай булды Мирсәеткә. Нәрсә диярга, ничек җавап бирергә белми югалып калды бермәлгә.

— Нәрсә, бер-бер хикмәтле эш кырганнармы әллә?

— Татар барда — хәтәр бар, дип юкка әйтмиләр икән бит. Шул иптәшегез бөтен Мәскәү — Казан тимер юлы эшен аякка бастырган, дип мактап язганнар... Идел буен ачлыктан коткаручы дигәннәр. Кем соң әле, кем? — дип гәҗиттән тегенең исем-фамилиясен эзләргә кереште Үзәк Комитет секретаре. Үзенең дә инглизчәсе чамалы булгандыр, күрәсең...

— Вәлидовмы әллә?

Җанланып китте Радек.

— Әйе, әйе, нәкъ үзе. Вәлидов. Юныс Вәлидов иптәш! Хикмәтле, гайрәтле кешемени?..

— Хикмәтле, гайрәтле, — дип кабатлады Мирсәет, шатланырга да, көенергә дә белмичә. Юныс Вәлидинең шулай санаулы гына көннәр эчендә Татарстанны икмәкле итүе, хәтта тиешеннән артыграк та ашамлык әйберләр кайтарып, бөтен республика авыллары һәм шәһәрләренә таратуны оештыруы турында Мирсәеткә мәгълүм иде инде. Мохтаровның аны эштән алыргамы, әллә трибуналга бирергәме? дип, киңәш сорап язган кәгазе дә шул минутта Солтангалиевнең күкрәк кесәсендә иде.

— Иптәш Сталинга да укыдым, — диде кәефе булган Үзәк Комитет секретаре. — Юкса, моңарчы «Советлар океан артыннан килгән икмәкне дә халыкка җиткерә алмый... Советларны паралич суккан», — дип лаф оралар иде. Бу әле буржуаз Америка матбугатының беренче тапкыр безнең эш нәтиҗәләрен тануы. Бу — безнең җиңү, иптәш Солтангалиев. Аңлыйсызмы, җиңү!.. Ул иптәшкә рәхмәт белдерүегезне үтенәм.

* * *

1923 елның 23 гыйнварында партия губерна комитетларына «бик тә яшерен» дигән гриф астында Политбюро һәм Үзәк Комитетның Оештыру бюросы исеменнән циркуляр җибәрелә. Ленинның соңгы васыятьләренә мөнәсәбәтле була ул. Анда түбәндәге сүзләр язылган:

«Ленин авырый, хәле яхшыдан түгел; ул инде Политбюро утырышларында катнашмый, беркетмәләр белән дә танышып бармый, кирәкле политинформацияләрне белми. Аңарга хәтта газета уку да тыелган.

Врачлар тарафыннан, кайбер фикерләрен язып бару өчен, көндәлек сыман нәрсә язгаларга гына рөхсәт бар. Аның гозерләп соравы сәбәпле, шул язмаларның кайбер фрагментлары матбугат битләрендә дә урын ала. Димәк, аларны хаста кешенең язмалары дип кенә кабул итәргә кирәк.

А. А. Андреев, Н. И. Бухарин, Ф. Э. Дзержинский, М. И. Калинин, Л. В. Каменев, В. В. Куйбышев, В. М. Молотов, А. И. Рыков, И. В. Сталин, М. П. Томский, Л. Д. Троцкий».

Шул рәвешле, вафат булганына кадәр нәкъ бер ел элек Ленин сәяси көрәш мәйданыннан читкә этәрелә, аның васыять булып яңгырарга тиешле соңгы хезмәтләренә «җитдилеккә дәгъва итмәгән язмалар» дигән ярлык тагыла. Партия һәм Совет җитәкчеләре арасында үзара ыгы-зыгы, төркемнәргә бүленү, урынсыз бәхәсләр артканнан-арта, куерганнан-куера бара. Үзәктә генә түгел, милли республика һәм губерналарга да йога әлеге фракцияара тарткалашу чире. Әле кайчан гына бер үзәкне тәшкил иткән большевиклар «уңнар» һәм «суллар»га бүлгәләнә. Милли республикаларда «милләтчеләр» һәм «интернационалистлар» барлыкка килә. Һәр ике якның яклаучылары, килешмәүчән көрәшкә өндәп, дәрт биреп торучылары табыла. Гражданнар сугышыннан йончыган, ике ел дәвамына сузылган корылык һәм ачлыктан иза чиккән, кырылган халыкны кайгырту уе калмый җитәкчеләрдә.

— Бу — нәрсә бу, нинди ыгы-зыгы китте, төшендерегез, зинһар? — дип, Сталинга мөрәҗәгать итә Мирсәет, Генеральный белән очрашуларның берсе вакытында.

Гаҗәп, әмма факт. Җавабы эчкерсез була Генераль секретарьның:

— Беләсең киләме?!. Күрмисеңмени, кресло өчен сугышалар. Менә шул!

— Ә халык турында кем кайгыртыр, эшче-крестьян мәнфәгатен кем кайгыртыр, иптәш Сталин?.. Түзәр-түзәр дә, халыкның да түземлеге бетүе ихтимал ич.

— Ишарәңне аңламадым...

— Халык массаларының революциягә ышанычын ныгыту өчен чаралар күрергә вакыт, дим. Канкойгыч сугыш һәм дә ачлыктан башканы күргәне юк ич әле аның.

— Тарих — көрәштән гыйбарәт, Мирсәет, син шуны гына аңларга тиешле. Революция тарихы исә тагы да киеренкерәк көрәш шартларында языладак. Социализм өчен көрәш әле башлана гына...

Бу елларда үзе дә дөнья революциясе турындагы хыял белән канатланып йөргән Мирсәетнең килешмичә хәле юк.

— Килешәм, — диде ул. — Әмма дөнья революциясе ясарга алынган тәҗрибәле иптәшләрнең кресло өчен, хакимият өчен көрәшеп гомерләрен заяга үткәрүләрен аңламыйм.

Шунда, кинәт көтелмәгән борылыш ясап, Мирсәетнең күзенә текәлде Сталин. Салкын, авыр карашны күтәрү җиңел түгел, әмма ул да сынатырга теләмәде, колак төпләренәчә чемердәп-кызышып чыкса чыкты — түзде.

— Син дә кул кушырып утырмыйсың, — диде партия җитәкчесе, һәр сүзенә, һәр иҗеккә басым ясап. — Солтангалиев иптәш аеруча активлашты, дигән хәбәрләр йөри.

— Ни әйтергә теләгәнегезне аңламадым, иптәш Сталин.

— Аңламадыңмы? Әллә аңламамышка салынуыңмы?!.

— Шулай кырыс каравыгызның сәбәбен аңламадым.

— Аңламасаң, аңлатабыз аны...

— Тыңлыйм.

Озак көттермәде Сталин. Әйтергә уйлаганы күптән тел очында торган икән.

— Иң элек, Политбюро фикеренә шик салып, партия лидерына каршы сөйләргә кем сорады икән Солтангалиев иптәштән?!

— Аңламадым.

Мирсәет чынлап та аның ни әйтергә теләвен тәгаенләп өлгермәде. Нигә шулай боргалый ул?

— Владимир Ильич авырый, Солтангалиев иптәш, — диде Сталин. Ниһаять, турыдан суктырып сөйләшүгә күчте ул. — Ә син аның саташып язган нәрсәләрен «туземный» коммунистлар арасында пропагандалап йөрисең. Политбюрода наданнар утырамы синеңчә?!.

Аңлады, ниһаять. Һәм шундук кызып бәхәсләшергә кереште Мирсәет.

— Ильичның ул хезмәтләренә минем үз карашым бар. Ул карашлар, чынлап та, сезнеке белән капма-каршы, иптәш Сталин. Әмма үз фикерләрем белән уртаклашырлык кына хокукым бар дип беләм. Һәм мин, чынлап та, Политбюроның ул хактагы яшерен циркуляры хата булды дигән фикердә. Ләкин мин коткы таратмадым, нибарысы фикер уртаклаштым...

Бу хакта бәхәсләшеп тору артык, дигәнне ассызыклагандай, гадәтенчә, канатлы сүз белән йомгаклап куйды Сталин:

— Атның ялына ябышырга өлгермәгәч, койрыкка үрелүдән файда юк, шуны онытма!

Яңгырашы белән шактый уңышлы тоелган бу әйтемнең урынлы-урынсыз икәнлегән уйлап торыр ара калдырмады Сталин. Вакыттан — чабып барган аттан соңга каласың. Ленин — үтелгән дәвер инде, дип әйтергә теләде кебек ул.

— Икенчедән, — дип дәвам итте партия лидеры. — Советларның явыз дошманы Зәки Вәлиди белән элемтәдә торасың, диләр. Монысын ничек аңларга кирәк итәсез?!

— «Диючеләр»дән сорарга иде, иптәш Сталин.

Ике уйлап тормастан, өстәл тартмасын ачты партия лидеры һәм, битараф кына, Мирсәетнең каршысына хат ташлады.

— Укы. Үзең язган хатны уку бәхете бик еш эләкми ул кешегә.

Чынлап та, Сталинның өстәл тартмасыннан чыккан әлеге хат Мирсәет тарафыннан язылган иде. Моннан ун-унбиш көн чамасы гына элек Башкортстанның мәгариф эшләре буенча Халык комиссары Әдһәмовка язылган хат. Гаҗәп, ул ничек монда килеп эләккән?..

— Кеше хатын уку яхшы түгел, иптәш Сталин, — диюдән башка чарасы юк иде аның.

— Синең хатмы?

— Минеке... Ләкин ул хат сезгә адресланмаган. Һәм, гомумән, ул хатка ни булган? Аны кулга төшерү һәм уку сезгә нигә кирәк булды? Генсекның эше бетмәгәндер ләбаса!..

— Миңа түгел, революция һәм партия өчен кирәк, Солтангалиев иптәш... Зәки Вәлиди белән элемтәгә керергә ниятләдем диген, ә?!. Бу адымыңнан нәрсә исе килгәнлекне аңлыйсыңмы соң син? Зәки Вәлиди — басмачы, революция дошманы. Ә үзең Ленин саташуларын таратып йөрисең. Кая монда логика?!.

— Логика бар! Вәлиди — дошман булып тумаган. Табигате белән ул зыялы һәм көчле кеше. Башкортларның милли азатлык хәрәкәтендә авыр язмышка дучар булган, адашкан шәхес ул. Вәлидине дошман ясаган, тарих сукмагында адаштырган иптәшләр бар, сез боларны яхшы беләсез. Вәлидинең басмачылар арасында булуы — ул безнең хата...

Сталин гаҗәпләнүеннән сикереп торды. Әлеге кинаянең үзенә төбәлгәнлеген төшенде булса кирәк.

— Син нәрсә, Солтангалиев, хисап бирәсеңме авызың сөйләгәннәргә?

Мирсәет исә, киресенчә, тынычлана төшкәндәй булды.

— Белеп сөйлим, иптәш Сталин. Татар-Башкорт республикасы төзү чынбарлыкка ашып килгәндә махсус мәҗбүр иттеләр аны коралга тотынырга. Ике тугандаш халыкның бердәмлеге куркытты кайбер иптәшләр-

не. «Бүлгәлә һәм идарә ит» дигән фәлсәфәне безнең партия һәм Совет оешмалары патшаның үзеннән дә остарак файдалана белде. Зәки Вәлиди — татарларга булсын, Советларга булсын — дошман түгел иде. Хәтерлисез, ул Ленинга һәм сезгә ышанып үзе килде бераздан, партиягә кирәргә риза булды хәтта. Әмма аны алдадылар. Ышанмадыгыз сез аңарга, икенче сортлы кеше итеп карадыгыз. Ә ул үз бәясен белә торган кеше. «Монда олтан булып йөргәнче, тауларыма кайтып солтан булам мин соң чиктә», — диде, кул селтәде дә китеп барды. Аның ул адымын хупламасам да, аңладым мин. Гаепләмим шуңа. Дошман түгел ул миңа, шуңарга эзләргә, элемтә урнаштырырга һәм табарга дигән бурыч куйдым үзалдыма. Үз халкы язмышын уртаклашып яшәргә хаклы ул. Зәки Вәлиди кебек каршылыклы, җәрәхәттән телгәләнеп беткән шәхесләрне үз тарафыбызга кайтару — безнең җиңү булачак, иптәш Сталин. Бу шәрык халыкларының безгә булган ышанычын арттырачак, социализм идеяләренең офыгын киңәйтәчәк. Зәки Вәлиди белән элемтәгә чыгуым — Совет дәүләтенә зыян түгел, зур файда китерәсем килүдән иде...

Шул урында партия лидеры аны, зур ялганда тоткан сыман, бүлдерергә кирәк тапты:

— Социализм идеяләрен тарату өчен шифрлы язу кирәк булдымы?!

— Шифр түгел, ул хат саф татар телендә язылган, безнең үз графикабызда.

— Совет дәүләте җитәкчеләре, коммунистларның бер-береннән яшертен серләре бар икән — бу миңа аңлашылмый, Мирсәет. Минем берәүгә дә грузин графикасында хат язганым булмады, чөнки ГПУ органнарыннан яшерен эшем юк. Ә сиңа яшерергә кирәк булган!..

— Ялгышасыз... Сез мине урынсызга җәберлисез. Үз милләттәшләрем белән үз ана телемдә сөйләшү, хат алышу — минем шәхси эшем! Һәм, кабатлап әйтәм, Зәки Вәлидине мин, һичшиксез,табачакмын.

— Урынсызга, дисең. — Мәкерле елмаю чагылып узды Сталинның кысык күзләре читеннән. — Инде мине тыңла. Беренчедән, Үзәк Комитет һәм Политбюрода булган сөйләшүләрне дөньяга чәчкәнсең. Партиясез Бикбаувка, мәсәлән. Икенчедән, Совет дәүләтеннән яшерен төстә аның явыз дошманы, басмачылар хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе Зәки Вәлиди белән бәйләнешкә керергә ният иткәнсең. Бу адымың белән син, Советларда да эшләр яхшыдан түгел икән, үзара татулык юк, дигән нәтиҗә ясау өчен нигез биргәнсең. Дөнья капиталистлары шуны көтеп кенә тора... Өченчедән, — дип чираттагы бармагын бөкте Сталин һәм беркадәр көттерергә кирәк тапты, — Совет дәүләтеннән һәм Коминтерннан яшерен рәвештә чит ил агентлары белән элемтәгә чыккансың...

— Ялган!

— Ә Таҗи-Бахшы һәм Җәләл хакында ни диярсең?!

Елмаеп җибәрә Мирсәет. Елмаймый чарасы юк чөнки.

— Алар бит һәр икесе коммунистлар, иптәш Сталин. Таҗи-Бахшы Иран коммунисты, ә Җәләл Төркиядән. Бу иптәшләр белән инде берничә ел дәвамына элемтәдә торам мин.

— Коммунистлардыр, бәлки... Әмма төрекләр!

— Аңламадым, иптәш Сталин... Төреккә ни булган? Мин үзем дә төрки милләт вәкиле.

— Димәк, бу хәбәр дә дөрескә чыга? — дип гаҗәпләнә Сталин. — Бу җинаятеңне дә таныйсың буламы?!

— Сезгә беренче кат кына әйтүем түгел. Көнчыгыштагы миллиазатлык хәрәкәтенә минем үз карашым бар, иптәш Сталин. Ул хакта Ильичка да, Троцкийга да махсус аңлатканым бар. Кызганыч, берегез дә ул тәкъдимне чынга алмады. Ни генә булмасын, мин үз фикеремдә калам: социализмның җиңүе өчен безгә шәрык илләренә йөз белән борылу зарур. Шәрыкның зур өстенлекләре бар:беренчедән, халык массаларының колониаль изелүдән котылырга омтылышы өлгергән чак. Кытайда булсын, Һиндстанда булсын, Әфганстанда яисә Иранда бул-

сын,милли-азатлык хәрәкәте башлау өчен бөтен шартлар бар. Ә Төркиядә исә ул хәрәкәт инде җиңеп чыкты. Шул хәрәкәткә ярдәм кулы сузу гына кирәк. Япониядән гарәп илләренәчә, хәтта Төньяк Африкага кадәр шундый бәрәкәтле җирлек була торып, Көнчыгышка йөз белән борылырга тиешмибез. Имеш, ул тарафлар безнең өчен әһәмиятле түгел. Дөньяның кендеге — Көнбатыш Европа... Коминтерн, миңа калса, буш хыял белән яши. Империализмга аяк баскан илләрдә хакимият тотрыклы, аларда якын киләчәктә социализм идеяләре өстен чыгарына ышанмадым һәм ышанмыйм. Көнчыгышта исә, кабатлап әйтәм, колониаль изелүдән йончыган илләрдә, революцион шартлар өлгереп җиткән. Әлеге форсатны ычкындырсак, төзәтеп булмаслык хата ясарбыз. Шәрык илләрендә Көнбатыш Европа буржуазиясе үзенең тәэсирен ныгытканнан-ныгыта барачак. Безгә беръялгызыбыз торып калудан башка чара калмас. Ә социализмның нибарысы аерым бер илдә җиңеп чыгу ихтималы буш хыял гына. Иртәме-соңмы, безгә шул хакыйкатьне танырга туры киләчәк. Икенчедән, Көнчыгыштагы милли-азатлык хәрәкәтенә ярдәм кулы сузу Төркестан һәм Урта Азия халыкларының Россиягә булган шикләнүле карашын шундук юкка чыгарачак. Басмачылык хәрәкәте — шул ук милли-азатлык хәрәкәте ул. Аңарга дөрес мөнәсәбәт урнаштыру зарур. Төркестан халыкларының үзгәлекләрен, милли һәм дини мәнфәгатьләрен аңлап, кайгыртып карау җитми безгә. Таҗи-Бахшы һәм Җәләл иптәшләр белән элемтә уңаеннан әнә шуларны әйтергә кирәк саныйм, иптәш Сталин.

Партия лидеры күзләрен тагы да кысарак төшеп текәлде Мирсәеткә.

— Ә Кырым республикасының Наркомюсты Фирдәвес белән яшерен һәм серле хат алышуларыңны ничек аңлатырсың икән?

Мирсәет гаҗәпсенүдән хәтта башын чайкап куйды. Сталинның гаепләү акты тәмамланмаган икән бит әле.

— Сез мине хәйран калдырасыз, иптәш Сталин. Чираттагы соравыгыз хәләл хатыным белән урын өстендәге сөйләшүләремә кагылышлы түгелдер бит?!.

Канәгать елмаеп куя партия лидеры. Мәкерле,шөбһәле елмаю бу.

— Кирәксә, аларын да кулга төшерербез... ГПУ органнары барын да ишетеп, күреп торырга тиешле...

Менә хикмәт, Мирсәетнең ул хакта уйлаганы юк иде бит әлегәчә. Чынлап та, ГПУ органнары инде партия һәм дәүләт җитәкчеләре өстеннән күзәтү оештыруны да гадәти эш саный башлаганнар. Гаҗәп, әмма факт!.. Кәефе кырылганлыкны сиздермәскә тырышты ул, куелган сорауга җавап бирергә кирәк тапты.

— Фирдәвес белән минем арада үзара аңлашу һәм дустанә мөнәсәбәт яшәгәнлекне яхшы беләсез, иптәш Сталин. Хат алышуыбызда һичнинди яшерен ният һәм серлелек күрмим. Ә сезне шикләндергән беркадәр конспирация исә Сәетгалиев иптәшнең күзенә чалынмау максатыннан иде. Конспирация җитәрлек булмаган, димәк, Сәетгалиев иптәшнең борыны ис сизә. Монысы кызганыч, әлбәттә...

Сталинның кая да булса китәсе бар иде булса кирәк, стена сәгатенә күз төшереп алгач та җыенырга кереште ул.

— Менә нәрсә, Мирсәет, — диде партия лидеры, әңгәмәне йомгаклап. — Күрәм, ут белән шаярасың. Якын күреп әйтәм, саграк бул, саграк эш итәргә тырыш, теләсә кемгә ышанма. Бу очракта үзеңне ГПУдан саклап калырмын, әмма киләчәктә саграк эш йөртергә киңәш итәр идем.

— Рәхмәт, — диде Мирсәет. Һәм, сүз җае чыгудан файдаланып, сорарга кирәк тапты: — Иптәш Сталин, ГПУның большевиклар өстеннән күзәтчелек итүе кемгә кирәк булды икән?!. Дәүләт өстеннән идарә органы булып бара түгелме ул?!

Сталин бермәлгә хәрәкәтсез, тынсыз калып торды. Әмма озакка түгел.

— Бу дөньяда һәрнәрсә тикшерелергә тиеш, Мирсәет. Алла да бит, әнә, саклanганны гына саклармын, дигән. Мин дә шуны гына әйттем...

— Аңладым, иптәш Сталин, партиядән, Совет дәүләтеннән яшерен эшем юк, беләсез. Киңәшләрегезне истә тотарга тырышырмын.

— Тырыш! Тырыш...

Сталин беренче булып кулын сузды аңарга. Берни булмаган, мөнәсәбәтләрендә һичнәрсә үзгәрмәгән сыман кул бирештеләр. Партия лидеры, аерылышкан мәлләрендә үз иткән атлы булып, хәтта аның җилкәсенә кагылып куйды.

* * *

Ә чынлыкта, әле 1922 елның икенче яртысында ук, турыдан-туры Иосиф Сталин кушуы буенча, ГПУның көнчыгыш бүлегендә Мирсәет Солтангалиев өстеннән эш кузгатылган һәм күзәтү оештырылган була. Моның максаты — милли мәсьәләләрдә гаять әзерлекле һәм төрле милләт вәкилләре, хәтта чит илдәге азатлык хәрәкәтләре җитәкчеләре каршында олы хөрмәт казанган җәмәгать эшлеклесен юлдан алып ату. Үзен «милләтләр атасы» сыйфатында күрергә хыялланган Генераль секретарь өчен гаять әһәмиятле эш була бу. Әлеге соң дәрәҗә яшерен операцияне башкарып чыгу ГПУның Көнчыгыш бүлеген җитәкләүче Екаб Петерска йөкләтелә. Ә гомуми күзәтүчелек вазифаларын Яшертен оператив идарә начальнигы Василий Менжинский башкара. Нәтиҗәдә, ГПУның бөтен бер бүлеге, аңарга буйсынган бүлекчәләре, Казан һәм Уфадагы вәкилләре, дистәләгән яшерен агентлар җиң сызганып күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Мирсәет Солтангалиевкә яла ягу эшенә керешәләр.

Соң дәрәҗә яшерен бу операциягә «Икенче парламент» дигән исем бирелә. Бу исә әлеге эшнең дәүләт-күләм әһәмияте вә масштаблылыгын ассызыклап торган янә бер деталь!.. Ил төкерсә — күл була дигәндәй, шул тикле бүлек һәм бүлекчәләр, яшерен агентлар «эшкә керешкәч», мәгълүматлар җыелмый калмас. Тавык та бит, әнә, күп тырмана торгач, тирес өеменнән алтын бөртек таба. Инде шул чорның рухын һәм эш алымнарын чамалау өчен, «соң дәрәҗәдә яшерен» тамгасы куелган кайбер документларга сүз бирик.

*«Ип. Грабовскийга:*

*Агентура эше ачыгыз, барлык булган материалларны туплагыз һәм ип. Петерска җиткерү, аның эшләнмәсе буенча директивалар алу өчен аларны миңа бирегез.*

*ГПУның Көнчыгыш бүлеге 3 нче бүлекчәсе начальнигы Волленберг Г.»*

ГПУның Көнчыгыш бүлеге агентурасы мәгълүматларыннан (1922 ел, 21 декабрь.)

*«Соңгы арада Көнчыгыш хезмәт ияләренең Коммунистик университеты һәм аның ячейка бюросына каршы зур интрига бара... Шуларның берсе, ачыклавымча, милли характерда: бу — барлык эшләргә, хәтта университетның ректорына кадәр, шәрык кешеләрен билгеләргә омтылыш. Уйлавымча, бу эшнең җитәкчеләреннән берсе Наркомнац әгъзасы Солтангалиев...*

*Мин бу группа белән тыгыз элемтәгә кердем һәм киләчәктә ачыкларга өметләнәм.*

*ГПУ агентурасы уполномоченные Грабовский».*

*«22 елның 5 декабрендә ип. Тарпищев полпред Солтангалиев белән Татарстан республикасына, Казанга килделәр. Һәм шул ук көнне Татреспублика Советлары Съездының тантаналы төстә ачылуы булды. Татреспублика съездының Президиумы сайланганнан һәм котлау речьләреннән соң татар телендә татар буржуаз сыйныфы тормышыннан, саф милли характердагы пьеса куелды...*

*Яшерен хезмәткәрнең гомуми фикеренчә, Татреспублика бары тик милләтчелек нигезендә генә яши.*

*1923 ел, 23 гыйнвар мәгълүматларыннан».*

*«Башкортстан республикасына — Уфага хезмәткәр (шымчы — авт.) 22 елның 13 декабре кичендә килде. Шунлыктан кичке утырышта катнаша алмады. Солтангалиев һәм Тарпищевның килүе турында ишетеп, башкорт хезмәткәрләре — Кушаев, Халитов, Шаһимәрдәнов һәм башкалар бик начар кәеф белән, алар үзләре әйткәнчә, коткаручы һәм соңгы өметләре, яклаучылары булган ип. Солтангалиевкә баш иеп килделәр. Һәм съездда рус хезмәткәрләренең үзләрен тәмам бетереп ташлаулары һәм Башкортстанның рус милләтчеләре кулына күчүе турында сөйли башладылар.*

*...Гомумән, хәзер аяк асларында бераз ныклык тоеп, татар хезмәткәрләре башкортларга бик көчле йогынты ясыйлар... Имза».*

ГПУның Көнчыгыш бүлеге начальнигы ип. Петерска телеграммадан:

*«Башкорт группасының эше турында Уфадан сез биргән информация һаман да раслана бара. Аларның шифрлап җибәрелгән һәм без кулга төшергән хаты, бик озак, төн буе тырышып ачыклаганнан соң, бик әйбәт нәтиҗә бирде — шифр безнең тарафтан чишелде һәм хат укылды. Хаттан шул беленде: Уфадан сез алган мәгълүматлар һәм алар нигезендә Мәскәүдә күрелгән чаралар Солтангалиевкә мәгълүм булганнар. Ул болар турында үзенең читтәге фикердәшләренә җиткерергә ашыккан. Шундый ук искәртүләр Татреспубликага, Кырымга, Төркестанга һ. б. җибәрелгән булса кирәк. Сездән, мөмкин булса, безнең шымчыбызны озак тоткарламавыгызны сорыйбыз. Чөнки ул хәзер биредә бик кирәк. Алар бик уяу, эчке шымчыдан башка эшләве кыен. Яңа ялланганнар аларның югары, ягъни җитәкче оешмалары мохитенә үтеп керә алмыйлар әле...*

*ГПУның Башкорт бүлеге начальнигы Белогуров.*

*11 апрель, 1923 ел».*

*«Мәскәү. Мирсәет Солтангалиевның үз кулына» дип адресланган хаттан:*

*Синең хатларыңны алдым. Съездга ничек кенә булса да килергә (бигрәк тә мин) тырышачакбыз... Әгәр без булмасак, безнең исемнән Галий башкарыр. Галий аша Сталинга милли мәсьәләгә үз карашыбызны җибәрәбез. Әлеге карашның күчермәсен съезд президиумына, яки үз карашыгызча, бәрәр төрле секциягә тапшырыгыз... Сезнең эшкә файда теләп калам. Габдулла. Хатны ерт. 2 апрель, 1923 ел».*

1923 елның 29 мартындагы мәгълүматлардан:

*«28 мартта Солтангалиев белән сөйләшүдә иптәш Сталин болай диде: «Мин Сез Башкортстанга хат язгансыз дип ишеттем һәм Сезнең биредә дә Зәки Вәлидовныкы кебек оешмагыз бар икән, дөресме бу?»*

Бу ВЦИКның милли мәсьәлә буенча утырышы алдыннан иде. Утырыштан соң С. Г. ип. Сталин янына килде һәм: «Мин язмадым, моның алдан әзерләнгән яла булуы ихтимал», — диде. Сталин аңа: «Кара аны, сак бул», — диде».

1923 елның 27 апрелендәге мәгълүматлардан:

*«26 апрельдә кичке сәгать 9 да Солтангалиевтә Фирдәвес һәм башкалар булдылар. Ип. Фирдәвес — Кырымның юстиция халык комиссары, С. Г. тарафыннан ашыгыч эш буенча чакырылган. Ул, ип. Ленинның авыруы сәбәпле, хәзер хезмәткәрләр арасында ике лагерь барлыкка килде: берсе Троцкий лагере, икенчесе Каменев, Сталин һәм башкаларныкы. Соңгысы Троцкийны массалардан аерырга тырыша, димәк ки, хәзер шул мизгелдән файдаланырга һәм безнең эшне көчәйтергә кирәк, дип сөйләде».*

1923 елның 7 маенда билгесез агент хәбәреннән:

*«4 майда Г. белән сөйләшкәндә Солтангалиев үз группасының рәсми киңәшмәсе булганлыгын, чөнки барлык билгеләнгән һәм күздә тотылган иптәшләрнең килмәве, ә аларның бары бер өлеше генә, аларның да кайсы — соң, кайсы иртә килүе турында сөйләде. Ул әлеге иптәшләрнең кайберләре белән генә һәм берничә генә сөйләшү булганлыгы, аннан соң аны каядыр ашыгыч рәвештә чакыртулары турында әйтте... Солтангалиев Ленинның хатлары булуны раслый һәм көнчыгыш өлкәләр өчен милли мәсьәләнең уңай мәгънәдә хәл ителергә тиешлеген әйтә».*

Шул рәвешле, язмалар, әләк һәм ялалар белән калын-калын папкалар тутырыла. Мирсәет язган хат һәм кәгазь кисәкләре дә бар анда, аңарга юлланган хатлар яки хатларның күчермәләре. Кем белән кайда очрашкан, кемгә сәлам биргән, кемгә елмайган яисә күз кыскан — һәммәсе. Җаваплы партия һәм дәүләт эшлеклеләре белән очрашып сөйләшүләре дә игътибар үзәгендә була. Хәтта Сталинның үзе белән очраклы күрешеп, ике-өч авыз сүз алмашулары да теркәлә барган.

Менжинский даими рәвештә үзенең «табышлары» белән Сталинны таныштыра килә.

— Йә, ничек, әзерме инде сез? — дип сорый Генераль секретарь, түземсезләнеп.

— Кәгазьләр байтак җыелды инде, — ди Менжинский, ярарга тырышып.

— Кулга алу өчен нигез бармы? Җитәрлекме?..

Менжинский уйлана кала, икеләнә әле.

— Белмим шул, иптәш Сталин, — ди. — Мәгълүматлар күбен күп тә, әмма аларның чынлыгын раслау җиңел булмаячак.

— Ә үзең, үзең ышанасыңмы соң? — дип, әрсезләнә, түземсезләнүен дәвам итә Сталин.

— Әйтү кыен, иптәш Сталин. Урынсыз яла ягуга охшашлары, шикләләре байтак күренә.

— Эшләгез, — ди Сталин, канәгать түгеллеген ачык белдереп. Һәм, сүз бетте дигәнне аңлатып, Менжинскийга аркасы белән борыла.

Димәк, «Икенче парламент» үзенең эшен дәвам итәргә һәм бермәбер активлаштыра барырга мәҗбүр.

* * *

Ирзиннар гаиләсе Октябрь инкыйлабыннан соң шактый күп каршылыкларны кичереп көн күрергә, яшәү өчен, сакланып калу өчен байтак җегәр сарыф итәргә мәҗбүр була. Әмма иң җитди сынау вә авырлыклар да бу нәселнең үз традицияләрен юкка чыгара алмый. Әйтик, бабалары Садыйк Ирзинның туган көне — аның оныклары өчен иң зур бәйрәм. Югыйсә, үз вакытында Мәскәүне шаулаткан аты һәм гайрәте булган бу мәшһүр затның инде тупланган байлыкларыннан җилләр искән. Ирзиннар да инде ничек булдыра алса, шулай очын-очка ялгап баручылардан. Калса да, өлкән буын вәкилләре телендә мәртәбәле исеме һәм Мәскәүнең уртасында диярлек, аның хисабына корылган мәчет кенә хәтерләтеп тора үзен. Ә шулай да исеме — изге...

1923 елның февраль ахырында тамыры Мәскәүдән күп еракларга таралган зур гаилә, ана йортына кайткан умарта кортларыдай, янә бер түбә астына җыелды. Ике кызларын ияртеп, Мирсәет белән Фатыйма да килде анда. Гаилә вә нәсел тантаналарының күрке муллыкта, эчемлек һәм аш-су күплегендә түгел, ә бергәлектә, иминлектә. Әлеге очрашу Ирзиннарның иминлектә һәм бергәлектә узган соңгы бәйрәме булгандыр. Шул ягы белән аеруча истәлекле дә инде ул көн.

һәм тагы... Хәер, бусы инде гаилә тантанасына мөнәсәбәтле түгел. Ә Мирсәеткә һәм Фатыйманың бертуган абыйсы Алиның хәләл җефете Зәкиягә кагылышлы. Зәкия дә чыгышы белән Касыйм шәһәреннән.

Бәйрәм тәмамланып, инде кайтырга җыенган чакларында, киңәшәсе бик җитди сүзе булуын хәбәр итеп, Зәкия Мирсәетне бер читкә чакырып ала. Шәфкать туташы булып эшләгән зирәк акыллы бу килен бөтен гаиләдә зур хөрмәт казанып өлгергән иде инде.

— Мирсәет абый,— дип дәште ул аңарга, яшь якларыннан бер тирә булуларына да карамастан.— Сездән бүтән киңәшер кешем юк, зинһар, ярдәм итегез миңа.

— Тыңлыйм, Зәкия... Кулдан килгән кадәрле ярдәмгә әзермен.

— Әмма икебезнең арада гына калуын телим ул сернең. Алиның да башын катырасым килми.

— Йә, тыңлыйм...

Як-ягына каранып куйды Зәкия. Һәм пышылдауга күчте:

— Мәскәүдә яһүдиләргә каршы антисемит оешмасы төзелгән. Шул оешмага керүемне үтенеп миңа тәкъдим ясадылар...— Гаҗизләнеп Мирсәетнең күзләренә уттай янып торган карашын текәде ул.— Нишлим икән?..— Мирсәетнең чигәләре кычытып куйды кинәт, колагы ишеткәннәргә ышанырга да, ышанмаска да белми торды. «Җүнлегә түгел бу!» — дигән шик биләп алды күңелен... Ә Зәкия аңардан киңәш, җавап көтә.

— Үзең ничек уйлыйсың соң? — дип сораган атлы булды. Ә күзләре Зәкияне сынады.

— Белмим шул,— диде һәм колак очларына кызыллык йөгерде хатынның. Күзләрен, табигый тартыну белән, читкә алды.— Ни диярга белмичә килдем яныгызга...

— Менә нәрсә,— диде Солтангалиев, бер карарга килеп.— Нәтиҗә ясарга ашыкмыйк. Берәр көн уйларга бир, ярыймы... Мин, һичшиксез, җавап бирермен үзеңә.

Янә күзләрен күтәрде хатын. Чарасыз икеләнүдә иде алар.

— Ә иртәгесен үк җавап бирүемне сорасалар? Нәрсә диярмен икән? Һичкемгә әйтмәскә куштылар бит миңа...

— Уйлыйм, диген... Үзең беләсең, ашыгып җавап бирә торган тәкъдим түгел.— Бераз пауза ясап алды Мирсәет. Һәм кинәт сорап куйды.— Ә кем чыкты сиңа ул тәкъдим белән?

— Студент Агеев,— дип, шундук җавап кайтарды Зәкия, уйланып тормады.— Апамның каен энесе. Ни дип җавап бирим икән, зинһар, киңәш итегез, Мирсәет абый...

«Агеев» фамилиясен ишеткәч тә мәсьәлә беркадәр ачыклана төште. Әлеге студентның абыйсы, ягъни Зәкиянең җизнәсе булган Абдулла Агеевның ГПУда, аның Көнчыгыш бүлегендә хезмәттәшлек итүе мәгълүм иде Мирсәет өчен. Абдулла Агеев — Ирзиннар гаиләсендә еш була торган кешеләрнең берсе. Һәм үзенең кайда эшләвен Солтангалиевтән яшерми иде ул. Хәтта берничә мәртәбә үзен кисәткәне, кайбер киңәшләре белән ярдәм дә иткәне булды. Хәер, ГПУ органнарында Мирсәетнең «үз кешеләре» бер ул гына түгел. Аны, берни белми, һични сизенми, дип уйлаучылар тирәнтен ялгышалар иде.

Әмма Зәкия Ирзина аңардан җавап көтә. Моны ничек аңларга соң? Күңелдән генә берничә төрле ихтималны барлап өлгерде ул:

Беренчесе. Студент Агеевның тәкъдиме һәм Зәкиянең әйткәннәре дөрескә туры килүе ихтимал.

Икенчесе. Агеев, ГПУның кушуы буенча, Зәкиянең кылларын тарткалап карарга булганмы әллә...

Өченчесе. Минем яһүдиләргә мөнәсәбәтемне белү максатыннан кылынган чара булуы ихтимал.

— Минем киңәшем кирәк дисең инде,— дип, үзалдына фикер йөртүне дәвам итте Солтангалиев.

— Әйе. Сез ни кушсагыз, мин шуны эшләячәкмен.

Мирсәетнең Зәкиягә ышанмау, аңардан шикләнү өчен һичнинди нигезе юк иде.

— Менә нәрсә,— диде ул, ныклы карарга килеп.— Агеевлар белән әлегә берни дә сөйләшмә. Иртәгесен үк ГПУга үзең бар. Иптәш Волленберг белән үзеңне күзгә-күз очраштыруларын үтен. Һәм үзеңә шундый тәкъдим ясаган студент Агеев өстеннән, ничек булса — шулай итеп, ишеткәннәреңне язып бир.

— Ә Агеевлар? Аларга ни була?..

— Борчылма. Агеевларга берни булмас.

Гаҗәпләнүдән күзләре дәү булып ачылды Зәкия Ирзинаның. Ни көтсә дә, мондый тәкъдим көтмәгән иде Мирсәеттән. Байтак кына карышу һәм икеләнүләрдән соң, шулай да ул барын да Солтангалиев кушканча эшләргә булды.

Волленберг «җитди хәбәр» белән килүчене Көнчыгыш бүлегенең булдыклы хезмәткәрләреннән саналган Садовскийга тапшырды. Кат-кат сораштырды тегесе. Бу хакта кемнәр белән киңәшкәнлеген төпченде. Зәкия һәммәсен Мирсәет кушканча башкарып чыкты, үзенең ихласлыгына шик ташлар урын калдырмады.

— Дәүләт куркынычсызлыгы органнары сезгә күп рәхмәтле булыр,— диде Садовский, килүче яшь ханымга ихластан ышанып.— Без ул яшертен оешманы, һичшиксез, ачыкларбыз һәм юкка чыгарырбыз.

Ә соңыннан, инде Зәкия Ирзина китәргә җыенганда, аңарга ГПУ органнары белән даими элемтәдә торырга тәкъдим ясала. Мондый «эшнең» яшь хатынга һичбер кирәге булмый, әлбәттә. Әмма, бу юлы да Солтангаливнең алдан кисәтеп куюын искә төшереп, ул хәл кадәри ярдәм итәргә ризалык белдереп кайта.

Шул рәвешле, ГПУның Көнчыгыш бүлегендә Мирсәет Солтангалиевнең янә бер ышанычлы кешесе, хәбәр житкерүчесе арта. Ул органнарда һичнинди шик-шөбһәгә урын калдырмыйча байтак еллар, ягъни 1930 елның 28 июлендә кулга алынганга кадәр, «хезмәт итә».

Заман һәм вакыйгалар, үзенең баш очында берөзлексез бөтерелгән кара болытлар Мирсәет Солтангалиевне, әнә шул рәвешле, саклык чаралары хәстәрен күрергә дә мәҗбүр итә.

*Ахыры киләсе санда*

## ЖУРНАЛЫБЫЗНЫ КЕМНӘР ҖИТӘКЛӘГӘН?

Мәгълүм булганча, «Казан утлары» журналының элгәрләре «Безнең юл», «Атака», «Совет әдәбияты» исемнәре белән чыгып килгән. «Безнең юл» журналының беренче саны 1922 елның май аенда дөнья күргән. Беренче мөхәррире **Гасыйм Мансуров** булган һәм журнал шул исем белән 1930 елның июль аена кадәр яшәгән.

1925 елда «мөхәррир» сүзе «редактор» сүзенә алыштырылган һәм, ни өчендер, «Редакторы — коллегия» дип бирелеп барган. «Редакционный коллегия рәисе — **Галимҗан Ибраһимов»** дип күрсәтелгән. Димәк, Галимҗан Ибраһимов гамәлдә мөхәррирлек вазыйфасын башкарган, дип уйларга нигез бар.

Алга таба 1926 елның унынчы санынннан мөхәррирсез-нисез генә «Редколлегия» дип бирелә, ә 1927 елда шулай ук исем-фамилиялләрсез «Редактор» һәм «Редколлегия» дип куела килә. 1928 елдан исә «Редактор» һәм «Редколлегия» сүзләре янына Гомәр Гали, Шәриф Камал, Г. Толымбайский, Галимҗан Сәгъди исем-фамилияләре теркәлгән.

1929 ел өчен Татарстан китап палатасында журналга кагылышлы белешмәләр табылмады.

1930 елда янә «Редактор — редколлегия»дигән сүзләрне генә укыйбыз.

Сигез ел дәвамында чыгып килгән «Безнең юл» журналы 1930 елның июль аеннан исемен алыштыра һәм ул «Атака» исеме белән яңарып китә. «Атака» журналының беренче мөхәррире **Гомәр Гали** була. Шул ук 1930 елның 8—9 нчы саннарында без «Редколлегия: Кави Нәҗми, Г. Толымбайский, Ибрай Гази, С. Каратай» дигән сүзләрне укыйбыз. Мөхәррире аерып күрсәтелмәгән. Бу хәл 1931 елның 5—6 нчы санына кадәр күзәтелә. Аннары ел азагына чаклы җаваплы мөхәррир **Кави Нәҗми** була.

1932 елда «Атака» журналының һәр унике санында җаваплы мөхәррир булып **Закир Гали** тора. Редколлегия составында Закир Гали, Кави Нәҗми, Ибрай Гази, Мөхәммәт Садрилар була.

«Атака»ның гомере кыска булып чыга — ул нибары ике ел ярым гына яшәп кала. 1933 елдан башлап журнал «Совет әдәбияты» исеме белән йөртелә башлый. Ике ел дәвамында җаваплы мөхәррире — Кави Нәҗми. Аннан соңгы ике ел — 1935—1936 елларда журналга янә Гомәр Гали җаваплы мөхәррирлек итә.

Ниһаять, 1937 ел... Ил-халык өчен дә, журнал өчен дә иң авыр, иң кара чор башлана: Сталин һәм иярченнәре котырынганнан котырына, алар корбан арты корбан сорыйлар.

«Совет әдәбияты» журналының 1937 елгы икенче саны мөхәррирсез — «Редколлегия» тарафыннан гына чыгарыла. Аннары өченче санда — вакытлы җаваплы редактор **Г. Разин (Гомәр Бәширов),** дүртенче-бишенче саннарда — җаваплы редактор **Газиз Иделле,** алтынчы-унберенче саннарда — вакытлы җаваплы редактор янә Г. Разин, уникенче санда вакытлы җаваплы редактор **Рахман Ильяс** була.

Шушы бер ел эчендәге «вакытлылар» аша да журналның нинди тетрәнүләр кичергәнен аңларга мөмкин.

«Совет әдәбияты»ның 1938 елгы беренче дүрт саны янә вакытлы җаваплы редактор Г. Разин җитәкчелегендә чыга. Шул елның бишенче санынннан башлап журналга җаваплы редактор итеп **Т. Имаметдинов** билгеләнә.

Т. Имаметдинов журналда 1938 елның бишенче санынннан алып 1941 елның җиденче санына кадәр җаваплы мөхәррир булып тора.

Бөек Ватан сугышы елларында күп кенә газета-журналлар ябылып бетсә дә, «Совет әдәбияты» журналы сакланып кала. 1941 елның июленнән 1942 елның августына кадәр аңа, алышына-алышына, өч язучы мөхәррирлек итә: Г. Разин, Г. Кашшаф, И. Гази.

1942 елның августыннан 1945 елның гыйнварына кадәр журналны **Гази Кашшаф** җитәкли. Ә инде 1945 елны, Бөек Җиңү көне килгәч, «Совет әдәбияты»ның алтынчы саныннан башлап җаваплы мөхәррирлек эше Газиз Иделлегә тапшырыла. Газиз Иделле бу вазыйфаны 1947 елның ноябренә кадәр башкара. Ә 1947 елның унберенче саныннан алып 1949 елның бишенче санына кадәр журналның җаваплы мөхәррире янә Кави Нәҗми була.

1949—1950 елларда — май аеннан май аена хәтле — вакытлы җаваплы мөхәррирлекне **Афзал Шамов** башкара.

Аннары журналга яңадан Гази Кашшаф килә. Һәм ул 1950 елның май саныннан башлап 1958 ел тәгәлләнгәнче — сигез ел ярымнан артык җаваплы мөхәррир булып эшли. Гази Кашшаф озак эшләгән мөхәррирләрнең берсе.

Шуннан соңгы дүрт ел дәвамында (1959—1963) җаваплы мөхәррир **Абдулла Гомәр** була. Аннары ел ярым — 1964—1965 елның алтынчы санына кадәр җаваплы мөхәррирлекне **Газиз Мөхәммәтшин** алып бара. Газиз Мөхәммәтшинның мөхәррирлеге «Совет әдәбияты» журналының соңгы чорына туры килә.

1965 елның июнь саныннан журнал яңа исем ала — ул «Казан утлары» исеме белән чыга башлый һәм бүгенге көнгә кадәр шул исемне саклап килә.

«Казан утлары»ның 1965 елгы алтынчы санына җаваплы мөхәррир буларак **Сибгат Хәким** кул куя, җиденче санына исә, «җаваплы редактор өчен» дип, журналның ул вакыттагы җаваплы сәркатибе Әхсән Баян имза сала.

1965 елның август саныннан журналның җаваплы мөхәррире итеп **Рафаэль Мостафин** раслана. Ул мөхәррирлек вазыйфасын 1969 елга кадәр алып бара.

1969—1971 елларда мөхәррир «Баш редактор» дип йөртелә башлый. Һәм бу вазыйфаны **Зөки Нури** үтәп килә.

1972—1974 елларда журналыбызның баш мөхәррире — **Гариф Ахунов.**

1975—1983 еллар — баш мөхәррир янә **Зөки Нури.**

1983—1989 еллар — баш мөхәррир **Ренат Харис.**

1989 елдан алып бүгенге көнгә кадәр «Казан утлары» журналы **Равил Фәйзуллин** баш мөхәррирлегендә дөнья күреп килә.

Бу мәгълүматларны редакциягә Татарстан Республикасы китап палатасының архив бүлеге мөдире **Раушания САФИНА** тапшырды.

# Ләбиб Лерон

## Багышлаулар бәйләме

### Гөлшат Зәйнашевага

Җырга сусаган халыкны
Җырлы иттең гелән-гел...
Халык сине хөрмәтләде —
Бирде Тукай бүләген!

### Батуллага

Кайда гына күз төшермә,
Күз салма кайда гына:
Әдәби мәйданга яки
Азатлык мәйданына,
Сәхнәләргә, газитләргә...
Һәркайда да ул булыр —
Кемгә — Роберт, безгә — Рабит
Батулла Мөхлис улы!

### Айдар Хәлимгә

Бораулодың, шигырь яздың —
Шагыйрь исме яуладың...
Казаннарда кайнадың да
Уфаларда шауладың;
Мәйданнарда, мөнбәрләрдә
Ирек-хөрлек дауладың...
Тез астыңа суксалар да,
Син барыбер аумадың!

## Әбрар Кәримуллинга

Мөхтәрәм китапчы галим,
Академик, доктор ул...
Чал тарихта бүтән мондый
Рыцарь Әбрар юктыр ул!

## Марсель Галигә

Роман язарга уйлады —
Башлады да ташлады.
«Төчкерек мәзәкләр» язып,
Күпме кәгазь «ашады»...
Юкка чыккан партиянең
Тетмәсен тетте, тетә...
Халык синнән, Марсель туган,
Яңа «Капитал» көтә!

## Гәрәй Рәхимгә

Шагыйрь ул, язучы, лауреат...
Исем бар, дәрәҗә бар, әйе.
Титулы гына да ни тора:
Советлар Союзы Гәрәе!

## Рәшит Әхмәтҗанга

Үз халкына авыр булган чакта
Читтә калмас — кемнең җаны бар:
Халкы өчен мәйданнарга чыгып.
Көрәшерлек Әхмәтҗанов бар.
Кирәк икән — эш-гамәле белән
Сүзен әйтә: «Әйдә, көрәшик!»
Азатлыкны язып кына түгел,
Ач торып та даулый ул Рәшит.

## Тәүфикъ Әйдигә

Язмыш өзгәләп ташлаган
Җепләрне табып бәйли:
Учлап сибелгән татарны
Бөртекләп җыя Әйди.

## Мансур Вәлигә

Шигырьнең ул барлыгын да,
Юклыгын да күргәли...
Шәхесләрне теткәли ул,
Әсәргә дә кергәли...
Кайчак язучы халкында
Шундый сүзләр йөргәли:
— Усал иде яшь чагында!
Олгайды Мансур Вәли!

## Рәдиф Гаташка

Кем Тукайны үз итәдер,
Кем укыйдыр Тактащны...
Сөюстан гашыйклары
Яратадыр Гаташны.
Мәхәббәткә мәрхәмәтле
Алар — изге ниятле:
— Мәҗнүн бүләгенә лаек
Гаташ шигърияте!

# ГАСЫР БАШЫ ШИГЪРИЯТЕННӘН

## Сәетгәрәй Еникеев

(1889 — 1914)

**Уфа шәһәрендә туа. Реальное училищеда укыганда ук үпкә авыруы белән авырый башлый һәм шуннан савыга алмыйча, бик яшьли үлеп китә. Ул өч кенә шигырен бастырып өлгергән (кульязма хәлендә калганнарының язмышлары билгесез).**

### Болгар кызы

Күрәм мин: зифа буй һәм пәрдә үтәли
Җем-җем кара бөдрәле сачләрен,
Фәрештә сынлы йөрүләрен һәм атлавын...
Бүтән юк, кайвакыт ишетәм сүзләрен:
Онытып дөньяны,
Тыңлыйм мин аны,
Әллә бер көмеш агачының яфрагы
Җилпердиме диеп
Уйлыймын, жаный.

Күтәрде ул кинәт каплаган пәрдәсен,
Таш һәйкәл мин булдым һәм каттым урнымда,
Болыт тик сачләрен һәм ай тик шәүләсен,
Таң нурын күрдем мин анда.
— Сөй мине, табыныйм сиңа, гашыйк,— дидем мин.
— Шәригать,— диде ул һәм япты йөзләрен...
Мин калдым... багынып, тәкърар кыйлдым
Шәригать!... дигән сүзләрен...

*«Аң», 1913 ел, 21 сан*

### Үткән гомер — искән җил...

*(Үткән минутлар тәэсире)*

Исеңдәме, җанкай... диңгез... текә ярлары —
Безнең актык исәнләшү... дулкыннарның шаулавы...
Хәтереңдәме... синең суырып гыйшык агуын эчкәнең...
— Эчкел, җаный, син дә...— диеп бәңа һәм дә әйткәнең...
Оныттыңмы дулкыннарның безнең зарга кушылып —
Акканнарын төрле якка диңгез буйлап ишелеп...

Исендәме... без киткәндә Чулпан сүнеп, таң атты,
Һәм дә гүзәл былбыл сайрап безне моңлап озатты!
Исендәме, җилләр орып... туздырды сачләреңне...
Хәтереңдәме... суырып үбеп сөрттем бән яшьләреңне...
Исендәме, актык күрешү... минем яшьле күзләрем...
Оныттыңмы... егълап-егълап бәңа әйткән сүзләрең...
Шул сүзләрне искә төшереп... икәү торган урында
Торам инде мин ялгызым... диңгезнең шул ярында...
Һаман шулай диңгез шаулый... дулкыннар ярга бәрелә —
Диңгез өсте... диңгез буе... һаман күренә...
Кызара офык... калтырый диңгез... яктыра башлый... таң җитә;
Шулай һаман былбыл сайрый... таңны тәбрик итә...
Шулай һаман элгәргечә... һичнәрсә кузгалмаган —
Кузгалмаган, шулай тора — киткән үтеп тик заман.

*«Аң», 1913 ел, 24 сан*

## Тәфтиләү

*(Җәйге тәэсирләрдән)*

Сайра... сайра... әй сандугач... сайра... җуат, күңлем ач!
Сайра... яңгырат... ачылсын гөлләр, чәчәк ярсын алмагач!

Тәрәзәмне киң ачам да... тыңлыйм матур сайравың,
Моңлы таушың әйтә миңа дөньяда ни калганын...

Сайра... сайра... әй сандугач, ерак таулар артында,
Сайра шунда күрнеп торган җаныем йорты каршында.

Белсен җаныем җир йөзендә яз яшәреп җиткәнен,
Белсен: сагынып көтәм аның тау башына килгәнен!

Сайра... сайра... әй сандугач... сайра... җуат, күңлем ач...
Сайра... яңгырат... ачылсын гөлләр, чәчәк ярсын алмагач!

*«Аң»,1914 ел, 1 сан*

# Фәрит Ибраһимов

(1893 — 1943)

**Чыгышы белән республикабызның Балык Бистәсе районы Түбән Ырга авылыннан. «Уйларым» һәм «Өмидемнең нурлары» исемле китаплары (Казан, 1912) белән шагыйрь булып танылa. Аерым шигырьләре «Аң», «Сөембикә», «Себер» кебек газета-журналларда басыла, берничә поэмасы да бар...**

**Ф. Ибраһимов Октябрь революциясен икеләнүсез кабул итә. 1919 елда партия сафларына керә. 20 еллардан башлап Ташкент, Сәмәрканд якларында яшәгән, югары уку йортларында укыткан.**

## Уй

Кайда китте (соң бу) уй?
Язалмыйм мин берни дә —
Керсә дә, юл табалмыйм,
Фикер-уйлар керми дә.

Языйм дисәм, качадыр
Күңелдәге хәзинә.
Торса — разый буламын
Хәзинәмнең әзенә.

Барыбер булмам вәли*,
Бер жай торсам — яратам;
Ләкин ул да булмыйдыр,
Ни илә кайгы таратам?

Тукта, булмас микән дип,
Карыйм әле тырышып;
Тик утыру ярамый
Бер урында бөрешеп.

Башка нәрсә кирәкми,
Халкым какмый караса,
Сызган кара буявым
Татарыма яраса.

Бар өмидем шул гына:
Әй, ходаем! Бирсәнә!
Качма, фикерем! Син дә кил,
Уем, зинһар, килсәнә!

Белеп тор, уй-фикерем,
Әрәм булмый килгәнең;
Яхшы жиргә таратып,
Начар жиргә бирмәмен.

Кадеренне бик белеп,
Бер дә каршы сүз әйтмәм,
Кирәкмәсләрне язып
Юкка сүзне күбәйтмәм.

Сүзем ялган булмыйдыр,
Ышан, фикрем, ант итәм!
Жавабың әйт, килмәсәң!
Мин дә килмәскә китәм.

Киләм дисәң әгәр дә,
Көтәм, фикрем, белеп тор!
Ушбу көннән капкама
Ялындырмый килеп кер!

## Шагыйрь тормышы

Ходай бирсә шагыйрьгә бер йөрер юл,
Табып алса язар бернәрсәне кул,

Теләвенчә чыга калса шигырь дә,—
Гаме калмый шагыйрьнең бер дә, бер дә.

Була барча галәмнең бәхтияры*,
Гүя кергән куенга яхшы яры.

Шулай ук һәм аңар хәсрәт тә жинел,
Уңай юллар белән бик тиз дә килер.

Әгәр тапмый гажиз булса язарга,
Колакка һични кермәсә базарда,

Яки тапкач язалмый булса гажиз,
Сугып китсә башыннан уйны фалиж,—

Була аңгар бөтен дөнья жәһәннәм,
Бизә күңел авыл, сәхра, шәһәрдән.

Торырга һич теләми бер минут та,
Бу дөньяда янадыр тереләй утта.

## Бар иде...

Бар иде дусларымнан файда көткән
Заманнар да — хәзер дә инде беткән.

Суынган гөл күңел «Дустмын!» дигәннән,
Минем башны кулы берлән игәннән.

---

Вәли — изге.
Бәхтияр — бәхетлесе.
Фалиж — паралич.

Әгәр килсә берәү «Дустмын!» дип әйтеп,
Миңа ялган планнарны киңәйтеп,—

Нидер, белмим, яныма шул вакытта
Килә дә «Син ышанма!» дип бирә әйтеп.

# Гыйззетдин Исәнбирдин

(1888 — 1968)

**Башкортстан әдәбиятчылары хәбәренә караганда, бу шагыйрь шул республиканың Чакмагыш районы Аблай авылында туып үскән. 1910 елда атаклы «Галия» мәдрәсәсен тәмамлагач, авыл мөгаллиме булып китә һәм гомеренең кырык елын мәгариф эшенә багышлый. Аның шигырьләре «Шура» журналы битләрендә еш күренгән. 1914 елда Уфада «Гыйззетдин Исәнбирдин шигырьләре» исемле җыентыгы басылып чыга. Шигъри тәрҗемәләре, мәкаләләре дә бар. Совет чорында әсәрләре басылмаган.**

## Кыйтга

Юк сүз ул: бәхте фәләннең ким, фәләнгә тиң түгел;
Юк, адәм аслында тиң, хөрмәт тә артык — ким түгел.

Тик хәятта күп низам рәтсез, тупаслыктан наши*
Бер бичараның көчен, бәхтен икенчеләр ашый.

*«Шура», 1916 ел, 16 сан*

## Үтте

Инде үтте бу гомернең иң җиңел һәм тын ягы,
Таш төяп тарткан кебек мөшкел монның калган ягы.

Күп заманнар үтте, мин күп төрле уйлар уйладым,
Күп өмид, тәмле өмидләр кичте миннән — калмады.

Инде ул да тик сабый чакта күрелгән төш кенә,
Онытып беткәнмен аларны: бик ерак һәм бик ары.

Калмады ялкын, йөрәк салкын хәзер боздан да ул;
Өрдерә, чиркәндерә: анда — буран, ямьсез давыл.

Чәч агарды, калды ул бик сип-сирәк һәм кардай ак,
Иске яшь, тойгыр көенчә җан гына тик калды чак.

*«Шура», 1913 ел, 16 сан*

## Игътираф

Ничә рәт тәүбәгә чүкмәдем мин,
Ничә рәт янмадым, яшь түкмәдем мин?

---

Наши — аркасында.
Игътираф — гаебеңне тану.

Явыз нәфсем, буйсынмам дип тагын бер
Ходая кем, ничә гаһед* итмәдем мин?!

Ләкин аздым, һаман яздым юлымнан,
Гөнаһлар эшләдем, нан* көтмәдем мин.

Өелгән тау да тау гайбем; исән-сау
Кеше гайбен һаман җентекләдем мин.

## Галәм вә мәшәкать

Киң галәмгә кил фәкать эшләр өчен җиң сызганып;
Буш-бушына башкалар икмәк ашатмас тоз манып.

Бик дөрест, бик зур үзеңчә үз башыңның кыйммәте;
Башкаларча: нуль торасың, күз дә салмый кызганып.

Чолгап алсын дүрт ягың эш һәм мәшәкать чаткысы;
Чытма йөз һәр дәмдә, бул эшлекле ир һәм шат кеше.

Үз-үзеннән шул вакыт исбатланыр инсанлыгың,
Бу мәшәкать чүлмәген ирләрчә тотыра алганлыгың.

*1914 елгы җыентыгыннан*

## Кәефең кыру

Дошманыңның көлүеннән кырма кәйфең, әй даһи!
Хәзрәти Әхмәтнең* өстеннән дә көлгән дошманы.

Илтифат итмә кара эчләргә — көлсен көлгәне;
Йөз дә чытма, өлешенә киң юлны бир, кансын дәни*.

Тик туганлыкка, мәхәббәткә тулы бул һәр заман,
Эш һәм хиссият беләндер инсанның инсанлыгы.

*1914 елгы җыентыгыннан*

## Кыйтга

Яхшымы алтын кию, кардәш сөю, меңнәр җыю,
Зәррә чаклы булмаса күңлеңдә инсанлык сөю?

## Авыл

Менә бак бу фәкыйрь, ярлы авылны:
Ялангачлык вә юклык монда нинди!

---

Ходая кем...— ходайга ничек...
Гаһед — ант.
Нац — оят, хурлык
Хәзрәти Әхмәт — Мөхәммәт пәйгамбәр турында сүз бара.
Дәни — түбән, начар (кеше).

Ничек монда табигать тә аларча:
Бөтенләй искечә, аулак, яланча.

Ята тып-тын, ята җансыз, хәятсез,
Кабынмый һәм сугармый, эшләминчә.

Табигатьне җигәргә, тарттырырга,
Тереклектә уңай якны алырга

Онытканнар, болар йоклый, болар тын,
Егылганнар тирән базга, кабергә.

Боларда якты көн юк, гел томанлы,
Аяк, кул, баш, муен — барсы богаулы.

*1914 елгы җыентыгыннан*

## Мин теләрмен

Нәрсә язмыш язмагандыр, нәрсәләр язмас, дисең,
Нәрсә килмәс, нәрсә китмәс; нәрсәләр булмас, дисең?

Бу озын тормыш юлы — михнәтле юл бу, мин ышанам,
Әлегә тикле түзгәнем төсле үк түзәрмен мин һаман.

Алда булган идеалым чиксез чуалчык булса да,
Күзләрем сукырайса да, саргайса да йөз, сулса да,

Гел бәхетсезлек камап, һәр як кырын күз салса да,
Иң күңел тарткан теләк тә булмаса, буш калса да, —

Мин ялыкмам, мин һаман бик күп теләрмен искечә,
Юк! — димәм, тәкъдир житеп тормыш юлымны кисмичә.

*1914 елгы җыентыгыннан*

Сәхифәне **Зөфәр РӘМИ** әзерләде.

# ТӘНЗЫЙМАТ ҺӘМ ИДЕЛ-УРАЛ ТАТАРЛАРЫ АРАСЫНДА МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ХӘРӘКӘТЕ

Бу мәкаләдә ике иҗтимагый хәрәкәткә — тәнзыйматка һәм Идел-Урал татарлары арасында барлыкка килгән мәгърифәтчелек хәрәкәтенә типологик характеристика бирү максат итеп куела. Минем аңлавымча, тәнзыймат — реформаторлык хәрәкәте буларак барлыкка килә һәм Төркиядә хакимлек иткән социаль-икътисади мөнәсәбәтләр һәм сәяси тәртипләрне үзгәртеп коруны күз алдында тота. Бу үзгәрешләргә 1839 елда Мостафа Рәшид паша тарафыннан игълан ителгән һәм тарихка Гөлхан «хатти шәрифе» исеме белән кергән белдермә белән юл салына. Бу белдермә нигезендә социаль һәм икътисади тормышка, шулай ук дәүләт сәясәтенә кагылышлы законнар чыгарыла. Дөрес, тәнзыймат дәвере озакка сузылмый, ил эчендәге мөнәсәбәтләр үсеше һәм халыкара вакыйгалар башланган процессны туктатуга китерә. Әмма тәнзыймат чорында үткәрелгән реформалар илдә яңа көчләр үсүенә мөмкинлек тудыра. Шушы көчләр арасыннан Намык Кәмал, Ибраһим Шонаси, Алия Суави, Зия паша кебек алдынгы фикер ияләре үсеп чыга. Болар исә 60 еллар уртасында «Яңа госманлылар» дигән җәмгыятькә нигез салалар, тәнзыймат дәверендә туган идеяләрне алга сөрәләр һәм үстерәләр. Шуңа күрә типологик чагыштыруларда мин, тәнзыймат дәвере калдырган мәгълүматлар белән беррәттән, «Яңа госманлылар» күтәреп чыккан фикерләргә дә таянам.

Идел-Урал татарлары арасында исә мәгърифәтчелек идеяләрен башта Г. Курсави (1776—1812), Г. Утыз-Имәни (1754—1834), И. Хәлфин (1778—1829) кебек культура эшлеклеләре күтәреп чыгалар. (Г. Курсави хаҗ сәфәре вакытында авырып китә һәм Истанбулда вафат була. Аның кабере Өскедарда булырга тиеш). Ләкин XVIII гасыр азагында һәм XIX гасыр башында мәгърифәтчелек идеяләренең киң таралуына социаль-икътисади, сәяси һәм мәдәни-идеологик шартлар тиешле дәрәҗәдә өлгереп җитмәгән була һәм шунлыктан алар халык арасында киң яңгыраш таба алмыйлар. XIX гасырның икенче яртысында татарлар арасында мәгърифәтчелек фикере яңа үсеш ала һәм шушы чорда киң таралыш таба. Әйтелгән елларда татар мәгърифәтчелегенең Ш. Мәрҗани (1818—1889), Х. Фәйзханов (1828—1866) һәм К. Насыйри (1825—1902) кебек күренекле вәкилләренең эшчәнлеге җәелә (Ш. Мәрҗани хаҗдан кайтышлый Истанбулда туктала. Төркиянең ул вакыттагы тышкы эшләр назыйре Гасим паша, күренекле дәүләт эшлеклесе Мөнир паша, башка дәүләт эшлеклеләре һәм укымышлылары белән очраша, шәһәрнең мәшһүр урыннары белән таныша. Илгә кайткач, тәэсирләрен «Рихләт әл-Мәрҗани» исемле хезмәтендә искә ала). Шушы чорда ук мәгърифәтчелек әдәбияты да барлыкка килә һәм Г. Ильяси (1856—1895), М. Акмулла (1831—1895), Ф. Халиди (1850—1923), З. Бигиев (1870—1902) һәм М. Акъегетзадә (1864—1923) йөзендә без аның күренекле вәкилләрен күрәбез. (М. Акъегетзадә 1888 елда Төркиягә китә, анда «Мөлкия» исемендәге югары уку йортын тәмамлый, соңыннан шунда ук рус теле укыта, ә 1914 елда Казаннан алдырылган профессор Катанов фондын эшкәртү өчен Истанбул китапханәсенә чакырыла).

XIX гасырның 80-еллары азагында мәгърифәтчелек хәрәкәтенең җәдитчелек дип аталган яңа баскычы башлана. Татар мәгърифәтчелек хәрәкәте үсешендәге бу этапның иң күренекле вәкилләре рәвешендә Риза Фәхретдин (1868—1936), Фатих Кәрими (1870—1937), Шәмсетдин Күлтәси (1855—1930) исемнәрен китерергә мөмкин.

Төркиядә тәнзыймат һәм «Яңа госманлылар» хәрәкәте дә, Идел-Урал татарлары арасында җәелгән хәрәкәт тә типологик яктан мәгърифәтчелек характерында иделәр, үзләренең феодаль тәртипләргә каршы булулары белән аерылып тордылар. Прогрессив иҗтимагый хәрәкәт вәкилләре буларак, аларны рухландыручы көчләр, заман ихтыяҗларыннан артка калган иске идеологик корылмаларга яңа, вакыты өчен алдынгы идеологияне каршы куйдылар һәм урта гасырлардан килгән деспотик тәртипләргә һәм төрле золымга кискен каршы чыктылар, гакыл хөрлеге һәм гаделлек байрагы күтәрделәр, тирән иҗтимагый үзгәрешләр таләп иттеләр.

Тәнзыйматны, «Яңа госманлылар»ны һәм татарлар арасында җәелгән хәрәкәтне мәгърифәтчелек тибындагы хәрәкәтләр дип бәяләгәндә түбәндәгеләр игътибарга лаек:

1. Социаль табигатьләре. Әйтелгән хәрәкәтләр үзләренең социаль табигатьләре ягыннан феодализмга каршы юнәлештә һәм буржуаз характерда иделәр. Аларның барлыкка килүләренең нигезендә Төркиянең һәм Идел буе татарларының капиталистик үсеш юлына тартылулары ятты һәм аларны рухландыручы көч буларак милли буржуазия чыкты. Тәнзыймат реформаларының буржуаз характерда булуларын кешеләргә тормыш иминлеге, аларның милке һәм намусының кагылгысызлыгы, салымнарны тәртипкә салуны вәгъдә иткән Гөлхан «хатти шәрифе» үк күрсәтеп тора иде. Татар мәгърифәтчеләренең иҗаты һәм эшчәнлеге дә феодал-уртагасырчылык мөнәсәбәтләрен ерып чыгу һәм буржуаз прогрессны яклау идеясе белән сугарылган иде. «Бу хәрәкәтнең нигезендә,— дип язды татарның күренекле язучысы һәм галиме Г. Ибраһимов,— урта гасыр шәрык артталыгы әсирлегеннән яңа дәвернең яктысына чыгарга, иҗтимагый, фикри, мәдәни торгынлыкны бетереп тәрәккыять юлына аяк басарга омтылу ята иде» (Каюм Насыйри, Казан, 1922, VI б.).

2. Кеше, аның ирке һәм хокукый тигезлеге мәсьәләсе. Тәнзыйматның мәгърифәтчелек тибындагы хәрәкәт булуын кеше проблемасының куелышы ачык күрсәтеп тора һәм бу Гөлхан «хатти шәрифе»ндә дә үзенең чагылышын тапты. Әйтелгән хәрәкәтнең бу мөһим белдермәсендә солтан тарафыннан вәгъдә ителгән гражданлык хокуклары һәм кануннар алдында һәркемнең тигез булуы игълан ителә. Гөлхан белдермәсендә күтәрелгән идеяләр соңыннан «Яңа госманлылар»ның әсәрләрендә алга үстерелә. Төрек мәдәниятенең бу эшлеклеләре шәхес һәм аның ирегә мәсьәләсен мәгърифәтчеләргә хас булган «кешенең табигый асылы» идеясе яссылыгыннан чыгып карыйлар. Кешенең шушы табигый асылы нигезендә, алар фикеренчә, шәхеснең табигый хокуклары туа; шәхси ирек, милекнең кагылгысызлыгы һәм гаделлек шушы хокукларның аерылгысыз өлеше булып тора. Үзенең «Цивилизация» дигән мәкаләсендә күренекле төрек мәгърифәтчесе Намык Кәмал: «Кешенең хокукы һәм максаты болай гадәти яшәү генә түгел, бәлки ирektә яшәү»,— дип язды. Илдәге икътисади торгынлыкның сәбәпләрен ул турыдантуры кешеләрнең ирекtән мәхрүм булуларында һәм тигезсезлекләрендә күрде (Кара: «Просветительство в литературах Востока». М., «Наука», 1973, б. 13).

Шәхес, аның ирегә һәм кешеләрнең бер-берсенә хокукый яктан тигезлеге мәсьәләсе татар мәгърифәтчелек фикерендә дә үзәк урынны алып тора. Бу идеяләр инде бер төркем буржуазлашкан ясаклы татарларның Екатерина II тарафыннан оештырылган законнар хәзерләү комиссиясенә җибәрелгән хатларында да үзләренең чагылышларын тапканнар (XVIII гасырның 70 еллары). «Һәр кеше,— дип яздылар бу хатның авторлары,— үзенең табигате белән нәрсәгә дә булса сәләтле булып туа; төрле катлаулардан чыккан кешеләрнең игенчелек хезмәтенә күнегүләре дә, үзләрен коммерция эшенә багышлаулары да мөмкин. Кеше үзенең рухына тынычлыкны бары тумыштан бирелгән ирегә сакланганда гына таба һәм ул иминлеген һичнинди көчләүсез, үз ихтыяры белән тәэмин итәргә хаклы. Рус дәүләтеннән читтә эш итәргә теләгән һәр кеше, әгәр үзенең кире әйләнеп кайтачагына ышанычлы дәлилләр китерсә, император җәнабларының башка бәндәләре кебек үк, һичнинди тоткарлыксыз паспорт белән җибәрелсен: коммерциядә беркем дә үзенең кәсебеннән мәхрүм ителергә тиеш түгел» (Русское историческое общество. 115 т. СПб. 1903, 375 б.). Монда, күренгәнчә, буржуаз эшлеклелекне урта гасыр богауларыннан һәм һични белән чикләнмәгән хакимият кысаларыннан азат итү, шәхескә аның табигый хокукларын һәм ирегөн кайтару, гражданнарның нинди милләттән булуларына һәм нинди дин тотуларына карамастан тигезлеген, алар милкенең кагылгысыз булуын тәэмин итү таләпләре чагылган.

Мәгърифәтчеләр исә нәкъ менә шушы идеяләрне алга сөрәләр, һәртөрле

золымнарны һәм шәхес иреген бастыруны кискен гаеплиләр, кешегә үзенең мәнфәгатьләрен яклау мөмкинлеген даулыйлар. Ирек, азатлык, алар карашынча, кешенең тормышында иң изге нәрсә. «Инсан мәгыйшәтендә бер бәһалы вә яхшы шәй хөррияттер... Хөрриятсез яшәмәк — көч вә зәхмәт»,— дип язды М. Акъегетзадә. Ә Каюм Насыйри исә, үзенең ирегеннән мәхрүм булганчы мохтаҗлыкта һәм бөлгенлектә яшәү күп яхшырак, дип хисаплый. «Алтын билбау бәйләп кол булудан,— дип яза ул,— иске-москы киеп иректә көн итү күп өстендер» (Насыйри К. Календарь, 1892, 31 б.). Ш. Мәрҗани белән Ш. Күлтәсинең философик хезмәтләрендә дә кеше һәм аның гакылына ирек даулау төп урыннарның берсен алып тора.

3. Милли яңарыш мәсьәләсе. Тәнзыймат, «Яңа госманлылар» һәм татар мәгърифәтчелегенең типологик бердәмлеге турында аларда милләт һәм милли яңарыш мәсьәләләренең куелышы да сөйли. Тарихчы галимнәрнең фикеренә караганда, тәнзыймат әһелләренең, бигрәк тә «Яңа госманлылар»ның ватанпәрвәрлек рухындагы уй-карашлары төрекләр арасында милли хисләрнең уянуын күрсәткән булсалар, алар күтәргән уй-фикерләр үз чиратында милли уяну процессын алга этәрделәр. Татар мәгърифәтчелек фикере белән дә эш шулай торды, аның барлыкка килүе һәм үсеше милли аңның уянуы һәм үсеше белән янәшә барды.

Милләт һәм халыкның тарихи язмышы татар мәгърифәтчеләре мирасында үзәк урыннарның берсен алып тора. Алар фикеренчә, халык язмышы, аның тәрәккыяте бөтен уй-фикерләрнең һәм эшчәнлекнең төп маягы булырга тиеш. Мәгърифәтчеләр халыкның милли аңына салынган чылбырлар, милләтнең тарихи тамырларын һәм мәдәни мирасын белмәү, социаль һәм милли тәрәккыят юлына салынган киртәләр дип саныйлар. Чөнки бу нәрсәләр милләт мәнфәгатьләренә карата ваемсызлык тудыра һәм аның киләчәгенә битарафлык тәрбияли. Тарих исә зур тәрбияви әһәмияткә ия тормыш мәктәбе вазыйфасын үти һәм таныш-белүгә ярдәм итә. Шулай булгач, халыкның үткәнен өйрәнү һәм кешеләрнең аңына җиткерү, аның киләчәктә милләт буларак яши алуының мөһим шарты булып тора. Шуңа күрә Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйри кебек күренекле мәгърифәтчеләр үзләре дә татар халкының тарихын һәм мәдәни мирасын өйрәнүгә кыйммәтле өлеш кертәләр. Ш. Мәрҗани исә Идел-Урал татарларының фәнни тарихына нигез салучы булып исәпләнә. Юкка гына XX гасыр башында татар культурасы тарихында зур роль уйнаган Җ. Вәлиди аны «безнең Геродотыбыз» дип атамады.

Ш. Мәрҗанинең «Мөстафад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган мәгълүматлар») һәм «Гыйләләт әз-заман фи әхвали Болгар вә Казан» («Болгар һәм Казан хәлләрен каплаган вакыт пәрдәсе») дигән хезмәтләрендә хәзерге татар халкының һәм аларның борынгы бабалары — Идел-Урал болгарларының тарихы һәм мәдәнияте, аларның икътисади һәм сәяси хәлләре, халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә урыны һәрьяклап тикшерелә. Татар халкының үткәне һәм мәдәни мирасы мәсьәләләренә ул шулай ук үзенең җиде томнан торган «Вафийәт әл-әслаф вә тәхиййәт әл-әхляф» (Үткәннәр турында тулы мәгълүмат һәм аларның варисларына васыяте) дигән хезмәтендә дә зур урын бирә.

4. Укыту-тәрбия мәсьәләләре. Тәнзыймат идеологлары да, «Яңа госманлылар» да, татар мәгърифәтчеләре дә уртагасырчылык чылбырларыннан котылу һәм тәрәккыят юлына басу мөмкинлеге ачу чарасы буларак алгы планга укыту-тәрбия, заманның фәнен һәм мәдәниятен үзләштерү мәсьәләсен куйдылар. Бу да аларның мәгърифәтчелек хәрәкәте буларак типологик якынлыгы турында сөйли. Тәнзыйматның уку-укыту һәм мәдәният мәсьәләләренә йөз тоткан хәрәкәт булуын Гөлхан белдермәсе нигезендә үткәрелгән беренче чаралар ук күрсәтеп тора. Алар арасында мәктәпләр һәм университет ачылу, беренче театрлар, матбугат барлыкка килү һ. б. Мәгариф һәм тәрбия мәсьәләләре төрек мәгърифәтчелегенең соңыннан килгән вәкилләре өчен дә мөһим проблемаларның берсе булып кала бирә.

Татар мәгърифәтчелегендә дә эш шулай тора. Аның вәкилләре өчен дә мәгърифәт, аң-белем тарату,халыкны заман фәненә һәм мәдәниятенә якынайту — алда торган бурычларның иң олысы һәм әһәмиятлесе. «Мәгариф эше,— дип язды Ш. Күлтәси,— барлык дөнья эшләренең төп тереге һәм төп нигезе... Белем һәм тәрбия бирү — яңарыш эшендәге иң мөһим һәм хәлиткеч нәрсә» (Күлтәси Ш. Һәйяте җәдидә. Казан, 1898, 2, 5 бб.).

Бу проблеманы хәл кылуда, мәгърифәтчеләр фикеренчә, төп урынны мәктәп алып тора. Шуңа күрә мәгърифәтчелек хәрәкәтенең беренче адымнарыннан

ук аның вәкилләре татарлар арасында киң таралган конфессиональ мәктәпнең характерын үзгәртү, мәктәп программасына дөньяви фәннәр кертү идеясе күтәреп чыктылар. Бу уңайдан узган гасырның 60 елларында Х. Фәезханов тәкъдим иткән мәктәп реформасы проекты игътибарга лаек. Җәдитчелек хәрәкәте җәелгәч, өлкән буын мәгърифәтчеләренең мәктәпкә кагылышлы хыяллары акрынлап тормышка аша башлый, мәктәпләр челтәре киңәя, кыенлыклар аша булса да укыту программасына дөньяви фәннәр үтеп керә башлый.

5. Әдәбият һәм тел мәсьәләсе. Мәгърифәт һәм белем тарату программасын тормышка ашыруда мәгърифәтчеләр, әдәбият мөһим урын алып тора, дип хисапладылар. Тәнзыймат тарафдарлары фикеренчә, әдәбият — мәгърифәтчелек идеяләрен һәм мәдәният казанышларын халыкка җиткерүдә, тәрбия эшендә актив чараларның берсе. Әйтелгән фикерләр төрек мәгърифәтчелегенең соңыннан килгән вәкилләре тарафыннан да алга үстерелә. Бу нәрсә Әхмәд Мидхәт мирасында ачык күренә. «Язучы,— дип язды ул,— үз иҗатында гомум фикерне чагылдыра һәм гомуми вәгазьче вазифасын үти. Дөнья цивилизациясенең язмышы матбугатның торышыннан бәйле булачак». («Просветительство в литературах Востока» дигән хезмәттән. М., Наука, 1973, 14 б.). 60 еллардан башлап мәгърифәтчелек әдәбияты иҗтимагый тормышка тагын да активрак катнаша башлый һәм моның белән феодаль хакимиятнең таркалуына үзенең өлешен кертә.

XIX гасырның икенче яртысындагы татар мәгърифәтчелеге әдәбиятына да иҗтимагый тормышның урта гасыр-патриархаль корамаларын фаш итүдә актив позиция, милләтне артталыктан һәм туңлык богауларыннан коткаруга, шәхесне зольмәт чылбырыннан, өә кеше акылын урта гасыр идеологик төшенчәләре хакимлегеннән азат итүгә омтылыш хас. М. Акъегетзадә һәм З. Бигиев романнары һәм хикәяләре, М. Акмулла шигырьләре, Г. Ильяси һәм Ф. Халиди пьесалары нәкъ менә шушы рухта язылганнар.

Әдәбият чын мәгънәсендә халык мәнфәгатьләренә хезмәт итсен, аның аңына җитәрлек булсын өчен мәгърифәтчеләр беренче чиратта түбәндәге ике мәсьәләне хәл итүне зарури санадылар:

а) Эчтәлек ягыннан да, шәкеле (форма) ягыннан да әдәбиятның характерын тамырдан үзгәртеп кору. «Диван әдәбияты» исемен йөрткән элеккеге төрек әдәбияты, мәгълүм булганча, сәнгатькярның үзенең шәхси дөньясы белән дә, гамәлдәге җәмгыять белән дә, үзгәрүчән дөнья белән дә, табигать белән дә аз бәйләнгән иде. Бу абстракт характердагы, үзенә йомылган, читтән кергән материал нигезендә ят образлар системасына буйсындырылып иҗат ителгән әдәбият иде. Татар әдәбиятында да шушы типтагы әсәрләр өстенлек иттеләр. Идел-Урал төбәгендә киң таралган шигъри әсәрләрнең һәм тылсымлы хикәяләрнең эчтәлегенә дә реаль тормышка һәм реаль ихтыяҗларга һичнинди мөнәсәбәте булмаган абстракт образлар һәм фантастик каһарманнар хас иде. Бу традициягә каршы буларак, төрек мәгърифәтчеләре дә, татар мәгърифәтчеләре дә чынбарлыктан алынган, реалистик әдәби әсәрләр тудырдылар. Бу әсәрләрдә тормыштан алынган каһарманнар үзәк урында торды һәм аларда иҗтимагый чынбарлыкның өлгергән ихтыяҗлары турында сүз барды;

б) әдәби әсәрләрне халыкка якын телдә язу. Төркиядә бу омтылыш «Яңа госманлылар»ның иҗатында ачык чагыла. Аларның әдәби әсәрләре халык сөйләм теленә якынлыклары һәм төрек әдәбиятын гарәп-фарсы алынмаларыннан чистартуга омтылышлары белән аерылып торалар. Татар мәгърифәтчеләре дә халыкны мәгърифәткә якынайту максатында әдәби телгә реформа үткәрү, аны гарәп теленең өстенлегеннән арындыру һәм халыкның сөйләм теленә якынайту идеясен алга сөрәләр. Бу, алар фикеренчә, халык арасында фәнни һәм гамәли белемнәрен тарату эшен җиңеләйтәчәк. Татар теле, дип күрсәтәләр алар, үзенең сүзлек составы белән дә, грамматик төзелеше белән дә башка телләрдән бер дә ким түгел һәм аның ярдәмендә фәнни фикерне дә, шигъри фикерне дә бик иркен рәвештә гәүдәләндерергә мөмкин.

Шул ук вакытта алар татар телен фәнни эшкәртү һәм әдәби телне сөйләм теленә якынайту буенча киң эшчәнлек тә җәелдерделәр. Бу эшчәнлек XVIII гасырның азагында башланып китә. Шул чорда беренче булып Казан гимназиясендә татар теле укыткан Сәгыйть Хәлфин тарафыннан «Татар теленең сүзлеге һәм кыскача грамматикасы» дигән хезмәт язылa һәм басылып чыга. Соңыннан И. Хәлфин, С. Кукляшев, А. Ваһапов һәм Х. Фәйзханов кебек мәдәният эшлеклелəре татар теленең сүзлеге һәм грамматикасы буенча китаплар язып, бу өлкәгә үзләренең өлешләрен керттеләр. Әмма татар әдәби телен

фәнни өйрәнүдә һәм эшкәртүдә иң зур өлеш К. Насыйри эшчәнлегенә бәйле. Татар мәгърифәтчелегенең бу күренекле вәкиле «Ләһҗәи татари» исеме белән татар теленең 2 томлык аңлатмалы сүзлеген һәм «Әнмүзәҗ» исеме белән зур фәнни грамматикасын хәзерләп бастырып чыгарды.

Мәгърифәтчеләрнең әдәби телгә баглы фәнни эзләнүләре һәм аны халыкның сөйләм теленә якынайту буенча алып барылган эшчәнлекләре зур социаль һәм мәдәни әһәмияткә ия булды. Бу өлкәдә алар күтәргән тәкъдимнәрне тормышка ашыру фәнни һәм матур әдәбиятны күпчелеккә аңлаешлы телдә язу, тарату мөмкинлеге тудырды һәм нәтиҗәдә аларны фәнни гыйлемнәр һәм мәдәният казанышлары белән аралаштыруга олы юл ачты.

6. Д ә ү л ә т - х а к и м и я т к ә  м ө н ә с ә б ә т. Тәнзыймат идеологларының һәм «Яңа госманлылар»ның, шулай ук татар мәгърифәтчеләренең фәнни һәм әдәби мирасында дәүләт-хакимият мәсьәләләрә дә мөһим урын алып тора. Бу мәсьәләләрне дә алар бер үк яссылыкта торып карыйлар. Гөлхан белдермәсендә үк инде күпмедер дәрәҗәдә ил белән гадел идарә итүче мәгърифәтле солтан идеясе үзенең чагылышын таба. Бу идея «Яңа госманлылар» әсәрләрендә ачыграк яңгырый. Габделхак Хәмит, мәсәлән, үзенең «Тарих» һәм «Тезер» дигән әсәрләрендә гадел хәлиф образын бирә. Шул ук вакытта төрек мәгърифәтчелек әдәбиятына конституцион солтанат һәм сайланып куела торган имам идеясе дә керә. Конституцион солтанат мәгърифәтчеләр тарафыннан икътисади һәм мәдәни үсешнең мөһим шарты итеп гәүдәләндерелә. «Хөррият» газетасының 1868 ел, 17 август санында Намык Кәмал, мәсәлән, табигый чыганакларны акыл белән файдалану, сәнагать һәм сәүдә үсеше өчен кирәкле шартлар бары конституцион тәртипләр урнаштырылган тәкъдирдә генә барлыкка киләчәк, дип язды. (Кара: «Зарождение идеологии национально-освободительного движения». М., «Наука», 1973, 19, 25 б.б.).

Татар мәгърифәтчелегендә хакимият мәсьәләсе тулырак рәвештә Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйри тарафыннан тикшерелә. Тәнзыймат идеологлары һәм «Яңа госманлылар» кебек үк, алар бу мәсьәләнә XVIII гасырдагы көнбатыш Европа мәгърифәтчеләре торган яссылыктан чыгып карыйлар. Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйри хезмәтләре белән танышу татар мәгърифәтчелегенең бу күренекле вәкилләренең «Иҗтимагый килешү» теориясе («теория общественного договора») турында хәбәрдар булганлыгын күрсәтә һәм бу хәбәрдарлык алар тарафыннан дәүләтнең килеп чыгышы мәсьәләсен тикшергәндә үзенең чагылышын таба. Татар мәгърифәтчеләре, төрек мәгърифәтчеләре кебек үк, әле гадел патша килүен көтүдән азат түгелләр. Шул ук вакытта алар катгый рәвештә зольмәткә каршы чыгалар, хөкемдарларның башбаштаклыгын гаепилиләр, мәгърифәтле, кешелекле һәм фәнне сөючән патша идеясе күтәрәләр. Мәрҗани фикеренчә, мәсәлән, мәгърифәтлелек гаделлек һәм кешелеклелек белән өзелмәслек җепләр белән бәйләнгән һәм бер-берсенә зарури алшарт булып торалар. «Бел,— дип яза ул,— чын падишаһлык кеше өчен табигый булган югары дәрәҗәле урын, чөнки ул табигате белән мәдәниятле. Җитәкчелек итү һәм үзенә буйсындыру, хөкемнәрендә гаделлек һәм җәбер-золымның булмавы — аның югары максаты». (Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты архивы, 22 фонд, 1 тасвирлама, саклау берәмлеге 20, 110 б.).

Шушы кыскача гына күзаллау да тәнзыймат тарафдарларының да, «Яңа госманлылар»ның да, татар мәгърифәтчеләренең дә хакимият мәсьәләсен мәгърифәтчелеккә хас яссылыкта торып яктыртканлыкларын күрсәтә.

Әйтелгәннәрдән тәнзыймат, «Яңа госманлылар» һәм татар мәгърифәтчелегенең типологик бердәмлегенең нигезендә нәрсә ята дигән сорау туа. Бу яктан, минем фикеремчә, 4 нәрсә игътибарга лаек:

1. Боларны тудырган алшартларның тиңгәллеге, аларның социаль асылы берлеге. Инде әйтелгәнчә, тәнзыймат та, татар мәгърифәтчелеге дә капиталистик мөнәсәбәтләр үсеше нәтиҗәсе буларак барлыкка киләләр, социаль табигатьләре белән буржуаз төсмер алалар һәм феодализмга каршы булган идеологик юнәлеш рәвешендә эш итәләр. Барлыкка килү алшартларының охшашлыгы һәм социаль табигатьләренең бердәмлеге исә котылгысыз рәвештә аларның бер үк характердагы иҗтимагый-сәяси идеяләр һәм таләпләр күтәреп чыгуларына китерә.

2. Төркиядә формалашкан иҗтимагый-сәяси карашларның Идел-Урал татарлары арасына үтеп керүе. Билгеле булганча, татар зыялылары белән төрек җәмәгатьчелеге арасында элек-электән тыгыз бәйләнеш саклана. Хаҗга барышлый һәм аннан кайтышлый Идел буеннан чыккан сәяхәтчеләр Истанбулда һәм Төркиянең башка шәһәрләрендә тукталалар һәм аларда яшәүче төрек

мәдәнияте өһелләре белән очраша торган булалар. Төркия белән Идел буе арасында сәүдә мөнәсәбәтләре дә яшәп килә. Шушы бәйләнешләр аркасында Төркиядән Идел буена анда чыккан китаплар килеп тора. Ә бу исә Төркиядә туган иҗтимагый-сәяси карашларның Идел-Урал татарларына килеп ирешүенә юл ача.

3. Чыганакларның берлеге. Дөрес, бу тулы берлек түгел. Татарлар Россия составында яшәделәр, алар рус җәмгатьчелеге белән бәйләнештә иделәр. Шунлыктан алар арасында барлыкка килгән мәгърифәтчелек хәрәкәте идеологлары да, төрек фикер ияләреннән үзгә буларак, рус чынбарлыгының, Россиядә таралган иҗтимагый-сәяси төшенчәләрнең һәм рус фәнни-фәлсәфи тәэсирен тоеп эш иттеләр. Әмма шул ук вакытта тәнзыймат белән татар мәгърифәтчеләренең фикри чыганакларында уртаклык та аз түгел иде. Төркиядә дә, Идел-Урал татарлары арасында да иҗтимагый фикер гасырлар дәвамында мөселман дөньясыннан чыккан фикер ияләренең фәлсәфи һәм социаль идеяләре тәэсирендә яшәде. Һәр икесендә шәрекънең әл-Фараби, Ибн Сина, Ибн Рошд, Ибн Халдун, Җәләлетдин Руми кебек олы затлары киң танылган иде. Бу идея традицияләре яңа гасырның идея юнәлешләре, шул хисаптан, тәнзыймат белән татар мәгърифәтчелеге барлыкка килгәндә дә үзләренең тәэсирен сиздерми калмады.

Тагын бер уртак фикри чыганак — гарби Европаның иҗтимагый һәм фәлсәфи фикере, беренче чиратта мәгърифәтчелек фикере. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, инде XIX гасырның урталарына ук төрек зыялылары француз мәгърифәтчелек әдәбияты белән ныклап кызыксына башлыйлар. Тәрҗемә эше киң җәелә. Фенелонның «Телемак»ы, Монтескьеның «Кануннар рухы», Вольтерның «Микромегас»ы һәм «Кандид»ы, Руссоның «Җәмгыять килешү»е һәм башка шушыларга охшаш хезмәтләр төрек җәмгатьчелеге арасында фикерләр куеруына китерә һәм зур бәхәсләр уята (Кара: «Просветительство в литературах Востока». М., «Наука», 1973, 8 б.). Европа мәгърифәтчелеге традицияләренә ияреп, төрек мәгърифәтчеләре үзләренең хезмәтләрендә халыкны мәгърифәт белән нурландыру социаль, сәяси һәм мәдәни үсешнең хәлиткеч чарасы булуы турында басым ясап күрсәтәләр.

Гарби Европаның фәнни-фәлсәфи һәм мәгърифәтчелек фикере татар мәгърифәтчелек фикере барлыкка килгәндә дә аның идея чыганакларының берсе булды. Татар мәгърифәтчеләренең фәнни-теоретик һәм әдәби мирасы күрсәткәнчә, алар гарби Европаның фәнни һәм мәдәни казанышларын яхшы ук тирән беләләр һәм бу аларның мәгърифәтчелек фикерләре формалашканда әһәмиятле роль уйный. Гарби Европаның фәнни-фәлсәфи һәм мәгърифәтчелек фикере Идел-Урал татарлары арасына ике канал аша үтеп керә: а) рус галимнәре, философлары һәм җәмәгать эшлеклеләренең әсәрләре; б) Төркиядә нәшер ителгән һәм татар сәүдәгәрләре яки изге урыннарга барган сәяхәтчеләрнең капчыкларында кайткан китаплар һәм кулъязмалар.

4. Исламга бәйле. Төрекләр дә, Идел буе татарлары да исламның сөнни мәзһәбе тарафдарлары булалар. Бу да төрек һәм татар җәмгатьчелегенең идея-фикри тормышында мөһим роль уйный һәм уртак нәтиҗәләргә китерә. аларда туган фикри юнәлешләрнең һәм эчтәлегенә, һәм рәвешенә, шул исәптән, мәгърифәтчелек юнәлешендәге агымнарга да көчле йогынты ясый. Һәм тәнзыйматның, һәм «яңа госманлылар»ның, һәм татар мәгърифәтчеләренең идеологик төшенчәләрендә дөньяви һәм дини чыганаклар тәэсире, исламга һәм дөньявилыкка хас күзаллаулар бәйләнеше, ислам төшенчәләре белән Европада булган төрле дөньяви теорияләрнең аралашуы үзен нык сиздерә. Боларның һәркайсы калдырган мираста да соңыннан мөселман реформациясе исемен алган агымга хас төшенчәләр, буржуаз үзгәртеп корулар һәм мәгърифәтчелекне шәригать кануннары белән килештерүгә омтылыш табарга мөмкин.

Әйтелгәннәр тәнзыйматның, «Яңа госманлылар»ның һәм татар мәгърифәтчелегенең типологик яктан бер үк юнәлештәге иҗтимагый агымнар булулары нигезендә яткан сәбәпләрнең кайберләре генә. Боларга охшаш сәбәпләрне, әлбәттә, тагын да китерергә мөмкин булыр иде.

Дөрес, әлеге типологик яктан берлек турында әйтелгәннәр аларны тулысынча тәңгәл агымнар дигән сүз түгел әле. Тәнзыймат суверен дәүләт кысаларында барлыкка килә һәм бу дәүләтнең эчке төзелешен үзгәртү мәсьәләсен күтәрә. Татар мәгърифәтчелеге исә рус дәүләтеннән бәйле рәвештә көн күргән халык арасында формалаша. Бу ике халыкның да социаль-экономик тормышына урта гасырчылык мөһере сугылган булса да, яхшы ук аермалыклар да була. Бу аермалыклар һәм ике хәрәкәтнең үзенә генә хас үзенчәлекләре туура китерә.

Татарлар, инде әйтелгәнчә, Россия кысаларында яшәделәр һәм аларның тормышы Россиядә хакимлек иткән социаль-икътисади һәм сәяси тәртипләрдән бәйле иде. Татар мәгърифәтчелегенең үзенчәлекләре дә беренче чиратта шушы нәрсә белән билгеләнде. Россия чынбарлыгы ул күтәргән мәсьәләләрнең эчтәлеген һәм аларның куелу рәвешен билгеләде. Татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенең үзенчәлекләрендә рус фәнни-философик фикеренең һәм мәдәниятенең тәэсире дә билгеле бер роль уйнады. Бу уңайдан татар мәгърифәтчелегендә, бер яктан, патша хөкүмәтенең милли сәясәтенә, ә икенче яктан, рус халкына, рус җәмәгатьчелегенең демократик даирәләренә, рус фәнни-фәлсәфи һәм иҗтимагый фикеренә мөнәсәбәт мәсьәләсенең куелышы игътибарга лаек. Әйтергә кирәк, татар мәгърифәтчеләренең патша хөкүмәтенең социаль һәм милли сәясәтенә карашлары кискен кире кагу рухында иде. Шул ук вакытта алар рус халкы белән үзара аңлашу һәм тату яшәү тарафдарлары да иделәр һәм рус мәдәниятен, рус телен белү кирәклеген яклап чыктылар.

Тәнзыйматның беренче адымнары ук инде югарыдан реформалар үткәрү юлы белән «мәгърифәтчел солтанлык» урнаштыру, илнең буржуаз үсешенә юл ачу, халыкка демократик хокуклар һәм ирекләр бирүгә юнәлдерелгән иде. Татарлар кулында исә югары хакимият юк иде. Шуңа күрә алар арасында барлыкка килгән мәгърифәтчелек хәрәкәте баштан ук демократик рухта тәрбияләнгән һәм түбән катлаулардан чыккан зыялылар хәрәкәте рәвешендә барлыкка килде. Бу зыялыларның күпчелек өлеше руханилардан торды. (Чөнки кулларында һичнинди сәяси хакимият оешмалары булмаган татарларның мәдәни оешмалары да, дөньяви фәннәр укытыла торган уку йортлары да, матбугатлары да юк иде. Шуңа күрә XX гасыр башларына кадәр алар арасында дөньяви белем алган зыялылар катламы да барлыкка килә алмады). Татар мәгърифәтчелек хәрәкәтендә демократик агым, җәдитчелек барлыкка килгәч, тагын да киң колач җәя. Чөнки җәдитчеләр арасында прогрессив рухта тәрбияләнгән руханилар белән беррәттән мөгаллимнәр, сәүдә хезмәткәрләре һәм шәкертләр зур урын алып торды.

Әмма тәнзыйматның, «Яңа госманлылар»ның һәм татар мәгърифәтчелегенең үзенчәлекле сыйфатлары булуга карамастан, аларның барысына да, типологик асылларыннан чыгып, мәгърифәтчелек хәрәкәте дип атарга мөмкинлек бирә торган идеологик төсмер хас иде. Нәкъ менә шушы төсмер аларның һәркайсына төрек һәм татар халыклары иҗтимагый тормышының билгеле бер дәверендә әһәмиятле роль уйнарга мөмкинлек бирде. Бу хәрәкәтләрнең эшчәнлеге әйтелгән халыкларның рухи тормышында мөһим бер баскыч булып торды, кешеләрнең уй-фикерләренә, тирә-юньгә карашларына зур төзәтмәләр кертте һәм иҗтимагый фикер үсешендә тирән үзгәрешләргә җирлек әзерләде.

Үзләренең эшчәнлекләре белән тәнзыймат әһелләре, «Яңа госманлылар» һәм татар мәгърифәтчеләре милли мәдәниятләр үсешенә зур этәргеч ясадылар. Төркиядә тәнзыймат реформалары нәтиҗәсендә китап бастыру эшләре колач җәя, гарби Европаның мәгърифәтчелек әдәбиятын, фәнни китапларын тәрҗемә итү һәм тарату мөмкинлекләре ачыла, вакытлы матбугат һәм дөньяви характердагы уку йортлары барлыкка килә, яңа рухтагы әдәбият үсә башлый, ә ахыр чиктә театрлар эшли башлый. Мәгърифәтчеләр эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак, татарлар арасына да дөньяви гыйлемнәр бәреп керә, ә җәдит мәктәпләре барлыкка килгәч, яшь буынны укыту-тәрбия эшенең эчтәлеге үзгәрә, бу өлкәдә яңа алымнар кулланыла, мәктәп программаларына дөньяви фәннәр керә башлый. XIX гасырның икенче яртысында татар китабы яңадан да киңрәк колач белән тарала. Татар мәгърифәтчеләре эшчәнлегенең шифалы тәэсире белән XIX гасыр азагында мәгърифәтчелек реализмы әдәбияты барлыкка килә, рус, гарби Европа, төрек язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итү һәм басып чыгару киң колач җәя. XIX гасырдан XX гасырга күчкән елларда сәхнә сәнгатенең һәвәскәр труппалары барлыкка килә һәм беренче һәвәскәр спектакльләр куела башлый, ә 1905—1907 революция елларында татар профессиональ театры туа.

**Яхъя АБДУЛЛИН,**
философия фәннәре докторы, профессор.

# .САН-ФРАНЦИСКОДА ТАТАР ҖӘМГЫЯТЕ

*Тын океан буендагы җылы табигатьле Калифорния штатында Американың читтән килеп яшәүче барлык халкыннан 40лап проценты яши. Баштарак алар күбрәк Африка һәм Аурупа илләреннән агылган булса, соңыннан Кушма Штатларның яңа милләтен төзүгә Азия халкы да ныклап катнаша башлый; кытайлар хәзер барлык эмигрантларның — 23, филиппиннылар — 20, японнар 12 процентын тәшкил итә. Килгән халык үз җәмгыятьләре белән яшәргә, үз милләтләре кулайрак күргән хезмәтне сайларга һәм үз гыйбадәтханәләренә йөрергә тырыша. Ул эмигрантларның төп хыялы — АКШ гражданлыгын алу. Аны алгач, алар бу илнең зур патриотларына әйләнәләр. Паспортларында милләт язылмый, шулай да баштарак үз илләрен, кавем-кыяфәтләрен юксыну аларны үзара оешып һәм күпмедер дәрәҗәдә йомылып яшәргә мәҗбүр итә. Моңа телне яхшы белмәү дә этәрә, әлбәттә.*

*АКШка безнең татар милләте вәкилләре дә килеп ирешкән. Алар әле бик күп һәм бай булмасалар да, кыйтганың капма-каршы ике ярына — Тын һәм Атлантик океаннар буенда урнашкан ике зур кала Нью-Йорк, һәм Сан-Францискода инде үз җәмгыятьләрен, очрашу урыннарын булдырып, егерменче еллардан бирле милли җәмгыятьләрен оештырып җибәргәннәр. Үзара аралашып яшәүче татарлар саны бер шәһәрдә 200—300 дән узмаса да, алар милли рухны саклау, тел һәм мәдәниятебезне белү, аны яшь буынга тапшыру юлында зур гына эш башкаралар. Әлифбабызның өч тапкыр алышынуы мөһаҗирләребезгә дә зур кыенлык китерә: гарәпчә дә, русча да укый белмәгән яшьләргә олылар җыр һәм шигырьләребезне латин хәрефләренә күчереп таратырга мәҗбүрләр. Шунлыктан да әдәбиятка караганда җыр, музыка сәнгатебез аларда күбрәк таралыш таба.*

*1990 елда АКШның Висконсин штаты, Мадисон шәһәрендә уздырылган Үзәк Азия халыклары тарихы һәм фольклоры буенча халыкара IV конференциягә баргач, без анда Сан-Францискодан махсус килгән өч америкалы милләттәшебез Салих әфәнде һәм Шәмсия ханым Апакайлар, Нәрмин туташ Диюш белән очраштык. Әңгәмәләр арасында без аларга үз җәмгыятьләренең оешу тарихын тәфсилләп язып җибәрергә тәкъдим иттек. Күптән түгел 80 яшен тутырган эшлекле Салих әфәнде элек үзе язган түбәндәге истәлеген тулыландырып җибәргән. Аның белән танышу күпләргә кызык булыр дип уйлыйм.*

**Флора ӘХМӘТОВА.**

Татарларның Рәсәйдән Ерак Шәрекъка килеп урнашулары 19 гасыр ахырларында ук башлана.

Рәсәй белән Кытай хөкүмәтләре арасында Кытай-Көнчыгыш тимер юлын төзү килешенгәч, Маньчжуриягә тимер юлы эшчеләре һәм татар сәүдәгәрләре килә башлаган иде. Милләттәшләребезнең күпчелеге Пенза һәм Тамбов якларыннан булып, Харбин, Хайлар кебек шәһәрчекләрдә төрле кибетләр ачканнар иде. Берничә елдан соң, эшләрен җайга салгач, Рәсәйдән гаиләләрен дә үз яннарына китерткәннәр иде.

Милләттәшләребезнең Ерак Шәрекъ илләренә икенче күченүләре Рәсәйдәге сыйнфый көрәш елларында башланды. Уфа, Казан, Троицк шәһәрләреннән һәм Пенза вилаятеннән Ерак Шәрекъка килеп урнашкан бабаларыбыз Хайлар, Харбин, Мукден, Тяньзин, Шанхай, Кобе, Кижу шәһәрләрендә зур мәхәлләләр корганнар, мәчет вә мәктәпләр торгызганнар, хәтта корылтайлар тәртип итеп, бөтен Ерак Шәрекъ мәхәлләләрен бер мәркәзгә җыюга ирешкәннәр иде. Токио мәхәлләсенең имамы вә рәисе Мөхәммәт Корбангали һәм Мукдендәге динимилли мәркәз мәгариф бүлеге рухыбызны ашлар өчен ихтыяҗыбызга җитәрлек

дәрәҗәдә дәреслекләр, мәҗмуга һәм газетлар нәшер иткәннәр иде. Бу эшчәнлек аркасында Ерак Шәрекътәге мөһаҗәрәт дини-милли үзенчәлеген саклап калуда кимчелек күрсәтмәде. Читтән һичбер ярдәм булмаганга күрә, мәхәлләләребезнең хәяты сәламәт нигездә дәвам итүе фәкать дәртле, тырыш милли сәүдәгәр вә һиммәт ияләренен матди һәм мәгънәви булышуына таяна иде.

Ерак Шәрекътәге эшлекле иҗтимагый хәят 1950 елларга чаклы дәвам итте. Шуннан соңгы үзгәрешләр исә бабаларыбызның мең бәла белән Ерак Шәрекътә корган милли мәхәлләләренең төбе-тамыры белән сүтелүенә, тар-мар килүенә сәбәпче булдылар. Нәтиҗәдә, анда яшәгән милләттәшләребез гөруһ-гөруһ яки аерым-аерым гаиләләр хәлендә Төркиягә, көньяк һәм төньяк Америкага күченеп китәргә мәҗбүр булдылар.

Бүгенге көндә Американың Нью-Йорк һәм Калифорния шәһәрләрендә яшәгән татарлар — югарыда язып узган мөһаҗирләр, Рәсәйдән күченеп киткәннәрнең балалары вә торыннарыдыр.

Милләттәшләребезнең Калифорниядә Сан-Франциско шәһәренә вә аның тирә-ягындагы кечерәк калаларга (Берлингәйм, Сан Матео, Санта Клара һ. б.) килеп тора башлауларына быел 68 ел булды.

Бу җирләргә беренче килеп урнашучылар — Хәсән Салих, Мотыйг Гарифулла һәм Габдулла Зәйнаш гаиләләре иде. 1927 елда Габдулла әфәнде Шанхайга китеп, Зәйтүнә туташ Акбирдингә өйләнеп, кире кайтты. Бу өч гаилә үзара йөрешеп-күрешеп яшәделәр. 1932 елда, Шанхайда Татар оешмасы булдыручылардан Исмәгыйль ага Акбирдин дә гаиләсе белән Сан-Францискога килеп урнашкач, беренче тапкыр буларак өйләрендә гает намазы укылды. Гаеткә пакыстанлы һәм төркияле мөселманнар да чакырылган иде.

1934 елда Калифорниядә яшәүче милләттәшләребез күбәя башлады. Фәйзерахман әфәнде һәм Рабига ханым Бигиләр килде. 1936 елда Исмәгыйль ага вафат булды. Бу туфракларда беренче татар мәете җеназасы албанияле Габбас әфәнде Рамазан тарафыннан укылып, җирле каберстаннарның берсендә дәфен ителде.

1960 елга чаклы дини бәйрәмнәребез шулай өйләрдә уздырылып килде. Америкада да төрле-төрле милләтләр арасында диңгездән бер тамчы булып, кем икәнебез беленмичә, шулар арасында югалып китмәвебез өчен, бабаларыбыз күрсәтеп калдырган эздән барып бер арага туплану, оешма төзү кирәклеге сизелде. Оештыру комиссиясе 1960 елның 27 апрелендә Заһидулла Агыш житәкчелегендә үзенең беренче утырышын уздырды. Бу утырышта Калифорния шәһәрләрендә яшәүче милләттәшләребезнең даими иҗтимагый һәм дини тупланмаларга ихтыяҗы булу фикере алга сөрелде. Бертавыштан оешма төзү карары чыгарылгач, идарә әгъзаларын сайлау, әгъзалык хаҗы һәм оешманың тотачак юлы кебек мәсьәләләр игътибар үзәгенә алынды.

1960 елның 15 маенда милләттәшләребезнең гомуми җыелышы Берлингәйм шәһәрендә, җирле клубларның берсендә уздырылды. Җыелышта 30 кеше бар иде. Гомуми җыелышның рәисе итеп Сәгыйть Килки, язу эшләрен алып барыр өчен Рәшит Акчурин сайландылар. Җыелыш рәисе оештыру комиссиясе тарафыннан каралган мәсьәләләр хосусында тәфсилле доклад укыды. Аннары түбәндәге карар кабул ителде:

1. Оешманың рәсми исеме — Америка төрки-татар берлеге;

2. Аның шөгыле — дини-мәдәни һәм иҗтимагый эшләр. 3. Оешма әгъзасы булыр өчен — татар булу шарт. Ят милләт кешесе белән никахланганнарның ире яки хатыны вә алардан туган балаларның оешмага керүләре мөмкин. 4. Әгъзалыкка язылу хакы — 10 доллар. Еллык әгъзалык өчен гаилә башы — 12, буйдаклар — 6, укучылар 3 доллар түли.

Гомуми җыелыш Сафа Акчураның кыска бер дога укуы белән тәмамланды.

Фәйзерахман әфәнде Биги өендә оешмабыз идарәсенә түбәндәге затлар сайланды: (рәис — Заһидулла Агыш, урынбасары — Сәгыйть Килки, сәркатип — Рәшит Акчура, казначы — Рабига Бини.

Июнь аенда, корбан гаете намазы күтәренке рух белән укылганнан соң, югарыда исемнәре аталган кемсәләр һәм янә биш кеше 56 тавыш белән оешмабызның идарә әгъзалары буларак алкышландылар. Бу бәйрәм көнендә оешма әгъзасы булып язылу хисабына 265 доллар акча җыелды вә шуның белән идарәбез эшкә тотынды.

Идарәнең беренче утырышы биш көннән соң Сәгыйть әфәнде Килки өендә уздырылды вә моннан соң булган утырышлар да, мәхәлләнең үз бинасы булмаганлыктан, чират белән шулай идарә әгъзаларының өйләрендә ясалып килде. Идарә тарафыннан Рамазан ае тәравих намазларын да шулай хосуси өйләрдә уку

карары кабул ителде. Шәһәрнең берәр клубын арендаларга мәхәлләбезнең матди хәле мөмкинлек бирми иде әле.

1961 елның мартында оешмабызның беренче рәисе Заһидулла Агыш вафатыннан соң, аның урынбасары Сәгыйть әфәнде рәисе вазифаларын үз өстенә алды. Мәрхүм Хафиз Салич идарәнең хисап эшләрен системага куеп, рәсми документ, дәфтәрләрне әзерләде. Шуннан соң оешмабыз Калифорния хөкүмәте тарафыннан рәсми рәвештә этник төркем, шулай ук дини-мәдәни оешма буларак танылды.

1962 елның 23 мартындагы идарә утырышында казначы Рабига Биги мәхәлләнең 930 долларын банк хисабына куйганлыгын белдерде. Шул ук утырышта мәхәллә әгъзаларына Сайпресс Лоан Семетри дип аталган каберстанда аерым жир сатып алу турында мәктүпләр күндерелеп, фикер алышу тәкъдим ителгән иде. Сафа Акчура белән Рабига Биги өйдән-өйгә йөреп, милләттәшләребез ниятен ачыклады. Нәтиҗәдә 100 каберлек урын сатып алуга мәрхүмнәребезне бер зиратка күмү чарасы күрелде. Шул ук вакытта мәет күмү оешмаларының берсе белән мәетләребезне юу, кәфенләү, җеназасын уку кебек йолаларны үтәү өчен килешү имзаланды.

Шушы елларда ук һәрбер җыелышта үз ихтыяҗларыбызны күрерлек зурлыкта һәм уңайлы бер җирдә бина сатып алу фикере туа, әмма мәхәлләбезнең матди хәле әле моңа мөмкинлек бирмәгәнгә, теләк киләчәк елларга кичектерелә килде. Ниһаять, 1966 елда барча идарә әгъзалары җыелып, гыйбадәт кылу һәм җыелышлар үздыру, дин дәресләре үткәрү өчен бер бинаны (Берлингейм, Эл Камино Реал, 1258) 30250 долларга алдан өч меңен түләп, банк аша мәгълүм бер микъдар процент белән егерме ел эчендә бәхилләтеп бетерүне шарт куеп, сатып алырга мөмкин булачагын игълан итте.

Алыначак йорт хәзерге торышында эшләребезне үтәрлек сыйфатта түгел иде. Шунлыктан аны үз ихтыяҗыбызга ярарлык рәвешкә китерүне махсус бер һәйәткә тапшыру карарлаштырылды. Бинаны ихтыяҗыбызга ярарлык рәвешкә китерү өчен оешмабызның карты-яше, бала-чагасы үз эшләреннән бушаган вакытларын, ял көннәрен йортны сүтү, чүп-чарны түгү, ишегалдын тәртипкә китерү өчен кыргый үләннәрне, комачаулап торган агачларны кисү кебек эшләргә сарыф иттеләр. Хатын-кызларыбыз өмәчеләргә өйләреннән кайнар ашлар пешереп китерде. Озын сүзнең кыскасы: бу эштә оешмабызның барча әгъзалары җан-тән белән тырышты. Мәрхүм Сафа абзый Акчураның Япониядәге милләттәшләребездән бер микъдар туплап кайткан акчадан тыш, читтән һичбер ярдәм булмаганы хәлдә, бу төзелештә бары тик үз көчебезгә таяндык. Финляндиядәге кардәшләребезгә хәлебезне аңлатып озын бер мәктүп язылса да, кызганыч ки, алардан бер төрле дә җавап алмадык. Материал алырга идарәбезнең акчасы булмау сәбәпле, төзелеш эшләре вакыт-вакыт тукталып та торды. Бер ел ярым маташканнан соң, ниһаять, бинабыз тәмам ителде.

Сан-Францискодан алып Лос-Анжелеска хәтле сузылган озын бер урам үзәгендәге бу бинабызга йөзгә якын кеше сыя. Ул газ белән җылытыла, аның җыелышлар залы, язу һәм аш бүлмәләре, тагын бүтән ханәләре бар.

Оешмабызның имамнары. Имам вазифасын байтак еллар албанияле Габбас Рамазан алып барды. Ул картайгач, аның урынына Дәүләтша ага Сизгән китерелде. 1970 елда исә бу бик мөһим хезмәтне Хәсән ага Килки үз өстенә алды.

Дин дәресләре. Мәктәп яшендәге балаларыбызга һәрбер эшебезне бисмилла белән башлау тиешлеген белдерү, аларга мөкатдәс динебезне өйрәтү иң беренче вазифаларыбыздан булды. Өстебезгә йөкләнгән бу бурычны үтәү максаты белән, башында Тасия ханым Килки торган ата-аналар һәйәте 1964 елның октябрь башыннан 6—12 яшендәге балаларга туган телебездә дин дәресләре курслары ачты. Шәмсия ханым Апакай 1968 елга чаклы ул укуларны уңышлы рәвештә алып барды. Бу елларда әле оешманың үз бинасы булмаганлыктан, егерме икеләп бала ата-аналары өйләрендә тупланып укыдылар. Бу елларда дини бәйрәмнәребез балалар гүзәл мәкам белән укыган Коръән сүрәләре белән башлана һәм тәравих намазлары да балалар әйткән салаватлар белән гаять әсәрле үткәрелә иде.

Дин дәресләре берничә ел тукталып торганнан соң, 1973 елда яңадан башланды. Бу юлы Сан-Францискодагы Ислам мәркәзенә мөрәҗәгать ителеп, мөгаллим соралды. Мәктәп һәйәте оештырылды. Һәйәткә Фазыл Садри, Сәрпил Утүш, Таһир Дәүләтша һәм Шәүкәт Тарпиш сайландылар. Инглиз телендә бирелгән бу курслар тәртипле рәвештә 1973 елның июнь ахырларына чаклы дәвам итте. Балалар, ике төркемгә аерылып, тәҗрибәле мөгаллимнәр җитәкчелегендә файдалы белемнәр алдылар. Моның өстенә балаларыбыз бер-берсе

белән танышырга форсат таптылар. Мәктәп һәйәте һәрбер дәрестә катнашып, тәнәфес вакытларында, беренчедән, тәртип саклау, икенчедән балаларга чәй һәм татлылар әзерләү белән мәшгуль булдылар.

1973 елның 24 июнь көне бинабызда диплом алу йоласы тантаналы рәвештә уздырылды. Бу мәрасимгә мәхәллә әгъзалары, мөгаллим әфәнденең гаиләсе чакырылган иде. Имам Хәсән ага Килки тарафыннан кыска бер дога белән ачылган бу мәҗлес оешмабыз әгъзаларында онытылмаслык хатирә калдырды. Асылы белән фиджиле булган Сохраб Галихан вә улы Бабыр безнең тарафтан һичбер түләү көтмәгәннәре хәлдә, балаларыбызга кыйммәтле вакытларын биреп, аларга гыйлем өйрәттеләр. Оешмабызның мәдәни һәйәте мөгаллимнәргә тәшәккөрләребезне белдергәннән соң, укучылар тарафыннан әзерләнгән дин белән бәйләнешле иншалар дикъкать белән тыңланылды. Мөгаллим әфәнделәргә укучылар тарафыннан җыелган бүләкләр тәкъдим ителде. Соңыннан кунакларга өйләрдән пешереп китерелгән бәлеш вә сумсалар белән чәй-каһвә эчерелде. Мондый мәҗлесләрнең күп еллар кабатлануын теләп, мәгънәви хозур эчендә өйләребезгә таралдык.

Уку яшендәге балалар булмау сәбәпле, берничә ел тукталып торгач, бу мөһим дәресләр 1979—82 елларда эшлекле әгъзаларыбыз Таһир әфәнде Дәүләтша һәм Шәмсия ханым Апакай җитәкчелегендә тәкърар башланды. 1988 елда Мәрьям ханым Апакай тырышлыгы белән фәләстинлы Мөнир әфәнде Коддура чакырылып, 6—12 яшендәге балаларга Коръән әлифбасы өйрәтелә башлады. Атнада бер кич шул ук Мөнир әфәнде өлкән яшьтәгеләргә Коръән сүрәләре мәгънәләрен аңлатты, ислам турында гомуми мәгълүмат бирде.

Оешмабызның бүлекләре.

1.«Ханымнар оешмасы» 1964 елда Рауза Рогард (Ибраһим) җитәкчелегендә төзелде. Бу бүлекнең вазифасы: һәр елның соңгы айларында идарә тәртипләгән «Шәрекъ кичәсе»нә аш-су әзерләү, елда бер кат Роммәҗ сәйл (актарма сатышы) дип аталган базар ясау. Бу кеби сатыш күп кенә мәшәкать белән бәйләнгән бер эштер: моны тәртипләгәндә оешма әгъзаларыннан вә аларның күршеләре һәм танышларыннан сатарлык әйбер җыю, аларга хак кую, тәртипләп төзү кебек эшләр байтак вакыт һәм көч таләп итә. Дини бәйрәмнәр вә башка җыелышларда чәй-каһвә һәм аш-су әзерләүне дә ханымнар оешмасы үз өстенә ала. Ханымнар оешмасы елда бер кат гомуми җыелышларын тәртипләп, идарәләренә яңа рәисә вә аңа булышчылар сайлый.

2.«Яшьләр түгәрәге» 1965 елда Әсгать Сизгән гайрәте белән төзелде. Түгәрәкне төзүдән максат: үзлегебезне саклау, милли мәдәниятебез белән танышу, мәдәният вә спорт буенча эшчәнлек итү белән бәрабәр, киләчәктә яшүсмерләребезнең мәхәллә һәм оешма эшләрен үз өсләренә алуга хәзерлек күрү, спорт аланында яшьләребезнең «Софт Бол» берлеге 1968 елда Сан Матео илчә каласында 14 команданы җиңеп, беренчелекне казанганнар иде. 1973 ел ярышларында икенчелекне алдылар.

1966 елда Нәркис Гели һәм Суфия Сәзгән төрек язучысы Кәримә Надирнең «Намус сакчысы» хикәясен татарчага тәрҗемәләп, ике пәрдәлек пьеса рәвешендә оешма әгъзаларына тәкъдим иттеләр. Уенны — Әмир Утүш, Таһир Дәүләтша, Суфия Сәзгән, Нәркис Гели зур осталык белән башкардылар. Бу турыда «Төрек Күлтүре» журналында Тәлгать бәй Тәкин бер мәкалә дә бастырды.

1969 елда яшьләребез Галиәсгар Камалның «Беренче театр»ын сәхнәгә куйды. Бу әсәр Рауза ханым Рогард режиссерлыгында гаять зур осталык белән башкарылып, карауч ыларга күп еллар онытылмаслык бер зәвыкъ бирде. Сәхнәдә Әсгать Сәзгән, Суфия Сәзгән, Таһир Дәүләтша, Рәшди Агый, Нәркис Гели, Нурия Шәрәфетдин, Равил Шәрәфетдин уйнадылар.

Оешмабыз мәхәллә күләмендә сабантуй да уздыра. Яшьләр түгәрәге бу сабантуйларда бала-чагаларны төрле уеннар уйнатып, очрашуларга аеруча бер җанлылык бирәләр.

1972 елның апрель аенда Яшьләр түгәрәге, ханымнар оешмасы ярдәме белән, сәхнәгә Гариф Богдановның өч пәрдәлек «Хуҗа һәм приказчик» комедиясын сәхнәгә куйды. Уенга айларча әзерлекләр күрелде. Балта осталарыбыз һәр күренеш өчен декорацияләр ясады. Сәхнә өчен затлы киемнәрен хатын-кызлар үзләре текте. Ирләр яхуд арендага бирә торган кибетләрдән милли кыяфәтне җанландырырлык кием-салым, сакал-мыек эзләде. Барча һәвәскәрләр, һич аруталуны белмәгән Рауза ханым Рогард җитәкчелегендә рольләрен ятладылар.

Бу уен өчен махсус арендаланган клубның залы тамашачылар белән шыгрым тулы иде. Утырырга урындыклар җитмәде, күпләр аяк өсте калды. Пәрдәнең ачылуын сабырсызлык белән көткән сәерчеләрнең өметләре бушка чыкмады:

декорация, кием, грим, бигрәк тә уен һәркемне шат итте, АКШта яшәгәнлекләрен берничә сәгатькә оныттырды. Уен барышында Галимҗан байның (Ибраһим Яуш) еш кына: «Яхшы сөйлимме мин?» — дигән сүзләре халык теленә күчте вә бу сүзләр байтак вакытларгача уенны сагынып сөйләргә сәбәпче булды. Бу пьесада Ибраһим Яуш, Рауза Янгураз, Нурия Шәрәфетдин, Салих Апакай, Рөшди Агый, Сара Ибраһим, Разия Мөхәммәдҗан, Халидә Диуш уйнадылар.

1982 елда Рауза ханым Рогард режиссерлыгында сәхнәгә И. Арсланның 1937 елда язган «Газизәкәй балдыз» атлы өч пәрдәлек әсәре куелды. 1985 елда Рәисә ханым Хәким режиссерлыгында Габбас Сөләйманның «Ерак Шәрекъта өйләнмәгән егетләр корылтае» атлы шигъри стильдә язылган көлке әсәре һәм «Кияү эзләү» атлы бер пәрдәлек комедия уйналды. 1986 елда Г. Камалның «Көндәш»е һәм 1989 елда «Ычкынды» исемле пьеса Р. Хәким режиссерлыгында һәвәскәр артистларыбыз тарафыннан башкарылдылар.

Оешмабызның башка мәдәни эшләре. 1970 елда Шәмсия ханым һәм Салих Апакайлар тарафыннан тәлинкәләрдән тасмаларга күчерелеп әзерләнгән милли җырларыбызны оешма әгъзалары үз бинабызда тыңлады һәм өйрәнергә керешгте. Моның өчен җырларның сүзләре гарәп һәм латин хәрефләре белән күчерелде, ксерокста күбәйтелде һәм тыңлаучыларга таратылды. Алар шуны укып, магнитофонны тыңлап, милли җырларыбызны өйрәнә.

1971 елда Салих Апакай тарафыннан әзерләнгән «Сан-Франциско татарлары тарихы» дигән доклад укылды.

1973 елның апрель аенда халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукайның тууына 87 ел тулу уңае белән оешмабызның «Мәдәни һәйәте» тарафыннан Тукай көне үткәрелде. Шагыйребезнең кыскача тәрҗемәи хәлен Килки инглизчә укыганнан соң, ана телебездә Г. Тукайның тәрҗемәи хәле, иҗаты вә хезмәте турында доклад сөйләнде. Илхан Садри «Кошларга», Бүләнт Садри «Бәхетле бала», Бану белән Туран Утешләр «Бала белән күбәләк» шигырьләрен сөйләп, тыңлаучыларны сөендерделәр. АКШта да Тукай көне традиционга әйләнсен, һәр ел шулай уздырылсын иде, дигән теләктә Ханымнар оешмасы әзерләгән чәй-каһвәне авыз итеп, өйләргә канәгать булып таралдык. Бу урында шуны да искәртәбез: мондый мәдәни җыелыш вә дини бәйрәмнәр тантанасына, оешма әгъзаларыбыздан керү хакы алынмый, оешма идарәсе мондый эшләр белән баглы булган бөтен чыгымнарны инде үзе күтәрә.

1973 елның башында эшчән әгъзабыз Рожер Гели тарафыннан «Хәбәрләр мәктүбе» чыгарыла башлады. Бөтен мәхәллә хәбәрләрен, вакыйгаларын һәҗүви стильдә вә бик асат аңлашыла торган садә телдә язып, бу кыйммәтле «Хәбәрләр мәктүбе» оешма әгъзаларының өйләренә почта белән озатыла вә һәркем тарафыннан сөелеп укыла. Әгъзаларның адреслары вә телефон номерларын билдергән күрсәткеч тә шушы басма тарафыннан төзелә һәм һәр ел таратыла.

Кириллица хәрефләре белән татарча уку курслары.

1966 елдан бирле «Казан утлары» һәм «Азат хатын» мәҗмугаларын, 1990 елдан башлап «Идел» мәҗмугасын тәртипле рәвештә почта белән Апакайлар гаиләсенә Казанда яшәүче туганнарыннан берсе — Фуат Апакай җибәреп тора. Бу мәҗмугалар белән өлкән яшьтәге милләттәшләребездән кайберләре кызыксынып, боларны укырга теләкләре булганын белдерделәр. Укыр өчен, әлбәттә, кириллицаны белү кирәк. «Игелекле эшнең иртә-киче юк», — дип, кириллица хәрефләре белән татарча уку курслары оештырып җибәрдек, ул бер кыш дәвам итте.

1988 елда бер төркем агай-эне Татарстанда туристик сәяхәттә булдылар. Алар байтак кына татарча китаплар алып кайткан иде. Бу китапларны укыр өчен янә кириллица әлифбасын өйрәнү ихтыяҗы туды. Бу сәбәптән тәкърар курслар ачылып, тагы кыш буе дәвам итте.

Әниләр көне. АКШта һәр ел уздырыла һәм әниләргә багышланган көннең кыскача тарихы түбәндәгечә: 1907 елның 9 маенда Пенсильвания штаты Филадельфия шәһәрендә яшәүче Җәрвис исемле яшь бер хатын, әнисенең вафат булу еллыгы истәлеге итеп, дус-ишенең әниләренә чәчәкләр җибәргән. Җәрвиснең бу эше бик хуш күрелгән. Җәрвис һәм дуслары, Май аеның бер көнен әниләргә багышлауны үтенеп, хөкүмәткә гариза кертkәннәр. Кыска бер вакыт эчендә АКШ хөкүмәте Май аеның икенче якшәмбесен Әниләрне хөрмәт итү көне дип игълан иткән. Берничә ел эчендә бу тирән хисле, гуманистик мәгънәле фикер бөтен дөньяга таралган. Сан-Франциско татарлары җәмгыятенең хатын-кызлар оешмасы да һәр елны май аенда әниләр көне уздырып килә. Ул җыелышка фәкать әниләр генә түгел, әле әни булмаган хатын-кызларыбызны да җәлеп итү максаты белән оешма әниләр көнен Ханымнар көне дип атауны уңышлырак тапты. Соңгы

елларда Ханымнар көненә мәхәлләбезнең барча хатын-кызлары чакырыла, чәйкаһвә эчерелә, бәлеш-татлылар белән кунак ителә. «Азат хатын» (хәзер — «Сөембикә») мәжмугасында әниләргә багышлап нәшер ителгән шигырьләрне сөйләп, милли җырларыбызны җырлап, ханым-туташларыбыз күңелле, мәдәниятле вакыт кичерәләр.

Шәрекъ кичәсе Оешмабызның 1963 елдан бирле ясалып килгән бу кичәсе 27 нче мәртәбәсендә 1990 елның ноябрь аенда шәһәрнең зур клубларыннан саналган «Эстәйт Рум»да зур уңыш белән ясалды. Бу кичәгә Төркиядән, Финляндиядән, Канададан, Нью-Йорк шәһәреннән вә Невададан килгән кунаклар бар иде. Мөһаҗәрәттәге халкыбыз Шәрекъ кичәсе дип аталган мондый тамашаларны беренче мәртәбә 1921 елда бөтен татар оешмалары катнашы белән Харбинда (Маньчжурия) уздырган иде.

1989 елда бабаларыбыз болгарларның ислам динен кабул итүләренә 1100 ел тулу мөнәсәбәте белән Татарстанда уздырылган бәйрәмгә Диния нәзарәте чакыруы буенча оешмабызның вәкилләре буларак идарә тарафыннан сайланган Шәмсия ханым Апакай белән Сәгыйть әфәнде Килки Татарстанга барып кайттылар.

Сан-Франциско татарлары оешмасына һәр ел әгъзалык акчасын түләп килгән милләттәшләребезнең 1990 елдагы саны 260 кешедән гыйбарәт. Идарәбезнең моңарчы хезмәт күрсәткән вә моннан соң да көчен бирәчәк рәисләренә, кәтип, казначыларына, бөтен әгъзаларына вакыт вә куәтләрен аямыйча сарыф итеп, урынлы-урынсыз һәм бигрәк тә нигезсез тәнкыйтьләргә бакмастан, оешмабызның яшәвен дәвам иттерүләре өчен рәхмәтләребезне белдереп, үзләренә һәм гаиләләренә сәламәтлек, озын гомерләр, барча эшләрендә тулы уңышлыклар телибез.

**Салих АПАКАЙ,**
Берлингәйм, Калифорния штаты, АКШ.

Айдар Мәмәт

# КЫРЫМ ТАТАРЛАРЫ

Кырым татарлары Кырымга XIII гасыр башында үтеп кергән монгол-татар басып алучыларының турыдан-туры варислары, дигән ялгыш караш безнең көннәрдә дә яшәп килә. Кызганыч ки, кырым татарларының килеп чыгуы турындагы мондый фикерләр кайбер тарихчыларның хезмәтләрендә дә, вакытлы матбугатта да еш чагыла. Мисалга, А. Бернштам: «Татарлар Кырымга XIII гасырда Алтын Урданың бер тармагы булган кыпчак урдалары сыйфатында үтеп керделәр»,— дип яза. «Кырым татарлары» туплан-масының каталогын төзүче Э. Тарчинская һәм Е. Кочетова: «Кырым татарлары — XIII гасыр башыннан алып Кырым ярымутравында яшәүче халыкларның берсе»,— дип расларга маташалар. Тарихчы Ю. Шмелев исә: «Дала кырым татарлары бар. Болары нугайларның нәсел-нәсәпләре. Көньяк яр буйларында яшәүчеләр — Кырымга Төркиядән килгән Анадулы төркиләре. Нугайлар — XIII гасырда Алтын Урда карачысы Нугай олысына кергән төрки һәм монгол ырулары нәселләре... Анадулы төркиләре — Көнчыгыш Төркестаннан Алтайга күчерелгән кабиләләрнең берсе»,— дип яза. Ул кырым татарларының килеп чыгышын менә шулай бик гади хәл итә дә куя. Аннары Шмелев: «Татарлар Кырым ярымутравына XIII гасырда күчеп килделәр»— дигән нәтиҗә чыгара.

Мондый караш, әгәр монгол-татарлар XIII гасыр башында Рәсәйнең көньягында һәм Кырымда җирле халыкны очратмасалар һәм андагы кавемнәрне тулысынча юк итсәләр, дөрес булыр иде. Мәгълүм ки, боларның берсе дә эшләнми. Киресенчә, монгол-татарлар Кырымда җирле төрки телле халыкларның, ягъни төркиләрнең һәм теле белән төркиләшкән һәм бик борынгы заманнардан ук монда яшәгән киммериялләрнең, таврларның, скифләрнең, сарматларның, аланнарның, готларның һәм башка халыкларның нык каршылык күрсәтүенә очрыйлар.

Кырым татарлары формалашкан җирләр, географик хәле, табигатенең байлыгы һәм төрлелеге аркасында, бик борынгы заманнардан ук төрле кабиләләр тарафыннан үзләштерелгән. Бу кавемнәр, үзара кушылып, яңа килгән күчмә ырулар белән аралаша һәм соңгылары, күршеләреннән күреп, акрынлап утрак тормышка күчә, үзләренекеннән шактый югары торган мәдәниятләргә якыная, аларның кабиләара бәйләнешләрдә яңа бер берәмлек барлыкка китереп, үзләренең телләрен бирәләр.

Кырымда яшәгән халыкларның иң борынгысы киммериялеләр булуын без антик чыганаклар буенча яхшы беләбез. Моны борынгы һәм урта гасыр тарихчылары да, хәзерге галимнәр дә раслый. Ярымутрауның көнчыгышында сакланып калган «Киммерия Боспоры», «Киммерия кичүе», «Киммерия стеналары», «Киммерик» кебек топонимик атамалар да шуны ук күрсәтә. Аларның көнчыгыш Европадагы хакимлеге безнең эрага кадәр II меңенче ел урталарыннан VII гасырга кадәр дәвам итә. «Бакыр һәм тимер гасыры башындагы казылма мәдәният безне киммерия кабиләсе тарихының иң борынгы көннәренә алып керә»,— дип яза А. Тереножкин.

Безнең эраның VII гасыр урталарында скифләр киммериялеләрне далалардан Кырымның таулы җирләренә кысрыклап чыгаралар һәм таврлар, тавр-скифләр исеме астында яшәп калалар. Кырымның таулы һәм яр буе җирләре — «Таврика», «Таврия», «Таврида» атамалары нәкъ менә шушы таврларга барып тоташа. Е. Крикун Кырымның таулы өлкәләрендә безнең көннәргә кадәр тавр-

Айдар МӘМӘТ (1944) — филология фәннәре докторы. Ташкентта яши.

ларның алачыклары һәм өйләре, аларның кромлехлары — вертикаль рәвештә утыртылган ташлардан ясалган божра рәвешендәге коймалары саклануын һәм аларның зират, ягъни таврларның «таш әрҗәләре»— табутлары булуын әйтә.

Геродотның хәбәр итүенә караганда, скифләр, Кырымның далалы җирләрен һәм Кара диңгезнең төньяк өлкәләренә якын төбәкләрне дә кертеп, Дунай һәм Дон елгаларының түбән агымнары арасындагы мәйданны билиләр. Скифләрнең Төньяк Кавказда яшәүләре хакында да мәгълүматлар бар. Геродот раслаганча, скифләр берничә кабиләгә бүленгәннәр. Алардан Днепр һәм Дон арасында яшәүче патша скифләре иң куәтлесе булган. Кырым далаларында һәм түбән Днепрнең уңъяк буйларында күчмә скифләр тереклек иткән.

Далаларда скифләр хакимлек иткәндә, безнең эраның VI — V гасырларында, Кырым ярында греклар үзләренең сәүдә колонияләренә нигез салалар. Мәсәлән, Пантикапей яки Боспор (хәзерге Керчь шәһәре) һәм Феодосия борынгы грек шәһәре Милеттән килгән халык, ә Севастополь чикләрендә урнашкан Херсонес шәһәре Понтий Гераклиясеннән чыккан греклар тарафыннан төзелә.

Безнең эраның V гасыр урталарында Керчь ярымутравы районында башкаласы Пантикапей булган колбиләүче Боспор дәүләте оеша. Антик Пантикапейнын акрополе Митридат тавына урнаша. Бу таудан ерак түгел урында археологлар атаклы Мәлик-Чесмә һәм Патша курганнарын казыйлар. Аларның эченнән таш табутлар, Боспор архитектурасына караган гаҗәеп һәйкәлләр табыла. Тикшерүчеләрнең әйтүенә караганда, бу курганнар безнең эрага кадәр IV гасырның икенче яртысында төзелгән булырга кирәк.

Боспор дәүләте составына шулай ук скифләр һәм синд-меот — кабиләләре яшәгән кайбер җирләр дә кергән. Бу дәүләтнең башында грекларның Археанактид ыруыннан чыккан хакимнәр тора, соңрак аларны грек һәм җирле Спартокидлар нәселе алыштыра.

Иң куәтле һәм чәчәк аткан заманында Боспор дәүләте скиф, сармат һәм башка дала кабиләләре белән киң бәйләнешләр урнаштыра. Грециядән һәм Кече Азиядән кайтарыла торган тукымаларны, металл әйберләрне, балчык савыт-сабаларны, зәйтүн маен Боспор сәүдәгәрләре терлеккә, икмәккә, мехларга, тире һәм башка товарларга алыштыру өчен далада яшәгән күршеләренә җибәргәннәр.

Безнең эрага кадәр III гасыр ахырына скифләр мәмләкәте сарматларның һөҗүмнәре нәтиҗәсендә шактый кечерәя. Скифләр башкалаларын Каменскидан Кырымга күчерергә мәҗбүр булалар һәм Салгир елгасы буенда (Симферополь тирәсендә) Скилур патша тарафыннан Неаполь шәһәренә нигез салына. Соңрак безнең эрага кадәр II гасырда Кырымдагы скиф патшалыгы чәчәк аткан дәүләткә әверелә. Сарматлар белән берләшеп, скифләр Ольвияне үзләренә буйсындыралар, төньяк-көнбатыш Кырымдагы Херсонес биләмәләренең бер өлешен яулап алалар һәм Боспор дәүләтенә каршы сугышалар, акрынлап аның шәһәрләренә күчеп утыралар һәм тышкы икмәк сәүдәсен үз кулларына төшерәләр.

Кырымдагы скиф дәүләте безнең эраның икенче яртысына кадәр яши, анары безнең эраның II гасыр ахырларында һәм III гасыр башларында Көнчыгыш Европадан (риваятьләргә караганда, Скандинавиядән) чыккан готлар тарафыннан юк ителә. Алар көньякта Кара диңгез буйларына, көнчыгышта Донның түбәнге агымына һәм көнбатышта Дунайга кадәр гаять зур җирләрне басып алалар.

В. Абаевның фикеренчә, киммериялеләр кебек үк, скифләр дә фарсы телендә сөйләшә. Борынгы авторлар сарматларны, аланнарны, роксаланнарны да шул телдә сөйләшкән дип раслыйлар. Кызганыч ки, бу телдә язылган тоташ текстлар безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән, ләкин сакланып калган этнографик һәйкәлләрне тикшерү һәм борынгы авторларның хезмәтләрендә кулланылган шәхси исемнәр, топонимнар һәм этнонимнар аны фарсы телләре белән генә чикләргә мөмкинлек бирми. Скиф кабиләләренең бер өлеше төрки телдә сөйләшүен хәзер байтак галимнәр таный.

Ләкин готлар монда озак тормыйлар. Һуннарның көчле һөҗүмнәре нәтиҗәсендә, алар IV гасырда Кырымның таулы һәм кеше яшәми торган өлкәләренә качарга мәҗбүр булалар. Готлар монда акрынлап тавр-скифләрнең нәселләре белән кушылалар һәм Кырымның кайбер төбәкләрендә яшәүче кырым татарларының формалашуында катнашалар. Ул заманнардан калган тарихи һәйкәлләргә «мәгарә шәһәрләре»не кертергә була. Алар Бакчасарай районында һәм Севастополь тирәсендәге кыялы тауларда урнашканнар.

Шулай итеп, һуннар бәреп кергәнче, Кырым халкының этник составы бик чуар була. Аңа киммериялеләр, таврлар, скифләр, сарматлар, аланнар, греклар

һәм готлар керә. Бу кавемнәр арасында үзара кушылу процесслары кызу барган дияргә нигез бар. Борынгы чыганакларда очраган «тавр-скифләр» һәм «скифтаврлар» дигән тәгъбирләр һәм археологик табылдыклар шул хакта сөйли. Соңгыларында борынгы грек мәдәнияте белән Кырымның җирле халкы мәдәнияте кушылуы үзен нык сиздерә.

Һуннарның көнбатышка үтеп керүе IV гасырның икенче яртысында башлана. Каспий тирәсендәге алан кабиләләренең каршылык күрсәтүен сындырып һәм аларны үз урдаларына кушып, алар алга таба баруларын дәвам итәләр һәм Кубаньдагы, Дондагы сармат авылларын һәм шәһәрләрен талыйлар. 370 еллар тирәсендә алан кабиләләре белән берләшеп һуннар, Баламбир җитәкчелегендә, Тамань ярымутравындагы Боспор дәүләте шәһәрләрен тар-мар итәләр һәм кыш җиткәч, Керчь бугазын боз өстеннән кичеп, аның башкаласы Пантикапейга һөҗүм ясыйлар. Боспор дәүләтен буйсындыргач, һуннар үзләре өчен бик тә майлы калҗа булган дала халыкларына ташланалар. Алар монда бай көтүлекләрне кулга төшерергә омтылалар. Менә шунда 371 елда һуннар белән готлар арасында бәрелеш була.

Остготларны тар-мар итеп һәм вестготларны Фракиягә кысрыклап, һуннар күп тапкыр Рим империясе чикләрен үтеп кереп, аның шәһәрләрен туздыралар. Һуннар юлбашчысының төп станы бу чорда каядыр Кара диңгезнең төньягында була. Рим илчесе Олимпиодорның әйтүенә караганда, һуннар юлбашчысының станына элләгер өчен, аңа Понт (Кара диңгез) аша кичәргә туры килә.

Һуннарның иң куәтле һәм чәчәк аткан заманы Атилла хакимлек иткән вакытларга туры килә һәм фәкать 451 елда Марне (Матроне) елгасы буенда атаклы Каталун сугышыннан соң гына һуннарның куәте кими башлый.

453 елда Атилланың үлеменнән соң һуннарның бөек дәүләте таркала. Һун кабиләләренең бер өлеше (сцирлар, сарагурлар һәм аланнар) Дунай һәм Кара диңгез буйларында калалар, ә икенчеләре Шәрыкка, Урта Азиягә күчеп китә. Аларны анда «ак һуннар» (эфталитлар) дип атыйлар.

Һун кабиләләре берлеге таркалса да, Боспор һәм аның тирәсендәге җирләр, монда башка төркиләр килгәнче, ягъни VI гасыр ахырына кадәр, һуннар кул астында кала. А. Якобсон күрсәткәнчә, алар монда Y гасырның икенче яртысында аеруча көчәеп китәләр. Бу хәл һун урдалары Дунай буе өлкәләреннән Азов буйларына һәм Таврикага агыла башлагач була.

Һуннарның яулап алулары Көнчыгыш Европаның көньяк төбәкләрен тамырыннан үзгәртә. IV гасырдан башлап Кырымның далалы җирләрендә, фарсы телендә сөйләшүчеләрне тәмам эретеп, төрки кабиләләре өстенлек итә башлый. Төркиләрнең һәм угырларның Көнчыгыш Европада бүтән кавемнәр белән кушылуы яңа халыклар һәм яңа этник төбәкләр барлыкка китерә. Шулай итеп, элеккесеннән шактый нык аерылып торган һәм башлыча безнең көннәргә кадәр килеп җиткән Көнчыгыш Европаның яңа этнографик картасы туа. Академик А. Куник Кара диңгез буенда һун яулап алуларыннан соң төрки элементының ачык чагылуын билгеләп үтә.

Кырым татарларының төрки бабалары арасында эреп юкка чыккан фарсы телле кавемнәр үзләреннән соң күпсанлы сүзләр, грамматик һәм синтаксик калыплар калдыра. Алар Кырым татарларының аерым бер өлешенә мәгълүм күләмдә антропологик һәм мәдәни йогынты да ясыйлар. Кырым татарлары телендәге фарсы алынмалары кеше эшчәнлегенең иң мөһим өлкәләрендә кулланылалар: 1) географик атамалар: җиһан — дөнья, галәм; дәрья — диңгез, елга; зәмин — туфрак; 2) хайван һәм кош атамалары: сансар — тиен, керкедән — мөгезборын, самур — кеш; 3) анатомик атамалар: пәнҗә — биш бармак, чырай — йөз, кыяфәт, җигәр — бавыр; 4) вакыт, атна көннәренең календарь атамалары: баһар — яз, чәршәмбе — чәршәмбе, һәфтә — атна; 5) бакчачылык атамалары: бостон — бакча, чөгендер, хыяр — кыяр, төреп — торма; 6) төзелеш әйберләре: такта, мых — кадак, җәм — пыяла; 7) идарә һәм сугыш атамалары: пайтәхет — башкала, зиндан — төрмә, җин — сугыш; 8) һөнәр атамалары: багчаван — бакчачы, дулгәр — балта остасы, әмширә — шәфкать туташы; 9) сәүдә атамалары: базарган — сәүдәгәр, пара — акча, сәрмәя — байлык; 10) көнкүреш әйберләре: келәм — келәм, пәрдә — пәрдә, чувал — капчык һ. б.

Фарсы алынмаларының яңа мәгънәне аңлатуда кулланылуы, яңарыш җирлегендә аларның беренчел мәгънәсе үзгәрү, төп төрки һәм кырым татарлары телендәге башка сүзләр белән синонимик, омонимик һәм антонимик мөнәсәбәтләргә керүе иран кабиләләренең кырым татарлары хәятенә бик борынгы заманнарда, бу тел әле калыплана башлаганда ук зур йогынты ясавы хакында ачык сөйли.

VI гасырда һуннар державасының хәрабәләрендә күчмә кабиләләрнең яңа берләшмәсе — аварлар күтәрелә. Аларны борынгы заманнарда һуннар союзына кергән көньяк кавемнәрнең тарихи варислары дип әйтергә мөмкин. Аварлар артыннан көньяк далаларына һәм Кырымга болгарлар, хазарлар һәм бүтән төрки ырулар үтеп керә.

VII гасырның икенче яртысында хазарларның хакимияте Азов, Каспий диңгезләре арасындагы далаларга гына түгел, бөтен Кара диңгезнең төньягына җәелә. Йосыф патша хатында хазарларның болгарларны Дунайга кадәр куып барулары телгә алына.

Византия Кырымда тамыр җибәрү өчен җан-фәрман тырыша, ләкин ул чакта гарәпләр белән сугышканга, Херсонны аның авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче төбәкләреннән аерып, Кырымга үтеп кергән һәм аның далалы җирләрен генә түгел, ә көньяк өлкәләрен дә яулап алган хазарларга тиешле каршылык күрсәтә алмый.

IX гасырның икенче яртысында көнчыгыш Европада башланып киткән сугышлар Хазар каганатын көчсезләндерә. Бу хәлне мажарлар оста файдалана. Алар Идел арьягыннан Кара диңгез буйларына бәреп керә һәм IX гасырның 60 нчы еллары башында Кырымга аяк басалар. Аларны монда Хазарстанга юл тоткан Константин Философ очрата.

Мажарлар артыннан көньяк далаларында бәҗәнәкләр дә күренә. 895 елда болгарлар белән берләшеп, алар мажарларны тар-мар итә. «Хазарларның бәҗәнәкләргә каршы аерым яулары никадәр генә уңышлы булмасын,— дип яза М. Артамонов,— алар соңгыларын тәмам тар-мар итеп, яулап алган өлкәләреннән кысрыклап чыгара алмыйлар... X гасырда Кара диңгез буеның төньяк төбәкләре хазарлар контроленнән чыга».

Ләкин бәҗәнәкләр дә көньяк далаларында озак яши алмый. Төркиләрнең (угыз), славяннарның һәм, ниһаять, кыпчакларның кысрыклавы нәтиҗәсендә, бәҗәнәкләр Дунай буйларына күченеп китәргә мәҗбүр була, аларның калдыклары XII — XIII гасырларда кыпчаклар белән кушылып бетә.

XI гасыр уртасында Кара диңгез буендагы далаларда яңа төрки телле халык — кыпчаклар (куманнар) күренә башлый. Угызларны һәм бәҗәнәкләрне җиңеп, кыпчаклар Көнчыгыш Европа һәм Көнбатыш Себер далаларында тулаем хакимлеккә ирешәләр һәм XI гасырдан башлап бу җирләр Кыпчак далалары яки Дәште-Кыпчак дип йөртелә башлый. Кыпчаклар тау тезмәләренә кадәр Кырымның бөтен далалы өлешен билиләр. Бу хакта шушы җирләрдә табылган топонимик атамалар һәм күпсанлы тамгалар сөйли.

Кыпчак ташкыны эчендә калган борынгы сармат-алан кабиләләренең, хазарларның, бәҗәнәкләрнең, угызларның калдыклары сәяси мөстәкыйльлекләрен һәм этник үзенчәлекләрен югалталар һәм Көнчыгыш Европаның далалы төбәкләрендә формалашкан халыклар сафына кереп бетәләр. Әле хазарларга кадәр үк сармат-аланнарның токымнары төркиләшкән була һәм төрки телдә сөйләшәләр. Бу хакта Салт мәдәниятенең бик тә үзенчәлекле һәйкәле булган Маяк шәһәрчеге диварларындагы язулар һәм ташка уеп язган тамгалар бик ачык сөйли. Алар төрки-орхон хәрефләре белән язылган һәм төркичә укылалар. Шул рәвешле, Салт мәдәниятенә караган халык ул заманда фарсыча түгел, ә төрки телдә сөйләшкән.

XIII гасырның беренче яртысындагы монгол-татарлар кыпчак җирләрен тулысынча яулап ала. Монгол-татарлар Кырымга 1223 елда үтеп керә һәм Судак шәһәрен тар-мар итә. Судакка икенче һөҗүм 1239 елда була. Бу һөҗүмнәрне алар һәр очракта да хакимлекләрен урнаштыру өчен генә түгел, ә беренче чиратта аларның абруйларын инкарь иткән җирле хакимнәрне акылга утырту өчен оештыралар. «Татарлар Таврияга кергәндә, анда фәкать бу халыкның олуг бәк исемендәге кенәзләре генә төпләнеп кала»,— дип яза С. Богуш. Бу хәл дә монголларның Кырым хакимнәре арасында бик аз санда булуын күрсәтә.

Кырымның халкы яулап алучыларга каршы күп тапкырлар баш күтәрә. 1299 елда Каф (Феодосия) шәһәре кешеләре бабасы Нугай тарафыннан Кырымга ясак җыярга җибәрелгән Актаҗны үтерәләр. Бу хакта ишетеп, Нугай Кырымга зур чирү җибәрә. Соңгысы Кафны алып, аны яндыра, бик күп кырымлыларны һәлак итә, анда булган мөселман, алан, франк сәүдәгәрләрен әсир ала, малларын кулга төшерә, Сары Кирмәнне, Кырык Җирне (Чуфут-кала), Керчьне талый. Алтын Урда ханнарының куәте озакка бармый. Инде XV гасырның беренче яртысында Алтын Урда мөстәкыйль дәүләтләргә таркала. 1420 еллар башында Себер ханлыгы, 1440 елларда — Нугай Урдасы, шул заманда ук Казан һәм Кырым ханлыклары, ә 1460 елларда — Казакъ, Үзбәк һәм Әстерхан ханлыклары оеша.

Алтын Урда дәверендә үк Кырымдагы татар-монголларның калдыклары

төрки тел тәэсиренә дучар була һәм тәмам төркиләшә. Бу Кырымда татар-монголлар яуларына кадәр үк төрки һәм телләре төркиләшкән җирле халыкның яшәве белән аңлатыла. Шунысы кызык, монгол теленең кырым татарлары теленә йогынтысы юк дәрәҗәсендә була. Кырым татарларының сөйләменә ясалган анализ монда монголдан алынган сүзләрнең утызлап кына булуын күрсәтте.

XVI гасырдан Перекоп муеныннан һәм Бессарабиядән төньякка таба акрынлап кына булса да тотрыклы нугай халкы калыплана башлый. Үз хакимнәренең сәясәтеннән риза булмаган, тәхет өчен узара сугышлардан туйган, иген уңмаудан иза чиккән нугайларның Иделдән һәм Төньяк Кавказдан күченеп утырулары XVII—XVIII гасырларга кадәр дәвам итә. Төркия җирләренә күчәргә ниятләп, алар узган йөзнең ахырында Төньяк Кавказдан чыгып китеп Кара диңгезнең төньяк яры буйлап Көнбатышка юл тоталар. Кече Азиягә соңгы мәртәбә күченгәннән соң кире кайтып Куят авылына утырган берничә дистә гаиләдән кала, Таврия губернасында нугайлар тәмам юкка чыга. Мондагы халыкның нигезен алар да, монголлар да түгел, ә шушында күп гасырлар буена яшәп килгән төрки кабиләләр тәшкил итте. Кырымдагы дала халкының төп өлеше формалашу Хазар каганаты таркалу һәм кыпчакларның көньяк далаларга һәм Кырымга үтеп керүләре дәверенә, ягъни X—XI гасырларга туры килә.

Хәзерге кырым татарлары теленең төп сыйфатлары да шул хакта сөйли. Н. Баскаков, үзенең төп диалектлары буенча кырым татарлары теле кыпчак телләренең кыпчак-куман төркемчәсенә керә, дип саный. Бу телнең башка төрки телләр арасындагы урынын билгеләп, карачай-балкар, комык һәм караим телләре белән бергә, аны К. Мусаев көнбатыш кыпчак төркеменә кертә. Кырым татарлары сөйләменең лексик-семантик һәм структур-грамматик анализы, тарихи җирлектә чагыштырганда да, күп елларга сузылган төрек йогынтысына карамастан, хәзерге кырым татарлары телендәге төп катламны кыпчак сөйләме тәшкил итә дияргә нигез булып тора.

Туган телендә сөйләшүче кырым татар халкын сыйфатлаганда тикшерүчеләр физик типлары, тел үзенчәлекләре, торак төзү рәвешләре, кием-салымнары һәм шөгыльләре белән үзара аерылып торган өч төп төркемне күрсәтә.

Беренче төркемгә килеп чыгышы ягыннан төрле борынгы кабиләләрне— киммериялеләр, греклар, римлылар, генуялыларны, шулай ук Кырымга XII гасырда күчеп утыра башлаган төрекләрне кертәләр. Гәүдә-кыяфәт ягыннан көньяк яр буйларында яшәүче татарлар даладагыларыннан монголларга хас билгеләрнең булмавы белән аерылып тора. «Көньяк татарлары,— дип яза В. Львович,— озын буйлы һәм таза бәдәнлеләр, барлык көньяк кешеләренеке кебек үк, йөзләре кара тутлы, битләре озынча һәм сөйкемле, борыннары туры, еш кына римлыларныкына һәм грекларныкына охшаган, чәчләре һәм күзләре чем кара».

Көньяк яр буйларында яшәүче кырым татарларының телендә угыз элементлары өстенлек итә, шуңа күрә тикшерүчеләр төрки телләрне классификацияләгәндә, аларның телен көньяк (угыз) төркеменә кертә. Б. Куфтин болай дип яза: «Көньяк яр буйларындагы татарларның сөйләме Кырымның башка татарлары теленнән аларда госманлы төрекләре йогынтысы көчле булуы белән аерыла... Алупка, Ялта, Гурзуф татарлары чиста төрекчә сөйләшәләр, ләкин Судак районындагы таулы авылларда яшәүче татарларда шивә үзенчәлекләре бик көчле. Мәсәлән, йомшак «к» ны «г» белән, каты «к» ны «х» белән алыштыралар. Өлешчә моны Анадулы сөйләмнәренең тәэсире белән аңлатып була». Шунысы гыйбрәтле, алда күрсәтеп үтелгән фонетик сыйфат, шактый гына өлеше 1778 елда Кырымнан Мариупольга күчерелгән җирле грек халкының сөйләменә дә хас булган.

Кырымның тау алды һәм далалы өлкәләрендә яшәүчеләр көньяк яр буйларында көн күрүчеләрне татлар дип атаганнар. Б. Куфтинның күзәтүләренә караганда, элеккеге генуя колонияләренә караган Судак районындагы Ускют, Шилен, Ай-Серез кебек авылларда яшәүчеләр үзләрен шулай дип йөриләр. Кырым татарларында татларны үҗәт, тыңлаусыз кешеләр итеп күрсәткән мәкаль дә сакланып калган. «Таттыр—инаттыр», ягъни тат—кире, үҗәт. Хәзерге вакытта тат исеменең килеп чыгуы хакында берничә фараз йөри. Безгә калса, алар Кырымның таулы өлкәләрендә төркиләшеп киткән фарсы телле кабиләләрнең калдыклары булса кирәк.

Көньяк яр буйларындагы кырым татарлары, башлыча, диңгездән ерак булмаган авылларда яшәгәннәр. Аларның яссы түбәле сакля рәвешендәге йортлары баскыч-баскыч урнашкан була. «Көньяк яр буйларындагы авылларның үзенчәлеге,— дип яза Б. Куфтин,— үзләренең килеп чыгулары буенча гомум төрки дала рәвешенә кайтарып та гот, алан, скиф кабиләләре йогынтысы белән дә

аңлатыла алмый. Аларны Кырым җирлегеннән эзләргә кирәк. Көньяк яр буйларындагы корылмаларның Кавказ арты һәм Кече Азиянеке белән охшаш булулары, аларның Кырымда барлыкка килүләрен һәм үсеш алуларын монда бөтен Урта диңгез буйларының борынгы этник тарихы белән бәйле скифлар һәм беренче грек колонияләре калдырган мәдәни катламнардан эзләргә этәргеч бирә».

Кырымның таулы һәм тауларга якын төбәкләрендә яшәүче кырым татарлары икенче төркемгә керә. Аларның формалашуында таврлар, скиф, алан, гот, һун, хазар, генуялылар һәм өлешчә монгол яулары аркасында тауларга качкан кыпчаклар катнаша. Палласның раславынча, таулы Кырымда озынча йөзле, кәкрәеп торган озын борынлы, як-яктан тарайган башлы, җирән һәм көрән чәчле аерым кешеләр очрый. Галимнәр аларны гот кавеменнән дип исәпли. «Кырым тауларының төньяк итәкләрендә һәм аларга якын үзәннәрдә яшәүче таулы татарлар нугайлардан күп аерылып тора,— дип яза В. Львович.— Алар озын гәүдәле, нык бәдәнле, житез һәм көчле кешеләр. Йөз чалымнары Кавказ кабиләләренә хас ак, күзләре зур һәм кара, чәчләре һәм сакаллары куе һәм кара».

Кырымның таулы өлкәләрендә яшәүче татарларның аерым вәкилләрен әлегә кадәр каторитлар (готфритлар) дип йөртәләр.

Монда сүзнең беренче өлеше гот этнонимы булса кирәк.

Кырымның тау итәге һәм таулы төбәкләрендә яшәүче кырым татарларының теле анда угыз сөйләме һәм грамматик формалары белән бернәттән кыпчакныкын файдаланылу белән дә аерылып тора.

Кырымның далаларда яшәүче халкы өченче төркем исәпләнә. Аның составына башлыча күчмә кыпчак кабиләләре һәм шулай ук алар белән кушылып киткән хазарларның, бәҗәнәкләрнең, угызларның (төрекләрнең), татар-монголларның һәм нугайларның калдыклары керә. Кырымның далалы районнарындагы борынгы авыл атамаларында монда калыплашкан кавемнәрнең — ыруларның һәм кабиләләрнең исемнәре сакланып калган. 1865 елда басылып чыккан Кырым өязе Таврия губернасы авыллары исемлегендә (Ялтадан кала) биш мәртәбә найман һәм аргын, дүрт тапкыр коңрат, өч мәртәбә кыпчак, алчын һәм кытай, икешәр тапкыр каңлы, алач һәм тама атамалары очрый. Моның өстенә шул ук исемнәр һәм кирәй, кирәят, кыргыз-казакъ атамалары да катлаулы авыл исемнәре составына кергән. Мәсәлән, «Бүз углы кирәят», «үнгәр-найман», «карт казакъ» гыйбарәләре. Бу кабилә вәкилләренең варислары казакъ, кыргыз, каракалпак һәм үзбәк кебек халыклар арасында да очрый. Бу исә Кырым далаларында яшәүче татарларның Урта Азия халыклары белән тарихи һәм кан кардәшлегенә ишарә ясый.

Далаларда яшәүче кырым татарларының этник составын тәгәл ачыклау өчен бу төбәкләрдә табылган тамгалар да шактый бай материал бирә. Алар кабер ташларында табылды. Бу һәйкәлләрдә мәетнең туу һәм вафат булу еллары юк. Фәкать ташка чокып язылган тамга гына гүр иясенең кайсы ырунықы яки олысынықы икәнен күрсәтеп тора. Бу тамгалар аларның сангур, карлык, каңлы, найман, кыят, кәнәгәс, кыпчак, аргын, алчын, коңрат, кирәят кебек борынгы төрки ыруларыннан һәм кабиләләреннән булганлыгы хакында сөйлиләр. Алда санап үтелгән ырулар һәм кабиләләр Кырымда утрак тормышка күчәләр һәм ярымутрауның төньяк төбәкләрендә яшәүчеләр белән бергә монда формалашкан халыкның үзәген тәшкил итә.

Кырымның көньяк яры буйларында һәм үзәк районнарында кабер ташларына тамгалар салынмаган. Тамга бу җирләргә сатып алынган хайваннар белән бергә далалардан китерелгән һәм фәкать үз терлеген башканыкы белән бутамас өчен генә файдаланылган. Алда билгеләп үтелгәнчә, монгол-татарлар Кырымда хакимлек иткән даирәләр сафына юк дәрәҗәсендәге юка катлам булып кына кергән. Шуңа күрә, халыкның тарихын аның этнонимы белән бутарга кирәкми. Кырым татарлары чын исемнәрен үзләре җир йөзендә яшәүләре дәвереннән күпкә соңрак алганнар. Ләкин бу хәл аларны элгәреге тарихыннан һич тә мәхрүм итәргә тиеш түгел. Кырым татарлары Кырымда фәкать XIII гасырда гына яши башлаган дип санау — үткәнне бозып күрсәтү. Болай дип уйлау тарихи вакыйгалар һәм күренешләрне гадиләштерү һәм саташтыру дигән сүз.

Димәк, кырым татарлары дигән халык шундый исемнән күпкә иртәрәк барлыкка килгән бик борынгы заманнарда ук монда яшәгән төрле кабиләләрдән һәм ырулардан формалашкан. Шул ук вакытта, башка халыклар кебек, кырым татарлары калыплашуда күчеп утыру, бер этник төркемнең икенчесен яулап алуы, аларның үзара кушылуы юлы белән дә барган.Аңлашылмаучанлык килеп чыкмасын өчен, Кырымны акрынлап үзләштергән төркиләрнең җирле халыкны

моннан беркайчан да тулысынча кысрыклап чыгармавы, кырып бетермәве, ә алар белән кушылып, этник һәм тел җәһәтеннән үзгәргән, яңарган халык барлыкка килүен билгеләп үтәргә кирәк.

Телләре һәм мәдәниятләре уртаклыгына карамастан, хәзерге кырым татарлары, үзләрен барлыкка китерүче ата-бабалары, ыруларына карап, физик рәвешләре белән аерылып торалар.

Көньяк яр буйларында һәм таулы өлкәләрдә яшәүче татарларның этник нигезен киммерия, тавр, грек, скиф, алан, гот һунн, генуя һәм өлешчә хазар, кыпчак һәм сәлҗүк төркләренең нәселләре тәшкил итә. Тарихи чыганаклар, археологик һәм антропологик тикшеренүләр, тел һәм этнография мәгълүматлары да шуны ук раслый.

Кырымның далалы өлкәләрендә формалашкан татар халкы составына башлыча хазарларның, бәҗәнәкләрнең, татар-монголларның һәм нугайларның (Автор бу халыкларның күп ыру, кабиләләрдән торуын, алар арасында кыпчаклар да булуын исеннән чыгара.—Редакция.) калдыкларын эреткән кыпчак кабиләләре керә. Кырымның төньягындагы иске топонимика, шул җирләрдә табылган тамгалар һәм телгә кагылышлы истәлекләр дә шул хакта сөйли. Хәзерге кырым татарлары әдәби теленың нигезендә угыз йогынтысына юлыккан кыпчак сөйләме ятуын билгеләп үтәргә кирәк.

Кырым татарлары, аларның теле килеп чыгуы белән кызыксынучы укучылар соравына тулы дөрес һәм камил җавап бирү әлегә мөмкин түгел. Бу, беренче чиратта, аларны тарихи, антропологик, этнографик һәм башка җәһәтләрдән җитәрлек өйрәнмәү кырым татарлары үткәненә карата әлегә кадәр яшәп килгән карашларның чын фәнгә нигезләнмәве белән аңлатыла. Шуның өчен бу мәкаләне татар укучылары кырымлы кардәшләре һәм аларның телләре белән таныштыруда беренче омтылыш дип кенә кабул итсен иде.

**Фоат Вәлиев,**
тарих фәннәре докторы, профессор

# СЕБЕРДӘ ИСЛАМ

Хәзерге буын Себер татарлары ата-бабаларының ислам динен кайчан кабул итүләре һәм аның үз мәдәниятләре үсешендә тоткан урыны турында тулырак беләселәре килә. Аларның бу табигый теләкләре бүген илебездә барган үзгәртеп кору, җәмгыятьне һәрьяктан яңарту чорында югары дәрәҗәгә күтәрелде.

Хәзерге Тубыл-Иртеш (Төмән, Тобол, Тара) татарларының бабалары ислам динен Идел буе болгарларына караганда 5-6 гасырга соңрак, тик XIV гасыр азагында гына кабул иткәннәр.

Ә Себер татарларының бер төркемен тәшкил иткән Бараба татарлары арасында исә ислам тик XVIII гасырда гына тарала башлаган. Моңа кадәр аларда нигездә мәҗүсилек хөкем сөргән. Бу мәзһәбдә торган татарлар һәм казакълар шаманнарны «кам» дип атаганнар. Себер татарларының дини инануларында ислам динен тоткан башка халыклар арасында очрый торган борынгы, исламга кадәр яшәп килгән диннәрнең (зороастризм, анимизм, фетинизм һ.б.) калдыклары сакланган. Мәсәлән, аларның сөйләү телендә «алла» мәгънәсендә йөргән «тәңре» атамасы киң кулланыла. Бу атама күк тәңре, тәңридәм формаларында еш кына борынгы төрек язу истәлекләрендә очрый. Себер татарлары һәм башка күп төрки халыклар һәрвакыт диярлек тәңре сүзе белән бергә алла мәгънәсендә ходай (хотай) сүзен дә кулланалар. Күренекле совет этнографы С. В. Иванов язуы буенча «ходай» дип саян-алтай төрекләре христианнар алласын да атыйлар.

Себер татарларының күпчелеген тәшкил иткән Тубыл-Иртеш татарлары арасында ислам динен Бохара һәм Хива якларыннан XIV гасыр ахырында килгән дин әһелләре (шәехләр) тарата башлаган. Бу дата Себер татарлары тарихына, этнографиясенә багышланган хәзерге әдәбиятта Тубыл шәһәре музее китапханәсенең кулъязмалар бүлегендә сакланган татарча язылган ике кулъязмага таянып күрсәтелә. Ул кулъязмалар — элек кемнеңдер кулында сакланып килгән документның күчермәләре. Күчермәләр исә тубыл татарлары Рәҗәп Мәмәт улы Сәгъде-Ваккас Аллакулов һәм Әбүсәгыйть улы Кашшаф исемле кешеләр тарафыннан эшләнгән. Үз вакытында бу кулъязмалар көнчыгышны өйрәнүче галим Н. Ф. Катанов тарафыннан асыл нөсхәсендәгечә татарча һәм рус теленә тәрҗемә итеп бастырылган[1].

Әлеге кулъязмаларда күрсәтелгәнчә, 1394 елда (мөселман календаре буенча 797 елда) Бохарадан 336 атлы шәех һәм Шәйбани хан кулы астында 1700 сугышчыдан торган атлы гаскәр Иртеш буйларына, хәзерге тубыл татарлары яшәгән җирләргә килеп чыга. Болар Бохарада мистик хуҗа Баһаутдин Нәкышбәнди (1318 — 1389) тарафыннан мәҗүси халыклар арасында ислам динен тарату һәм аның сафлыгы өчен көрәшү максаты белән төзелгән дини мәзһәп әгъзалары булып, себер татарларын, шулай ук анда яшәгән башка мәҗүси халыкларны ислам диненә өндәгәннәр, ә инде үз ирке белән исламны кабул итәргә теләмәгән халыкларга каршы шәфкатьсез сугышлар ачканнар. Бу сугышларда Шәйбани ханның 1700 сугышчысыннан 1448

---

[1] Катанов Н. Ф. О религиозных войнах учеников шейха Багаутдина против инородцев Западной Сибири. «Ученые записки Казанского университета», 1903. китап 12. Бит 133 — 146.

кеше, 336 шәехтән 300 е һәлак була, ә исән калганнары Бохарага кайтып китәләр. Һәлак булган шәехләр Төмән өлкәсенең Тубыл, Дубровно, Вагай, Яркәү районнарында, Омск өлкәсенең Ишемтамак һәм кайбер башка районнарында күмелгәннәр. Шул урыннарны татарлар «астана» дип атаганнар. Бу сүз иран сүзе булып, изгеләр яткан урын төшенчәсен аңлата.

Югарыда санап үткән районнарда 39 астана табылган һәм аларда күмелгән байтак шәехләрнең исемнәре дә билгеле. Мәсәлән, Себер ханлыгының баш каласы булган Искәр шәһәрендә һәм аның тирәсендә Айкани, Бири, Назар, Ширбәти шәехләр, Хуҗайлан авылында Муса Шәех, Колларда — Йосыф, Вагайда — Касыйм, Супрада — Әхмәт Гали, Тибендедә — Әнҗиран, Ишемтамакта — Бигәч-Ата шәехләр күмелгән.

Менә инде берничә гасыр буе астаналар мөселманнар өчен изге, кадерле булып саналып килә, хәтта аларны саклап карап торучылар да булган. Аларны «астана тотучылар» дип атыйлар. Димәк, Себер татарлары арасында ислам башта көчләү ысулы белән таратылган. Моны Бохара һәм Хива феодаль дәүләтләрендә хакимлек иткән даирәләрнең себер халыкларын, шулар эчендә себер татарларын, үзләренең сәяси һәм икътисади сферасына алырга теләүләре, шул уңайдан ислам дине таратучы шәехләрдән дә файдаланырга тырышулары белән аңлатырга мөмкин. Соңрак, аеруча Себер ханлыгында Үзбәк ханнары Шәйбанилар династиясеннән чыккан Күчем хан хакимлек итә башлаган елларда (Себергә Ермак походы башланганга кадәр) Себер татарлары арасында ислам чагыштырмача тыныч ысул белән тарала башлый.

Бу чорда Себердә ислам диненең таралуында Себер татарларының эчке иҗтимагый-сәяси шартлары төп рольне уйнаган. XVI гасырның икенче яртысында Себер ханлыгы мөстәкыйль феодаль дәүләт булып җитешә. Ләкин бу дәүләт әле вак-вак биlекләргә бүленгән була. Мәсәлән, Ермак килгәндә Тавда елгасы тамагында Бабахәсән Морза, Карачын авылында Карача Морза, Сүкләм елгасы буенда Сүкләм Морза һ.б. хакимлек итә. Вак биләкләр исә ханга буйсынмаган. Ханлыктагы сәяси таркаулык, ыруглык төзелеше калдыклары — мәҗүсилек үзәкләштерелгән дәүләт төзүгә, аны ныгытуга комачаулык ясаган. Ислам үзенең бер аллага ышану, мөлкиягә буйсыну идеяләре белән ыруглык мөнәсәбәтләрен җимерү һәм феодализмны ныгыту максатларына тулысынча җавап бирә. Менә шуның өчен Күчем хан Бохара ханы Габдуллага (1557 — 1598) Себердә ислам динен таратуда ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Күчем ханның бу үтенечен канәгатьләндерү йөзеннән Габдулла хан 1572 елда Төркестан шәһәрләреннән берничә кешедән торган югары даирә дин әһелләрен Искәр шәһәренә җибәрә. Алар арасында исеме тубыл татарлары хәтерендә безнең көннәргә кадәр сакланган Ширбәти шәех тә була. Аның белән бергә байтак ахуннар, морзалар килә. Күчем хан бу кешеләрне хөрмәт белән каршы алып, хәтта үзенең Нолишханыш исемле кызын Хәрәземнән килгән Дингали хуҗа дигән руханига хатынлыкка бирә.

Күчем хан ислам динен таратуда күп иҗтиһад итсә дә, биләмәсендә яшәгән барлык халыкларны да хак дингә кертә алмаган. Искәрдән ерак булган урыннарга мөселман голәмәләре бара алмавы сәбәпле, андагы халыклар, мәсәлән, ханты-мансиларның күпчелеге мәҗүсилектә калганнар. Хәтта Иртеш буендагы кайбер татар кабиләләре, Себер ханлыгы үзәгеннән еракта булулары сәбәпле, исламны ханлык чорында кабул итмәгәнәр. Шундыйлардан Тара елгасы тамагында яшәгән аялы татарларын күрсәтергә мөмкин. Тура елгасының уң ягыннан коя торган Ница елгасы буенда яшәүчеләр 1639 елда да мәҗүсилектә булганнар. Ә бараба татарлары ислам динен тик XVIII гасырда гына кабул иткәннәр. Сәяхәтче, этнограф, натуралист И. Г. Георгиның язуы буенча, алар арасында ислам динен әкренләп, яшерен рәвештә татар муллалары тараткан.

Себергә ислам барып керүнең икенче юлы Казан ханлыгы аша була. Әлбәттә, ислам диненең Себергә Идел болгарлары аша барып керү мөмкинчелеге турында да фикер йөртергә мөмкин. Моны беркадәр исбатлый торган дәлилләр дә китерергә була. Мәсәлән, болгар галимнәренең күк җисемнәрен өйрәнү өчен ерак төньякларга кадәр барып чыгулары һәм Урал таулары аша үтеп Себер якларына, Обь елгасы буйларына җитүләре турында мәгълүматлар бар[1]. Хәтта, Себер татарларының борынгы бабалары арасында ислам Идел буе Болгар дәүләтенә Багдад шәһәреннән килгән илчелек составында булган гарәп руханилары тарафыннан таратылган булуы мөмкин, дигән караш та чынбарлыкка якын, чөнки гарәп сәүдәгәрләренең егерме дөя белән Йәнәсәй елгасы ярларына китүләре билгеле. Шулай да без монгол яуларына кадәр булган дәвердә болгарлар Себер халыклары арасында ислам дине

---

[1] Даркевич В. П. Аргонавты Средневековья. Наука: М. 1976. 786.

таратканнар дип кисеп әйтә алмыйбыз, чөнки әлегә бу фикерне тулысынча раслый торган конкрет дәлилләр җитәрлек түгел.

Ә инде Идел болгарларының варислары булган Казан татарларының Себердә ислам динен таратуда катнашуларын раслый торган ышанычлы тарихи мәгълүматлар бар.

Себер татарлары белән Идел буе татарлары арасында булган бәйләнешләр Көнбатыш Себерне Рус дәүләте яулап алганга кадәр үк башланган. Себер елъязмасында Себер татар аксөякләре эченнән чыккан, легендар Тайбуга хан ыруыннан күтәрелгән Төмән ханнарының Казан ханнары белән династик элемтәдә булулары турында язылган. Мәсәлән, Тайбуга ыруыннан булган Мар (Гомәр) ханның Казан ханы Упакның сеңлесенә (яки кызына) өйләнгәнлеге турында язылган. Дөрес, Казан ханнары арасында Упак исемле хан очрамый. Һади Атласов Упакның «Идел һәм Яик арасында ханлык итүче бер кечкенә хан булуы мөмкиндер»,— дип яза. Аерым вакытларда Себер (Төмән) ханлыгының буйсынып торуы да билгеле.

Ә 1496 елда Казан тәхетенең Себер морзасы Мамыкның кулына төшүе, ләкин тиз арада аңа каршы баш күтәргән Казан халкы тарафыннан куылганлыгы турында да мәгълүматлар бар.

Себер ханлыгы башына Күчем утыргач, (1563 елдан соң) аның чакыруы буенча Себергә Казаннан еш кына югары катлау мөселман руханилары килә башлый. Алар әле ислам динен кабул итеп өлгермәгән татарлар һәм төньяк халыклары (ханты, мансилар) арасында ислам динен тарату максаты белән, хәзерге вакытта да яз һәм җәй айларында баруы читен булган Лаймы, Носка, Алымка елгалары буенда урнашкан «Сазарты» татар авылларына да барып чыкканнар[1].

Себердә ислам динен таратуда Казан татарларының тоткан урынын өйрәнгәндә урыс тарихи чыганакларында очрый торган мөселман рухание мәгънәсендә йөргән абыз сүзе билгеле бер кызыксындыру тудыра. Мәсәлән, 1682 елда Иртеш буендагы татар авылларының халык санын язу кенәгәсендә берничә казан татарларының исемнәре «абыз» кушаматы белән теркәлгән. Мәсәлән, шулар арасында абыз Айтуганов, абыз Ишбулла Корбанов, абыз Ишмәй Уматчаев дигән кешеләр бар[2]. Татар телендә абыз сүзе төрле мәгънәдә кулланылса да, нигездә дин әһеле мәгънәсен аңлаткан. Кайбер авторлар абыз сүзен гарәп телендәге хафиз сүзенә бәйләп, галим, белемле (рухани) шәхес шулай ук Коръәнне яттан белүче мәгънәсендә дә кулланалар. XIX гасырның алтмышынчы елларында тубыл татарлары «абыс» дип гыйбадәт вакытында мәчеттә хезмәт итүче кешеләрне атаганнар.

Себер татарлары арасында ислам дине таратылуына анда ачыла башлаган дини мәктәпләр, ә соңрак, XVII — XIX гасырларда татарлар яшәгән шәһәрләрдә һәм зур авылларда нигез салынган мәдрәсәләр зур роль уйнаган.

Укучыларда Себер татарлары мәдәнияте үсеше тарихында ислам диненең тоткан урыны, әһәмияте нәрсәдән гыйбарәт соң? — дигән сорау туу табигый. Әйтергә кирәк, бу сорауга бүгенгә кадәр Себер татарлары тарихын, мәдәниятен өйрәнүгә багышланган әдәбиятта әле җавап бирелмәгән. Шәхес культы чорында һәм торгынлык елларында һәр диннең, шул исәптән, исламның да аны тоткан халыкларның тарихында, мәдәнияте үсешендә күренгән уңай якларын күрсәтү яраксыз, хәтта зарарлы бер эш итеп каралып килде. Тик илебездә барган үзгәртеп кору, революцион яңартулар дәверендә генә бу өлкәдә ачыктан-ачык сүз алып барырга мөмкинлек туды.

Әгәр дә без ислам динен кабул итүнең Себер татарлары өчен булган әһәмиятен Идел болгарлары һәм аларның варислары — Казан татарлары тарихында һәм мәдәниятендә тоткан әһәмияте белән чагыштырсак, байтак уртак яклар күрәбез.

Табынучылар саны буенча хәзер дөньяда икенче урынны алып торган ислам дине Көнбатыш Себердә яшәп килгән вак татар патшалыкларын бетереп, мөстәкыйль Себер татар ханлыгы төзүдә зур роль уйный: а) Ислам Себер татарларын элекке мәҗүсилек диннәре калдыкларыннан арындыруда зур әһәмияткә ия була; б) Себер татарлары, ислам динен кабул иткән башка халыклар, шул исәптән, Идел буе татарлары төсле үк, исламдагы хокук нигезләрен тәшкил иткән фикһе белән һәм мөселманнарның хокук, әхлак нормаларын эченә алган шәригатьне, аның мөселманнарга булган таләпләрен үзләштерделәр.

---

[1] Бу турыда авторга мәгълүматны 1971 елның апрель аенда Тубыл районы Янгытум авылында яшәүче 1880 елда туган Мөхәммәт Нәби Күчемов биргән иде.

[2] Центральный государственный архив древних актов (ЦГИДА), Ф. 214, оп. 5, д. 254, л2. 20 б., 3-4.

Себер татарлары, ислам динен кабул иткәч үк, мәчетләр каршында башлангыч дини мәктәпләр, соңрак мәдрәсәләр ачып, билгеле бер тәртиптә уку-укыту эшләрен җайга сала.

Ислам дине аша Себер татарларына да гарәп һәм фарсы телләре, урта гасырларда «Көнчыгыш мәдәнияте» дип аталган «мөселман» яки «гарәп» мәдәнияте тарала башлый. Мәдрәсәләрдә укып гарәп, фарсы, төрки телләрен яхшы үзләштергән себер татарлары вәкилләре Урта Азия аша Әбелкасыйм Фирдәүси (934 — якынча 1020), нигездә гарәп телендә язган Әбу-Рәйхан Бируни (973 — якынча 1050), Галишир Наваи (1441 — 1501) кебек бөек үзбәк, таҗик шагыйрьләре һәм галимнәренең әсәрләре белән таныша алганнар. В. В. Бартольд фикеренчә, бу бөек шәхесләр арасында Галишир Наваиенең тоткан урыны аеруча зур була. Ул үзенең шигырьләрен фарсы телендә дә язган, ләкин төрки шагыйрь буларак дан алган. Аның әсәрләре Истанбулдан себер татарлары яшәгән Тубыл шәһәренә кадәр барлык төрки халыклар өчен классик әсәрләр булып әверелгән.

Өргәнечтән Себергә күчеп килгән үзбәкләр аша Себер татарларына үзбәк язучысы һәм тарихчысы, Хива ханы Әбелгазыйның (1603 — 1663) кыйммәтле әдәби һәм тарихи чыганак булган «Шәҗәрәи-төрек» исемле әсәре дә килеп җиткән. Аны 1743 — 1753 елларда Себердә фәнни экспедициядә булган, «Себер тарихы» әсәре авторы академик Г. Ф. Миллер Тубыл шәһәрендә бер мулла кулында очрата һәм аның ярдәме аша урыс теленә тәрҗемә итеп ала. Күрсәтелгән әсәрләрне һәм бөтендөнья төрки халыклары мәдәнияте үсеше тарихында зур әһәмияткә ия булган кыйммәтле дөньяви һәм дини китапларны революциягә кадәр Манчыл (хәзерге Төмән өлкәсе) мәдрәсәсе китапханәсендә, Тара байлары Әйтикиннәрнең хосусый китапханәләрендә, аерым китап сөючеләр кулында очратырга була иде.

Революциягә кадәр Себер татарларының татарча укый-яза белү дәрәҗәсе Себердә яшәгән урыс булмаган аз санлы халыкларга (ханты, манси, казакъ h.б.) караганда шактый югары иде. Шунлыктан алар, бигрәк тә төрле мәдрәсәләрдә укып белем алганнары, башка тугандаш төрки халыклар телләрендә, шул исәптән, татар әдәби телендә басылган тарихи, дини, публицистик әсәрләрне һәм матур әдәбият үрнәкләрен укып барганнар. Бу төркемгә кергән Себер татарлары Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Риза Фәхретдинов, Габдерәшит казый Ибраһимов кебек прогрессив караштагы булган галим-мәгърифәтчеләр, язучылар, публицистлар әсәрләре белән таныш булалар. Ә инде Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ш. Бабичларның гарәп шрифтында басылган әсәрләрен Себер татарлары бигрәк тә яратып укыганнар.

Шунысы аеруча кызыклы, XIX йөз азагында һәм XX йөз башында Себердә яшәгән казакълар һәм башкортлар белән якын мөгамәләдә булган тара, Төмән татарлары арасында шагыйрь Мифтахетдин Акмулла (1831 — 1895) һәм казакъ акыны Абай Конанбаев (1845 — 1904) шигырьләре киң таралган иде.

Ислам Себердә җиңел генә тамыр җибәрми. Монда аның көчле көндәше булып патша хөкүмәте тарафыннан якланган христиан дине мәйданга чыга. XVI — XVIII гасырларда Себер татарларын, анда яшәгән башка аз санлы халыкларны көчләп чукындыру эше алып барыла.

1620 елда Тубыл шәһәрендә махсус епархия төзелә һәм аңа христиан динендә булмаган Себер халыкларын христианлаштыру бурычы йөкләнә. Патша хөкүмәтенең христиан динендә булмаган халыкларны чукындыру сәясәте XVIII гасырның беренче чирегендә аеруча активлаша. Бу эш беренче Петр патшаның эчке сәясәтенә бәйләнгән иде. Үзәкләштерелгән хакимият өчен көрәш барышында ул Себернең җирле кабиләләрен христианлаштыру бурычын куя. 1714 елның 16 декабрендә Себер митрополиты Федор Лещинскийга җиткерелгән указында паштa аңа «Себер татарларына барырга, аларны христиан диненә күчерергә,ә аларның пычрак гыйбадәт урыннарын яндырырга»[1] әмер итә. Патша Указын тормышка ашыру өчен Ф. Лещинский, махсус экспедиция оештырып, 1718 — 1720 елларда Тура елгасы буенда яшәгән татарларны, Обь һәм Чулым төркиләрен көчләп чукындыра. Себер һәм Тубыл митрополитларының христиан динен кабул итәргә теләмәгән татарларны, зинданга ябып, аш-сусыз тотулары, хәтта, ут белән җәзалаулары турында да мәгълүматлар халык хәтерендә бүгенгә кадәр сакланып кала. Себер татарларын ирексезләп чукындыру 1749 — 1755 елларда аеруча көчәя. Тубыл губернасында 2500 җан чукындырыла[2]. Митрополитларның христиан динен таратуда кылган ерткычлыклары татарларның төрле катлауларында ачы рәнҗү һәм кискен каршылык тудырган. Бу хакта алар хәтта патшага да шикаять иткәннәр. Мәсәлән, 1751 елда Тубыл губернасында яшәгән мөселманнар тарафыннан сайланган Галим Шәеховнең митрополит С. Главатский өстеннән патша исеменә язылган шикаятне Елизавета Петровнага тапшыруы билгеле.

Патша хөкүмәте һәм Себер митрополитлары төрле ысуллар кулланcалар да, Себер татарларын христиан диненә күчерүдә зур уңышларга ирешә алмаганнар, чөнки ислам христиан дине өчен шактый көчле көндәш булган. Ә инде төньяк халыклары (ханты һәм мансилар) табынган мәҗүсилек, таркау чорын кичергән ыругълык дине буларак, чукындыруга каршы тора алмаган. Шул сәбәпле урыс руханилары христиан динен тарату өлкәсендә төньяк халыклары арасында зуррак уңышларга ирешкәннәр.

Урыс миссионерлары Себер татарларын, казакъларын чукындыру эшен XIX гасырда һәм XX йөз башларында да дәвам итә. Дөрес, бу вакытларда алар христиан дине нигезләрен халыкка тыныч ысул белән аңлатырга тырыша. 1900—1910 елларда Тубыл татарлары арасында христиан динен таратуда миссионер Ефрем Елисеев аеруча зур активлык күрсәтә. Ул христиан диненең «изгелеге» турында вәгазьләр белән генә чикләнмичә, уңайлы очраклардан файдаланып, аерым кешеләргә, яисә татарларның аерым төркемнәренә ачыктан-ачык чукынырга тәкъдим итә. Елисеевның шундый эшләре татар руханилары һәм барлык мөселман җәмәгатьчелегендә протест тудыра.

Православие миссионерларына каршы көрәштә Себер мөселман руханилары төрле алымнар кулланалар, шул исәптән, христианлаштыруга каршы рухтагы халык иҗатының гадәти жанры булган бәетләрдән дә файдаланалар. Моңа мисал итеп 1958 елның җәендә Тубыл шәһәрендә табылган «Рәддия нәзар»ны күрсәтергә мөмкин. Аның төп максаты — христиан дине карашларын кире кагу, юкка чыгару. Бәетнең авторы Тубыл өязе ахуны, Хуҗа Бәргәр авылы мулласы Габделҗәмил Әнвәрев була. СССР Үзәк дәүләт тарих архивында Г. Әнвәревнең һәм Тубыл шәһәрендә яшәүче Тәүхитдин хаҗи Гаидмөхәммәтовларның Е. Елисеевка каршы нинди чаралар күрергә кирәклеге турында киңәш сорап 1901 елда мөфти Мөхәммәдьяр Солтановка язган хатлары да сакланган.

Исламга каты һөҗүм Себердә егерменче еллар азагында утызынчы еллар башында илдә күмәкләштерү җәелдерелгәндә һәм шәхес культы елларында ясалды. Омск, Тара һәм башка Себер шәһәрләрендә таш мәчетләр, шулай ук барлык авыл мәчетләре җимерелде. Дин тотучыларның дини хисләре тупас рәвештә мәсхәрәләнде.

Илебездәге башка төрки халыклар кебек, Себер татарларына да егерменче еллар азагында ислам дине белән кергән гарәп язуыннан яңалифкә, аннары урыс графикасына күчәргә туры килде. Бу Себер татарлары мәдәнияте үсешенә ифрат тискәре тәэсир итте.

Әлифбаны болай еш үзгәртү халыкның өлкән һәм урта буын вәкилләрен аеруча кыен хәлгә калдырды, чөнки башта латинга, аннары кириллицага күчү аларны бөтенләй укый-яза белмәүчеләр дәрәҗәсенә төшерде.

Гарәп алфавитыннан латин алфавитына күчү аркасында Себер татарлары, башка төрки халыклар төсле, гарәп графикасында язылган дини һәм дөньяви әсәрләр белән файдаланудан, гомумән, йөзәр еллар буе татарларның милли мәдәниятенә ислам аша кергән «көнчыгыш мәдәнияте»ннән аерылдылар. Дәһшәтле шәхес культы елларында исә күпме Коръән һәм башка дини китапларны, шулай ук гарәп графикасында язылган кыйммәтле бик күп фәнни әсәрләрне, бик күп матур әдәбият үрнәкләрен кешеләр утта яндырдылар, зиратларга алып барып күмделәр. Надан атеистлар өчен гарәп алфавитында басылган китап тотучы һәрбер кеше мулла саналып, аңа котылгысыз рәвештә «халык дошманы» дигән ярлык тагылды. Илебездә үзгәртеп кору хәрәкәте кузгалгач кына, тарихыбызда һәм мәдәниятебездә урын алган ислам диненә объектив бәя бирү мөмкинлеге ачылды.

---

[1] «Странник»,— С. Петербург, 1886, № 8. С. 378.

[2] Центральный государственный исторический архив (ЦГИА) СССР. Ф. 796, оп. 27, д. 22, л. 2-4 и об., 5.

# «НУР»ДА БАЛКЫГАН ГОМЕР

СӘХИПҖАМАЛ ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА-ВОЛЖСКАЯНЫҢ
ТУУЫНА 100 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕ БЕЛӘН

Татар халкы арасыннан чыккан зур талантларның берсе, һичшиксез, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская. Сизгер йөрәкле Тукай да Сәхипҗамалны тиз күреп алган, аңа «Мәдхия» шигырен багышлаган. Шуның белән артистканың татар культурасы тарихында урыны да билгеләнә, ул татар халкының иң сөекле кызлары сафыннан урын ала.

Үз чорында С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның иҗат эшчәнлеге татар вакытлы матбугатында тулы гына яктыртып барылган. Театр тәнкыйтьчеләре Габдрахман Кәрам, Кәбир Бәкер, Самат Шәрәфетдинев «Аң» журналында, «Йолдыз», «Вакыт», «Тормыш» һ.б. газеталарда С. Гыйззәтуллина-Волжская, ул оештырган «Нур» труппасы һәм аның шәкертләре Ш. Шамильский, Г. Казанский һ.б. турында әледән-әле рецензияләр язып торалар. Мин үзем дә артистка белән күп еллар таныш булып, хатлар язышып тордым. Һәм ул миңа зур гына күләмдәге истәлеген дә язып калдырды.

Менә бу айда Гыйззәтуллина-Волжскаяның туына йөз ел тулды. Ә без аңа нинди хөрмәт күрсәттек соң? Дөрес, Гази Кашшафның «Беренче артистка» исемле кыскача монографиясе басылды, Н. Исәнбәтнең «Гөлҗамал» исемле драмасын Татар Дәүләт Академия театры сәхнәләштерде. 1982 елда минем «С. Гыйззәтуллина-Волжская турында истәлекләр» басылды. «Татар совет театры» (1976 ел), «Октябрьгә кадәрге татар театры» (1988 ел) дигән китапларында артистканың тормышы һәм иҗат юлы бераз яктыртылды. Ләкин бу көнгә кадәр бөек талант иясенә тиешле бәяне биргәнебез юк әле. Ә кыскача гына әйткәндә, рус театры тарихында В. Ф. Комиссаржевская нинди урын тотса, С. Гыйззәтуллина-Волжская да безнең мәдәният тарихында шундый күренекле урын тота.

... Бик күп җирләргә чәчелеп яшәгән татар халкының үскәннән-үсә барган культура ихтыяҗын бер «Сәйяр» труппасы гына канәгатьләндерә алмый иде. Шуңа күрә, бу труппа белән беррәттән, Уфада оештырылган «Нур» труппасы да үзенең эшен башлап җибәрә. Аны Сәхипҗамал Гыйззәтуллина оештыра.

«Нур» труппасы оештырылганчы, Уфаның татар яшьләре театр өлкәсендә зур активлык күрсәтә. Шуңа күрә труппаның беренче спектакльләре үк Уфа халкы арасында зур популярлык казана. Ул татар һәм башкорт хатын-кызларының аяныч тормышын тасвирларга тырыша, русчадан татар тормышына яраклаштырып тәрҗемә ителгән «Җиңел хезмәт» исемле пьесаны куя.

Бу спектакль зур уңыш белән бара, тамашачы тарафыннан яратып карала. Моннан тыш Ф. Әмирханның «Яшьләр» драмасы һәм «Ирем кайтты» исемле комедия куела, ә аннары труппа гастрольгә китә. Чиләбенең «Народный дом» залында «Җиңел хезмәт» драмасы куела. Биредә Чиләбе һәвәскәрләре, ярдәмче составта актив катнашып, труппаның эшен шактый җиңеләйтәләр. Аларга приказчик Гариф Бурнаев төрле яктан ярдәм итә. Монда да «Җиңел хезмәт» тамашачыларда тирән тәэсир калдыра. «Кайбер абыстайлар күзләрен сөртә-сөртә, менә гыйбрәт, менә театрда нинди гыйбрәтләр күрсәтәләр икән, дип сөйләшәләр. Кат-кат кул чабып алкышладылар. Безнең дә башка милләтләрдәге шикелле театрыбыз, яхшы уйнаучы артистларыбыз бар икән, дип куаныша-куаныша таралдылар»,— дип яза «Тормыш» газетасы хәбәрчесе.

Чиләбе гастроленнән соң «Нур» труппасы Петропавловскида чыгышлар ясый. Урал һәм Себер шәһәрләрендә йөри. Ә 1914—1915 еллар сезонын уздыру максаты белән Оренбургка килә. Алты ай эчендә уналты спектакль куя. Алар арасында Г. Камалның «Уйнаш», «Банкорт», «Бүләк өчен», «Беренче театр», «Бәхетсез егет», «Кайниш» исемле әсәрләре, С. Рәмиевның «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин», М. Вәзирев-

нең «Мөсиббәте Фәхретдин», Я. Вәлинең «Ачлык кушты», тагын «Җиңел хезмәт», «Хатыннар эше» һәм башка әсәрләр була. Тамашаларда С. Гыйззәтуллина-Волжская, Ф. Сәмитова, З. Богданова, Е. Сумчинская (Лиза Сыртланова), И. Әлмәшев, Г. Казанский, К. Шамил, Ш. Шамильский һәм Ф. Сумашев чыгыш ясый.

1915 елның икенче яртысында «Нур» труппасы, «Сәйяр»дан килгән берничә артист белән берләшеп, Оренбургта «Татар драма артистлары труппасы» дигән исем белән йөри башлый. Чөнки Беренче бөтендөнья сугышы башланып, труппадагы артистларның берничәсе солдатка алынгач (Ш. Шамильский һ.б.), «Нур» труппасының составы ярлылана төшә. Ләкин бу елларда да «Татар драма артистлары труппасы» Мольерның «Саран», Ш. Камалның «Хаҗи әфәндә өйләнә», Г. Кариевның «Артист», «Хуҗа һәм приказчик»ны һәм башка спектакльләр куя.

«Хаҗи әфәнде өйләнә» спектакленнән соң, ноябрь аенда С. Гыйззәтуллина-Волжская иптәшләре белән «Татар драма артистлары труппасы»ннан аерыла. Алар ике труппа булып эшли башлый. Беренче спектакль итеп Оренбургта «Нур» үзе генә «Дәһшәтле серләр» исемле драманы сәхнәгә куя.

«Нур» труппасы 1915—1916 еллар сезонын үткәрү өчен Оренбургта калса да, башка шәһәрләргә дә гастрольгә чыгып йөри. Орск шәһәрендә ул Г. Камалның «Кайниш» исемле комедиясе белән «Мәхәббәт өчен көрәш» водевилен, В. Иманскийның «Качкыннар», Р. Ярыгинның «Табылдык» комедияләрен куя.

«Нур» труппасын Орскида эшләп килгән театр һәвәскәрләре шатланып каршы ала. Алар арасында Мирхәйдәр Фәйзи, Бәдәр Йосыпова (соңыннан РСФСРның атказанган артисткасы), Мөхәммәт Сәлимҗанов һәм башкалар була. Орск яшьләре «Нур» труппасы һәм аның җитәкчесе С. Гыйззәтуллина-Волжская хөрмәтенә банкет оештырып, артистларга зур уңышлар теләп Оренбургка озата.

Труппа, Оренбургта бераз эшләгәннән соң, Уфага 1916 елның җәендә кайта. Ләкин труппа үзенең эшен башлап җибәргәнче, С. Гыйззәтуллина-Волжская Уфа шәһәрендәге алдынгы яшьләр белән тыгыз бәйләнешкә керә. Г.Камал, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, Г. Исхакый һәм дөнья классиклары әсәрләренең тәрҗемәләре хисабына труппаның репертуарын яңарта. Шулай ук сәләтле яшь һәвәскәрләр исәбенә коллектив тулылана бара. Яшьләрдән Әмин Зөбәеров, Локман Аитов, Маһира Мирвәлиева, Нәҗип Габдрәшитов һ.б. труппага килә. Алар белән Гыйззәтуллина-Волжская өзлексез эшли.



Рәсемдә: *«Нур» труппасын оештыручы С. Гыйззәтуллина-Волжская һәм Локман Аитов 1960 елда.*

1916 елның көзендә Ижау шәһәрендә гастрольдә йөреп кайткач, «Нур»ны Уфада калдыру мәсьәләсе матбугат битләрендә күтәрелә. «Нур»га мәхәббәтен баглаган Уфа татар тамашачысы, труппа бирдә калып кышкы сезонны үткәрер, дип өмет итә. Шул уңай белән «Тормыш» газетасында «Нур» труппасы Уфада калачак» исемле мәкалә дә басыла. «Сәхипҗамал ханым вә иптәшләре Уфада калсалар, Уфа

халкы аларга гаять ачык йөз күрсәтер»,— дип язды бу газета. Һәм, чыннан да, «Нур» труппасы үзенең Уфада калу теләген белдерү белән, труппага ярдәм итү өчен махсус театр комиссиясе төзелә. Бу комиссия яшь артистларны труппага тарту, пьесалар сайлау, кирәкле әсәрләрне тәрҗемә итәргә булышу һәм шулай ук оештыру эшләрендә, бина алу, билетлар сатышуда ярдәм итә. Театр комиссиясендә шагыйрь һәм язучылардан Сәгыйть Сүнчәләй, Шәриф Сүнчәләй һ.б. була. Ярдәмче составка Әмин Зөбәеров, Нургали Әминев, Нәҗип Габдрәшитов, Шәехзадә Бабич һәм башкалар кертелә.

1916 елны татар театрының тууына ун ел тула. Бу уңай белән кайбер шәһәрләрдә юбилей кичәләре уздырыла. Казанда юбилей тантанасы оештырылмаса да, бу уңай белән Ф. Әмирхан «Аң» журналында «Сәхнәбезнең ун еллык мөнәсәбәте белән» исемле мәкаләсен язып чыга. Ә Уфада юбилей зур әзерлек һәм оешканлык белән үтә. Лекцияләр укыла, бенефислар оештырыла.

Шул уңай белән 1916 елның 30 декабрендә С. Гыйззәтуллина-Волжская бенефисы Уфада оештырыла. Бенефиста «Уйнаш» һәм «Бәхетсез егет» драмалары куела. С. Гыйззәтуллина-Волжская исә үзенең яраткан рольләре Сәрбиҗамал белән Гайнине башкара.

Февраль революциясеннән соң матбугат эшләре иркенәя, театрларга, шул җөмләдән татар труппаларына, элек патша цензурасы тарафыннан тыелган әсәрләрне сәхнәгә куярга мөмкинлек туа.

Труппаның реалистик юнәлештәге эшчәнлеге Февраль һәм Октябрь революциясе көннәрендә Г. Коләхметовның «Яшь гомер» драмасын кую дәрәҗәсенә кадәр җитә. Бу — «Нур»ның бик кыска вакыт эчендә идея-эстетик яктан да, актерлык осталыгы ягыннан да зур уңышларга ирешүе турында сөйли. «Яшь гомер» тамашачыларның иҗтимагый зәвыкларына ятышлы була.

1917 елның көзендә «Нур»га үзенең «Картҗан» дигән дүрт пәрдәлек әсәрен Сөләйманов фамилияле яшь артист тәкъдим итә. Бу пьесаны труппа зур уңыш белән куя. Шул рәвешчә труппа үзенең авторларын булдырырга тырыша. Шулай ук «Тормыш» газетасының 1917 елгы 26 ноябрь санында мондый хәбәр дә бар:

«Труппа тарафыннан «Новый клуб» бинасында мәшһүр мөхәрриребездән Гаяз Исхакый шәрәфенә үз нәзарәтендә соңгы әсәрләреннән «Мөгаллимә»не уйнарга әзерләнә».

«Нур» труппасы төрле җәмгыять файдасына әледән-әле спектакльләр куеп, ярдәм итеп тора. 1918 елның 2 апрелендә Уфаның «Яңа клуб» залында Г. Тукай хөрмәтенә «музыка вә драма җәмгыяте» тарафыннан оештырылган кичәдә катнаша.

1917—1918 еллар сезонында «Нур» А. Островскийның «Гроза» исемле драмасын Уфа сәхнәсендә куя. Бу спектакльдә С. Гыйззәтуллина-Волжская Катерина образын иҗат итә.

«Нур» труппасы башкорт халкы тормышын чагылдырган пьесаларны да куярга омтыла. Яшь драматург Сөләйманов тарафыннан язылган «Ашказар» исемле драманы артистлар шатланып каршы алалар һәм сәхнәгә кую чарасына керешәләр. «Җомга көн, 30 мартта «Яңа клуб» залында «Нур» труппасы тарафыннан мәшһүр «Ашказар» көенең вакыйгасыннан алынып язылган «Ашказар» исемле дүрт пәрдәле драма уйнала. Җырлау, бию, скрипка вә курай уеннары булачак. Башкорт халкының кыз бирү вә туй гадәтләре күрсәтеләчәк. Бу пьеса өчен махсус яңа киемнәр әзерләнә»,— дип яза «Тормыш» газетасы.

С. Гыйззәтуллина-Волжская һәм аның иптәшләренең Уфа сәхнәсендә булган хезмәтләрен зур ихтирам белән искә алып, РСФСР һәм Башкортстанның халык артисты Әмин Зөбәеров үзенең «Чын күңелдән» исемле мәкаләсендә болай дип яза: «Татар сәхнәсенең кадерле әнисе Гыйззәтуллина-Волжская, Шакир Шамильский, Мәһира Мирвәлиева, Фатыйма Ильская, Локман Аитовларның башкорт сәхнәсендә тудырган образлары безнең һәркайсыбызга иҗат үрнәкләре булып торалар...» («Совет Башкортстаны», 1957, 24 май саны). Ә Башкортстан халык шагыйре Мостай Кәрим: «Татар әдәбияты, татар музыкасы һәм сәнгате безнең кешеләрнең йөрәгенә туры юл тапты. Татар халкының бай һәм зур культурасы безнең милли культурабызны формалаштыруда һәм үстерүдә дә никадәр роль уйнаганлыгын сүз белән генә әйтеп бетерерлек түгел»,— дип язды.

Соңгы елларда «Нур» исемендәге яңа театр Уфада үзенең пәрдәсен ача дип ишеттек. Аның да халыкка игелекле хезмәт итүен телибез.

**Хәсән ГОБӘЙДУЛЛИН,**

сәнгать фәннәре кандидаты.

# ТАТАР ДИКТОРЫ

Миңа ундүрт яшьләр чамасы иде. Безнең авылда гаҗәеп бер вакыйга булды. Урамның буеннан-буена баганалар утыртып чыктылар һәм шулардан һәр өйгә чыбыклар суздылар. Безнең яртылаш җиргә казылган таш өйгә дә, түбә-түшәмне тишеп, алсу төстәге чыбык керттеләр, ямь-яшел төстәге «радиу тишеге» куеп чыктылар. Нократ Аланына (Вятские Поляны) базарга барган җиреннән әни кап-кара эшләпәле «радиу» алып кайтып куйды. Өйгә әллә нинди, колакка ятышсыз музыка тавышы таралды.

Без: «Тагын ни булыр икән?» — дип, бу хикмәт янында озак утырдык, тик урыс-марҗа җыруыннан башка әйбер булмагач, бик нәүмизләндек. Күрше Гөлҗамалтәй әйтә куйды:

— Син, Нурхәят, юкка бу радиуны Пүләнкәдән алгансың, әнә Каймә Кукмара кибетеннән кайтарткан. Кич белән кергәнием, кычкырып татарча сөйләп утыра. Пүләнкәнеке урысча сөйләми — нишләсен, урыслар сиңа татарча сөйләшле итеп ясар, бар, көтеп тор, әйе.

Шулай бөтенләй өмет өзелгәч, бер заман «Казан сөйли!» дигән сүз яңгырамасмы? Минем колакларым үрә торды, ничек итеп кара тәлинкә янына барып басканымны сизми дә калдым. Аннан исә бик матур хатын-кыз тавышы ишетелә иде. Һәр сүзен ничек йотып баруымны әни дә күзәтеп торган икән. Теге апа, сөйләп бетергәч, «укыды Камал Саттарова» дип куюга:

— Сөбханалла, шулкадәр матур, ягымлы сөйли. Бу гади генә кеше түгелдер, остабикәдер бу. Китап сүзләрен ничек килешле итеп әйтә,— дип тел шартлатты әни.

Бер минем әни генә шулай уйламый иде, ахры. Үтә матур сөйләүче апага авылда «остабикә» исеме үзеннән-үзе ябышып калды. Гомерләрендә бер тапкыр үзен күргәннәре, кара-каршы килеп сөйләшкәннәре юк, ә кушаматны тагып та өлгерделәр:

— Әнә теге остабикә сөйли башлады инде...

— Остабикә яңгыр була, диде...

— Остабикә кичә Гөлсем Сөләймановааны җырлатты...

Мин үзем дә, көн саен тыңлый торгач, хыялымда Камал Саттарованың кыяфәтен тудыра башладым. Зифа буйлы, озын күлмәкле, чиккән читекле, иңенә ак ефәк шәл япкан. Шулай күз алдына китереп каршы алам, сөйләп бетергәч, шулай рәсемләп озатып калам. Бу апа, торабара, ничектер, үз туганым, Нәсимә, Зәйтүнә апаларым кебек үтә газиз булып тоела башлады. Аны күзнең бер кырые белән генә булса да күрәсем килә иде.

1957 елда Татарстан яшьләренең беренче фестивале булды. Мин дә Кукмара районыннан Казанга баручылар арасына кертелдем. Анда «Дим буе» дигән җыр башкарырга тиеш идем. Хәзер инде хәтерләмим, кайсыдыр бер клубта җырлагач, миңа чибәр генә апа: «Син радиодан чыгыш ясарга сайлап алындың, хәзер шунда китәбез»,— диде. Мин, бик дулкынланып (минә сиңа күктән төшкән бәхет!), шунда киттем. Ләкин Камал апаны күрергә дигән өметләрем барып чыкмады, аны: «Әлегә юк»,— диделәр. Ә безнә, җырлаткач, рәхмәт әйтеп чыгарып җибәрделәр.

Миңа әле бу апаны күрер өчен, тагын ун ел көтәргә кирәк булган икән. 1967 ел. Радиодан игълан ишетеп калдым: ир дикторга конкурс була икән. Кукмара районы радиосында һәм өч-дүрт ел хәрби хезмәттә вакытта часть радиоузелыннан тапшырулар алып барганыма таянып, мин дә тәвәккәлләргә булдым. Ниһаять, декабрь аенда үзем өчен дөньяда иң мәртәбәле хезмәт урыны булып тоелган радиога эшкә алындым! Нәкъ шул көнне курка да калдым. Конкурстан үтүен үттем, ләкин Камал Саттарова белән бергә эшлисе бит! Булдыра алырмынмы? Ул кем дә, син кем?

Ни өчендер без конкурс вакытында очрашмадык. Хәер, Камал апа анда булгандыр инде. Үзе белән янәшә утырып эшлисе кешене сайлап алганда нишләп битараф кына читтә калып торсын ди инде ул?



Без аның белән көтмәгәндә радио йортының ишек алдында очраштык. Мин эчкә кереп барам, каршыга ике апа килә. Берсе мине таный да икән инде.

— Менә, Камал, таныш, безнең яңа ир тавышыбыз шушы була инде.

Минем алда җыйнак кына гәүдәле, бик тере күзле, мөлаем гына апа басып тора иде.

— Бик әйбәт, бик әйбәт, төкле аягың белән!

Ул мине, мин аны карашып бераз торгач, мин күзләремне аска яшердем. Теге апа сорап куйды:

— Бу егет синең ничәнче хезмәттәшең була инде?

— Ничәнче икән? Әйдә, санап карыйк: Фатих Колбарисов, Фатих Шәрәфиев, Айрат Арсланов, Вәис Саматов, Эльс Гаделев, Рим Кәримов — димәк, бу энекәш җиденче кулалмаш була инде. Матур гына эшләргә насыйп булсын, үскәнем.

«Үскәнем». Камал апа миңа шул сүз белән эндәшә торган булып китте. Ара-тирә, «матурым», «акыллым» дип тә куя иде. Бара-тора шуны абайладым, ул мондый ягымлы сүзләрне бер миңа карата гына кулланмый, үзе белән аралашучыларның күбесенә шулай әйтә. Үзеңә карата шундый матур итеп мөрәҗәгать иткән кешене аннан да уздырып хөрмәтлисе, олылыйсы килә башлый. Шуңа күрә аның үзенә дә «Камал апам, җаным», «Камалкаем», «Вәсфикамал ханым» дип әйтәләр, җылы мөнәсәбәтләрен даими белдереп торалар.

Камал апа радиода 1943 елдан бирле эшли икән инде. Ул бала чагында йә укытучы, йә артист булырга хыялланган. Әмма аңа унсигез яшь тулганда сугыш башлана һәм вакытлыча гына булса да бөтен хыяллардан баш тартып торырга туры килә. Аны яхшы белгән кешеләр, сәләтен, талантын искә алып, радиога дикторлар конкурсына барып карарга киңәш итәләр. Чыннан да, Вәсфикамал җиңеп чыга. Ул вакытка кадәр радиода диктор булып Зәйнәп Хәйруллина эшли. Үзенә ярдәмгә килгән кызны ул колач җәеп каршы ала, аңа бу профессиянең бөтен хикмәтләрен җиткерергә тырыша. Бу турыда З. Ш. Хәйруллина, байтак еллар узгач, болай яза: «Һәркөнне аның белән күнегүләр алып бару, аны дикторлыкка өйрәтү миңа йөкләтелде. Ул бик тырыш иде. Күп тә үтми, тапшыруларны үзе алып бара башлады. Иртәнге тапшыруларга әзерләнү өчен, ул эшкә 4 сәгать 30 минутта килеп җитә иде. Төнге дежурлыктан соң аның өчен тапшыруларны мин алып барам» (Социалистик Татарстан, 1985, 12 июль).

Ул вакытта биредә радиокомитет рәисе булып Гариф Гобәй, аның урынбасары вазифасын Гомәр Бәширов башкара. Кави Нәҗми исә — пропаганда тапшырулары мөхәррире, Мирсәй Әмир — әдәби тапшырулар җитәкчесе. Камал апа Г. Гобәй, Г. Бәшировларның тел осталыгы, сөйләм кагыйдәләре буенча үзенә бик күп ярдәм иткәннәрен яратып искә ала иде.

Сугыш вакытында биналар рәтләп ягылмый, савытларда язу каралары ката, микрофон алдына пальто киеп утырырга да туры килә. Әмма шушы шартларда да беркем зарланмый, үзенә төшкән бурычны икеләтә-өчләтә үти. «Дуслык, бердәмлек, бер-береңә булышырга әзер тору көчле иде,— дип искә ала шул ук З. Хәйруллина.— Онытылмаслык хатирәләр. Кави ага эшкә бер-ике чи бәрәңге алып килә. Аны бик нечкә итеп түгәрәкләп кисә дә, редакция бүлмәсе уртасында торган тимер мич өстендә кыздырып ала. Аннан «Галия, бу кисәк сиңа, ә бусы Зәйнәпкә, монысы яшь дикторыбыз Камалга»,— дип өләшеп чыга. Шул бәрәңгегә өстәп, икмәк сыныкларыбызны бүлешәбез һәм тамак туйган кебек була». (Социалистик Татарстан, 1985, 12 июль).

Ниһаять, көтелгән җиңү көне дә килеп җитә. Камал апа бу турыда бик дулкынланып сөйли иде. «Казан радиосында эшләү дәверендә бик күп вакыйгалар булып үтте. Әмма берсе истән һич чыкмый.

1945 елның мае иде. Мәскәү радиосыннан күптән көтелгән җиңү турында хәбәр ишеттем. Бездә бу хакта хәбәр юк иде әле. Ә тизрәк студиягә керәсе, Татарстанны иңләп-буйлап үтәрлек итеп микрофоннан кычкырып укыйсы килә. Матбугат йортына «Кызыл Татарстан» редакциясенә барып, үземә кирәкле текстны алдым.

Урам тулы халык. Кешеләрне аралый-аралый йөгерәм. Шулай да бик акрын барам төсле, аяк буыннары бушаган, тын кысыла.

Ниһаять, каршымда — микрофон. Мин ашыгып укыйм: «Совет гаскәрләре — Берлинда! Рейхстаг өстендә Советлар Союзы байрагы җилферди!... Германия капитуляция ясады».

Сүзне ничек түгәрәкләвемне дә, тавышымның ничек яңгыравын да хәтерләмим. Микрофон әзелгәндә мин инде сулкылдап-сулкылдап елый идем». (Азат хатын, 1968, № 12, 14 бит).

Тагын еллар уза. Камал Саттарова дикторлык һөнәренең нечкәлекләренә тирәнрәк төшенергә тырыша. Ул Мәскәү дикторлары Юрий Левитан, Ольга Высоцкая, Валентина Соловьева, Виктор Чижов, Георгий Шумаков, Юлия Саломатина һәм башкалар белән аралаша, алардан күп нәрсәләргә өйрәнә, курсларда була. Казанда үзе белән бергә эшләгән Маһинур Хәбибуллина, Айрат Арсланов, Әминә Сафиуллина, Итфал Ихсанов, Наил Иртуганов, Ильяс Латыйпов, Галина Земенкова (хәзер Үзәк телевидение дикторы) һәм башкалар белән тәҗрибә алмашу һәм бер үк вакытта үзе дә өйрәнү аңа осталыгын чарларга ярдәм итә.

Кыскасы, Камал апа янында урта кул диктор гына булып калу мөмкин түгел. Хезмәтенә битараф булган, үз өстендә эшләмәгән, тапшыруларны ничек укысам да ярый, дип утырган кешеләрне ул яратмый, алар белән ачылып сөйләшми. Мәгълүм бер чорда аның белән бергә дикторлык хезмәтен башкарган Рим Кәримов болай яза: «Кем яки нәрсә турында гына укыса да, язылганнарга карата аның үз мөнәсәбәтен ишетәсең. Укылган материалның эчтәлегенә бөйле шушы тойгылар диктор тавышы аша тыңлаучы күңеленә күчә. Ул кулындагы материалга, анда телгә алынган кешеләргә эчкерсез ышанса, язылганнарны йөрәгеннән ялгансыз кичерә алырлык киң күңелле кеше булса гына тыңлаучыны үзенә буйсындыра ала. Моңа исә матур тембрлы тавыш һәм шома уку белән генә ирешеп булмый. Тәҗрибә, осталык һәм үз эшеңне чын ярату кирәк». (Социалистик Татарстан, 1973, 25 июль). Мин, бу фикерне дәвам иттереп, болай дияр идем: радиотыңлаучы диктор алдындагы кәгазьне сизмәскә тиеш, ягъни аның чыгышы әзер текстны укуны түгел, бәлки үзлегеннән сөйләү тәэсире калдырсын! Менә бу — диктор укуының иң югары ноктасы. Камал Саттарова шушы осталыкка ия диктор иде. Аның иң соңгы укучысы Данил Ибраһимов та Камал апаның үзендә шундый сыйфат тәрбияләргә омтылуын яратып искә ала.

Чыннан да, Камал апа укыган тапшыруның тыңлаучы күңеленә барып җитәчәгенә шикләнмәскә мөмкин. Шуңа күрә Мидхәт Миншин, Тәүфикъ Сәгыйтов, Фәләх Насыйров, Наил Гыйззәтуллин, Нәсимә Әхмәтҗанова һәм башка журналистлар үзләре әзерләгән тапшыруларны Камал ападан укытырга тырышалар иде. Менә ни өчен бу сөйкемле апа татар халкы өчен үз кеше булып әверелде. Аны күрергә районнардан, чит шәһәрләрдән киләләр, җылы сүзләрен әйтәләр, кунакка чакыралар, саулык-сәламәтлек телиләр, күчтәнәчләрен тәкъдим итәләр. Хәтерлим, җитмешенче еллар башында Казанга АКШтан техник күргәзмә килде. Андагы экскурсоводлар арасында татарлар да бар иде. Шулар, Казанга килгәч, радиотапшыруларны бик яратып тыңлый башлыйлар, иләренә алып китү өчен, магнитофонга язып-язып та алалар. Дикторларның үзләрен дә күрергә телиләр. Бер көнне, җыелып, радио йортына килеп чыгалар, безгә дикторларны күреп сөйләшергә рөхсәт итегезче, диләр. Әмма җитәкчелек, ниндидер хәйлә табып, бу теләкне үтәми. Бу турыда белгәч, Камал апаның кәефе китте: «Әйдә, матурым, тау Мөхәммәткә бармаса, Мөхәммәт тауга бара, дигәндәй, үзебез барыйк шул күргәзмә дигәннәренә». Чыннан да бардык. Халык белән татарча сөйләшүче америкаң апаны хәйран калып тыңлап тордык, ләкин үзебезне таныты-рга, сүз кушарга курыктык. Дус бар, дошман бар, дигәндәй, я берәрсе тиешле җиренә җиткереп куяр.

— Ярар инде, үзләрен күрдек, безнең кебек ике куллы, ике аяклылар икән, очраштырган булсалар, ни булган инде,— дип кенә куйды Камал апа.

Дикторларга еш кына радиотыңлаучылардан хатлар килә. Алар арасында төрле эчтәлектәгеләре була: үз итеп кайгы-хәсрәтен, шатлык-куанычларын уртаклашучылар да, киңәш сораганнары да, рәхмәт әйтүчеләре дә, хәтта ачуланып язганнары да очрап куя. Мәсәлән, кырык ел балалар укыткан Гөлсем Хөсәенова җитмешенче елларда Кукмара районыннан Әсән-Елга авылыннан болай дип яза: «Мин сезнең өчегезне дә — Камал Саттарова, Мәрьям Арсланова һәм Фоат Галимуллин — чылтырап аккан чишмәдәй саф тавышыгызны, баштан ахырга кадәр тыңлап, үземә ямь, ләззәт табам. Бигрәк тә Камал белән Мәрьямнең ничә яшьтә булуларын беләсем килә. Чөнки ничәмә-ничә еллар инде сез өчегез бергә эшлисез, тавышта бернинди артка китеш юк, мин аларны бик яшьләрдер дип күз алдына китерәм».

Камал апа хатлар укырга бик ярата иде, ул аларны кат-кат укый, укыган саен яңа мәгънәләрен таба, үзеннән шәрехләүләр өстәп, безнең белән сөйләшеп утыра иде. Аны, мәсәлән, түбәндәге хат бик тетрәндер-

гән иде. «Күр инде, татар халкының язмышын! Кайларга гына чәчеп бетермәде аны бу авыр тормыш? Ә барган бер җирендә аның телен, рухын кысып интектерделәр... Менә бу хат татарның йөрәге кычкыруы бит»,— дип безгә әрнеп утырганы хәтеремдә. Әлеге хат ничектер минем архивымда калган булып чыкты. Менә ул хат: «Саттарова, Галимуллин, кадерле тугандашлар, дуслар! Без Казакъстан, Урал җирләрендә яшәүче татарлар һәм башкортлар сезгә зур үтенеч белән мөрәҗәгать итәбез: Казан шәһәрендә грампластинкалар сатыла торган кибетләрнең адресларын җибәрегез, зинһар. Безнең Җаектагы беренче номерлы пластинкалар кибетенә менә инде 3—4 ел татар һәм башкорт телинкәләре кайтмый. Без үзебезнең матур җырларны тыңларга телибез. Баянда Мөхтәр Әхмәдиев, Оркыя Ибраһимова уйнаганы, Габдулла Рәхимкулов, Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров кебек самый атказанганнары җырлаганы кирәк. Матур, моңлы көйләребезне икмәк кебек күрәбез, алар да җанга-тәнгә сихәт бирә бит».

Без, яшьләр, хат язу мәсьәләсендә ваемсызрак идек бугай, әмма Камал апа икебез исеменнән дә җавап язган булып чыкты. Ник дигәндә, шул ук елның 8 июнендә без рәхмәт хаты алдык.

Бу безнең илдә милли телләргә, милли мәктәпләргә ныклап һөҗүм алып барылган, бигрәк тә үз милли республикаларыннан аерылып яшәүчеләрне өкренләп руслаштыру сәясәте алып барылган чор иде. Әлбәттә, хат язып кына аларның хәлен җиңеләйтү мөмкин түгел. Әмма кеше күңеле шуңа да чиксез куана, шул да аны күпмедер бәхетле итә.

Камал апаның кече күңеллелеген һәм кешеләрне ярату мисалы булган тагын бер вакыйга истә калган. Кичке тапшыру башланырга бер сәгать вакыт калып бара. Ул, кулына бер хат тотып, музыкаль редакциягә йөгерде. Хатны Чүпрәле районы «Йолдыз» колхозыннан Әбделхәй Кәбиров язган икән. «Борчуым бар,— дигән ул,— безнең Габдулла Рәхимкулов соңгы көннәрдә нигә җырламый? Мин үземнең аз гына башым белән уйлап йөримме бу турыда дигән идем, юк, һәммә булган Чүпрәле мишәре хәйран калган икән: кая бу безнең Шәйморза җырчысы?» Камал апа, фототеканы ачтырып, тиешле җырны алып, аны рәсми рәвештә программага керттереп, сораулар буенча концертта шушы колхозчы абзыйның теләгән үтәүгә ирештә, шулай итеп аның яраткан җырчысының исән-имин икәнлеген белдерде.

Әлбәттә, кайбер радиотыңлаучылар кайчак бер нәрсәне белеп бетермиләр: эфирга бирелә торган тапшыруларны, концерт программаларын дикторлар үзләре әзерләми. Аларның бурычы икенче — әзерләнгән әйберләрне мөмкин кадәр үтемле итеп тыңлаучыга җиткерү. Кон саен тавышларын, сүзләрен ишетеп торгач, радиотыңлаучылар бөтен дәгъваларын дикторларга белдерә. Камал апа Саттарова безгә — ягъни үзе белән янәшә эшләүчеләргә дә, җирле радиотапшырулар алып баручылар өчен уздырылган семинарда да — болайрак сөйли торган иде: «Диктор белән актер охшаш профессияләр дисәк, бу диктор хезмәтен җиңеләйтеп күрсәтү булыр иде. Актер да, диктор да автор фикерен бөтен нечкәлеге белән тыңлаучы күңеленә җиткерә алырга тиеш. Тик актер моңа атналар, айлар буе репетицияләр аша ирешә. Ә диктор текстны бер-ике кат укып чыгарга мөмкин, оператив информацияләрне машинкада басылуга укыган чаклар да була.

Радионы һәркөнне миллионлаган кеше тыңлый. Алар авторны белми, хата автор гаебе белән китсә дә, дикторны гаепли. Шелтәсен телефон аша да, хат белән дә әйтергә ашыга. Шуңа күрә тыңлаучы игътибарына тәкъдим ителгән һәр материал диктор җаваплылыгында. Актерның тыңлаучысы — каршысында ук. Ул үзенең ничек кабул ителүен, тамашачысының күзенә карап, сулышыннан тоеп белә. Ә дикторның сиземләү сәләте көчле булырга тиеш. Шушы сыйфатлардан мәхрүм диктор тыңлаучы белән үз арасын тоташтыручы «күпер» сала алмый. Укыла торган текстның эчтәлеге буенча үз аудиториясен дөрес күз

алдына китергән дикторның гына һәр сүзе тыңлаучыга ачык һәм үтемле тәэсир итә.

Кырык еллык эш дәверендә үз хезмәтем турында тыңлаучылардан күптәрле фикерләр ишетергә туры килде. Иртән сәгать биштән, алтыдан эшкә барганда танып белүчеләр очраса: «Көн саен шулай иртә йөрисезме? Ай-һай хезмәтегез тынгысыз икән»,— диделәр. Транспортта: «Камал Саттарова кебек, көнгә сәгать-сәгать ярым радиодан сөйләп кенә эшең бетсен иде ул»,— дигәннәрен дә ишеттем.

Берсе белән дә бәхәсләшмим. Мин үз бурычымны, үз вазифамны беләм: дикторның көндәлек эш нормасы — алты сәгать. Тик ул сәгатьләр тоташ түгел шул. Көнгә ике дә киләсең, өч тә. Иртән дә, көндез дә, кич тә. Ял көнне дә, бәйрәмдә дә киләсең эшкә.

Диктор профессиясе никадәр генә тынгысыз, җаваплы, җитди булмасын, яшьлегем кире кайтса, мин яңадан нәкъ шушы юлны сайлар идем». (Татарстан яшьләре, 1984, 28 август).

Боларның һәммәсе дөрес иде. Аның хезмәттәшләре, билгеле бер вакытны эшләгәч, кайсы филармониягә, кайсы журналистлык хезмәтенә, кайсы фән юлыннан китеп барды. Ә Камал апа һаман үз урынында кала бирде.

Хәтерлим, бервакыт радиога Габдулла абый Шамуков килгән иде, ул ниндидер тапшыру язды, кулында гарәпчә хәрефләр белән язылган калын китаплары да бар иде. Камал апа, аның бушаганын көтеп алып, кайбер фарсы-гарәп алынмаларының әйтелешен сорап калды. Әлеге олы оста барында миннән байтак сүзләрне әйттереп карады, бергәләп киңәшләр бирделәр. Ибраһим Гафуров, Фуат Халитов, Хәким Сөлимҗановлар белән дә шундый ук үзенә күрә аяк өсте «дәресләре» уздырып алганы хәтердә.

Камал апа радиодан «Тел күрке — сүз» тапшыруларын башлап җибәргән кешеләрнең дә берсе булды. Ул бу тапшыруларны аеруча бер ярату, җылылык, ихласлык белән укый иде. Камал апа әлеге тапшыруны гомеренең соңгы елына, ягъни 1985 елга кадәр алып барды. Бу тапшыруларның хәзер дә халык тарафыннан сөелеп тыңлануы Камал апаның якты рухына хөрмәт кебек тоела миңа.

1973 елның 30 июлендә, ягъни Камал Мәгъсүм кызының илле яше тулган көнне, хезмәттәшләре болай дип яздылар: «Кадерлебез Камал! Нурлы Казан, моңлы Казаныбыз Сезнең тел белән сөйли. Барлык радиоаппаратлар Сезнең үтемле һәм йомшак тавышыгызга көйләнгән. Сезнең тавышыгыз Татарстан кырларына, Идел-Кама буйларына сузылган могҗизалы күпер ул. Шул күпер аша күпме хәбәр, тормышыбызны бизәүче яңалыклар, шатлык аһәңнәре узган. Без шулай ук үзенә бар сабырлыкны һәм тыйнаклыкны җыйган, тырыш, кайгыртучан ана булган татар хатынының гүзәл сыйфатларын Сездә күрүебез белән дә горурланабыз.

Кайбер яхшы гына кешенең сөйләвен биш минут тыңлавы да авыр. Без Сезне ничә дистә еллар тыңлыйбыз — туймыйбыз. Рәхмәт хисләре белән кулыгызны кысып, баш иеп Сезгә әйтәбез: Сез сөйләгез әле, Камал апа, сөйләгез әле...»

Ни аяныч, моннан соң Камал апага унике ел гына сөйләргә калган икән...

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН**

# ЯЛКЫНЛЫ МОҢ

Заманында матбугатта актив катнашып та, иҗатлары төрле сәбәпләр аркасында җәмәгатьчелек игътибарыннан читтә калган шәхесләр татар әдәбиятында шактый. Шундыйларның берсе — шагыйрь Вакыйф Җәлал.

Вакыйф Җәлалның иҗаты да, тормыш юлы да бик аз өйрәнелгән. Ә бит ул шактый кызыклы, зур гына әдәби мирасы булган шагыйрь. Аның дүрт шигырь җыентыгы һәм бер чәчмә әсәре барлыгы билгеле.

В. Җәлалның биографиясенә кагылышлы мәгълүматны хәзерге матбугатта беренче булып М. Әхмәтҗанов бирә. Ул аны Казанда яшәүче өлкән педагог, Ватан сугышы ветераны Габдулла Вахитов авызыннан язып ала. Габдулла Вахитов үзе чыгышы ягыннан Татарстанның Куйбышев районы Ямбакты авылы кешесе. В. Җәлал исә шушы авылның укытучысы Шабанов Габдулла белән дус була. Шагыйрь еш кына Ямбактыга кунакка кайта. Илдә әле яңа гына Октябрь революциясе шаулап узган була. Шабанов һәм Җәлал авылда шигырь кичәләре оештыралар, сүзләреннән һәм гамәлләреннән революцияне, яңа хөкүмәтне хуплаулары сизелеп тора. Ә халык аларны «әчеп беткән большевик» дип атый. Вакыйф, Ямбактыга кайтып йөри торгач, Г. Шабановның балдызы Мәрьямгә өйләнә. 1921 елгы ачлык вакытында Вакыйф Җәлал, Габдулла Шабанов, аларның каенише Гаяз Ганиев һәм яшь укытучы Мингариф Мостафин гаиләләрен алып Ташкентка китәләр. Шул китүдән бер Габдулла Шабанов кына кире әйләнеп кайта.

Ул Ташкент ягында үз юлдашларының нинди канлы вакыйгага юлыгулары турында сөйләп бирә. Үзбәкстанда аларны бер кышлакка укытучы итеп билгелиләр. Бер вакытны Шабанов эш белән кышлактан чыгып киткән була. Ул югында басмачылар кышлакка басып керәләр, укытучыларны җыеп, сахрага алып чыгып аталар. Димәк, истәлектән күренгәнчә, Вакыйф Җәлал да басмачылар корбаны була.[1]

Шагыйрьнең үлеме турында Г. Сәгъди түбәндәге юлларны язып калдырган: «Бу шагыйрь ачлык вакыйгалары вакытында Ташкентта кызганыч рәвештә вафат итте»[2]. Тәнкыйтьче бу очракта В. Җәлалның үлеме турындагы беренче версияне күз алдында тоткан булса кирәк, аның сүзгә саранлыгы шул хакта сөйли.

Шагыйрьнең шигырьләреннән туган авылының исеме Суксу икәнен ачыклап булды. Ләкин кайсы Суксу? Татарстанда мондый исемле авыллар күп бит...

«Вакыйф Җәлал шигырьләре» җыентыгына автор язган сүз башыннан без шагыйрьнең 1909—1910 еллар тирәсендә Әстерханда яшәвен ачыклый алдык. Бу якларга нинди эш-максатлар китергән шагыйрьне? Сорау әлегә җавапсыз кала. Әстерхан өлкә архивында бу кеше турында кыска гына мәгълүмат биргән кәгазь бар барын. Анда ул «сәяхәт итүче шагыйрь» дип күрсәтелгән.

В. Җәлалның бердәнбер чәчмә әсәре — «Кара тормыш» хикәясе дә Әстерхан якларында булып кайтканнан соң язылган. Төп геройның прототибы да авторга сәяхәте вакытында очраган булса кирәк.

«Кара тормыш» ялкаулыгы, эшкә сәләтсезлеге аркасында бәхетсезлеккә тарыган авыл кешесе Хәсән һәм аның гаиләсе хакында. Хәсән авылда берниндә эш майтара алмагач, рәхәт тормыш эзләп, гаиләсе белән бай шәһәр — Әстерханга юл тота. Бу якларга иябәшкән кешеләр Әстерханны һәм анда торучыларны

---

[1] М. Әхмәтҗанов. Татар әдәбияты тарихына яңа исемнәр. Җыентыкта: Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш. Казан, 1987.

[2] Г. Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы. Казан, 1926.

бик мактап сөйләгән була. Имеш, монда кешеләр бик ярдәмчел, юмарт, ә аз гына язу таныган кеше казакъ һәм кыргыз арасына чыгып, үзен укымышлы итеп танытса, шактый зур байлык җыярга чама бар... Хәсән, аз-маз язу таныганлыктан, шушы эшкә керешергә уйлый. Ләкин ялкаулыгы, пошмаслыгы, катып калган фикерле булуы аны монда тәмам бәхетсез итә: беренчедән, аны хатыны ташлап, башкага кияүгә чыга; икенчедән, улы вафат була, өченчедән, буй җиткән кызы бозыклык юлына баса. Хәсән, кире авылына кайтып, йорт-җирен сатарга мәҗбүр була, картлык көнендә каңгырап бер ялгызы йөрергә кала.

Шулай итеп, хикәянең сюжеты хәйран кызыклы гына. Ләкин әдәби эшләнеше ягыннан аны камил дип әйтеп булмый, әлбәттә. Әсәр шактый коры, бизәксез тел белән язылган. Әһәмиятле дип саналган вакыйга-күренешләрне артык озынга сузып, тәфсилләп, кабатлана-кабатлана тасвирлау күзгә ташлана. Геройларның эчке дөньясын сурәтләү өстән-өстән генә алып барыла. Эчке монолог һәм диалоглар бик сирәк. Белгәнебезчә, геройларның хис, уй-фикерләрен, тойгыкичерешләрен сурәтләүдә болар беренчел рольне уйныйлар.

В. Җәлал биографиясендәге бер факт Ш. Бабичның бер үткен эпиграммасы туугa сәбәп булган:

*Әл-Җәлалов чын вакыйф булдың әсирлек хәлендә,*
*Ул, ахрысы, тончыгып үләр фәган вә зарына.*[1]

Бу эпиграмма басылган җыентыкның аңлатмалар өлешендә түбәндәгеләрне укыйбыз: «Әл-Җәлалов-Вакыйф әл-Җәлали (1886—1922) татар шагыйре, дистәдән артык шигырь китабы авторы, революциядән соң Урта Азиягә китә, шунда фаҗигале рәвештә һәлак була.

«...булдың әсирлек хәлендә» — шагыйрь монда Вакыйф Җәлалның Казанда Гайшә Апанаева дигән бер хатынга йортка керүен «әсирлек хәлендә төшүгә» («чын вакыйф булуга») тиңләп яза.

Шагыйрьнең иҗади эшчәнлегенә һәм әдәби мирасына бәя биргәндә автор ялгыша булса кирәк. Аның шигырь китаплары дистәдән артмый. Ләкин 1912—18 елларда «Аң» журналында иң актив язышкан яшьләр арасында аның исеме дә атала. (М. Мәһдиев. Татар журналлары. «Казан утлары» 1989, 6 нчы сан).

Заманында В. Җәлал турында күренекле тәнкыйтьчеләр сүз алып барган. Мәсәлән, Г. Сәгъди, В. Җәлалның шагыйрьлеге бик түбән баскычтан башланып, вакытлар үтү белән аның шактый көчле, үзенчәлекле шагыйрь булып җитешүен әйтә: «Аның шигырьләрендәге сүз вә тәгъбирләр бара торгач үткенләнеп китте. Шуның өстенә, ул вәзен (шигырь төзи белү) вә кафиягә (рифма) бик оста, өслүбе аһәңле, тәэсире куәтле. Хикмәт вә фәлсәфә белән сугарылмаган шигырьләре моның аз булыр».

Г. Ибраһимов исә В. Җәлал исемен С. Рәмиев, Дәрдемәнд, С. Сүнчәләй, Сөнгати, Г. Харис, Җ. Юмаев исемнәре белән беррәттән куя (Г. Ибраһимов. Әсәрләр. Сигез томда. 5т. Казан, 1987.)

М. Мәһдиев «Әдәбият һәм чынбарлык» дигән китапта В. Җәлалның «Йолдыз» газетасында Төркия дәүләтен кызганулы шигырь бастыруын, Балкан сугышын төрле дингә табынучылар арасындагы сугыш дип аңлап, ялгышуын күрсәтә. Ул В. Җәлалга «әдәбиятта актив катнашып та, романтик буяулар, субъективизмнан уза алмаган шагыйрь» дигән бәя бирә.

Монда М. Мәһдиев биргән бәя белән килешү-килешмәвебезгә тукталып тормыйча, бер фикер әйтеп китәсе килә. Шагыйрьнең Төркиягә йөз белән борылуының үзенә күрә сәбәбе бар. Чорының алдынгы карашлы кешесе буларак, В. Җәлал Европа культурасына ия булуны хуп күрә. Ләкин монда аны борчыган мәсьәләләр дә калкып чыга.

*Европада милли шәүкәт-шан сизәм,*
*Тик бу шәүкәткә аралаш кан сизәм.*
*Изһар итсә дустлыгын көчле халык,*
*Хак димә ялгыш, аны ялган сизәм.*
*(«Ни сизәм?»)*

Н. Ашмарин үзенең бер мәкаләсендә Европа культурасына ия булу омтылышы татарлар арасында көчле булуны билгеләп үтә. «Ләкин шул ук вакыт-

[1] Ш. Бабич. Зәңгәр җырлар. Казан, 1990.

та,— дип яза ул.— Казан татарлары моңа урыс җәмәгатьчелеген читләтеп үтеп, Төркия аша ирешергә уйлыйлар, чөнки кайбер мөселманнарны, нигезсез булса да, урыслашу мөмкинлеге куркыта...»[1]

В. Җәлал да югарыда китерелгән шигъри юлларны нәкъ менә шундый уйлар белән язган, күрәсең. Аны дине, гореф-гадәтләре үзгә булган «көчле халык» арасына кереп югалу куркыта. Шунлыктан шагыйрь Төркиягә борыла.

В. Җәлалнең шигырь җыентыклары 1908—1918 еллар аралыгында басылган. Димәк, аның иҗаты ун ел чамасы вакытны колачлый. Моңа реакция дәвере дә керә. Үз заманының алдынгы кешесе буларак, В. Җәлал иҗтимагый тормышта барган вакыйга-үзгәрешләргә битараф кала алмый. Аның шигырьләрендә пессимистик рух ярылып ята. Шагыйрь җир йөзендәге тормыштан канәгатьсезлеген белдерә. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр ялганга, икейөзлелеккә корылган, һәркем үзе өчен тырыша, тыштан ялтырый. Акчага корылган җәмгыять кешенең шәхесен изә, кимсетә, киләчәккә булган ышанычны үтерә.

*Шулкадәр эреткән хакыйкать нурларын алтын-көмеш,*
*Бәйләнеп беткән, чуалган акчага һәр сүз, һәр эш...*
*Ул имансыз ерткандыр кешелек пәрдәсен,*
*Һәр урында үстерә безгә җинаять зәрдәсен.*[2]
*(«Акча»)*

Заманасы буталчык, һәр адымда гаделсезлек сизелә. Шагыйрь шушы хакта ачынып яза:

*Хак сөйгәнгә җәһәннәм булды гомер,*
*Түбән халык дөньяда ризван булды.*
*Җиһанның фитърәтендә*[3] *миллион сер бар,*
*Яманнарга яхшылык бер гөнуан*[4] *булды.*
*(«Җиһан»)*

В. Җәлал — мәгърифәтчелек позицияләрендә торып иҗат иткән шагыйрь. Тормышның начар булуы мәгърифәт булмаудан, дигән карашны үзенең күп шигырьләрендә уздыра. «Зәһәрләнгән гомер» шигырендә ул менә ничегрәк яза:

*Раббым! Нинди зур гафләткә талдык*
*Биреп арка җиһан мәгърифәтенә.*

Шагыйрь халыкның тормышын яхшыртуда мәгърифәт хәлиткеч роль уйный дип ышандыра. Мәгърифәтле, аң-белемле булу өчен көрәшергә кирәклеген әйтә. Һәм бу көрәштә үзенең коралы итеп каләмне таный.

*Таудан олкән һәм кылычтан булды үткен бу каләм.*
*И каһарман! Кулга тот үткен каләмне, йотма гамь.*
*Ошбу тормыш мәйданында ул көрәшче, ул богатыр,*
*Күз уңында булса мең сәд, ул җибәрмәс, туктатыр.*
*(«Әһле каләм шәрифләренә»)*

Егерменче йөз башында мәгърифәтчелек алымы белән иҗат иткән күп кенә язучы-шагыйрьләр кебек, В. Җәлал үзенең шигырьләрендә хөкем сөргән явызлык, тигезсезлекләргә кеше үзе гаепле дигән фикер уздыра.

*Әйтмә пакьләрмен дип җирнең шарын,*
*Чөнки җир өстендә мин инсан сизәм.*
*(«Ни сизәм?»)*

Шул ук вакытта аның шигырьләрендә кешенең чиксез мөмкинлекләренә ышаныч та чагылып китә:

---

[1] Н. Ашмарин. Несколько слов о современной литературе Казанских татар. Отдельный оттиск из журнала Министерства народного просвещения.— 1905 г., сентябрь.— 3 стр.
[2] Зәрдә — бакча үләне, пастернак.
[3] Фитърәт — кул тимәгән табигать.
[4] Гөнуан — титул.

*Дәлил булды вә хур булды, ялангач,*
*Таянмыйча кеше үз кодрәтенә.*
*(«Зәһәрләнгән гомер»)*

В. Җәлалда интим-мәхәббәт кичерешләре тудырган шатлык хисе турында җәелеп сөйләп булмый. Шигырьләрнең байтагы тигезсез мәхәббәт сагышы белән өртелгән.

*Аһ, синең дәрдең вә дәрдем чаклы утлы булса иде,*
*Миндәге хис чаклы хисләр күкрәгеңә тулса иде,*
*Шөбһәсез, нәкъ шул вакытта син дә мин булыр идең...*
*(..гә)*

Хатын-кызның гүзәллеген мактап, аның төс-кыяфәтен чагыштырулар аша ачып бирү — Көнчыгыш классик поэзиясенә хас алым. В. Җәлал да матур хатын-кызга дан җырлаганда традицион чагыштырулар куллана.

*Ул кара каш, күзләре тылсым аның,*
*Иң нәзек былбылыдыр дөньяның.*

. . . . . . . . . . . . . . .

*Ай ничек күктә тора бер нур гына,*
*Ул да дөнья җәннәтендә хур гына.*
*(«Шәрекъ кызы»)*

В. Җәлал гаилә, аның нигезләре, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр турында да күп уйланган, күрәсең. Җәмгыятьнең башлангыч һәм иң әһәмиятле буыны — гаилә, киләчәккә барачак кеше нәкъ менә шунда формалаша. «Үкенечле мәхәббәт» дигән шигырендә В. Җәлал гаилә таркалу күренешен тасвир итә. Аның чоры өчен гайре табигый күренеш бу.

*Күңелгә килмәгән эш эшләнәдер,*
*Хатын ирдән китәргә көчләнәдер.*
*Үкенгән хәлдә: «Ник яндым икән,— ди,—*
*Нигә килдем, ник алдандым икән?» — ди.*

В. Җәлалның кайбер шигырьләрендә символизмга хас булган сурәт чаралары да чагылып китә. Ләкин монда саф символизм яки бүтән бер әдәби агым турында сөйләп булмый әле.

*Тукта, тукта, кайгыланма,*
*Бездә атсын таң гына.*
*Яктырып китсен һава,*
*Керсен халыкка аң гына.*

Символик таң сурәте килеп керсә дә, саф символистларча шигырьнең ахырына кадәр «яшеренлек», ягъни символик сурәтләр белән сөйләү дәвам ителми. Таң ату аша шагыйрь халыкка аң керүне күз алдында тотуын үзе үк әйтеп бирә.

В. Җәлал иҗатында үз бәхете өчен көрәшергә, кыенлыклар кичерергә һәм җиңеп чыгарга әзер торган лирик герой образы калку булып сурәтләнә.

*Җыламам инде тагын мин хәят дулкыннары какса,*
*Буармын, яшь көчем бар, таплы дулкын гомеремә акса.*
*(«Килер көннәр»)*

Лирик герой җәбер-золымга түзеп торудан узган, ул, үз шәхесен яклап, көрәшкә күтәрелергә әзер. В. Җәлалның иҗатына мондый герой килеп керүе очраклы булмады. Аның баштагы героена бунтарьлык хас иде инде. Ләкин ул башта пессимист иде әле.

*Хис итә яшерен генә*
*Бу моңлы күңелем дөньяны.*
*Булса куәт, бер сәгатьтә*
*Юк итәр идем аны.*
*(«Күңелем»)*

Шәхес тора-бара үзгәрә.

*Кайвакытта мохтаҗ вә ачларны күрәм.*
*Тәэсир итә.*
*Кайвакыт мәлгунь бу акчаны күрәм,*
*Тәэсир итә.*
*Акчага мәфтүн бу бакчаны күрәм,*
*Тәэсир итә.*

*(«Тәэсир итә»)*

Әйе, үз заманының алдынгы кешесе буларак, В. Җәлалны бик күп мәсьәләләр борчый, ул алар хакында дулкынланып яза.

Чәчелеп яткан, югалырга җиткән мәдәни мирасыбызны туплар вакыт житте. Тукай белән иңгә-иң торып иҗат итүче каләм ияләренең иҗатын, тормыш юлын өйрәнү тарихыбызны баетыр гына. Ләкин без В. Җәлалны билгеле кыса-калыпларга салып азапланмыйк. Ничек бар, шулай кабул итик, укучыга кайтарыйк аны. Милләт киләчәген кайгыртып, гуманизм идеяләренә таянып иҗат иткән шагыйрьнең моңа тулы хакы бар.

**Руфия ГЫЙЛӘҖИЕВА,**
Казан дәүләт педагогия институты аспиранты.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ЕРАКТАГЫ ЯКЫН МАТБУГАТ

Демократик революцияләрдән соң сәяси мәйданда һәрчак яңа газета-журналлар пәйда була. Татар матбугаты белән дә шулай. 1905 һәм 1917 елгы революцияләрдән соң бездә әллә ничә төрдә газета-журнал чыга башлаган. Хәбәрдарлык һәм демократия алып килгән бүгенге тыныч революция дә шундый сыйфатлары белән тарихта калыр. Әле анда, әле монда төрле форматта, төрле юнәлештәге татар газеталары барлыкка килә һәм бу процессның тукталганы юк.

Белемгә омтылыш элек-электән хас булган безнең халыкка. Ә бу изге теләккә бары тик мәктәбең, газета-журналың, радио-телевидениең булганда гына ирешергә мөмкин. Халык трибунасына әверелгән газеталарыбыз хәзер, җәмәгатьчелек фикерен туплау һәм уяту белән бергә, мәгърифәтчелек хәрәкәтенең дә үзәгенә әйләнделәр. Татарстаннан читтәге — милләттәшләребез тупланып яши торган төбәкләрдәге — газеталарны барлагач, әнә шундый фикергә киләсең.

Төрле кысрыклау һәм кимсетелүләргә карамастан, 80 елларның урталарына кадәр Татарстаннан читтә татар телендә берничә газета чыгып килде. Иң әүвәл шуларга тукталыйк булмаса.

«Кызыл таң». 1918 елдан алып Башкортстанда шундый исем белән татарча зур форматлы газета чыгып килә. Соңгы елларда аның тиражы 120 меңгә якынлашты. Башкортстанның байтак кына районнарында да татарча газеталар нәшер ителә. Ульяновск өлкәсенең Кулаткы районында исә «Күмәк көч», Пермь өлкәсенең Барда районында «Таң», Чувашиянең Батыр районында «Авангард», Киров өлкәсенең Малмыж районында «Авыл тормышы», Самара өлкәсенең Келәүле районында «Ватан Байрагы» кебек татар газеталары чыкты. Аларның күпчелеге, илебездәге башка басмалар кебек, коммунизмга өндәде, саннар белән мавыкты, завод-фабрика һәм колхоз-совхозларда план үтәлешен яктыртты, иҗтимагый аң һәм милли хәрәкәт турында язулар тыелды. Коммунистик тоталитар идеология кысаларында, әлбәттә, ике төрле фикер йөртү мөмкин түгел иде. Яңа фикер әйтүчеләргә ул чакта нинди генә ярлык такмадылар да, кайсы гына зинданнарга япмадылар! Журналистикабызның иң асыл затлары Сталин концлагерьларында кырылды. Матбугат руле тирәсен зәвыксыз, үз фикере булмаган, партия сүзеннән чыкмаган ялчылар басты. Газеталарыбыз, эченә суалчан оялаган балыклар сыман, сулыгып, тәссезләнеп калды.

Ирексезләп социализм һәм коммунизм төзергә мәҗбүр ителгән илләрдә ниһаять, демократик хәрәкәт җәелеп китте. Милли азатлык дулкыны ярларга куәтлерәк кага башлады. Шушы дулкынны хәрәкәткә китерүдә милли газеталар башкарган һәм башкара торган эшчәнлек гаять зур.

Әйдәгез, бергәләп шул газеталарга күз салыйк, аларның үсеш тенденцияләрен билгелик, хәл итәсе проблемаларга тукталыйк.

Татар матбугатын чыгару һәм таратуда зур тәҗрибә туплаган Башкортстанда янә ике басма барлыкка килде. Аның берсе — «Өмет» дигәне — татар яшьләре өчен чыгарыла. Сүз уңаенда тагын шуны да әйтик, матбугат турындагы Закон нигезендә, хәзер аерым кешеләр дә үз газета-журналларын чыгара башлады. «Вакыт» — шундый газеталарның берсе. Аны Башкортстандагы күренекле татар журналисты Равил Кәрамов нәшер итә. Бәйсез бу газета милли азатлык хәрәкәтенә һәм төрле фикерләр, тәкъдимнәргә киң урын биреп, үз аудиториясен киңәйтә тора.

Ызандаш күршеләребез булган Киров өлкәсендә — «Дуслык», Ульяновскида — «Өмет», Самарада — «Бердәмлек», Төмәндә — «Яңарыш», Оренбургта —

«Яңа вакыт», Нижний Новгородта — «Туган як», Ленинградта — «Нур», Әстерханда — «Идел», Удмуртиядә — «Янарыш», Пермьдә — «Халык чишмәсе», Казагыстанның Семипалат өлкәсендә — «Галиябану», Магнитогорскида — «Фикер», Мәскәүдә — «Ватан», Пензада — «Нурлы таң», Чиләбедә — «Дуслык» һәм башка шундый үзенчәлекле, кабатланмас исемнәре белән күңелләргә уелырдай басмалар барлыкка килде.

Дөресен әйтик, бик күп авырлык һәм каршылыклар белән дөнья күрде алар. Империячел сәясәттән арына алмаган йогынтылы гына көчләр милли матбугатны үстерергә теләми. Бу бик тә аңлашыла. Чөнки ул газеталар урысның шовинистик политикасына каршы көрәш ачачак, милли хәрәкәтнең тагын да көчәеп китүенә булышлык итәчәк. Әмма милли үзаңның уянуын туктатырлык бүтән көч юк инде. Әнә, гыйбрәт алырлык мисаллар янәшәдә генә. Балтыйк буе республикалары янадан үз дәүләтчелекләрен кайтарып алдылар. Башка республикалар да үзләрен бәйсез дәүләтләр дип игълан итә. 1552 елда үз дәүләтчелеген җуйган татар халкы да шушы изге хәрәкәткә кушылып китте. Әлеге хәрәкәтне оештыруда милли газеталар үзләреннән зур өлеш кертте.

Яңа барлыкка килгән газеталар һәръяктан ярдәмгә мохтаҗ. Әйтик, кадрлар мәсьәләсе бик борчый аларны. Сер түгел, моңа чаклы Казаннан кала башка бер генә югары уку йортында да татар журналистлары әзерләнмәде. Ә яңа газеталарны кемнәр җитәкләргә тиеш иде соң? Түмәндә, мәсәлән, газетага мөхәррир итеп укытучы Азат Сәгыйтовны куйдылар. Нижний Новгородта «Туган як» газетасын элеккеге партия хезмәткәре Рифат Ибраһимов җитәкләде. Киров өлкәсендәге «Дуслык» газетасын Малмыжда татар телендә чыгып килгән «Авыл тормышы» мөхәррире Шамил Боһаров әйдәп китте. Газета редакциясендә бер генә көн эшләп карамаган мөхәррирләр дә бар.

Татар хәрефләре куелган язу машиналарына булган кытлык, линотиплар өчен татарча матрицалар юклыгы, кәгазь табу проблемасы — болар барысы да киеренке көрәш, тырышлык, инициатива, вакыт белән хисаплашмауны таләп итә. Татарстан бу редакцияләрне тиешле җиһазлар белән тәэмин итүдә хәленнән килгәнчә ярдәм кылды. Кызганычка каршы, республикабызның Журналистлар берлеге бу игелекле эштән нигәдер читтә тора әле. 1991 елның май аенда «Социалистик Татарстан», Татарстан студентларының «Мәгърифәт» газеталары һәм Казан дәүләт университетының журналистика факультеты белән берлектә, Татарстаннан читтә чыга торган газета мөхәррирләренең дүрт көнлек семинар-киңәшмәсен үткәрде. Анда танылган галимнәр, журналистлар һәм язучылар чыгыш ясады, тәҗрибә алмашу булды. Ә бит шундый чараларны уздыруның инициаторы итеп Татарстан Журналистлар берлеген күрергә теләгән идек.

Безнеңчә, Татарстаннан читтә татар телендә чыгучы газета журналистлары белән әледән-әле семинар-киңәшмәләр уздыруны гамәлгә кертергә, Татарстан республикасы Министрлар Кабинетында чит җирләрдә яшәүче милләттәшләребезне кайгыртучы махсус бүлек булдырырга күптән вакыт. Татарстан Югары Советы да бу мөһим мәсьәләне читләтеп үтәргә тиеш түгел. Дөрес, бу юнәлештә Бөтенсоюз Татар иҗтимагый үзәге кайбер чаралар күрә, әмма болар гына һич тә җитәрлек түгел.

Гомумән, безгә бүген татар халкы тарихын җентекләп өйрәнер көн килде. Ә аны газеталар тарихын, алардагы язмаларны өйрәнми торып тормышка ашырып булмаячак.

Ераграк тарихка күз салыйк. Кайсы төбәкләрдә генә чыкмаган татар газеталары! Хәтта чит илләрдә дә. Әйтик, беренче бөтендөнья сугышында немецларга әсирлеккә эләккән татар солдатлары өчен газеталар басылган. Бөек Ватан сугышы чорында да әсирлектәге татар солдатлары өчен берничә газета-журнал чыгуын беләбез. Төркиядә җитмешенче еллар уртасына кадәр «Казан» дигән журнал чыгып килде. Финляндия һәм Кытайда да андый басмалар бар иде. Ә соң аларны өйрәнгәнебез бармы? Өйрәнсәләр дә, мөгаен, КГБ хезмәткәрләре генә өйрәнгәндер. Ә аларның максаты билгеле: милли азатлык хәрәкәтен буу, большевистик идеология дошманнырын юк итү, ике фикергә урын калдырмау. Бер генә мисал. Оренбург каласында 1906 елдан бирле «Вакыт» газетасы чыгып килә. «Әйтергә кирәк, тарихи, әдәби, информатив материалларның байлыгы буенча бу газета татар газеталары арасында иң югары урында тора иде. Нәширләрнең (Рәмиевләрнең) акчага бай булулары газетаны полиграфик яктан да затлы итеп чыгарырга мөмкинлек бирә. Газета 12 ел буена халкыбызга игелекле хезмәт күрсәтеп, барлыгы 2309 сан чыгып, 1918 елның 26 гыйнварында яшәүдән туктый», — дип язды бу хәлләр турында күренекле әдибебез Мөхәммәт Мәһдиев 1991 елның 26-31 октябрендә чыккан «Яңа Вакыт» (Оренбург) газетасында.

Газетаның туктатылуы турында аның мөхәррире Ярулла Вәли 1918 елның гыйнвар санында түбәндәге белдерүне ясый: « 1918 ел, 26 гыйнвар иртәсе сәгать унда Оренбург мөселман Военно-революционный комитет (хәрби комитет) тарафыннан унике ел милләт хезмәтендә дәвам итеп килгән «Вакыт» газетасының матбагасы кәгазе конфисковать ителде вә газета туктатылды...» «Вакыт» әнә шулай кызыл большевизмның корбаны булган. Андый мисалларны тарихтан күп табарга мөмкин.

Милләтебезгә хезмәт итәргә дип яралган бүгенге басмалар ни турында язалар соң? Нинди яңа сәхифәләр белән сөендерәләр үз укучыларын?

Иң әүвәл, тиражларга күз салыйк. Ульяновскида чыга торган «Өмет» (атнага бер тапкыр, район газетасы форматында басыла) 1991 елда үзенә 7 меңгә якын даими укучы туплый алды. Әлеге газета 1992 елдан атнага бер мәртәбә 8 битле булып чыга. Тираж да шактый артты. Самарадагы «Бердәмлек»нең тиражы да 1991 елда 7 мең чамасы булды. Ул атнага бер мәртәбә район газетасы форматында чыга. 1992 елдан башлап әлеге газета үзенең кушымтасын булдырды, ул «Иман» дип атала.

«Туган як» (Нижний Новгород) газетасының беренче саны 1990 елның 6 декабрендә 2 мең тираж белән дөнья күргән булса, 1991 ел ахырына аның укучылар саны 5 меңгә якынлашты. Түмәндә чыга торган «Яңарыш» газетасы беренче тапкыр үз укучыларына 5 мең тираж белән барып ирешкән булса, 1992 елда аның укучылар даирәсе ике мәртәбә артты. Мондый мисалларны башка төбәкләрдән дә китерергә мөмкин булыр иде. Әйтик, Казагыстанның Семипалат каласында «Семей таңы» дигән газета 30 меңгә якын тираж белән тарала. Ул казакъ телендә нәшер ителә. Шуның бер сәхифәсе «Галиябану» дип атала, анысы татар телендә чыга. Үз эшенең энтузиасты булган Наилә ханым Абделкадыйрова ул сәхифәләрдә җирле шагыйрьләрнең яңа әсәрләрен, Татарстан хәбәрләрен, мәдәният, мәгърифәт хәлләре турында кызыклы һәм мавыктыргыч итеп сөйли, биредәге Татар иҗтимагый үзәге башкарган эшләргә анализ ясый. Гомумән, газета татар халкы мәнфәгатьләре сагында тора. Нәкъ менә аның башлангычы белән Семипалатта 1991 елда (революциядән соң беренче тапкыр!) Сабантуе зурлап уздырылды. Онытыла башлаган йолаларыбыз әнә шулай кабат әйләнеп кайта.

Бу уңайдан тагын шуны әйтик, татар телендә чыга торган газеталар мәчетләребезне торгызуда һәм аның тарихын язуда әйтеп бетергесез саваплы эш башкаралар. Нижний Новгородның «Туган як» газетасы, мәсәлән, мәчет рәсемнәреннән махсус галерея булдырган, аларның үткәндәге һәм бүгенге тарихын җентекләп язып бара. Ә Сергач мишәрләре яши торган авылда һәм шәһәрләрдә мәчетләрне гаҗәеп зур осталык белән салалар һәм аларны кадерләп тоталар. Болар бит халкыбызның архитектура үрнәкләре, сафлык, иманлык үзәкләре.

Тарих димәктән, яңа басмалар халкыбыз тарихын, аның авыллары тарихын язу һәм булдыруга үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр. Шул ук «Туган як» газетасы үз алдына мондый максат куйган: ай саен берәр татар авылы тарихын чагылдырып махсус куш битләр эшләргә! Ульяновскида чыга торган «Өмет» газетасы да бу юнәлештә кыю һәм игелекле адымнар ясый. Моны хупларга гына кирәк.

Татарстаннан читтә чыга торган газеталар башкарган тагын бер зур һәм күркәм эш турында сөенеп әйтмичә булмый. Сер түгел, соңгы вакытта татар әдәбиятына көчләр Татарстанның үзеннән генә килә торган булып китте. Ә бит элегрәк киресенчә булган. Тукай — Казан артыннан, Дәрдемәнд — Оренбургтан, Такташ — Тамбов якларыннан, Кави Нәҗми — Нижний Новгородтан, Галимҗан Ибраһимов — Башкортстаннан, Нури Арсланов — Казагыстаннан... Күрдегезме, ничаклы төбәктән, әллә ничаклы бизәкләре белән килеп кергән безнең әдәбиятка язучылар! Ә бүген? Аз алар, юк дәрәҗәсендә! Чөнки талантлы балаларның үсәр, сыналыр өчен мәйданнары — газеталары юк. Яңа басмалар барлыкка килү исә яшь көчләрне барларга, аларның сәләтләрен ачарга һәм үстерергә мөмкинлек тудыра. Ул көчләрне үстерүнең бүген кызыклы һәм отышлы алымнары да табыла тора. Әнә шул ук Нижний Новгородның «Туган як» газетасы иң актив авторга дип үзләренең якташы Кави Нәҗми исемендәге махсус премия булдырган.

Самараның «Бердәмлек», Ульяновскиның «Өмет» газеталары да яшь талантларны үстерүгә күп көч куя. Башкортстандагы «Кызыл таң» исә әледән-әле әдәби сәхифәләр биреп, талантларны ачуга булышлык итә.

Татарстаннан читтәге газеталар кылган игелекләрнең тагын берсенә тукталып үтик. Бу — туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләү, аны пропагандалау. Шушы максаттан байтак кына газеталар «Татарча сөйләшәбез», «Бу саннын сүзлеге» һәм башка шундый исемдәге рубрикалар булдырып, бик отышлы эш башладылар.

Газеталар татар милли хәрәкәтен оештыручы үзәкләргә әверелә бара дигән идек. Әйе, Татарстанның мөстәкыйльлеге һәм бәйсезлеге өчен ул төбәкләрдә нинди генә чаралар уздырылмаган. Бу эш бүген дә дәвам итә, чөнки Татарстан бәйсез, мөстәкыйль дәүләт булса, чит төбәкләрдәге милләттәшләребезне дә санга сугачаклар, без аларга да эшлекле ярдәм күрсәтә алачакбыз. Менә шуна да бу тема саннан-санга кыю күтәрелә, авторларның даирәсе арта тора. «Социалистик Татарстан» газетасында ай саен куш бит булып чыгып килүче «Милләттәшләр авазы» сәхифәсендә дә бу көрәш ялкыны ачык күренә. Тарихчыларга, журналист һәм телче галимнәребезгә бу хәрәкәтне һәм читтәге милләттәшләребез тормышын өйрәнүгә игътибарны бермә-бер арттырасы, үзгәртеп кору чоры тудырган басмалар буенча эшлекле сөйләшүләр башлыйсы иде. Ул газеталар туплаган тәҗрибә шактый кызыклы, уйландырырлык.

Киров өлкәсендә (Малмыж шәһәре) «Дуслык» исемле атналык газета нәшер ителүен әйткән идек инде. Бизәлеше белән башка басмалардан шактый калышса да, ул халкыбыз мәдәниятен, динен, телен саклау, үстерү юнәлешендә кыю адымнар ясый, әхлак темасына берсеннән-берсе гыйбрәтле язмалар тәкъдим итә. «Гаилә» сәхифәсе — үзе бер мәктәп. Анда ата-аналар, укытучылар, табиблар чыгыш ясый; үрнәк гаиләләр турында сөйләү белән бергә, яман чиргә әверелгән гадәтләрнең серләре ачып бирелә, укучы хатларына урын бирелә.

Узгандагы тарихыңны белми торып, бүгенгене һәм киләчәкне аңлау мөмкин түгел икәнлекне газета хезмәткәрләре яхшы төшенгәннәр. Шул максаттан «Тел, тарих, мәдәният» дигән махсус сәхифә бирү биредә матур гадәткә әверелгән. Аларда Киров өлкәсендәге татар халкының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәк язмышы, Татарстан белән бәйләнешләр, Вятка-Нократ якларында туып-үскән күренекле шәхесләр, Сталин репрессиясе корбаннары, Бөек Ватан сугышы каһарманнары турында әледән-әле гыйбрәтле язмалар дөнья күрә.

Түбән өлкәсендә чыга торган «Янарыш» газетасы «Татарстанның мөстәкыйльлегенә куркыныч яный» дигән баш астында кызыклы һәм гыйбрәтле язмалар урнаштыра. Өлкәдә яшәүче 230 мең татар исеменнән татарларның бердәмлеге ассоциациясе президенты И. Рафиков Россия, Казагыстан, Төркмәнстан, Азәрбәйҗан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Украина, Беларусь житәкчеләренә, Татарстанны үзләре белән бертигез хокукта күрүләрен таләп итеп, телеграммалар җибәрүен хәбәр итә.

Газеталар әледән-әле философ, тарихчы һәм телче галимнәребезнең милли хәрәкәт һәм бәйсезлек өчен көрәш турындагы теоретик язмаларына киң урын биреп, Татарстанның бәйсезлеген яулауда үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр, халык массаларын шушы игелекле эшкә туплыйлар. Татар халкының Милли мәҗлесен булдыру һәм шуның янына берләшү идеясен дә алар беренчеләрдән яклап чыктылар.

Сүз уңаеннан шуны да әйтик: Татарстаннан чит төбәкләрдә нәшер ителүче газеталар Казандагы басмалар белән ныклы элемтә булдырып, уртак чаралар уздыра башлады. Мисал өчен, 1991 елның сентябрь аенда Нижний Новгород өлкәсенең Сергач, Кызыл Октябрь, Пильнә һәм Спасс районнарында «Социалистик Татарстан» һәм шушы төбәктә чыга торган «Туган як» газеталарының уртак фестивале булып узды. Биредә яшәүче милләттәшләребез үз ана телләрендәге матбугатка бик сусаган булганнар. Шуңа күрә газета белән укучы арасында нык элемтә урнаша бара. Хәбәрчеләр армиясе яңадан-яңа көчләр белән тулыланә. Хөсәен Фәесханов, Кави Нәҗми, Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев, Лотфулла Фәттахов, Рамил Курамшин кебек талантлы шәхесләрне биргән бу төбәкнең шигърият чишмәсе яңа көч һәм дәрт белән ургый башлаган. Бүген аның даими язышып торучы кырыктан артык шагыйре генә бар. Нинди жанрда гына язмый алар! Гади шигырьдән башлап, баллада, бәет һәм поэмалар да иҗат итәләр. Шулай итеп, поэзиябез офыгын яңа җәүһәрләр белән бизиләр. Газетаның абруе үсә баруга тагын бер сәбәп, әлбәттә, хезмәткәрләрнең нык эзләнүләре. Алар иҗат иткән сәхифә һәм рубрикаларның исемнәренә генә күз салып алу да җитә: «Шигърият», «Сез яраткан җырлар...», «Безнең мәчетләр», «Авылым тарихы», «Күренекле якташларыбыз» һ.б.

Әйе, милли басмаларыбызның саны соңгы елларда шактый артты. Ләкин яңа газета-журналларны, барлыкка килгән радио һәм телевидение тапшыруларын өйрәнү юнәлешендә әле безгә тырышлыкны арттырасы бар. Ничаклы байлык, халкыбызның энҗе бөртегедәй иҗаты җыйналган ич аларда! Дөрес, җитмешенче елларда А. К. Айнетдинов «Фронттагы татар матбугаты» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклаган иде. Аннары ул 1984 елда «Летопись подвига» исемле китап та чыгарды. Бу хезмәтләр Бөек Ватан сугышы елларында төрле фронтларда чыккан татар газеталары сулышына гаҗәеп сәяхәт һәм алар башкарган эшкә җитди анализ да. Мисал өчен, сугыш елларында Мәскәү янындагы Шатура торф ятмаларын үзләштерүдә 3 меңнән артык татар хатын-кызы газап чигә, җинүне якынайту өчен сазлыкларда интегә. Шушында эшләүчеләр өчен «Правда» газетасының татар телендәге махсус чыгарылышы булдырыла. Ниләр турында язган ул газета, кемнәрне мактаган яки тәнкыйтьләгән? Әнә шундый сорауларга без үзебезнең 1989 елда Казан дәүләт университетында «Татарстан матбугаты Бөек Ватан сугышы елларында» дигән темага яклаган кандидатлык диссертациясендә җавап бирергә тырыштык. Татарстаннан читтә татар телендә басылучы газеталар, журналлар, радио һәм телевидение тапшырулары турында Казан дәүләт университетының 1990 елда ачылган журналистика факультеты студентлары да кайбер күзәтүләр ясарга өлгерделәр. Әмма бу әле республикадан читтәге татар матбугатын өйрәнүдә тәүге адымнар гына.

**С. ХӘЙРЕТДИНОВ,**

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

# МИРЗА КӘЗИМБӘК ҺӘМ ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕ

Бөтен дөньяга танылган Казан университеты күп кенә милли мәдәниятләр тарихында күренекле роль уйнады. Бу йогынтыдан Әзербайҗан мәдәнияте дә читтә калмады. Революциягә кадәр бу шөһрәтле югары уку йортында 30 лап әзербайҗанлы белем алды, алар арасыннан тора-бара күренекле дәүләт эшлеклеләре, галимнәр һәм язучылар үсеп чыкты. Казан университетында озак еллар күренекле ориенталист, «Рәсәйдә шәрекъне өйрәнүнең атасы» (И. Н. Березин), чыгышы белән Әзербайҗаннан булган Мирза Кәзимбәк тә эшләде.

М. Кәзимбәк Казанга 1826 елның башында килә. Дөрес, аның юлы Омскига була. Ул анда җирле Азия училищесына шәрекъ телләре укытырга билгеләнә. Ерак һәм салкын Омск аны тартмый, ә менә Казан, империянең университетлы икенче шәһәре, М. Кәзимбәккә бер күрүдә ошый. Ул үзе белән университетның шул замандагы ректоры профессор К. Фукска атап язылган юллама хат та алган була. Ә иң мөһиме, Әстерханда ике ел яшәү дәверендә ул садә һәм саф күңелле татар халкын яратып өлгерә, аның теле, мәдәнияте һәм көнкүреше белән якыннан таныша. Шуңа күрә, Казанга килгәч үк, М. Кәзимбәк язмышын шушы шәһәр белән бәйләргә карар кыла. «Азияле укытучы Мирза Кәзимбәк» хакында Көнбатыш Себер губернаторы, Казан университеты башлыклары, тышкы эшләр һәм мәгариф министрлыклары арасында озакка сузылган, ялыктыргыч хат алышулар башланып китә. Ниһаять, Казандагы дусларының тырышлыгы аркасында, аны 1826 елның 31 октябрендә университетка шәрекъ телләре лекторы итеп билгелиләр[1].

Лектор итеп куйган чакта М. Кәзимбәк тиешле дәрәҗәдә урыс телен белми торган була. Өстәвенә, укытучылык тәҗрибәсе дә җитеп бетми. Менә шундый кыен хәлдә калган яшь хезмәттәшенә ярдәмгә университетның адъюнкт профессоры, күренекле татар мәгърифәтчесе Ибраһим Хәлфин (1778—1829) килә. Аның булышлыгы белән 24 яшьлек лектор Мирза Кәзимбәк укытучылык һәм фәнни эшчәнлеген башлап җибәрә. Татар теленең грамматикасын да ул И. Хәлфиннән башка гына үзләштермәгәндер, дип әйтергә тулы нигез бар. Менә шуны белүе аркасында ул соңрак гарәп, фарсы, төрек телләре белән берәттән университетта һәм Беренче Казан гимназиясендә татар телен дә укыту мөмкинлеге ала. И. Хәлфин тарафыннан төзелгән дәреслекләрне һәм хрестоматияләрне Мирза Кәзимбәк төрек-шәрекъ телләрен укытуда да киң файдалана. И. Хәлфин Казанда Шәрекъне өйрәнүне башлап җибәрүчеләрнең беренчесе була һәм шуңа күрә, һич тә шикләнүсез, Мирза Кәзимбәк илдәге шәрекъ белемен өйрәнүнең бөтен дөньяга мәгълүм Казан мәктәбен үзенең укытучысы тәҗрибәсенә дә таянып төзегән, дип әйтергә була.

Мирза Кәзимбәкнең мәгърифәтчелек карашлары Казан мохитендә, Европа, урыс һәм татар иҗтимагый аңының алдынгы карашлы эшлеклеләре белән тыгыз бәйләнештә формалаша. И. Хәлфин артыннан ул империядәге татар һәм гомумән төрки халыкларны университетта белем алуга тартуның кирәклеген ачык аңлый. Шушы максатларда махсус өндәмәләр һәм чакырулар да төзи. Аның «Казан университетының ординар профессоры Мирза Кәзимбәкнең тәкъдиме буенча Мөхәммәт динендәге балаларны Халык мәгарифе министрлыгының уку йортларында белем алырга чакыру турында»гы язмасы ТССР Үзәк дәүләт архивында саклана[2].

---

[1] ТССР Үзәк дәүләт архивы, 91 фонд, 1 тасвирлама, 3051 эш, 2 бит.
[2] 92 фонд, 1 тасвирлама, 4816 эш, 1—5 битләр.

Бу чакыру-өндәмәсендә М. Казимбәк игътибарны мөселман цивилизациясенең борынгы һәм бай үткәненә юнәлтеп, яшьләрне ата-бабаларының данлы традицияләрен дәвам итәргә чакыра, аларны дөньяви гыйлемнең файдалы хәзинә булуына ышандыра. «Бу уку йортларында,— дип яза М. Казимбәк Әстерхан, Казан гимназияләрен һәм университетны күздә тотып,— һәр егет үзенең акылын һәм йөрәген белем белән сугарырга, шәрекъ һәм гарәп телләрен өйрәнеп, фәннәр үзләштереп үзенең киләчәген тәэмин итәргә мөмкин. Гимназиядәге кырыс тәртипләр, яшьләрнең әхлагын саклауга юнәлдерелгән гамәлләр Әстерханда һәм Казанда яшәүче мөселманнарның күбесенә билгеле инде, анда шәрекъ телләрен сезнең үз арагыздан чыккан лаек кешеләр укытты һәм укыталар»[1]. Шунысы игътибарга лаек, М. Казимбәкнең империядә яшәүче төрки телле халыкларга мөрәҗәгате игътибарсыз калмый. Узган гасырның 40 нчы елларыннан башлап университетта татар студентларының саны 30 нчы еллар белән чагыштырганда, шактый арта. Озак еллар буе 1 бүлекнең деканы булып М. Казимбәк торган тарих-филология факультетында 40—50 нче елларда Ташмөхәммәт Сәйфуллин, Сәйфулла Токымбетов, Мөхәммәт Максутов, Сәетягъфар Ибраһимов кебек татар студентлары укый. Университетка татар яшьләрен тарту фәкать бер М. Казимбәкнең күп еллык тырышлыгы нәтиҗәсе генә булмыйча, башында И. Хәлфин торган татар мәгърифәтчеләренең уртак хезмәте булуы бәхәссез. Алдынгы татар мәдәниятенең шушы көчләренә таянып, М. Казимбәк татар телендә газет чыгару кирәкле һәм мөмкин эш дип исәпли. Ул: «Кем тарафыннан булмасын, татар телендә газит чыгару мәгърифәт ягыннан да, һәм бигрәк тә сәүдә һәм промышленность җәһәтеннән дә, һичшиксез, татарларга зур файда китерәчәк. Казан кебек шәһәрдә ул файдалы гына түгел, ә кирәк тә. Монда аны бастыру өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар»[2].

И. Хәлфин үлгәннән соң, 1829 елның 21 январеннан башлап М. Казимбәк 1 нче Казан гимназиясендә татар теле буенча аның дәресләрен дә алып бара һәм, Казан университеты советы карары нигезендә, профессор Эрдман белән бергә И. Хәлфин урынына татарлар арасыннан лаеклы кеше эзләүдә дә зур тырышлык куя. Гыйлем иясе булган татар муллалары Әхмәтҗан Сәгыйтов, Сәйфулла Мортазин һәм ахун Әмин Диминов бу эшкә алынырга ризалык бирәләр[3]. Аларның гаризаларыннан күренгәнчә, Ә. Сәгыйтов Бохарада Күкелташ мәдрәсәсен тәмамлый, гарәп, фарсы, төрек телләрен камил белә, «мантыйкка, фәлсәфәгә, Коръәнне шәрехләргә өйрәтелгән була». Ләкин, тиешле сынауларны узгач, аның урыс телен белмәве аркасында И. Хәлфин урынын алырга лаек түгел икәне ачыклана. М. Казимбәк һәм профессор Эрдман Сәйфулла Мортазин кандидатурасын яклап чыгалар. Соңгысы «татар телен тирән үзләштергән һәм укытканда урысча да аңлаша алган». Ләкин ул татар теле лекторы итеп билгеләнми. Аның дингә карата салкын мөнәсәбәттә булуы, ахун һәм ишан дәрәҗәсеннән читләштерелүе ачыклана[4]. Университет галимнәре ахыр чиктә ахун Әмин Диминов кандидатурасына тукталалар. «Татар мулласы Диминов,— дип язылган ректор Н. И. Лобачевский кулы белән,— ул-бу булмаса, ике атнадан килеп җитәм һәм билгеләнгән лекцияләрне укыйм, дип вәгъдә итеп Казаннан китеп барды»[5]. Ләкин, күп кенә мәгълүматларга караганда, ахун Әмин Диминов университетка килми, М. Казимбәк фарсы һәм гарәп телләре белән бергә татар телен дә укыта башлый.

М. Казимбәкне Казан, Әстерхан, Уфа мәдрәсәләрендә еш күреп була. Ул анда талантлы шәкертләр эзли. Галим Рәсәй шәрекъ белеме фәнен мөмкин кадәр чит ил йогынтысыннан коткарырга омтыла, шуңа күрә аны, дин фәннәре белән беррәттән, мәдрәсәдә гарәп, фарсы һәм төрек телләрен дә тирән өйрәнгән татар яшьләре нык кызыксындыра.

Казанның дин белгече Хәйбулла хәзрәт мәдрәсәсендә аның игътибарын үзенең матур язу сәләте белән аерылып торган талантлы шәкерт Мөхәммәтгали Мөхмүтев җәлеп итә. Озак та үтми, М. Казимбәк аны 1 нчы Казан гимназиясендә һәм университетта матур язу һәм гамәли дәресләр алып бару өчен тәкъдим итә. Аның Казан уку-укыту округы попечителе Н. М. Мусин-Пушкинга язган

[1] ТССР Үзәк дәүләт архивы, 92 фонд, 3 тасвирлама, 566 эш, 8 бит.
[2] ТССР Үзәк дәүләт архивы, 92 фонд, 1 тасвирлама, 2972 эш, 1 бит.
[3] Шунда ук, 6 бит.
[4] ТССР Үзәк дәүләт архивы, 92 фонд, 1 тасвирлама, 2972 эш, 16 бит.
[5] Шунда ук, 2 бит.

юлламасында: «Шушы елның 11 ноябрендә университетта яки 1 нче Казан гимназиясендә матур язу буенча укытучы урынын эзләүче М. Мәхмүтев бу уку йортлары өчен кирәкле кеше булырга мөмкинме, диген сорабыгызга түбәнчелек белән хәбәр итәм: тышкы эшләр министрлыгында эшләргә ниятләгән безнең тәрбияләнүчеләребез өчен каллиграфиянең хәтта бик тә кирәк булуын күздә тотып, соңгы өч елда аларга матур язу белән шөгыльләнү файдалы булачак»[1]. Бу эш өчен ул М. Мәхмүтевне кулай кеше дип исәпли. «Шушындый сәләте һәм яшьлеге белән Мәхмүтев киләчәктә университетка да, 1 нче Казан гимназиясенә дә зур файда китерергә мөмкин. Ул шулай ук беренче гимназиянең профессорлары һәм укытучылары кушуы буенча тәрбияләнүчеләр белән практик дәресләр һәм күнегүләр дә уздыра ала». Бу гамәлен Кәзимбәк университет башлыкларының җирле халык алдында өхлакый бурычы һәм аларны университетта белем алуга тартуда нәтиҗәле адым дип исәпләгән: «Ул гына да түгел, без мондагы мөселманнарны өйрәнгән шартта Казан татарларының иң яхшы мәктәпләренең берсендә укучы студент безнең белән эшләргә тели икән, түрәләрнең аны ничек хөрмәт итүләрен күреп, башка татарлар да мәгърифәткә тартылырлар иде»[2],— дип яза Кәзимбәк.

Кәзимбәкнең бу эшне юллап йөрүеннән соң биш ай чамасы узгач, 1843 елның гыйнварында М. Мәхмүтев шәрекъ каллиграфиясе буенча укытучы итеп билгеләнә. Дөрес, аны әле университет штатына ук алмыйлар, ә Кәзимбәк М. Мәхмүтевнең ничек итеп дәрес бирүен күзәтеп-тикшереп торырга тиеш була. Остаз үзенең шәкертен күз уңыннан төшерми, түрәләргә язган хатларында Мәхмүтевнең «эшкә бирелгәнлеге һәм гаять тырышлыгы»[3] хакында күп тапкыр искә ала, шәрекъ каллиграфиясе укытучысын ясак түләүче сословиедән чыгару һәм матур язу укытучысы итеп раслауларын сорап түбәнчелек белән мөрәҗәгать итә. Университет түрәләре моңа фәкать күп санлы инстанцияләр белән хат алышкач, алты елдан соң гына ирешә. 1849 елның 22 июлендә М. Мәхмүтев ясак түләүчеләр катламыннан чыгарыла, ә Казаннан Петербург университетына күчеп китәр алдыннан Кәзимбәк уку-укыту округы попечителенә аны Анна исемендәге тасмалы алтын медаль белән бүләкләүне сорап мөрәҗәгать итә[4]. М. Кәзимбәкнең бу юлламасы, М. Мәхмүтевнең педагогик сәләттән тыш, фәнгә һәм университетка тугрылыгы, күркәм кеше булуы, татар мәгърифәтчесенең фидакарьлеге һәм кешелеклелеге хакында да сөйли: «Шәрекъ каллиграфиясен башкару өчен махсус каләм, кара, төрле төстәге буяулар кирәк, ә Мәхмүтев әфәнде укучыларга шөгыльләнү өчен таләп ителгән бу нәрсәләрне сорап түрәләргә мөрәҗәгать итмәде, алты ел буена аларны үз материаллары белән тәэмин итте, зур булмаган хезмәт хакының бер өлешен шуларны сатып алуга тотты»[5].

Кәзимбәк М. Мәхмүтевнең педагогик сәләтенә һәм бу өлкәдәге эшчәнлегенә югары бәя бирә: «Моннан тыш шәрекъ телләрен бик яхшы белгәнгә ул, минем күрсәтмәләрем буенча, алда әйтеп үтелгән фәннәрне үзләштерүдә укучыларга бик еш ярдәм итә, моның өчен аерым хак алмый һәм, гомумән, ул шулкадәр күп файда китерде ки, мин моны Сез Галиҗәнәпләренең игътибарына җиткерүне үземнең бурычым дип саныйм»[6].

М. Мәхмүтев шәрекъ телләре һәм каллиграфиясе белән беррәттән И. Хәлфин һәм М. Кәзимбәк тарафыннан эшләнгән методика нигезендә татар телен дә укыта. Аның «Татар телен өйрәнүчеләргә практик ярдәмлек» китабында Кәзимбәкнең «Төрки-татар теленең гомуми грамматикасы» йогынтысы ачык сизелә.

1849 елда Казаннан киткәндә «М. Кәзимбәк Рәсәй шәрекъ белеме мәктәбе язмышы хакында зур кайгыртучанлык күрсәтә. Шәрекъне фәнни өйрәнүнең бишеге һәм яхшы кадрлар әзерли торган үзәк буларак Казанга зур бәя биреп, ул аның шушы абруен киләчәктә дә саклап калырга тырыша. Шул максат белән Кәзимбәк, Мәхмүтев белән киңәшеп, министрга соңгысын Казан гимназиясендә татар теле укытучысы итеп калдырырга кирәклекне дәлилли. Ул моны Мәхмүтевнең укытучы буларак та, үз теленең белгече буларак та, каллиграф

[1] ТССР Үзәк дәүләт архивы, 92 фонд, 1 тасвирлама, 5319 эш, 2 бит.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук, 20 бит.
[4] ТССР Үзәк дәүләт архивы, 92 фонд, 1 тасвирлама, 5319 эш, 31 бит.
[5] Шунда ук.
[6] Шунда ук.

буларак та гаять зур талантка ия икәнен һәм... европалылар белән һич тә алыштырырга ярамаганлыгы белән аңлата»[1].

Мәдрәсә шәкертләре арасында Кәзимбәк талантлы татар егетен — киләчәктә Петербург университетында лектор булып эшләячәк атаклы галим һәм мәгърифәтче Хөсәен Фәезхановны (1828—1866) күреп ала. Мәдрәсәдә укыганда ук яшь Хөсәен университет белән элемтә тоткан. М. Кәзимбәк һәм Х. Фәезханов Шиһабетдин Мәрҗани янында да очрашканнар. Фәезхановның Петербургтан остазы Шиһабетдин Мәрҗани язган хатлары аша Кәзимбәкнең, башка татар мәгърифәтчеләре белән беррәттән, Ш. Мәрҗанине дә яхшы белүе, ул гына да түгел, күп тапкырлар очрашуы ачыклана. Алар сирәк очрый торган шәрекъ китапларын һәм тәскирәләрне эзләп табуда, гарәп телендә язылган катлаулы текстларны укуда бер-берсенә ярдәм итешкәннәр. Кәзимбәк белән Ш. Мәрҗани арасында хезмәттәшлек дәвамлы булмый, чөнки Мәрҗани Бохарадан кайткач берничә айдан Кәзимбәк Петербургка китә. Ләкин алар алга таба Хөсәен Фәезханов аша элемтәдә торалар, ә соңгысы исә үзенең остазы белән гомеренең соңгы көннәренә кадәр хат алыша.

Европа күләмендә танылган галим М. Кәзимбәк белән танышлык яшь Х. Фәезхановка шәрекъне өйрәнә торган фәннәргә һәм, гомумән, дөньяви гыйлемнәргә карата зур кызыксыну уята. Ул Казан университетына еш йөри башлый. «Хөсәеннең кайбер шәрекъ белгечләре һәм беренче чиратта Мирза Кәзимбәк һәм И. Н. Березин белән якын мөнәсәбәтләрдә торуына шикләнмәскә кирәк»[2],— дип яза профессор Миркасыйм Госманов. «Мирза Кәзимбәк һәм И. Н. Березин чынлыкта шәрекъ мәдәнияте хәзинәләрен өйрәнүдә һәм фәнни тикшерену методларын үзләштерүдә аның беренче укытучылары булдылар»[3],— дип раслый С. М. Михайлова. Бу шулай ук Брокгауз һәм Ефронның «Энциклопедик сүзлеге», «Урыс биографияләре сүзлеге» башка җитди басмалар белән дә дәлилләнә[4].

Барлык төп телләрне һәм каллиграфияне бик яхшы белгән Х. Фәезханов университет профессорлары — ориенталистлары өчен чын табыш була, алар төптән уйлый белә торган талантлы татар егетенә төрле йомышларны бик теләп тапшырганнар. Кайбер мәгълүматларга караганда, ул әле Казанда чагында ук Кәзимбәккә «Коръәннең тулы шәрехләмәсе»нә күрсәткечләр төзүдә булышкан.

Казан университеты профессорлары һәм укытучылары, беренче чиратта М. Кәзимбәк белән фәнни хезмәттәшлек, Х. Фәезхановка үзенең киләчәк эшчәнлеге хакында ныклап торып уйланырга этәргеч бирә. Артка, дин фәннәренә юл инде ябылган була. Классик мөселман мәктәпләре һәм мәдрәсәләре үзкләре башкача аны үзләренә тартмыйлар. Ш. Мәрҗәни дә үзенең шәкертенә «изге Бохарага» китәргә киңәш бирүдән ерак тора[5]. Шуның өстенә, Шәрекъне өйрәнү фәннәрен Петербург университетына туплау максатында, Казан университетында шәрекъкә кагылышлы барлык фәннәрне ябарга җыеналар.

Петербургмы, әллә Бохарамы? Х. Фәезханов төньяк башкаланы сайлый. Бу кыю адым була. 1853 елда, Кәзимбәкнең чакыруын алгач, ул үзенең көчен сынап карау, сәләтен күрсәтү өчен Петербургка юл тота. Петербургтагы тормышының беренче көннәре матди кыенлыклар һәм рухи төшенкелек белән тулы була. Менә шул чакта М. Кәзимбәк аны үз канаты астына ала, яшь татар галименең якын дустына һәм киңәшчесенә әверелә. Хәзер инде Петербург уку-укыту округы попечителе урынын билгән Н. М. Мусин-Пушкин 1855 елның 2 ноябрендә җибәргән тәкъдимендә халык мәгарифе министрына: «Шәрекъ факультеты деканы Мирза Кәзимбәк Фәезхановны җиде ел дәвамында фәкать яхшы яктан, шулай ук талантлы ориенталист-галим буларак белә, ул шәрекъ телләре факультеты өчен бик тә файдалы кеше булырга мөмкин»[6] — дип яза.

«Бик тә файдалы» галим ике ел буе Петербургта эшкә кайчан билгеләячәкләрен көтеп чиләнә. Ләкин озак кына вакыт аны университетка урнаштыра алмыйлар. Университет профессорлары һәм хәтта студентлар да Х. Фәезханов-

[1] С. М. Михайлова. Идел буе татарлары арасында мәгърифәтчелекнең формалашуы һәм үсүе. Казан, 1972, 188 бит.
[2] М. Госманов. Хөсәен Фәезхановның мөкатдәс хыялы. Казан, 1980, 26 бит.
[3] С. М. Михайлова. Алда әйтелгән китап, 198 бит.
[4] М. Госманов. Алда әйтелгән китап, 6—7 битләр.
[5] Кара. М. Госманов. Алда әйтелгән китап, 20—29 битләр.
[6] Шәрекъ телләре факультеты тарихы өчен материаллар. СПб, 1905, 1 том, 295 бит.

ны шәрекъ телләре укытучысы итеп билгеләүне сорыйлар. Хөсәен үзе башлангыч мөлне хезмәт хакы алмыйча да эшләргә риза була. Ләкин беренчеләренең үтенечләре дә, икенчеләрнең фидакарьлеге дә нәтиҗә бирми. Казимбәк 1857 елның 25 сентябрендә җибәрелгән хәбәрләмәсендә: «Казанда туып үскән, мөселманча күркәм белем алган, төрек һәм татар телләреннән тыш гарәп һәм фарсы телләрен яхшы белгән, урыс телендә иркен сөйләшкән татар мулласы Хөсәен бернинди хезмәт хакы алмыйча студентларга атнасына бернечә лекция укырга әзер торуын әйтте»[1],— дип яза.

Яңадан, М. Мәхмүтев мисалындагыча, университет башлыклары белән бергә, Казимбәк Х. Фәезхановны ясак түли торган катламнан чыгару өчен тырышып йөри. Ниһаять, 1863 елда элеккеге дәүләт крестьяны Санкт-Петербург император университетының шәрекъ телләре лекторы итеп билгеләнә. Петербургта тулыр-тулмас унөч ел яшәү дәверендә Хөсәен Фәезханов Казимбәк белән генә түгел, И. Н. Березин, В. В. Вельяминов-Зернов, академик Б. Дорн кебек башка күренекле урыс ориенталистлары белән дә хезмәттәшлек итә. Соңгысының үтенече буенча, ул XVIII гасырда яшәгән әзербайҗан тарихчысы Габделлатыйф әфәнденең «Шөке ханнарының кыскача тарихын» күчереп чыга, аның текстын соңрак Б. Дорн матбугатта нәшер итә. Х. Фәезханов Казимбәккә аерата дустанә мөнәсәбәтләрдә тора, менә ни өчен аның 1865 елда шәрекъ факультетын үзгәртеп кору турындагы бәхәсләрдә, университетта хәлнең тотрыксыз булуына карамастан, һич тә икеләнмичә остазын яклап чыгуы очраклы вакыйга түгел.

Хөсәен Фәезханов вафат булгач, М. Казимбәк мәрхүм галимнең гаиләсенә даими рәвештә матди ярдәм күрсәтеп килә. Хөсәеннең тол калган хатыны Фатыйма Фәезханованың Петербург университеты ректорына язган гаризасында: «Шушы өч ел дәвамында (ире үлгәннән соң — В. К.) мин фәкать университет советына үтенеч белән мөрәҗәгать иткәч, ара-тирә бирелә торган ярдәм исәбенә генә көн күрдем. Мәрхүм иремнең хатирәсенә хөрмәт белән караган шәрекъ телләре факультеты деканы Мирза Казимбәк, шушы чорда олкән кызымның Мариина кызлар гимназиясендә тәрбияләнгәнә өчен түләп торды һәм минем ятимнәремне ярдәменнән ташламады»[2],— дигән сүзләрне укыйбыз.

М. Казимбәк Хөсәен үлгәннән соң 4 кенә ел яши. Ләкин, аның килене Мария Львовна Казимбәкнең Казан университеты Н. И. Лобачевский исемендәге китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган көндәлекләреннән күренгәнчә, атаклы шәрекъ белгече үлгәч тә, Хөсәен Фәезханов балалары аның гаиләсе белән элемтәдә торганнар. Табигый, Мирза Казимбәкнең булмавы аның гаиләсе әгъзаларының Хөсәеннең ятимнәренә мөнәсәбәтләрендә сизелми калмый. Бу бигрәк тә 1892 елның ахыры, 1893 елның башларында аның улы йортында яшәгән Әминә Фәезхановага карый. Ул заманның типик аксөяге Мария Львовнаның кыска һәм образлы тел белән язган көндәлекләре бу ике гаилә арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне өйрәнүдә генә түгел, ә XIX гасыр ахырында татар революцион фикере үсешен билгеләү күзлегеннән караганда да кыйммәтле чыганак булып тора. 1893 елның 11 гыйнварында ул: «Көздән бирле бездә Әминә Фәезханова яши. Мин аңа үзебезнең буш торган бер бүлмәбезне бирдем һәм вакыты булганда Петя (Мирза Казимбәкнең оныгы — В. К.) белән һавада йөрүен сорадым. Ләкин соңгы вакытларда минем аңардан күңелем кайтты. Чикләнгән булуына карамастан, ул үзенең либераль фикерләре белән балаларга начар йогынты ясарга мөмкин. Ул зур идеалистка һәм гавәм, каһарманлык, фидакарьлек дип аталган һәр гамәл белән тиз мавыгып китә»[3],— дип яза.

Университетның шәрекъ телләре лекторы кызы, башкаларда яшәп, революцион хәрәкәт белән якыннан кызыксынган, народоволецларның гамәлләрен «фидакарьлек», «каһарманлык» дип исәпләгән икән. Бу Әминәнең атасындагы демократик, мәгърифәтчелек карашларын сеңдерүен һәм аларны лаеклы үстерүен тагын бер кат раслый.

Алга таба Мария Львовна үзенең ничек итеп балаларын Әминә Фәезханованың начар йогынтысыннан коткаруын тасвирлый: «Бүген Әминәгә ул яши торган

---

[1] Ленинград өлкәсенең Дәүләт тарих архивы. (ГИАЛО), 14 фонд, 1 тасвирлама, 5615 эш, 77 бит.

[2] Ленинград өлкәсенең Дәүләт архивы, 14 фонд, 1 тасвирлама, 514 эш, 126 бит.

[3] Казан университеты фәнни китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, № 8075 а.

бүлмәнең кирәк булачагы һәм аңа башка фатир эзләргә туры киләчәге турында әйттем. Башта ул аңламый торды, бүлмәне вакытлыча гына бушатырга кирәк дип уйлады. Мин сүземне кабатларга мәҗбүр булдым». Ул 12 январьда: «Әминә Фәезханова бездән күчеп китте. Ләкин кыланышы кырга сыярлык кына түгел иде. Ул гөнаһсыз кыерсытылган мескен баладай авызын-борынын турсайтты»[1]. Монда Әминәнең атасы кебек үк горур, үзсүзле булуы күзгә ташлана. Татар хатын-кызының революцион хәрәкәт белән кызыксынуы (бәлки әле анда катнашуыдыр да) XIX гасыр ахырында бик тә гыйбрәтле хәл, ул тагын бер мәртәбә татар иҗтимагый һәм мәгърифәтчелек фикеренең активлыгын, тормышчанлыгын күрсәтә, аның күренекле вәкилләре И. Хәлфин, Ш. Мәрҗани, М. Мәхмүтев, Х. Фәезханов чәчкән шифалы орлыкларның уңдырышлы туфракка эләгүен дәлилли.

Шәрекъне өйрәнүче галим, мәгърифәтче педагог буларак Мирза Кәзимбәк шушы мохиттә кайнап җитлегә. Татар мәгърифәтчеләре һәм алдынгы карашлы зыялылар белән аралашу, хезмәттәшлек итү аның акыл һәм әхлакый үсешенә уңай йогынты ясый. Ул Рәсәйдә шәрекъ фәннәре үсешендә Казан университеты һәм Казан ореанталистлары ролен бик югары бәяли. Петербург университетында шәрекъ факультетын ачкан көндә М. Кәзимбәк горурланып: «Әгәр башкаладан ерак бер губерна шәһәрендә (Казанда — В.К.) шәрекъ телләре бүлеге Европа күләмендә танылып, алар дәрәҗәсендә саналып йөрсә, безнең яңа оешкан факультеттан Россия һәм Европа нәрсә көтә ала?.. Бездәге кебек, урында шәрекъне өйрәнүче җирле халык вәкилләренең һәм урыс галимнәренең моның кадәр күп санда беркайда да булганы юк иде әле»[2],— ди.

М. Кәзимбәк үзе дә кергән бу «шәрекъне өйрәнү фәненең җирле вәкилләре» арасында аның Казан һәм Петербург университетлары буенча дуслары һәм коллегалары Ибраһим Хәлфин, Сәлихҗан Күкләшев, Мөхәммәтгали Мәхмүтев, Хөсәен Фәезханов, Ибнеәмин Әминев кебек кешеләр була. Мирза Кәзимбәк алардан укый һәм үзе дә аларны өйрәтә. Бу хезмәттәшлек — XIX гасырда әзербайҗан — татар иҗтимагый-мәдәни багланышларында иң якты сәхифәләрнең берсе.

**Виләят КУЛИЕВ,**
филология фәннәре кандидаты,
Әзербайҗан Фәннәр академиясенең Низами исемендәге
әдәбият институты директоры урынбасары.

---

[1] Шунда ук.
[2] Халык мәгарифе министрлыгы журналы, 1853, № 10—12, 88 бүлек, 20 бит.

# ТАТАР-БАШКОРТ ДУСЛЫГЫ

Мин үзем Башкортстанның Салават районы, Нәсибаш авылында туып үстем. 17 яшькә кадәр шунда яшәдем. Аннан соң да ел саен диярлек туган җиремә, тәягем һавасын суларга, туганнар һәм дуслар белән очрашырга — ә алар арасында башкорт кардәшләр дә бихисап — кайтып йөрдем. Шуңа күрә минем өчен «татар-башкорт мөнәсәбәтләре» дигән нәрсә абстракция түгел, бәлки үзем белгән, бөтен тәнем-җаным белән тойган чынбарлык ул.

Салават районында 70 ләп авыл бар, шуның 7 се: Нәсибаш, Лаклы, Таймый, Миәшәгәр, Шәрип, Малаяз, Аргы Малаяз — татар, өчесе урыс авыллары, ә калганнарында башкорт кардәшләр яши. Шунысы куанычлы: мин бер генә мәртәбә дә татар, башкорт, урыс арасында ниндидер аңлашылмаучылык, низаг чыкканын ишеткәнем, күргәнем булмады. Моны башкалар да белми. Алай гына да түгел: гомер буе бер-беребезнең шатлык һәм кайгыларын уртаклашып яшәдек. Атаклы җырчы Хәбир Галимов (Лагыр авылы), мәшһүр башкорт шагыйре Рәми Гарипов (Илтәй авылы, безнең район егете) белән горурланмаган Салават районы кешеләрен белмим мин. Шагыйрь Сафуан Әлибаев (Тирмән авылы) белән дә эшләр шулай тора. Зур галим, профессор Габдрахман Сәгъди — Таймыйныкы. Бөек әдип, галим Нәкый Исәнбәт — Малаяздан. Кавказ арты хәрби округы члены, Бөек Ватан сугышында бик зур батырлыклар күрсәткән 65 нче армиянең (аның командующие П. И. Батов үзенең бер китабында татар генералы Х. Ганиевның куркусызлыгына соклануын әйтә) политбүлек начальнигы генерал Хәбиб Ганиев — Нәкый Исәнбәтнең авылдашы. Ленин премиясе лауреаты, хәрби фәннәр кандидаты, Мәскәү һәм Кенигсберг сугышы герое, генерал, озак еллар генштабта эшләгән Рәфкать Вәлиев (соңгы ике елда «Правда» газетасы битләрендә аның өч рәсеме басылып чыкты) — Лаклыда үскән. Аларны шулай ук район халкы бик якын, үз итә. Мондый мисалларны тагын да һәм күпләп китерергә булыр иде. Ә бит хәлләр бөтен Башкортстанда шулай тора!

Шунысы ачык: башкорт халкы, татар халкы кебек үк, аерым милләтне тәшкил итә. Әмма бу кайчандыр башкорт җирләренә күчеп килгән һәм шунда йөзәр еллар буе гомер иткән татарларга килмешәк итеп карарга мөмкинлек бирү дигән сүз түгел. Кызганычка каршы, шулай уйлаучы үтә милләтчеләрне Уфада очратырга бик мөмкин әле. Әмма алар бер төркем иҗат интеллигенциясе вәкилләре генә, башкорт халкының фикеренә колак салмаучы «түрәләр»генә. Шул ук вакытта бу чынбарлыкка әһәмият бирмичә дә булмый. Чөнки бу «түрәләр» кулында җәмәгатьчелек фикерен формалаштыручы көчле корал — матбугат, әдәбият, радио-телевидение һ. б. бар. Моны, минемчә, муафыйк-акыллы һәркем дә беләдер.

Ярый, алар кебек тайгак юлга бастык, ди. Әлеге «түрәләр»нең (безнең Башкортстанда бу төшенчә бик еш һәм урынлы кулланыла) артыннан киттек, ди. Әмма тормышта бик еш очрый торган менә мондый очракларда нишләргә?

Мәсәлән, минем бабамның әнисе Гөлзадә Белокатай районының бик матур башкорт кызы булган. Ул — татар авылы старшинасы Әсәдулла хатыны — үз чиратында, өч кызын башкорт егетләренә кияүгә биргән. Безнең бер җиңгибез, мөгаллимә Җәмилә, районыбызның Бишәүләр авылы кызы иде. Без һәммәбез дә аны бик яраттык. Хәтерлим, бер генә мәртәбә дә аның кайсы милләттән икәнлеге искә төшмәде. Шулай булмыйча соң — гади халыкка кайда әйбәт, шунда яхшы.

Җәйләрен авылга кайткач, авылым урамнарында йөрим дә, адым саен башкортча сөйләшү ишетәм... Болар — безнең киленнәрнең матур тавышы. Ә күпме татар кызлары, башкорт киленнәре булып, балалар үстерә! Шунда әллә кайчангы хәл искә төшә: Габдрахман Сәгъдинең әнисе дә башкорт кызы булган. Бу мисалга күренекле тел галиме, фольклорчы Нигъмәт Хәкимне дә өстәргә була... Инде Уфага

килсәк, башкорт интеллигенциясенең бик күбесенең хәләл җефетләре татар булуын күрербез. Хөрмәтле якын якташларым — язучы Б. Рафиковка, Г. Шәфыйковка, профессорлар Г. Саитбатталовка, Т. Карамышевага, А. Багумановка мөрәҗәгать итәм: югарыда китерелгән өзекләрдә сез нәрсә эшләргә кушасыз? «Килмешәк кияүкиленнәрне» кая куярга соң? Куаргамы?

Башкортстанның башкорт дәүләте булуына берәү дә шик белдерми — исеме үк шуны әйтеп тора. Ләкин чал тарихка мөрәҗәгать итсәк, халыкларның бөек күчешенә күз салсак, ирексездән күңелдә сорау туа: башкортлар бу бик тә бай, бик тә матур җирләрне аллаһе тәгаләдән сорап алдылар һәм ул җирләргә беркемне дә якын җибәрмәскә дип ант иттеләр микәнни?

Тарих готларның, гуннарның, кыпчакларның, печенегларның һәм хазар, фин-угры кабиләләренең көнчыгыштан күчеп килүләрен раслый. Татар-болгарларның ата-бабалары Кытайда яшәүче югары культурага ирешкән төркиләр булган, ди фән. Башкортлар кыпчак кабиләләреннән барлыкка килгәннәр. Шулай булгач, бүген: «Минем җир дә, синең җир»,— дип күсәк күтәрүләр урынлы булыр микән?

Башкортстанда, башкорт һәм татарлардан, күпсанлы урыслардан тыш, компактлы яшәүче немецлар, марилар, чувашлар бар. Чуваш әдәбиятына нигез салучы халык шагыйре Константин Иванов Башкортстанда туган һәм иҗат иткән. Һәм башкортларның аларга мөнәсәбәте әйбәт. Ә менә телләре, диннәре, гореф-гадәтләре белән шактый якын булган ике төрки халык — башкортлар һәм Уфа татарлары арасында мөнәсәбәт нормаль түгел. Югыйсә, татар халкы һөнәрле, эш сөючә, киң күңелле, динендә, көнкүрешендә пакь халык. Гаҗәеп түземле дә. Бу турыда поляклар, немецлар, финнар, кытайлар, японнар, американнар, төрекләр, канадалылар h. б., яки үзләре белән бергә татарлар яшәгән ил халыклары әйтәләр.

Гаҗәеп хәлләр бар бу дөньяда. Бүген, совет чорында, татарларга явызларча пычрак атучы язучылар бар. Менә бер-ике генә мисал. Үзен рус дип исәпләгән Аркадий Крупняков Йошкар-Олада «Марш Акпарса» дигән роман бастырып чыгарды. Әй татарны тукмый да инде ул, түз генә! Әмма һәр язган юлы — ялган. Минскида белорус язучысы Чигвинцев «Плач перепелки» дигән китабында, безгә немецлар кергәч тә, беренче полицайлар булып татарлар хезмәт итте, дигән ялган сата. Ә бит шунысы хак: партизаннар хәрәкәте киң таралган Белоруссиядә, нигездә, полицайлар да белоруслар иде ич! Әчне шул да пошыра, бу китаплар Мәскәүдәге кайбер агай-эне ак мыекларга шулкадәр ошады ки, үзәк нәшриятлар аларны миллионлы тиражлар белән кат-кат итеп басып чыгардылар. Башкалар турында берәр сүз әйтеп кара, күрмәгәнне күрсәтерләр иде. Бервакыт бер рус язучысы саксызлык белән «грузин кепкасы» дип әйтеп ташлагач, әллә күпме рус язучыларын «бүтән алай булмабыз», дип кат-кат ант иттерделәр. Эш Э. А. Шеварднадзега кадәр барып җитте. Ә татар дигән бәндә түзә...

Югарыда телгә алынган ике оятсыз китап уңае белән мин Татарстан Язучылар берлеге идарәсенә мөрәҗәгать иттем. Җавап кыска булды.

— Энекәш борчылма. Андый китапларны укып, нервыларыңны бозма. Менә без укымагач, тыныч яшибез,— диделәр чал чәчле язучылар.

Шул булдымы җавап? Мин бу үтә татарлык, коллык — сатраплык позициясен аңламыйм һәм аңларга да теләмим. Ничек инде ул, бер битеңә чалт итеп сукканда, икенче битеңне кую ди! Алай эшләү китапта гына әйбәт булырга мөмкин. Хәлбуки, Уфадагы күп татарлар да әнә шундый. Ә бит моңа карап «түрәләр» үзгәрми, алар шашыналар гына. Мин бу хәлнең асылына төшенергә теләп, Уфадагы татар һәм башкорт кардәшләремә мөрәҗәгать итәләдем. Әмма алар бу «феномен»ның эчтәлеген ача алмадылармы, әллә ачарга теләмәделәрме — җавап бирмәделәр.

Мин күрәзәче түгел, әмма уфалылар белән сөйләшүләрдән шул сизелә: башкортлар сан ягыннан үзләреннән артык булган татар халкының «йотуыннан» шикләнәләр, бугай. Әмма бу — урынсыз хафалану. Татар халкы андый түгел. Башкорт әдәбиятына, мәдәниятенә, сәнгатенә зур өлеш керткән М. Гафури, А. Таһиров, М. Кәрим, С. Кудаш, Ә. Вәли, Н. Сабитов, Д. Исламов, Ф. Кудашева, Ф. Камалетдинова (Нәкый Исәнбәтнең авылдашы), Б. Гайсин, Р. Хәсәнев һәм башка йөзләрчә татарлар үзләрен чын интернационалистлар һәм Башкортстанның ялкынлы патриотлары итеп күрсәттеләр ич.

Тагын бер мәсьәләгә — «татарларның башкорт эчке эшләренә тыгылу» проблемасына тукталу урынлы булыр.

Бу «проблема» — уйдырма, бармактан суырып чыгарылган. Татар бөтен илгә таралган. 20 ләп чит ил мәмләкәтләрендә, хәтта ерак Австралиядә дә яши. Әлбәттә, моның тарихи сәбәпләре бар һәм алар һәртөрле уйдырмалардан өстен торалар.

Беркемгә дә сер түгел: Башкортстан җөмһүриятендә, башкорт паспорты белән көн иткән татарлардан тыш, рәсми рәвештә 1 миллион 300 мең татар яши. Бу

кечкенә сан түгел. Мәсәлән, Чуваш, Мари, Мордва, Удмурт республикаларының төп халкы бу саннардан күп түбәнрәк... Шул ук вакытта һәр халык — бу бөтен дөньяга характерлы — үзенең читтә яшәгән туганнарына ярдәм кулы суза. Ул бигрәк тә халык мәгарифе, мәдәният, тел, әдәбият мәсьәләләренә карый. Тагын бер куанычлы мисал. Татарстанга даими рәвештә диярлек чуваш (безнең республикада аларның саны 110 меңгә җитә) кардәшләребез — язучылар, композиторлар һ. б. килә. Без дә аларга барабыз. Уртак шатлык хисләре күңелләрне биләп ала. Ә менә безнең республикадан баручыларны Уфада бик тарсынып кабул итүчеләр дә бар. Аларча, янәсе, татарлар башкортларның эчке эшләренә тыгылалар. Буш сүз бу.

Ләкин Уфа татарының тиресе эченә кереп утырсаң, күп нәрсә ачыклана төшәр. Еракка китмик, без беләбез бит: йөзләгән татар мәктәпләрендә башкортча укытуны административ юл белән керттеләр. Уфадагы радио-телевидение тапшырулары гел башкортча (рус теленнән тыш) бара. Бердәнбер республика татар газетасы «Кызыл таң» озак еллар буе искиткеч кыенлыклар кичереп яшәде. Аның хезмәткәрләре өчен газетаны пропагандалау эше дә бик хәтәр иде. Бу хакта миңа авылдашларым болай дип әйттеләр: «Без белгәннән бирле, авылга, артистлар ияртеп, «Совет Башкортстаны» хезмәткәрләре килә, газетага язылырга өндиләр иде. Почта бүлекчәсендә дә, разнарядка шулай: лимит юк дип, «Кызыл таң» газетасына подписка алмадылар. Гел шулай булды. Бу газетаны киосклар да өнәп бетермиләр, чөнки югарыдан күрсәтмә шулай... Мондый хәлне Балтыйк буе республикаларында, хәтта Грузиядә дә очратып булмавын искә алсаң, теләсәң-теләмәсәң дә, күңел борчыла башлый. Ә без, боларны яхшы белсәк тә, кыл да кыймылдатмыйбыз, авызны басып, күзләрне йомып йөрүне дәвам итәбез. Нигә бездә дә Ю. Рытхэу кебекләр юк икән? Ул әнә үзенең 10 мең тирәсе булган чукча халкы өчен җан ата, бөтен китаплары шул халыкны данлауга багышланган. Матур үрнәк!

Башкорт халкын татар халкы тирән ихтирам итә. Сәнгатен, әдәбиятын, мәдәниятен югары бәяли. Башкорт халкының уңышларына сөенә, кайгыларына көенә. Чөнки ул белә: башкорт канында татар каны, татар канында башкорт каны бар. Без — якын туганнар.

Иманым камил, ышанычым зур: бу ике, бер-берсенә лаек халык, үзара күбрәк дус булса, аларның көч-куәтләре артачак, тормышлары гөлдәй чәчәк атачак!

**Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ,**
педагогия фәннәре кандидаты.

# ГЕЛ БУЛДЫҢ ИСӘРЕМДӘ

«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ ЧЫГА БАШЛАУГА 70 ЕЛ ТУЛУГА

Моннан кырык дүрт ел элек, сугыш елларыннан соң, иң авыр чорларда булды бу хәл. Мин ул вакытларда Кандра урта мәктәбенең тугызынчы сыйныфында укый идем. Без, малайлар һәм кызлар, Бишкурай авылыннан, атналык бәрәңгеләрне аркага биштәрләп, беренче таң әтәчләре тавышы белән гыйлем юлларына омтыла идек. Кемгә ничек булгандыр, иллә мәгәр, мин үзем фатирымнан бик уңдым. Нилектән, дип уйларсыз әле. Хуҗаның миннән берничә яшькә зур Ләбиб дигән улы район элемтә бүлегендә телеграфист булып эшли иде. Мин аның белән ныклап дуслашып алдым һәм, үземнең шартым итеп, дуслык бәрабәренә «Совет әдәбияты»на еллык язылуны куйдым. Ул үзенең хезмәт хакыннан, начальнигы аша гына, үз исеменә яздырды. (Ул вакытларда да Татарстан газетасы яки журналларына язылу җиде йозак белән бикләнеп куелган иде). Ә мин әнием атна буена ашар өчен биреп җибәргән ризыкларны «кысып» кына тотканнан «калганын» сатып акчага әйләндерә идем һәм тиз түләдем әҗәтемне. Җаны теләгән, елан ите ашаган, дигәндәй, рәхәтләнеп журналларны кат-кат укыйм, ашау да онытыла (ризык янга кала). Ә күңелләрем, укыган саен, күбәләк канатыдай, җилбер-җилбер килә. Минем «чирем» әкренләп Ләбиб абыема да йокты.

Үземнең күңелемдәге матур әдәбиятны уку дәртен туган авылымдагы татар теле укытучысы Хөсния апа Габдуллина уятты, кабызды һәм каләм тибрәтергә этәреш ясады, үстерде. Монысы инде алтынчы сыйныфта укыган чагым, ягъни сугыш еллары иде. Ул «Совет әдәбияты» журналындагы әдәби әсәрләрне, башка материалларны укый иде безгә һәм өйдә укырга биреп тә тора иде. Сирәкләп кенә килеп торган бу журналны алып уку бәхетенә ирешүче укучыларга сокланып туя алмый идек. «Кайчан безнең чират җитә инде укырга» дип, түземсезлек белән көтеп ала алмый интегә идек.

Яз айлары җитте. Тышта шомырт агачлары чәчкә атарга йомарланган. Фатирыбыздагы дәрес әзерләргә тәгаенләнгән өстәлдә дәреслекләр һәм ел башыннан алып килгән өч данә «Совет әдәбияты» журналы. Сәмәрканд якларыннан кайткан фатир хуҗабызның сеңлесе минем укуларымны сораштыра, белгән кеше кебек гаиләбез турында, хәтта киләчәктә кем булырга җыенуымны да калдырмады. Шуннан, әкренләп, каршыбыздагы журналларга да сүз якынлашты.

— Әнвәр улым, үзең беләсең, кызым Шәмсинур кече яшьтән үк хәрәкәтсез ята гуй. Татарча китаплар гына укырга ярата гуй, җанына дәваны шулардан гына таба гуй. Мөмкин булса, минә бу журналларыңны миңа сатып бир әле, йөз илле сум бирәм гуй.

Мин нәрсә эшләргә, ни дияргә дә белми карап тик торам икән. Ник дигәндә, пионер сафына да, комсомолга кергәндә дә әниемнең рөхсәтеннән башка бер нәрсә эшли алмаган кешегә, әниең кебек кеше алдында күз яшьләре белән тетрәнеп сорагач, ни дияргә дә белми идем. Ә ул кадәре акча турында уйга да керми торган иде.

— Юк, юк...— дидем мин көчкә-көчкә генә,— сатмыйм мин аларны.

— Чирле кызым хакына, зинһар өчен, мин...мин алдыңа тезләнергә дә әзер гуй.

Мин мондый дәрәҗәдә үтенеп сорауны үз күзләрем белән үз алдымда күрүгә хәйран калдым. Каушадым...

Бүләк итеп кенә биргән журналларым өчен ул фатир хуҗабызга үзе әйткән чаклы акчасын калдырып киткән, чөнки минем алмаячагыма ышанган ул. Со-

нынnan тагын Шәмсинурдан рәхмәт хатлары укып та күңелләрем булды, күз керфекләрем дымланды.

Ерак Себер якларында Томск «урманнарында» хезмәт иткән чакта (адәм ыстырамы, әйтерсең, безнең чик буйлары шунда) «Совет әдәбияты» журналларын сораттып ала идем. Шалуны белән ат йөртә торган вагоннарга төялеп барган татар малайлары миндәге журналны кулдан-кулга йөртеп, укый-укый туздырып бетерә торганнар иде. Аннары шунда ук яшәүче Туган районындагы татарларга бирә идек һәм тагын кулдан-кулга китә иде. Укучыны ялыктырудан куркып мондагы «ярсуларны» язмыйча да калдырыйм әле.

Жир шарының татар булган барлык континентларында сөелеп укылган, «Безнең юл», «Атака», «Совет әдәбияты», «Казан утлары» дип исемләнгән журнал, син гел минем исләремнән чыкмадың. Мин синең белән үстем, яшәдем. Синең, җитмеш еллык кеше гомере кадәр дәвер, битләреңдә илебез тарихы, шушы чор кешесенең тарихы чагылыш тапты. Син халыкка хезмәт иттең, шуның тарихы син...

Менә бүген дә, үзем басып торган сәяси ноктадан чыгып, уйлап торам: йә, кешенең бүгенге халәте кичерешләрен бирә торган әсәрләр ничек инде язылмаска мөмкин?! Киресенчә, шундыйларның булырына ышанып, һәр санын көтеп торам мин.

**Әнвәр НИЗАМЕТДИНОВ.**
Башкортстан, Туймазы районы, Югары Бишенде авылы.

## Азат Ганиевка 50 яшь



Азат Ганиев (Азат Вәли улы Мөхәммәтганиев) 1942 елның 1 маенда Татарстанның Әлмәт районы, Кама-Исмәгыйль авылында укытучы гаиләсендә туган. Урта белемне шул ук районның Габдрахман авылында ала. Сигезенче класслардан каләм тибрәтә башлый, беренчә хикәясен район газетасында бастыра.

1961—62 елларда ул газ кудыру заводында токарь булып эшли, аннары Лениногорск шәһәрендәге рәсем сәнгате училищесында укый. 1966 елда бу училищены тәмамлагач, мәктәптә рәсем һәм сызым укытучысы булып эшли, төрле оешмаларда бизәүче-художник хезмәтләрен башкара.

1969 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Ике елдан соң читтән торып уку бүлегенә күчә һәм Габдрахман авылында рәсем фәненнән укыта башлый.

Азат Ганиев әдәбият сөючеләргә «Тагын күченәбез» исемле хикәяләр җыентыгы һәм «Сүзсез җыр» (1971), «Габделхак» (1984) повестьлары белән таныш.

Ул республика матбугатында күренгән беренче әсәрләре белән үк әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итте. Башка каләм ияләрен кабатламаган язу рәвеше, чор кешесенең уйлау һәм хис итү дөньясын тәэсирле, сәнгатьле итеп тасвирлавы, үз әсәрләренә чорның тирән социаль һәм фәлсәфи конфликтларын кертүе — болар барысы да Азат Ганиевны заман сулышын тирән тоючы каләм иясе буларак танытты.

Ул — 1977 елдан Язучылар берлеге әгъзасы.

*Илле яше тулу уңае белән юбилярны кайнар котлыйбыз һәм аңа яңа иҗат уңышлары телибез!*

## РЕФЕРЕНДУМ — МӨҺИМ АДЫМ

БМОга кермәгән милләтләр һәм халыклар оешмасы Генераль секретаре д-р Микаэль ван Вальт ван Прааг 1992 елның 24 мартында Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевкә мөрәҗәгать итте.

«БМОга кермәгән милләтләр һәм халыклар оешмасы исеменнән мин Татарстан халкын Татарстанның Суверен Статусы турындагы референдумны уңышлы үткәрүе белән котларга теләр идем. Референдум һәм аның уңай нәтиҗәсе Татарстан халкының үзбилгеләнүгә хокукын тормышка ашыруда мөһим адым булып тора»,— диелә мөрәҗәгатьтә.

Генераль секретарь үзенең котлавын: «Сезне, әгәр Сез һәм Татарстан халкы үтенеч белдерсәгез, бу процесска ярдәм итү өчен мөмкин булганнарның барысын да эшләрбез, дип ышандырабыз»,— дигән сүзләр белән тәмамлый.

## АКШ ЭШМӘКӘРЛӘРЕ — ТАТАРСТАН КУНАКЛАРЫ

Апрель башында Татарстан Президенты М. Шәймиев Кремльдә «Идел-Трейдинг» Америка корпорациясе президенты Ильдар Агиш, аның генераль директоры Ильхан Айдагуль һәм маркетинг буенча директоры Мария А. Скоттины кабул итте. Ерактан килгән кунаклар Президентны 21 мартта уздырылган референдум нәтиҗәләре белән котлады, АКШтагы татар диаспорының җөмһүриятебез белән тагын тыгызрак бәйләнешләр урнаштырырга ниятләре барлыгын сөйләделәр.

Дусларча җылы әңгәмә барышында М. Шәймиев АКШтан килгән кунакларны шушы елның июнендә Казанда уздырылачак Бөтендөнья татарлары конгрессына чакырды.

## ГАДЕЛЛЕККӘ — ДЕМОКРАТИК ЮЛ БЕЛӘН

Татарстан Республикасының Премьер-министры М. Сабиров 18 апрель көнне Россия Федерациясе депутатларының VI съездында чыгыш ясап, җөмһүриятебездә үткәрелгән референдум нәтиҗәләре, икътисади-сәяси хәл, Россия Федерациясен яңарту һәм реформалар үткәрү, милли мөнәсәбәтләр, Россия Конституциясе хакындагы кайбер фикерләрен уртаклашты.

«Без,— диде ул,— Россия Президенты Б. Н. Ельцинның бу съездда, милли-территориаль төзелеш мәсьәләсе, милләтара мөнәсәбәтләр бары тик сөйләшүләр юлы белән генә җайга салынырга тиеш, дигән сүзләрен тулысынча уртаклашабыз... Без Татарстан турындагы мәсьәләнең ясалма рәвештә кискенләштерелүен теләмибез. Безнең гаделлеккә демократик юл белән омтылуыбызны Россия белән мөнәсәбәтләрне өзәргә омтылу дип аңларга кирәкми».

## РӘХИМ ИТ, КОНГРЕСС!

Инде хәбәр ителгәнчә, быелның июнь аенда Казанда Бөтендөнья татарлары конгрессы узачак. Татарстан Президенты указы нигезендә, аны әзерләү комиссиясе оешкан һәм анда министрлык җитәкчеләре, Президент аппараты һәм Министрлар кабинетының җаваплы хезмәткәрләре, халык депутатлары, җәмәгать оешмалары, галимнәр һәм иҗат берлекләре вәкилләре кертелгән иде.

8 апрельдә Казанда конгрессны әзерләү комиссиясенең утырышы булды. Аны комиссия рәисе урынбасары, Татарстан фәннәр Академиясе президенты М. Хәсәнов алып барды.

Бөтендөнья татарлар конгрессы үткәрү ЮНЕСКОга хәбәр ителгән. Конгресста шулай ук ЮНЕСКОның Генеральный секретаре ярдәмчесе килүе көтелә.

Комиссия утырышында мәдәният министры М. Таишев, Казан шәһәр администрациясе башлыгы К. Исхаков, финанс министры Д. Ногманов, Татарстан халык депутатлары Ф. Сафиуллин, Р. Фәйзуллин, М. Мөлеков һ. б. бу олы чараны уңышлы үткәрү буенча күп кенә тәкъдимнәрен әйттеләр.

Утырышта Татарстанның вице-президенты В. Лихачев катнашты һәм чыгыш ясады.

## КУЛЪЯЗМАЛАР ЯНМЫЙ, ДАСТАННАР ЮГАЛМЫЙ

Төркиянең мәдәният министрлыгы нәшриятында киевлы, борынгы болгар әдибе Микаил-Башту ибн Шәмси Тәбир (ул күбрәк Шәмси Башту исеме белән билгеле) тарафыннан иҗат ителгән «Шан кызы дастаны» аерым китап булып басылып чыкты. Бу күренекле әсәр 882 елда Киевта — ягъни Украина-Русь җирләрендә дәүләтчелек оешып килгән һәм аның башкаласында төрле милләт вәкилләре, аеруча славян һәм төрки халыклар күпчелек булып яшәгән заманнарда язылган.

«Башту» — төрки-болгарлар телендә «киевлы» дигәнне аңлата. Бу исем-псевдонимны шагыйрь үзенә юкка гына алмагандыр: поэмасын тәмамлаганнан соң ул тиздән Киевтан китеп бара һәм, патша сарае әһелләре белән берлектә, Идел Булгариясенә (хәзерге Татарстан Республикасы) күчеп китә.

Төрек һәм украин телләрендә басылган әлеге китапны әзерләүдә татар, төрек һәм украин галимнәре катнашкан. Борынгы текстларны Казаннан тарихчы Фәрхад Нуретдинов эшкәрткән. Украинаның атказанган рәссамы, китап графикасы остасы Рафаэль Мәсагутов басманы гаҗәеп матур сурәтләр белән бизәгән.

## АБРУЙЛЫ ИДАРӘДӘ — ТАТАР ӘДИПЛӘРЕ

Татарстанның дәүләт дәрәҗәсен күтәрүгә багышланган референдум уңаеннан Казанга дөньяның төрле төбәкләреннән котлаулар, мәмләкәтебез бәйсезлеген тану турында хәбәрләр килә тора.

Беларусь башкаласы Минскидан «Совет детектив һәм политик роман Ассоциациясе» Татарстан Язучылар оешмасына котлау хәбәре җибәргән. Алар март азагында уздырылган гомуми җыелышның карарын да юллаганнар. Әлеге Ассоциация Идарәсе составына Татарстаннан Мәгъсүм Насыйбуллин һәм Ташкентта яшәп иҗат итүче Равил Мирхәйдәров кертелгәнлеге дә хәбәр ителгән.

## 1992 ЕЛНЫҢ ТУКАЙ БҮЛӘГЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитетының тәкъдимен караганнан соң, 1992 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовка («Киләчәккә кайту» һәм «Мин әйттем» дигән шигырь китаплары өчен), Семен Липкинга («Идегәй» татар халык дастаны һәм татар шигърияте классикларының тәрҗемәләре өчен), җырчы Әлфия Авзаловага (соңгы еллардагы концерт эшчәнлеге өчен) һәм артист Равил Шәрәфиевкә (Г. Камал театры сәхнәсендә иҗат иткән образлары өчен) бирергә карар итте.

## ИДАРӘНЕҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе 2 апрельдә узган утырышында байтак мәсьәләләрне карады. Болар — элекке СССР Язучылар берлеге белән Татарстан Язучылар оешмасы арасындагы мөнәсәбәтләр, мөстәкыйль иҗат оешмасының кайбер атрибутлары хакында фикер алышу, шигырь бәйрәменә әзерлек мәсьәләсе һ. б.

Әлеге утырышта республикабызның төрле төбәкләрендә яшәүче каләм ияләреннән Ә. Габиди, И. Әхсәнов, Р. Вәлиуллин, Ф. Галиев, Д. Гарифуллин, Р. Мөхәммәтҗанов, С. Зыятдинова, Ф. Исмәгыйлева, М. Каюмов, Ш. Мостафин, Р. Низамова, Д. Салихов, И. Хөсни Язучылар берлегенә кабул ителделәр.

## КЫСКАЧА

Татарстан Республикасы хөкүмәте, күренекле революционер, дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе Мирсәет Солтангалиевның истәлеген мәңгеләштерү максатыннан, аңа Казанның М. Солтангалиев исемендәге мәйданында һәйкәл куярга карар чыгарды.

* * *

Күренекле рәссам, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының халык художнигы Бакый Урманченың истәлеген мәңгеләштерү йөзеннән Татарстан Министрлар Кабинеты, республикабызның мәдәният министрлыгы, Казан администрациясе һәм иҗат берлекләренең тәкъдимен искә алып, Казанда рәссамга һәйкәл кую турында карар кабул итте.

* * *

Апрель аенда «Казан» мәдәни үзәгендә Түбән Кама шәһәрендә яшәп иҗат итүче рәссам Әхсән Фәтхетдиновның «Ияләр» дип исемләнгән күргәзмәсе ачылды. Сәнгатебез тормышында зур вакыйга булырлык әлеге күргәзмә өч кисәктән тора. Беренчесе халкыбызның мәҗүсилек чоры: Шүрәле, Су анасы, Бичура һ. б. «Кабер ташлары» дип аталган икенче бүлек шагыйрь Равил Фәйзуллинның кыска шигырьләре чокып язылган ташъязмалардан тора. «Интеккәннәр» дигән өченче өлеш милләтебезнең моң-зарын, язмышын сурәтли.

# Укучыларыбыз игътибарына!

Журналыбызны саклап калу өчен без, башка газета-журналлар кебек үк, икенче ярты еллыкка өстәмә язылу уздырырга мәҗбүрбез.

Алдагы еллар тәҗрибәсен һәм күпсанлы укучыларыбызның теләген искә алып, журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан, бу санда 1992 елның икенче яртысына өстәмә язылу өчен әзер квитанция тәкъдим итәбез. «Казан утлары»н ел буена алдырырга теләүче укучыларыбыз, квитанциягә үзләренең тулы адресын язып, исем-фамилиясен күрсәтеп, аны өзек-өзек сызыклар буенча кисеп ала һәм элемтә бүлегенә тапшыра.

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
„Союзпечать"

АБОНЕМЕНТ на газету/журнал 73210 (индекс издания)

"Казан утлары" (наименование издания)

Количество комплектов: I

на 1992 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | X | X | X | X | X | X |

Куда ____ (почтовый индекс) ____ (адрес)

Кому ____ (фамилия, инициалы)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ ____ место ____ литер ____ на газету/журнал 73210 (индекс издания)

"Казан утлары" (наименование издания)

| Стоимость | подписки | 60 руб. 00 коп. | Количество комплектов: | I |
|---|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___ руб. ___ коп. | | |

на 1992 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | X | X | X | X | X | X |

Куда ____ (почтовый индекс) ____ (адрес)

Кому ____ (фамилия, инициалы)

# «КАЗАН УТЛАРЫ» — ЯРАТКАН ЖУРНАЛЫБЫЗ!

Яраткан журналыбыз, кызганычка каршы, авыр көннәр кичерә. Бер санының үзкыйммәте 1992 елның икенче яртысында уналты сумнан артып китәчәк. Шуңа күрә без өстәмә язылу уздырабыз да. Бер саныбыз бәясе язылучыларга 10 сум, ваклап сатуда 15 сум күләмендә булачак. Күргәнегезчә, бу — журналның үзкыйммәтеннән барыбер шактый ким. Чыгымнарыбызның калган өлешен Татарстан хөкүмәте күтәрер дип өметләнәбез.

«Казан утлары»н икенче яртыеллыкта да алдырыр өчен, Сезне өстәмә язылу уздырырга чакырабыз. Ярты еллык бәябез — 60 сум. Индексыбыз — 73210.

Багланышларыбызны өзмәбез дип өметләнәбез.

## ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

**На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.**

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ—МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

1988 г. Обл. тип., г. Кострома, зак. 983, тир. 141.150.000

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Татарстан Республикасының Дәүләт гербы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** «Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре. Сулдан уңга: (утырганнар) мөхәррир Рәшит Әхмәтҗанов, мөхәррир Кояш Тимбикова, журналның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, җаваплы сәркатип Марс Шабаев, техник мөхәррир Тәслимә Сибгатуллина, баш мөхәррир урынбасары Рашат Низамиев; (басканнар) мөхәррир Мәгъсүм Хуҗин, секретарь-машинистка Флера Сабирова, мөхәррир Мансур Вәлиев, корректор Гөлзада Моратова, мөхәррир Шамил Маннапов, машинистка Гөлназ Хөснетдинова, мөхәррир Рәдиф Гатауллин.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотосы

Бәясе килешү буенча

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ
# QAZAN UTLARI
# ОГНИ КАЗАНИ

**Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)**

Журнал включен во Всесоюзный каталог